Әсгать Сәлах
Каеннар юлы
*Повестьлар*

КАЗАН 2006
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
УДК 821. 512. 145-31
ББК 84 (2Рос = Тат) - 44
С18

**Салах Ә.С.**

Каеннар юлы: Повестьлар / Әсгать Салах. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 208 б.

ISBN 5 – 298 – 03923 – 5

Җыентыкта язучы Әсгать Салахның соңгы елларда иҗат ителгән өч повесте урын алды.

«Соңгы вальс» — татар әдәбиятында Чернобыль афәте турында тәүге әсәр. Повестьта шушы һәлакәтнең куркыныч нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан, фаҗигане үз җилкәсендә татыган кешеләрнең ачы язмышы сурәтләнә.

«Каеннар юлы» әсәрендә сугыштан соңгы авыл тормышы, тимерче Сафуан белән урман каравылчысы хатыны Сандра-Сания арасындагы мәхәббәт тасвирлана.

«Көт син мине...» повесте геройлары тормыштан алынган. Әсәрдә бәхет өмет итеп тә, аңа тиенә алмый калган яшьләр язмышы бәян ителә.

ISBN 5 – 298 – 03923 – 5
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Салах Ә.С., 2006

# Соңгы вальс

*Чернобыль атом электр станциясе фаҗигасендә вафат булган энем Әгъдәс Сәхап улы Салахның якты истәлегенә багышлыйм.*

*Автор*

Авырсынып кына килүенә карамастан, әлегә кадәр аңа һич таныш булмаган курорт бик ошады. Сигез катлы бина борынгы Болгар иленең диңгез кебек җәелеп киткән киң һәм мул сулы олуг Чулман елгасы буенда, кояшка йөзе белән торган иркен калкулыкта урнашкан иде. Әле автобуста чакта ук балконнары кып-кызылга буялган ак кирпеч бинаны күреп, әллә нидән тынычланып калды ул. Ә инде ишекне ачып керү белән, пөхтә, ак киемле, ачык йөзле кызлар аның юлламасын алып бүлмәгә дә урнаштыргач, алдагы шөбһәләнүләреннән җилләр исте. Сирәк булса да, курортларның төрлесендә дәваланырга туры килде аңа. Төрлесендә төрлечә кабул иттеләр, төрлечә дәваладылар. Биргәннең битенә карама, диләр. Кайсысыннан ярыйсы гына канәгать булып, кайсыларыннан игътибарсызлыкка гаҗизләнеп, ачка какланып кайткан еллары да булды. Ә монда... Кызларның үз итеп каршы алулары эретте дә җибәрде. Якты йөз, тәмле сүз. Үзеңнеке — үзәктә икән шул. Үз җирең, үз кешеләрең, үз телең...

— Әйдә, абый җаным, түрдән уз, тартынып торма. Юлда талчыккансың да бугай, нигәдер бик салмак атлыйсың...

Адымнары әкренәйде, авырайды аның соңгы вакытта — бусы хак. Сәламәтлеге шәптән түгел — бөтен сәбәп шунда. Яшьнәп торган яшьлеге үтте инде. Илле яшь — ир уртасы, дисәләр дә, бу гыйбарә Газиз Солтанов өчен түгел. Авыртмаган җире юк хәзер. Кояш күрмәгән гөл сабагыдай көннән-көн кибә, хәлсезләнә бара.

Шуны аңлап, яшь табибә аңа аерым игътибарлылык күрсәтте, озак итеп хәлен сорашты, тикшермәгән, тыңламаган җирен калдырмады. Аннары бирергә мөмкин булган барлык дәваларны аның курорт кенәгәсенә язып куйды.

— Тормыш мәшәкатьләрегез турында бөтенләй онытып, кайгылы уйларыгызны ташлап, тыныч күңел белән дәваланыгыз, ял итегез, абый. Дәвалау процедуралары чорында бер-бер хәл туса, турыдан-туры үземә керегез. Сәламәтләнеп, алып кебек тазарып, көч җыеп китәрсез бездән, иншалла, — диде ул, олыларча кайгыртучанлык күрсәтеп.

Уннарча минераль матдәләргә бай шифалы суы, югары дәрәҗәдәге дәвалау ысуллары белән танылган бу шифаханәдә яшәү өчен дә, дәвалану, ял итү өчен дә бөтен шартлар бар икән. Бүлмәләр кечкенә генә булса да якты, уңайлы, һәрберсендә телевизор, җылы суы, ваннасы, бинаның беренче һәм икенче катларында төрледән-төрле процедура алу бүлмәләре, минераль су ванналары, бассейны, коры мунча-

сы, ашханәсе, кино залы... Газиз кебек сырхаулар өчен бу бигрәк тә мөһим, һичбер кая чыкмыйча дәвалан да ят. Ашау — байдан, үлем — Ходайдан...

Бүлмәдәше дә үз кеше булып чыкты — Арча ягыннан, Габделфәт атлы. Үз яшендәге тыйнак, сабыр холыклы авыл кешесе. Ул инде бер атна дәвалана икән биредә, шифаханәнең эчке тормышы, тәртибе белән дә яхшы ук таныш. Газизне дә үзе белән ияртеп, дәвалану урыннарын күрсәтеп йөрде. Аннары алар бергә иртәнге ашны ашадылар, дәвалар алырга беренче катка төшеп киттеләр.

Әнә шулай Газиз тормышында яңа көннәр башланды. Көндезге ике-өчләргә кадәр төрле процедуралар ала, аннан төшке аш ашый, вакыты калса, төштән соң бүлмәсендә бераз ял итә, кичен исә, дәвалану мәшәкатьләреннән арынып, бераз телевизор карап ята.

Ә бу вакытта бүлмәдәше Габделфәт, киенеп-ясанып, концерт яисә спектакль карарга төшеп китә, шөкер, шифаханәнең тамаша залында һәр көн күрше калалардан килгән артистлар чыгыш ясап торалар — берсеннән икенчесе кызыграк көлкеле спектакльләр дә, җырлы-биюле концертлар да өзелми монда. Ә тамашадан соң ял итүчеләрнең олысы-кечесе ашханәгә бару юлындагы киң һәм озын коридорда даңдоң килгән көчле музыкага иркенләп бер биеп ала. Габделфәт аларны да калдырмый. Тик ул Газизне боларның берсенә дә чакырмый, кыстамый, аның үз хәле үзенә җиткәнен күреп тора.

Шулай көн артыннан көн үтә дигәндәй, беренче атна төгәлләнде. Вакытында дәвалану, тәмле ашауэчү, дөнья мәшәкатьләрен онытып ял итү нәтиҗәсез калмады, күрәсең, Газиз арык тәненә ит кунуын, үзенә хәл кергәнен сизә башлады. Кәефе дә күтәрелде. Моны Габделфәт тә сизми калмады:

— Күз тимәсен, матураеп барасың, курорт килешә үзеңә, — диде ул аңа, чын күңелдән. Ә кичен аны биергә чакырды. — Әйдә, ятма пыскып, хәрәкәттә — бәрәкәт. Биючеләрне күрерсең, үзеңне күрсәтерсең...

Бүлмәдән өстерәп диярлек алып чыкты ул аны. Габделфәттән күрмәкче, киемнәрнең дә пөхтәсен киде Газиз. Ашханәгә бару юлы халык белән тулган, даң-доң килеп бар көченә нинди дер чит телдә колагыңа чөй тыксаң да ишетелерлек каты тавышлы музыка яңгырый, бернинди калыпка сыймаслык мәгънәсез тамаша бара: кайсы аякларын чалыш-полыш китереп бөгелә дә сыгыла, кайсы, үрдәк кебек, әле бер якка, әле икенче якка тирбәлә, кайсы, анасы сөтенә туенган кәҗә бәтие кебек, тук-тук сикерә, ә кайсылары бер урында таптанып тора. Шуларның биюенә Габделфәт тә килеп кушылды.

Газиз бер почмактагы йомшак эскәмиядә бию дигән шушы тамашаны гаҗәпкә калып карап утырды-утырды да, аптыраганнан көлемсерәп, урыныннан кузгалды. Өске катка, бүлмәсенә менеп китәргә иде аның исәбе.

Шулчак залда башка, колакка күптән таныш музыка яңгырый башлады. Чү, вальс түгелме соң бу? Йа Хода, вальсны да уйната беләләр икән бит әле биредә, аны да онытмаганнар. Газизнең яшьлек юлдашы, мәңге ашкынулы, мәңге дәртле, мәңге яшь вальс. Йөзләгән уен коралларыннан торган зур оркестр башкаруындагы бу музыка, бер-бер артлы йөгерешкән тынгысыз диңгез дулкыннарын хәтерләтеп, көчәйгәннән-көчәя барды. Су буе озын һәм киң ашханә юлын, аннан вестибюльне, баскычлар мәйданын, шифаханәнең икенче, өченче, дүртенче катларын яулап алды. Газизнең кинәт аяк бармакларыннан алып башына, чәч төпләренә чаклы кайнар чымырдау үтте, әйтерсең лә аны кинәт кенә көчле электр тогына тоттылар. Әмма татлы, ләззәтле чымырдау иде бу. Вальс... Күптән ишеткәне юк иде аның мондый таныш, җанга рәхәт музыканы... Тукта, тукта, нинди вальс соң әле бу? Һичшиксез, Штраус, Иоһан Штраус вальсы. «Вена урманы әкиятләре», «Язгы авазлар»... Та-та-та, та-та-та... Кайсысы соң боларның? Бу «Гүзәл зәңгәр Дунай» да түгел, аны Газиз аермачык хәтерли.

Яшь чагында Газиз боларның барысын да белә иде, чөнки аз биемәде ул вальска. Бу яктан гади авылдан чыккан мишәр егетенең бәхете булды. Бер килмәсә, бер килә, диләр бит. Армиядә хезмәт иткәндә, аларны кино карарга гарнизондагы бердәнбер Офицерлар клубына йөртәләр иде. Шунда ул клуб мөдире, Новосибирск егете Рәшит белән танышты. Ике милләттәш сөйләшеп, дуслашып киттеләр. Рәшит клубта бию түгәрәге дә алып бара икән. Авиация полкы очучылары, башка офицерлар, аларның яшь, гүзәл хатыннары, җитеп килә торган сылу кызлары атнасына ике тапкыр кичкырын бию түгәрәгенә йөриләр.

— Мин монда чагында биергә өйрәнеп кайтып кит, үкенмәссең, — диде Рәшит.

Аның үзенең нинди талантка ия егет булуын Газиз шунда гына аңлады. Биюче дисәң дә биюче, чын танцмейстер икән бит. Башта ул хәрби округ ансамблендә төп биюче булган. Аның түгәрәгенә йөргән кеше биергә өйрәнә алмыйча калмагандыр. Истә, һаман истә ул түгәрәк. Рәхмәт Рәшиткә, ул булмаса, ямьшәеп беткән кирза итекле кече сержант Солтановка түгәрәккә йөрү дә тәтемәгән булыр иде әле.

Газиз үзе дә сер бирмәде, биергә тиз өйрәнде. Бигрәк тә бал биюләрен ярата иде ул. Вальс кына түгел, танго, фокстрот, кадриль, краковяк, полька, падеспань, падеграс — барлыгы уникe төр биюгә өйрәнде егет. Бар кимсенгәне — ямьшәеп беткән итекләр булгандыр, тик аның белән парлап чыгарга теләгән гүзәл затлар моңа артык игътибар да итмәделәр бугай. Кичәдән кичәгә остарып барган мишәр егетенең түгәрәккә йөргән аксөяк сылубикәләр арасында абруе зур, аларның һәркайсы Газиз белән бию не мәртәбәгә саный, алдан ук ниятләп тора, хәтта сөйләшеп куя. Егет бию залындагы иң сәләтле кавалерлардан да остарак башкара иде биюне.

Хәзер исә соңгы тапкыр кайчан биегәнен дә хәтерләми, аңа кимендә унбишләп ел үткәндер, кайда инде ул яшьлектәге вальсларның исемен хәтердә калдыру?

Ул шулай уйланып торган арада, бер-бер артлы вальс әйләнә башлаучылар да табылды. Музыка Газизнең үзен дә җилкендереп җибәрде: «Әллә берәрсен чакырып караргамы?» Ул күзләре белән якынтирәдә утырган хатын-кызлар арасыннан үзенә ошардай пар эзли башлады. Мондый чакта вакыт кыска була, кайчак беренче кул астына туры килгән хатын-кызны да чакырасың. Ләкин Газизнең күзе үзеннән-үзе ике-өч кеше аша утырган утыз-утыз биш яшьләрдәге бер ханымга төште. Түгәрәк ачык йөзле, җилкәсенә төшеп торган тузынкырак кара чәчле, куе кызыл төстәге озын күлмәге тыгыз гәүдәсенә килешеп тора. Газиз, урыныннан торып, аңа каршы килеп басты һәм яшь чагында өйрәнгән, чын кавалерларга хас гадәт буенча башын иде: «Мин сезне вальска чакырам...» Хәзер ханым сикереп торыр да, алар парлашып вальс әйләнә башларлар сыман иде, тик Газиз ялгышты: ханым гаҗәпкә калып карап торды һәм «юк» дигән мәгънәдә башын чайкады...

Газизнең, кырау суккан чәчкә кебек, кәефе төште. Ул, кире урынына барып утырырга уңайсызланып, икенче якка чыкты һәм, аптырап, дивар янына барып басты. Беренче коймак төерле булды ла! Эш нәрсәдә, нигә ул чыкмады? Күренеп торган бернинди сәбәп юк кебек. Газиз ап-ак күлмәктән, пөхтә итеп үтүкләнгән кара чалбардан, туфлиләре дә ялтырап тора, гәүдәсе дә төз, килешле әле аның. Әллә соң шулай бик олы күренәме ул авыру килеш? Юк, бүген бүтән берәүне дә чакырмаячак ул вальска. Менә музыка гына тәмамлансын да, бүлмәсенә менеп китәр. Үз-үзеңне кимсетеп тагын монда калырга...

Кинәт диварга сөялеп басып торучылар арасыннан бер яшь хатын, кузгалып, Газизгә таба килә башлады. Газиз аны үтеп кенә китәр дип уйлаган иде, ләкин алай булып чыкмады, ул, аның янына тукталып:

— Абый, сез вальс биисезме? — диде.

Газизнең яшьлегендә ир-атны хатын-кыз ак вальска гына чакыра торган иде. Хәзер әнә башка гадәт икән.

— Яшь чакларда ярата идем вальсны, — диде Газиз һәм, ханым белән җитәкләшеп, биючеләр арасына юнәлделәр. — Әле менә берәүне чакырган идем дә, чыкмады. Кәефе юкмы...

— Ә мин күрдем аны. Шуңа сезне чакырдым да. Белдем сезнең вальс танцевать итәсегез килгәнне.

— Рәхмәт...

Башта алар салмак кына әйләнделәр, чөнки Газизгә вальсның инде онытылып беткән нечкәлекләрен искә төшерәсе бар иде. Аннан темпны тизләтә төштеләр. Вальслар шундый инде алар: биегән саен син тизрәк әйләнә, дәртләнә, җилкенә барасың, кәефең, рухың күтәрелә. Вальс ашкындыра сине, сиңа каяндыр көч-куәт килә. Хәтта соңгы вакытта авырган Газизне дә кодрәтле музыка әнә илһамландырып җибәрде, ул парын әле уң, әле сул якка әйләндерә-әйләндерә бию залын аркылыга-буйга ерып чыкты, тиргә батты. Ләкин, музыка төгәлләнмичә, парын ычкындырмады.

— Сез бик оста биисез икән бит. Шулкадәр җиңел, рәхәт сезнең белән, — диде аңа пары. — Каршы булмасагыз, мин сезнең белән тагын биер идем. Башка вакытта да дим. Минем бөтен яратканым — вальс, кич буена биергә дә риза...

Ләкин бу кичне бию залында бүтән вальс яңгырамады.

Бүлмәдә Габделфәт:

— Күрдем, күрдем синең бер чибәр белән ничек әйләнгәнеңне. Шәп чыкты, сезгә сокланып карап торган кешеләр дә аз булмады бугай. Афәрин! — диде.

* * *

Иртән курорт кабат үз тормышында кайный башлады. Аның ике катында да халык ыгы-зыгы килә, бер процедураны алып чыккач, икенчесенә, өченчесенә чаба. Дәваланып йөргән арада, Газиз күзләре белән нигәдер йә бер, йә икенче дәвалану урынында процедурага чират көтеп утыручылар арасыннан кичә биергә чакырып, аның теләген кире каккан хатынны эзләде. Чибәр, ләкин артыгы белән горур хатын иде ул — Газизгә шулай тоелды. Кичәге хәлдән соң, Газизнең күңел түрендә кимсетелү, рәнҗетелү кебек хис калды. Әллә соң чынлап та горурланырлыгы бармы? Горур, димәк, җилбәзәк хатын түгел. Шулай да биергә чыкмаса да, күзгә-күз карашып бер-ике сүз алышасы иде үзе белән. Кем икән соң ул тутый кош, кайсы яклардан, кайсы елга аръягыннан? Ләкин Газизнең күзенә ул хатынны хәтерләткән бер генә кеше дә чалынмады.

Кичен тагын биюләр булды. Репертуар тагын шул ук: бар куәткә яңгыраган музыкага барысы да кубарылып үзенчә бии. Газиз исә сабыр гына вальсны көтте. Бүген аның пары булачак инде, әнә бит кичә аның белән биегән яшь ханым алдан ук әйтеп куйган иде. Тик кайда соң әле үзе, залда бер дә күренми.

Ниһаять, вальс... Ах, аның күңелләрне тибрәндерерлек, йөрәкне ашкындырырлык көче!

Газиз, халык арасыннан сабырсызланып, күзләре белән кичәге парын эзли башлады. Ә ул нишләптер юк. Инде парлашып бии башлаучылар да күренде. Шулай кич буена бер тапкыр уйната торган вальска әйләнә алмый менеп китәрмени соң ул?

Газиз күзләре белән әле бер, әле икенче якны айкады. Ниһаять, тапты ул аны — кичә кара костюмнан чыккан яшь ханым бүген аяз көндәге күк сыман үтә ачык зәңгәр төстәге, өрфия кебек җиңел, озын, бераз гына купшы, ләкин искиткеч килешле күлмәктән ишек катында басып тора икән һәм, Газизнең эзләвен күрепме, аңа кулы белән ишарәләр ясый. Әйтерсең «Мин бит биредә, күрегез мине...» ди. Газиз дә аңа ым ясады, «Әйдә чыгабыз...» Һәм алар бер-берсенә каршы тиз-тиз атладылар. Шулчак һич көтмәгән, уйламаган бер хәл булып алды. Әллә каян аның каршына башка бер ханым атылып та чыкты:

— Сезнең белән мөмкинме? — дип сорады.

Гаҗәпләнүдән Газизнең күзләре шар булды: бу бит кичә аның белән вальска чыгудан баш тарткан ханым! Шул ук ачык йөз, шул ук ярым тузгыган кара чәчләр, шул ук үзенә килешеп торган куе кызыл төстәге күлмәк. Кичәгедән аермалы буларак, ул бүген нигәдер авызын ерган. Газиз исә бу хәлдән кинәт каушап китте. Шулай да үзен тиз кулга алды:

— Гафу итегез, әнә килә бит инде, — диде, һәм, бераз ясалма тәкәбберлек белән, әлеге ханымны үтеп китте.

Зәңгәрсу өрфия күлмәкле яшь ханым зал уртасына килеп җитә иде инде. Алар бер-берсенә каршы ашкынып килделәр һәм, мизгел эчендә җитәкләшеп, көчле музыканың «та-та-та, та-та-та» дигән өчле тактына дәртләнеп вальс бии башладылар. Бу күренеш залдагылар өчен шулкадәр көтелмәгәнчә, хәйран калырлык матур, чын сәнгатьчә, нәзакәтле килеп чыкты ки, күбесе бу парга чын күңелдән сокланып, ә кайберәүләр исә хәтта көнләшеп карап куйдылар. Бигрәк тә төз, зифа буйлы, арыслан ялыдай күпереп торган саргылт чәчле партнерның үзен вальста виртуозларча оста тотуы, аның яшьләрчә җитез кыймылдавы, зыр-зыр әйләнүе шаккатырды аларны. Кичә чирканчык алганнан соң, чыннан да Газиз бүген биюдә һич ялгышмады — яшьлегендәге кебек дәртле хис белән җилтерәтте ул кочагындагы яшь бикәсен. Ханым да төшеп калганнардан түгел икән, Газизгә әле тәмам сыланып, әле кулга-кул гына тотынышып, аның һәр хәрәкәтен тоеп, үзенең хәрәкәтләрен анықына тәңгәл китереп, бербөтен булып, коштай канатланып уңга да, сулга да әйләнде дә әйләнде...

Вальс хозурына бирелсә дә, Газизнең башында тынгысыз уйлар да гизде. Кичә бөтен халык алдында чакырып та вальска чыкмаган ханым бүген үзе аның каршысына килде ич: «Сезнең белән мөмкинме?» — дип сорады. Һич мантыйкка сыймый әле бу хәл. Хикмәт нәрсәдә? Бу гүзәл затларны һич тә аңламассың: бер карасаң, ялындыралар, икенче карасаң, үзләре күзгә керәләр. Шулай да бу хәлдән соң Газизнең үпкәсе бераз басылгандай булды.

Вальстан соң татар бию көен уйната башладылар — ул да һәр көнлек репертуарда иде. Яшьләр дә, урта яшьтәгеләр дә, олыраклар да атылып чыгып биергә тотынды. Берсе икенчесен чакырып, авылдагыча бер-берсенең кулларыннан тотып әйләнгәләп ду-у килделәр.

Бу вакытта Газиз, вальстан соң хәле бетеп, диварга терәлеп тора иде. Әллә ничек шунда, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде, йөрәге тыпырчынды, башы әйләнде, тын алырга авыр булды. Нәкъ шул вакытта бии-бии кызган халык арасыннан тагын теге кызыл күлмәкле ханым коштай очып чыкты һәм көчкә сөялеп торган Газизгә китереп басты. Газиз исә уңайсызлыктан моңсу итеп елмаеп кына куя алды...

* * *

Хәлсезлек, баш әйләнүе аның икенче көнне дә бетмәде. «Чамаңны белмисең, биергә чыккан буласың тагын», — дип, үз-үзен битәрләп йөрде ул көн буе. Хәлен аңлап, Габделфәт аны төштән соң һава сулап керергә чыгарып җибәрде.

— Баш авыртуың басылыр, саф һава җитми сиңа, дустым, бинадан чыкмый ятасың, — диде ул, чын кайгыртучанлык белән. — Бар, бар, әйләнеп кер...

Ә тышта, чыннан да, саф һава, җиләс, матур көн. Сентябрьдә сирәк була торган җылы көннәр. Теплоходлар, үзйөрешле баржалар, башка төрле суднолар йөреп торган киң елга ягыннан талгын җил исә. Рәхәт! Газиз, бераз вакыт күкрәген киереп, саф һава сулап басып торды.

Курортта ял итүчеләрнең шактые урамда икән. Сигез катлы ак бина яныннан төрле якка бетон плитәләр түшәлгән берничә сукмак китә. Һәр сукмак — үзе бер маршрут. Берсе — каен, икенчесе — нарат урманына, өченчесе елга буена алып төшә ул юлларның. Барлык җирдә дә халык: парлап та, төркемләп тә. Ялгызлар да җитәрлек. Газиз дә әнә шул юлларның берсенә төшеп, ашыкмый гына нарат урманына таба китте. Нәкъ менә шул урман аланындагы зәвык белән эшләнгән чатырда утырып ял иткәндә, аның янына кабат кызыл күлмәк килеп чыкты. Башта ул, исәнләшеп, үтеп китәргә уйлаган иде. Ләкин ике-өч адым киткәч тә, кырт кына борылды һәм тәвәккәл атлап чатырга керде.

— Мин дә ял итеп алыйм әле яныгызда. Рөхсәттер бит?! — диде ул, елмаеп.

— Үтегез, утырыгыз, урын җитәрлек, — диде Газиз, ә үзе ханым турында: «Чая, хәерсез», — дип уйлады.

— Нәрсә, хәлегез китеп торамы әллә? Төсегез үзгәргән...

— Юк, болай гына... Ял итәм, — дигән булды Газиз.

— Сез авырыйсыз, әйеме?

Газиз иңнәрен җыерып куйды:

— Белмим инде, бәлки, авырыймдыр...

— Авырыйсыз. Миннән яшерә алмассыз, мин бит табибә. Әйтегез дөресен, нәрсә сезнең?

— Ике сүз белән генә аңлатып булса икән, — диде Газиз, авыр сулап. Бер-берсенә карашып шактый гына сүзсез утырдылар алар. Соңгы ике-өч көндә тәмам тынгылыгын алган, хәзер исә янына ук кереп утырган бу таныш булмаган чая хатынның күзләренә карады Газиз. Күзләре коңгырт төстә икән. Елмаеп җибәрергә күп сорамый торган түгәрәк, якты йөзле. Күзләренә, йөзенә караганда акыллы, киң күңелле, шәфкатьле булырга охшый. Үзе сөйкемле.

Гомер агышында Газизнең яратып йөргән, һич югында, аңа бик ошаган кызлар, хатыннар аз булмады. Тик ул һәрбер тәүге очрашуда ук килеп ябышырга әзер җилбәзәк, җиңел акыллылардан ерак йөрде. Тышкы бизәк, тышкы матурлык аны кызыктырмады, чөнки бер-ике мәртәбә авызы пешкәч, чибәрләргә шикләнеп карый башлады ул. Аның күңел дәфтәрендә кайсыдыр бер мәшһүр шәхеснең әйткән сүзләре язып куелган: «Есть красивые девушки, которые напоминают красивый дом, окна в котором никогда не светятся...» Ә бит, чыннан да, бар гүзәлләрнең гүзәле, тик якынрак килеп, танышып киткәч, бу гүзәлнең буш куык булуына, анда он суы да, тоз суы да юклыгына төшенәсең. Юк, тышкы бизәк белән түгел, ә рухи дөньясы белән матур кеше. Шуңамы, кызлардагы тышкы матурлыкка караганда, аларның сөйкемлелеген артыграк бәяләде Газиз. Чөнки сөйкемлелектә үзенә бер аерым күркәм сыйфат, тирән мәгънә барлыгын белде. Йөзләрендә нур балкыган хатын-кызлар гына нечкә күңелле, бай табигатьле, көчле рухлы, гүзәллек, садәлеккә омтылышлы, төпле акыллы, сабыр холыклы була алалар. Газизне дә әнә шундый гүзәл затлар гына кызыксындырды. Әмма андыйлар күп булмыйлар. Элек тә аз иде алар, хәзер исә бөтенләй сирәк.

— Йә, карап бетердегезме? Бәлки, берничә сүз катарга рөхсәт итәрсез? — диде Коңгырт Күз.

Аның тел төбендә, сөйләү рәвешендә шаянлык-шуклык бар икән, үзе гел елмая.

— Рөхсәт, — диде шундый ук шаян тонда Газиз дә.

Ә хатын, кинәт җитдиләнеп:

— Абый, исемегезне белмим, гафу итәсез, телибезме, теләмибезме, безгә сезнең белән танышырга насыйп булган, ахры, — дип, сүзен башлады. — Әлбәттә, әдәби әсәрләрдәгечә сандугачлар сайраган салкын чишмә буенда, яфраклары шыбырдашкан карт тирәк янында танышу килеп чыкмады. Эт талашмый танышмый, диләрме әле? Талашуын талашмадык, тик шулай да... Мин сезне бик үпкәләттем бугай. Ялгышымны төзәтим дип, үзем килеп вальска чакырдым — башка белән чыгып киттегез, биергә чакырдым — бөтенләй мине санга сукмадыгыз. Мин бит теге кичне сезне бер карт җилбәзәк, танышыр өчен генә чакыра дип белдем. Сезнең мине чын күңелдән вальс биергә чакырганыгызны, үземнең ялгышканымны бик тиз аңладым. Хәзер инде терсәкне тешләп булмый. Белсәм икән сезнең биюдә шулай оста булуыгызны. Ә сез әнә нинди, бөтен курорт халкын шаккатырдыгыз. Әкәмәт биюче икәнсез, суда балык та шулай оста йөзә алмый торгандыр. Чын менә...

— Гаҗәп матур сайрыйсың икән, сеңлем...

— Айсылу минем исемем, Ай-сы-лу...

Ул, сөйкемле елмайган килеш, Газизнең күзләренә текәлде.

Газиз аны аңлады:

— Газиз. Газиз абыең Солтанов...

— Кем соң сез? Бик серле... Гадәти генә кеше түгел бугай сез. Һәм авыруыгыз нидән гыйбарәт, Газиз абый? Бәлки, минем профильдер һәм сезгә булыша алырмын? Чын менә...

— Чернобыль дигән сүз таныштыр бит? — диде Газиз, Айсылуга сынаулы караш ташлап.

— Ма-ла-ка-ем! — Айсылу кычкырып ук җибәрде. — Әйтәм... Күңелем сизгән иде аны сездә нидер барлыгын. Әстәгъфирулла!..

Айсылу, бераз аңын югалткан кеше кебек, өнсез-тынсыз калды. Аннары гына сүзен дәвам итте:

— Ничек соң ул якка барып чыктыгыз, нинди хәерсез җилләр ташлады сезне ул Алла каргаган җиргә?

— Үзем дә еш кына шул турыда уйланам. Архитектор мин, проект бүлегендә эшлим. Беркөнне ашыгыч рәвештә хәрби комиссариатка чакыртып алдылар: «Атом станциясендәге авария турында ишеткәнсеңдер инде, аны туктатыр өчен ниндидер архитектура корылмасы эшләргә белгечләр кирәк», — диделәр. Белгән булсам икән нинди корылма кирәклеге турында! Тәүге тапкыр балта тоткан кеше дә эшли алырлык бетон әрҗәсе булып чыкты ул. Без бит теге еллар тәрбиясен алып үскән балалар. Патриотизм, интернационализм... Ил өстенә куркыныч килгән, тар муенлы чүлмәккә ябылган пәри бөкене бәреп чыккан да котырына хәзер. Мин бармасам, башканы алып китәчәкләр... Башымда төрле уйлар гизде. Гаиләдә дә аңлашу юк иде ул көннәрдә. Күңелдә төшенкелек. Шулай киттем дә бардым. Арттан елап калучы булмады, хәтта кая барасың, дип тә сорамадылар...

Газиз сүзсез калды, тагын Айсылуга таба борылды. Йөзендә аптырашлы елмаю иде аның. Аз аптыраган елый, күп аптыраган көлә. Газизнең хәле дә шундыйрак хәзер. Үзе ябык, йөзендә йөзләрчә вак буразна, карашы моңсу. Югыйсә чибәр генә кеше икән, шушы халәтендә елмаюы да аның үзен сөйкемле итә.

Кинәт Айсылу аңа таба якынрак килеп, терәлеп үк утырды:

— Сөйләгез, Газиз абый, — дип пышылдады ул Газизнең колагына. — Сөйләгез, минем сезне тыңлыйсым, юк, ишетәсем, әйе, ишетәсем килә. Бушану үзегезгә дә зыян итмәс. Чын менә...

— И-и, Айсылу сеңлем, андагы мәхшәр турында сөйләргә көн дә, төн дә җитмәс. Чернобыль хәзер дә төшләремә керә. Саташып, бастырылып, куркудан кычкырып, шабыр тиргә батып уянам...

* * *

— Без барып җиткәндә, саркофагны төзи башлаганнар иде инде, — дип башлады хикәятен Газиз. — Дүртенче блок... Җәһәннәм уты... Болай күзгә күренми, билгеле. Атом куркынычын күргән кешеләрмени без? Томаналар, гәрчә нидер сизенсәк тә, аңламыйбыз. Атом уты көйрәгән корылмалардан ерак та түгел бер якта бер-ике мәртәбә файдаланып ташланган автомашиналар, тракторлар һәм башка «төр техника зираты» санап бетергесез күп. Авариядә хисапсыз урта азиялеләр — төрекмәннәр, үзбәкләр, таҗиклар, кыргызлар, казахлар. Һәм без — татарлар, башкортлар, удмуртлар, марилар... Мин соңыннан бу турыда бик күп уйландым. Урыс бик аз, бөтенләй юк диярлек анда. Империя сәясәтенең мәкерлелегенә исең-акылың китәр. Гомер буе шулай булды — хәтәр җиргә һәрвакыт башта урыс милләтеннән булмаган халыкны тыктылар. Тарих шул хакта сөйли. Урта Азиядәге Басмачылар хәрәкәтен Татбригада кулы белән бастырганнар. Ә бит Басмачылар милли азатлык өчен көрәшкән. Әфган сугышында исә ислам динендәге илгә каршы мөселман республикаларында яшәүче ир-егетләрне җибәрделәр. Чечняда да шул ук хәл кабатланды. Бер-берсен кырсын дигән сүз бу. Төрки кабиләләрне, ислам динендәге халыкларны бүлгәләү, бер-берсенә каршы кую, котырту, ызгыштыру империянең элек-электән калган сәясәте ул.

Әрҗәне чират торып төзедек. Үзебез яшәгән зонадан блок өстенә санаулы вакыт эчендә килеп җитәбез. Һәрберебез маскхалатлардан, авызда респиратор, кулларда балта, пычкы, чүкеч, кадаклар, такталар... Кыскасы, кемгә бәлеш, кемгә шеш: алдан кемгә нәрсә алып барырга кушылган булса — шул. Блоклар өстендә нәкъ унбиш минут эшлибез — бу безнең көнлек норма. Без килгәнче башта җиде, аннан ун гына минут эшләткәннәр. Монда да безне бәхет читләтеп үтте. Көннәр кызу, ә безнең өстәге киемнәр авыр, респиратор аркылы суларга һава җитми, күзлекләр булана — күреп булмый. Һәрберебез манма тиргә батып эшли, монда мунчадан да кызурак. Ашыгабыз, кабаланабыз, ялгышабыз, тик ялгышны төзәтергә вакыт юк. Тизрәк, тизрәк...

— И-и, Газиз абый, сүзегезне ефәк белән бүләм. Ул саркофаг дигәнегез телевизордан гел киртләч-киртләч булып күренә иде. Чыннан да шундыймы соң? — дип сорады Айсылу.

— Менә, менә шунда да хикмәт. Әйтәм бит, ялгышны төзәтергә вакыт җитмәде, дип. Кая инде аны хасиятләп тору! Коелган тимер-бетон измәсен тотамы әрҗә? Тота! Шул җиткән...

Газиз сөйләвеннән беразга туктап торды. Сөйләр сүзләрен барлыймы күңелендә, әллә йомгак очын югалттымы? Күз карашы астыннан каядыр еракка, елга аръягына карап, уйланып утыра бирә. Айсылу да эндәшми, уйларын бүлдерүдән яхшысынмый.

Юк, йомгак очын югалтмаган икән Газиз. Елга аръягына караган килеш, ул сүзен дәвам итте:

— Анда эшләү тәмуг газаплары белән бер. Вакытны бер-беребездән сорашып кына торабыз: «Күпме калды? Ничә минут? Ничә секунд?» Вакыт чыгуга, эшне ташлап чабабыз — хәтәр учактан ераграк булуың хәерле. Кесәдәге дозиметрлар безнең нормадан ике-өч мәртәбә артык радиоктив нурлар алуыбызны күрсәтә. Ләкин дозиметристлар: «Юк, алай түгел, сезнең дозиметрлар дөрес күрсәтми», — дип, безнең белән җан талашалар, хәрәмләшәләр, алдашалар. Шулай һәр көн. Бигрәк тә Урта Азия республикаларыннан килгән халыкны нык алдыйлар иде. Алар үзләре дә — Аллам сакласын! — акча өчен җаннарын сатарга да әзер. Җимерек блок кабат атом өермәсен тышка, һавага ташлагач, без вакытлыча блок янына барудан баш тарттык. Бу инструкция буенча да шулай: радиация фоны күтәрелгән очракта, блокта эшләү тыела иде. Хәтта безне куркынычсызрак җиргә күчерергә дә тиешләр иде. Ләкин ул көннәрдә һава торышы үзгәрде, җил исә башлады һәм радиация фоны без торган җирдән икенче якка авышты. Без күчеп йөрмәдек инде.

Шулай да безне эшкә куарга маташып карадылар. Пәри оясының авызын томаларга кирәк бит. Аңлыйбыз: катлаулы, четерекле хәл. Ләкин кемнең күрәләтә кабергә керәсе килсен? Көйләп-җайлап та, янап-куркытып та карадылар, бик күп акча да вәгъдә иттеләр — булмады, без күнмәдек, җиңә алмадылар. Шуннан соң бер төркем таҗикларны, шулай ук бик күп акча бирәбез дип, төрлечә юмалап, алдап-йолдап блок өстенә җибәрделәр. Алар әлеге атом-төш ягулыгы урнашкан скважинаны тимер-бетон измәсе белән томаларга тиешләр иде. Белмим, нәрсә, күпме эшли алганнардыр, шул керүдә иллешәр радиоктив нурлар белән зарарланып чыкты мескен таҗиклар. Чатырга кайтканда, каратуткыллы таҗикларның йөзләре ап-ак иде. Чәчләре, кашлары, керфекләре, сакал-мыеклары күз алдында касмак-касмак

булып коелып төште. Өрәк тә өрәк, таҗиклар да өрәк, яннарында басып торырга, йөзләренә карарга да куркыныч иде. Барысын да ашыгыч рәвештә Киевка, госпитальгә озаттылар. Күбесе шунда беренче көннәрдә үк җан тәслим кылган, калганнары соңрак берәм-берәм дөнья белән бәхилләшкән...

— Чынлап та шулай булдымы, Газиз абый? Дөресме соң бу? — дип, Айсылу гаҗәпләнүдән Газизнең беләгеннән тотып алды.

Газиз исә сүзен җөпләп тормады. Малай чакта булса, ул: «Валлаһи, җир йотсын, ике мәчет арасында кысылып үлим», — дип ант иткән булыр иде. Гүя ул Айсылуның сүзен колакка да алмады, үзенекен тәкрарлады:

— Әсрар исемле таҗик әле дә күз алдымнан китми. Нык бәдәнле, киң җилкәле, чибәр, кара мыеклы утыз биш яшьләрдәге бу таҗик белән танышып киттек без.

— Татарларны хөрмәт итәм мин. Минем дә янга татар, бик уңган, яхшы хатын, — ди.

— Кем соң ул «янга»? — дим.

— Абыйның хатыны.

— Ә, җиңги, димәк.

Янга — җиңги... Бер үк сүз бит, тик ике телдә, әйтелешләре охшаш икән, гәрчә татар теле белән таҗик теле ике тел төркеменә керсә дә. Сөйләшә-сөйләшә әллә никадәр уртак сүз таптык: килен, кәнди, табак, каймак...

Блок өстенә җибәрелгән көнне мин Әсрарга (таҗиклар үзләре аңа Осрор дип эндәшәләр иде):

— Нигә риза булдыгыз, ялгышасыз бит, тормышыгызны, гомерегезне куркыныч астына куясыз, уйлашыгыз тагын бер кат, — дидем.

Ул аптырап кулларын җәйде:

— Уйлаштык инде, мин генә аерылып кала алмыйм иптәшләрдән...

Бу вакытта мин аларны буар елан тарафыннан сихерләнгән, гипнозланган куян халәтендә күрдем: үзе чиный, үзе һаман елан авызына таба бара...

«Ашыгыч ярдәм» машинасына утыртып җибәрер алдыннан, әле унбиш-егерме минут кына дулкын-дулкын кара чәчле, куе кара кашлы, кара мыеклы Әсрарны күреп шаккаттым: ул да өрәк кебек шәп-шәрә калган иде...

Газиз авыр сулап куйды һәм шактый вакыт тын утырды. Уйлары да авыр иде бугай аның. Айсылу аны бүлдермәде, сүз катмады, ул да уйлана иде.

Аннары Газиз тагын кабынып китте:

— Әгәр шул вакытта аварияне бетерү буенча штаб вәкилләренең сүзен тыңлап блокка менгән булсак, Газиз абыең синең яныңда менә шулай юк-бар сүз сөйләп утыра алмаган булыр иде, Айсылу ханым...

Безнең смена җитәкчесе кипкән таракан кебек ябык Гончаренко дигән бер украинлы иде. Украинлылар, гомумән, матур, таза халык. Ә бу ябыклыкның чигенә чыккан. Саргылт йөзле, очлы күзле, кылыч борынлы, ачы тавышлы. Шул инде безне утка да, суга да кертергә әзер торучы. Безнең илдә, гомумән, беркайчан да кеше хакын хаклау, кеше кадерен белү юк. Бу түрә кисәге дә шул күзлектән чыгып эш итә торганнардан. Синең турында кайгыртуны белми дә ул, ә менә эшләтеп җаныңны ала. Көнлек норманы үтәргә кеше җитмәде исә, инде бер мәртәбә эшләп кайтканнарны кабат блок өстенә җибәрә. Бу — инструкцияне ачыктан-ачык бозу. Безнең белән бер сменада Николай дигән керәшен эшли иде. Бәлеш төбе кебек йомшак, тыңлаучан, сабыр, аз сүзле. Гончаренко моны бер мәртәбә җибәрде икенче катка, ике җибәрде...

Мин түзмәдем:

— Что вы делаете с человеком, хотите прежде времени в могилу загнать? — дидем.

— Не твое дело, здесь я начальник смены, — ди бу.

— Ах, вы начальник смены? Тогда пойдем в штаб, доложите, как соблюдаете инструкцию...

Шөлләде, кабахәт, Николайга да, башкаларга да бәйләнми башлады.

Теге вакытта реактор коесын авызлыкларга барырга үгетләп, янап, куркытып йөрүче дә ул иде. Шул чакта мин аңа:

— Хорошо, мы согласны, но только пойдем вместе с вами, — дидем. — Без вас — ни шагу!

Корт чактымыни, күз ачып йомганчы Гончаренкобыз юк булды.

Газиз тынып калды. Айсылу исә аның атом мәхшәре турында шулай тыныч, олы сабырлык белән сөйләвенә шаккатты. Нинди зур ихтыяр көченә ия бу кеше! Айсылу янында гади кеше генә түгел, чын каһарман утыра икән. Ул гомер буе батыр, кыю, фидакарь кешеләр турында укып, аларны телевизордан карап, кылган гамәлләренә сокланып яшәде, әмма үзләрен болай якын, янәшәдә генә күрергә насыйп булмады. Ниһаять, шундый кеше белән дә очраштырыр икән аны язмыш...

— Менә шулай, Айсылу сеңлем, — дип сөйләвен дәвам итте Газиз. — Таҗиклар Чернобыль җиреннән ерак китә алмадылар, гүр иясе булдылар, ә миңа Ходай үз җиремә кайтып үләргә насыйп иткәндер. Картлар әйтмешли, хәерле булсын инде. Нишлисең бит язмышың шундый булгач. Артыгын да сөйләп ташладым инде, гафу ит...

— Юк, юк, минем өчен зур ачыш ясадыгыз, Газиз абый. Чернобыль турында бик аз беләм икән. Чын менә.

— Бөтен ил халкы бик аз белә бу зур һәлакәт, аның тәэсире турында. Башта бит аны гади, бәләкәй, зыяны да зур булмаган бер авария итеп кенә күрсәтергә тырыштылар. Чынында исә дөньяда атом белән бәйләнешле иң зур катастрофа булды ул. Хиросима белән Нагасаки өстенә ташланган бомбалар да, Тоцк полигонындагы сынап карау да атом-төш мәхшәренең балалары гына булган. Газеталар, телеканаллар әнә бу һәлакәткә юлыккан, аны бетерүдә катнашкан, шул төбәктә яшәп радиация белән зарарланган алты йөз мең кешенең вакытыннан алда вафат булуы турында хәбәр итәләр. Алты йөз мең! Һәр ел саен бу сан алтмыш-җитмеш меңгә арта бара. Чернобыль җире, аның тирәсе әле озак еллар кан косачак...

Инде кичке ашка кайтырга вакыт җиткән иде — алар урыннарыннан кузгалдылар. Нарат урманының һавасы Газизгә килеште, ул үзен әйбәт хис итә иде. Бетон плитәләр салынган тигез сукмактан алар, ашыкмый гына, шифаханәгә таба атладылар.

— Язмышыгыз бик үзенчәлекле икән, Газиз абый. Кызганыч та, гыйбрәтле дә. Ходай сәламәтлек бирсен үзегезгә. Сез моңа лаек кеше, — диде Айсылу һәм, һич тартынмыйча, Газизне култыклап алды.

— Яхшы сүзеңә рәхмәт, сеңлем, тик сәламәтлекнең ни дәрәҗәдә икәнен үзем генә беләм...

— Алай димәгез әле. Менә курорттан тазарып, көч җыеп, яшь егетләр кебек күкрәк киереп кайтып китәрсез. Мин сезгә шуны телим. Безнең әле сезнең белән вальс биисебез бар, аны да онытмагыз. Мин дә бик яратам бит вальсны. Бүген, шәт, сезнең белән парлап чыгарбыз, мин сезнең белән вальс әйләнмичә моннан китмим. Үземнән торса, беркайчан да сезнең чакыруны кире какмам. Ялгышуым яшьлегем аркасында булды, диләрме әле?

Айсылу ягымлы елмайды һәм башы белән Газизнең иңсәсенә җиңелчә кагылып алды.

Ул ишектән керә-керешли Газизнең җиңеннән тартты һәм, үтеп-сүтеп йөрүчеләр ишетмәсеннәр дигәндәй, шыпыртлап:

— Газиз абый, биер алдыннан тагын һава суларга чыгарбыз әле. Миңа бик рәхәт булып китте сезнең белән. Күпне күргәнсез, меңне беләсез, мавыктыргыч итеп сөйлисез. Мин бит ялгыз...

Лифт белән үз катына күтәрелеп, бүлмәсенә таба атлаганда, Газиз Айсылуның: «Мин бит ялгыз...» — дигән сүзләрен кабат исенә төшерде. Нәрсә әйтергә теләде ул моның белән? И-и, җаным, бер син генә ялгызмыни бу дөньяда? Төптәнрәк уйласаң, кеше тумыштан ук ялгыз, көчсез, ярдәмгә мохтаҗ, мескен ул. Чернобыль вакыйгасы моның шулай икәнлеген Газизгә артыгы белән исбатлады. Шуның өстенә эчкечелеккә сабышкан хатыны... Ул да ялгыз иде бу дөньяда һәм ялгыз үлеп тә китте. Әнә шулай хәсрәт өстенә хәсрәт килеп тора Газизнең башына. Бар шатлыгы — тормыштагы кызы һәм яңа туган оныгы. Бар булганын, бар тапканын шуларга бирә хәзер. Бу тормышта үзе ялгыз. Болар турында сөйләп тә, әйтеп тә бетерә торган түгел...

* * *

Кичен алар каен урманына таба киттеләр.

— Ә син миңа артык кәттә, горур булып күренден башта, — дип, әңгәмәсен дәвам итте Газиз.

— Әйе, мин шундыйрак, Газиз абый, сез дөрес сиземләгәнсез, — диде Айсылу. — Мин балачактан ук үпкәчел һәм горур булып үстем, яшьтән үк буем җитмәс биеклекләргә үрелдем. Мәктәптә әйбәт укыдым мин, бәлки, шул миңа үземне горур тотарга нигез биргәндер. Беренче мәхәббәт мәктәптә килә, дигән булалар. Мин сыйныфташларым арасында гашыйк буларлык егет тапмадым, гәрчә артымнан ияреп кайтучылар аз булмаса да. Көчкә-көчкә өчле билгесенә өстерәлгән малай-шалайны санга да сукмадым. Мәктәпне яхшы билгеләренә тәмамлап, югары белем алгач, принц кебек егетне очратып, аны сөеп, аңа кияүгә чыгып, ханбикә кебек гадәттән тыш шартларда тормыш итәсе идем. Чын менә. Унынчы сыйныфта безне астрономиядән әле шушы елны гына институт тәмамлап кайткан Зөфәр абый укытты. Аның безнең класска беренче керүендә үк мин хушсыз кала яздым. Зифа буйлы, дулкын-дулкын күпереп торган кара чәчле, зур зәңгәр күзле, сүзендә дә, эшендә дә чатнап торган яшь егет. Менә ичмасам принц! Дәресләрен шундый кызык, мавыктыргыч итеп үткәрә, кырык биш минутның ничек үткәнен дә сизми калабыз. Дәрес буена аңардан күзләремне ала алмый утыра идем. Әллә нинди тормышка ашмас хыялларга чумам һәм төн саен диярлек төшемдә күрәм. Тик Зөфәрем күтәрелеп миңа күзен генә дә сирпемәде. Ә минем хисләремне җиткерергә аңа кыюлыгым җитмәде. Ул елларның кызлары тыйнак иде бит, кая инде хисне белдерү?! Тик ул елларда да кызларның төрлесе булган икән. Шул ук Зөфәр абыйга: «Яратам», — дип килгән кыз безнең сыйныфта гына укыган — соңыннан ишеттек. Зөфәр абый акыллы иде шул, шөпшә кебек әзер балга төшмәгән, ул кыз белән әйбәтләп кенә сөйләшкән, син дә миңа ошыйсың, ләкин син яшь әле, алда мәхәббәтең очрар үзеңә, ә минем яраткан, ярәшкән кешем бар, дигән. Булганмы, юкмы аның яратканы-ярәшкәне, тик без урта мәктәпне тәмамлап чыккан елны Зөфәр абыйны армиягә алып киттеләр. Хәрби самолетта укчы-радист булып хезмәт иткән һәм, катастрофага

очрап, экипажлары белән һәлак булганнар. Менә шундый инде минем «беренче мәхәббәт». Үзем ярар инде, менә Зөфәр абый юк, ул кызганыч. Нинди шәп егет иде бит!

Аннан соң миндә беркемгә карата да көчле хис кабынмады, йөрәгемдә ут дөрләмәде. Институтта укыганда да принц очрамады, эшли башлагач та...

Берәү белән торып карадык, тик, урыс әйтмешли, «не сошлись с характерами».

Мин үземне әллә кемгә санап, гадәттән тыш мәхәббәт көтеп йөргән арада, иң гади, һәркем өчен мөмкин булган мәгънәле генә яшьлек минем яннан узып китеп бара икән. Ханбикә, имеш! Гади бер хатын булып, бер оя балалар табып, шуларны үстереп, ир хатыны исемен йөртеп яшисе калган.

Хәзер бар юанычым — эш: хастаханә, авырулар, моң-зар, хәерчелек, бетмәс-төкәнмәс проблемалар. Ярый инде эш көне ыгы-зыгыда үтә. Ә кичен мин берүзем, дуадак каз кебек ялгыз.

— Беркемең дә юкмыни?

— Апам бар, тормышта, әлбәттә, ире, балалары. Без әни белән яши идек, былтыр җирләдек, хаста иде. Әнине карамадым түгел, карадым, миңа рәнҗеп китмәде. Хәзер менә ялгыз башым. Ялгызлык интектерә...

— Тукта әле, Айсылу, күңел төшенкелегенә бирелмә, синә килешми бу. Син бит яшь әле...

— Каян яшь булыйм инде, Газиз абый, утыз өч бит миңа.

— И-и, җаным, Бальзак яше ул утыз өч. Иң ялкынлы чагың. Үзең чибәр — гүзәлләрнең гүзәле, үзең акыллы. Юкка гына борчыласың. Барысын да яңабаштан башларга сиңа һич соң түгел.

— Яңабаштан башларга ышанычлы юлдаш, өметле кеше кирәк, Газиз абый. Аны хәзер кайдан табасың? Бөтен дөнья сәрхуш белән тулган, аек ирне көндез чыра яндырып та таба алмыйсың. Кайгы-шатлыкларны уртаклашырга, сереңне сөйләргә, эчеңне бушатырга да ышанычлы кеше кирәк бит. Менә без, Газиз абый, сезнең белән... Гафу итегез, минем сезгә «син» дип эндәшәсем килә...

— Эндәш әйдә, мин каршы түгел.

— Рәхмәт якын иткәнең өчен! Менә без синең белән һич уйламаганда очраштык, таныштык, фикер сөрешебездә, тормышка карашыбызда уртаклык таптык. Син мине игътибар белән тыңлыйсың, мин сине. Бер-беребезне аңлыйбыз. Шулаймы, Газиз абый?

— Әлбәттә!

— Иң мөһиме: мин, Газиз абый, синдә сер сыйдырырдай кеше таптым. Минем күптән болай ачылып сөйләшкәнем юк иде. Һәркемне җәлеп итә торган, сөйкемле, әйбәт кеше син. Ләкин шуны да беләм: тагын берничә көн аралашырбыз да аерылышырбыз. Син мине белмәссең, мин сине. Икебез ике якка китәрбез дә шуның белән вәссәлам!..

Газиз бу сүзләргә каршы ни дип әйтергә дә белмәде. Һәркемнең үз хәсрәте, үз кайгысы. Шул ук вакытта, «синдә сер сыйдырырдай кеше таптым» дип, бу ханым нәрсәгәдер өмет тә итә кебек. Аның кемгә дә булса сыенасы килүе күренеп тора. Бу да табигый. Бер-берәңә сыенып яшәгәндә генә җаныңа тынычлык, ялгызлыктан качу җаен табарга мөмкин. Газиз үзе сыенмас идемени Айсылуга? Чын мәгънәсендә сылу, сөйкемле, бик чая, теле белән җаныңны эретә, күңеле дә саф булырга охшаган...

Тик аны нәрсәгә булса да өметләндерү бик үк дөрес булмас иде. Газизнең хәле шундый: бүген бар ул, иртәгә юк...

Айсылу Газизне уйларыннан бүлдерде:

— Газиз абый, менә син тормышның ачысын да, төчесен дә күп татыган кеше. Мәхәббәттә дә тәҗрибәң бардыр. Әйт әле: чын мәхәббәт нинди булырга тиеш? Зөфәр абыйга булган җавапсыз хисләремнән башка чын мәхәббәтнең нәрсә икәнен дә белми яшим бит мин.

— Мәхәббәтнең, Айсылу, чыны яки ялганы, яхшысы яки яманы, тегендие яки мондые юк. Чын мәхәббәт дип әйтү, минемчә, үзе үк дөрес түгел. Мәхәббәт бер ул. Бар мәхәббәт — ихлас хис, утлы-ялкынлы тойгы. Инде, ике гашыйк арасында мәхәббәт нинди булырга тиеш дип сорасаң, уртаклык, аңлашу, гармония булырга тиеш — минем моңа иманым камил. Ике сөйгән яр арасында гыйшык уты сүнмәсен, көйрәп торсын. Кышын өйдә җылы булсын өчен, мичкә ягалар бит. Мәхәббәт тә сүрелмәсен, сүынмасын өчен шундый «мич» янып, көйрәп торырга тиеш. Чәчәкләр — яз белән, мәхәббәт — наз белән. Шунсыз тормышның мәгънәсенә, ике арадагы тигезлеккә, татулыкка өмет юк.

— Ә синең үзеңнең беренче мәхәббәтең ничек булды? Сөйлә әле, Газиз абый?! — диде Айсылу ялынган, үтенгән тавыш белән һәм астан гына елмаеп куйды.

— Хәйләкәр син, кызый, — диде Газиз, эчкерсез елмаеп. Аннан җитди кыяфәт белән сөйләп китте: — Кызганычка каршы, мин үзем дә сиңа шулай булырга тиеш дигән фараздан чыгып кына җавап бирәм. Син хыялланган, күңелеңдә йөрткән чын мәхәббәтне мин үзем дә күрмәдем бугай. Беренче тапкыр сөю хисе белән янганда, мин әле бик яшь идем. Төзүчеләр техник училищесында укый идек ул чакта. Төзелешкә өйрәнергә практикага йөри башладык. Шунда кранда эшләүче бер чибәр кызга күзем төште бит. Күпереп торган, ике калын толымга үреп салган кара чәч, зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләр, алсуланып торган чия иреннәр... Төн йокыларым качты. Ярый әле ул да минем хисләремне кабул итте. Очраша башладык. Сөйгәнем миңа фоторәсемен дә бүләк итте. Сәрмәдиянең — исеме шулай иде аның — үзеннән башка үткән сәгатьләрдә шул рәсемне туксан мәртәбә алып карыйм, йоклаганда да мендәр

астына куеп ятам. Күп тә үтмәде, кызым өйләнешү мәсьәләсендә сүз кузгатты. Соң, мин әйтәм, миңа унсигез генә бит әле, быел армиягә дә алып китүләре бар. «Ул чагында мин синең армиядән кайтканыңны көтеп тора алмыйм, кияүгә чыгам», — ди. Мин курка калдым: сөйгәнемнән коры калам бит...

Беләсеңме, яшь чактагы сөю-яратулар бала-чага уены кебек. Әле төптән уйларга өйрәнмәгәнсең, тормыш кануннары белән санашу кирәклеге турында белмисең, тәҗрибәң юк, аягыңа сыер басмаган, гел үз фикереңне генә дөрес дип санныйсың, үз сүзеңне генә сөйлисең, синеңчә барысы да дөрес дип уйлыйсың һәм, әлбәттә инде, бик нык ялгышасың.

Миңа да ул вакытта яхшылап уйлыйсы калган. «Синең кайтканыңны көтеп торалмыйм...» Юкса сиңа карата хисләренең булмавын, яратуының юклыгын ачыктан-ачык әйтеп тора кеше. Торалмыйсың икән, дүрт ягың кыйбла, дип кенә әйтәсе бит. Сине яратып, синең өчен өзелеп торган кыз сиңа бөтенләй икенче төрле сайрар иде: «Ничә ел хезмәт итсәң дә көтәрмен. Син минем өчен бердәнбер. Синсез миңа авыр булыр, ләкин түзәрмен...» Кая ул? «Кайтканыңны көтеп торалмыйм...» Шулар турында уйланырга баш җитмәгәнме, әллә сөю хисе белән томанага әйләнгәнменме?

Хәтеремдә, беркөнне олы абый шалтырата. Аңа инде егерме биш яшь, армиядән дә күптән кайткан, үзе җан-фәрманга буровойда эшли, авылдагы әнигә, туганнарга булыша, анда өй салалар, абый бер үк вакытта читтән торып университетта да укый башлаган. Аның өйләнергә әле уенда да, бәлки, вакыты да юк. Ә мин, җүләр, өйләнергә йөрим. «Башыңа тай типтеме әллә?» — ди абый. Тыңларга кирәк бит югыйсә. Юк, тыңламадым. Өйләнештек. Берничә айдан мине, чыннан да, армиягә алып киттеләр.

Никадәр тинтәк булуымны мин соңыннан гына аңладым. Әлбәттә, өйләнешү фәкать минем ярату аркасында гына булды. Сәрмәдия өчен иң мөһиме мәхәббәт тә, ярату да түгел, ә үз вакытында иргә чыгып калу, чөнки яше бара — аңа ул вакытта егерме ике яшь иде инде. Ләкин ул да ялгышкан, ул бит моннан бернәрсә дә отмады. Мин ничек кенә матур гаилә кору турында хыяллансам да, тату тора алмадык, чөнки аңлашу юк иде.

Кем гаепле? Яшьлек, тәҗрибәсезлек, җавапсызлык... Мин беркайчан да үземне гаепсез дип санамадым. Гаепле, әлбәттә...

— Әллә аерылыштыгыз?

— Юк, аерылышмадык. Минем хәрби хезмәттән кайтуыма, ул миңа карата шактый суынган иде. Бәлки, аның башка кешесе булгандыр, гәрчә ул вакытта андый уй минем башыма да килмәде. Мин аны элеккечә ярата идем. Ләкин тора-бара миндә дә хис бетте. Сөю, ярату берьяклы гына булмый икән шул. Ул үз эченә бикләнде һәм аз-азлап салгалый башлады. Мин үз дөньям, үз тормышым белән яшәргә мәҗбүр булдым. Укып югары белем алдым, яңа эшкә күчтем. Архитектура — иҗат эше бит ул, кызыклы, мавыктыргыч эш. Иҗат белән янганда, гаиләдә аңлашу булмаса да яшәргә була. Мин әллә нинди борынгы төзелеш стильләрен камилләштереп, матур-матур йортларның проектларын сызып, хыялланып бетә идем эштә дә, өйдә дә. Тик теге елларда минем сызымнар буенча нинди дә булса бина яки йорт төзү генә мөмкин булмады. Зәвыксыз чор иде бит ул. Гел соры солдат казармаларына, колхоз фермаларына охшаган килбәтсез торак йортлар, шыксыз администрация биналары төзелде ул елларда. Мин ясаган проектлардан сөяк-санак кына кала иде, чөнки «экономная экономика» чоры иде ул. Ә менә хәзер иҗат кешесенә хөрлек килде. Тормыш яңа юлдан бара. Малкуарлар, эшкуарлар, кәсәбәчеләр пәйда булды. Барысы да икешәр-өчәр катлы мунчалары, бассейннары, спортзаллары белән йорт җиткерә. Мин моңа уңай карыйм. Мөмкинлекләре бар икән, төзесеннәр. Безнең ише хыялый архитекторларга да эш муеннан, фантазияң генә эшләсен. Мин унлап проект эшләп бирдем инде, һаман киләләр. Проектларым үзләренә ошый, күрәсең, шуңа киләләрдер. Мин аларга йорт проекты сызам, үзем турында шәһәрдә истәлек калыр. «Бу матур йорт кем проекты белән төзелгән?» — дип сораганда, «Газиз Солтанов проекты белән төзелгән», — дисеннәр. Бу дөньяда беркем дә мәңгелек түгел. Минем исә... Без Чернобыльдә җидәү идек. Дүртебез юк инде, өчәү генә калдык. Чиратта кайсыбыз — беркем дә белми. Кызганыч, әлбәттә, дөньякүләм шедевр төзеп калдырып булмады, гәрчә хыяллансам да. Шулай да истәлек булып мин сызган проект буенча төзелгән йортларым кала икән — шуңа да бик риза. Зур эштә җаның чыкса, даның калыр, диләр бит... Син тагын бу картлач мактана дип уйлый күрмә. Мактанудан үтте. Соңгы елларда эшемнән канәгать мин, шуны гына әйтәсе идем.

— Газиз абый, җаным...

Айсылуның Газизгә әллә нәрсәләр әйтәсе килгән иде, тик ул артык дулкынланудан бер сүз дә әйтә алмады. Аның бу минутларда йөрәге дөп-дөп тибә, күңеле ярсулы, ә коңгырт күзләре мөлдерәмә яшь белән тулган. Ул шул яшьле күзләре белән Газизнең күзләренә карады, аннары кысып кочаклап алды һәм алар беравык шулай икәүдән-икәү өнсез-тынсыз басып тордылар.

Инде караңгыланып килә. «Соң инде, сезгә кайтырга вакыт» дигәндәй, сукмак буенда яшь усак яфраклары шыбырдашалар иде...

* * *

Газизнең Чернобыльгә китү вакыйгаларыАйсылуга сөйләгәнчә генә түгел иде. Гел генә дөп-дөрес итеп сөйләргә дә мөмкин түгел шул. Нәрсәгә үз җаныңны үзең әрнетеп артык сүз куертырга? Булган-беткән, өстенә мүк үскән.

Ай-һай, беткән микән? Алай булгач, нигә соң, торып-торып бер амин дигәндәй, һаман искә төшә, һаман аның җанын бимазалый, тынгылык бирми андагы хәлләр?

...Әле яшьлегендә, техник училищеда укыган елларында ук аның бер иптәше бар иде. Орчыктан аз гына калку гәүдәле, эченә сәнәк белән төртсәң дә каны чыкмас ябык, керпе сырты кебек тырпайган ак-сыл чәчле, торна күзле бу Тансык исемле малай белән бер партада утырып укыдылар. Исеменә җисеме — училище малайлары аңа Торна Күз дигән кушамат та тактылар, чөнки төркемдәшләре Тансыкны һич кенә дә тансыкламады, дус күреп түгел, хәтта рәтле иптәшкә дә санамадылар. Һәркемгә яракла-шырга, тәлинкә тотарга күнеккән малайның абруе булмауга гаҗәпләнәсе дә юк иде. Шуңа да Тансыкка йомшак бәгырьле, киң күңелле, беркатлы Газизгә сыенудан башка юл калмады. Шулай, артык дус бул-масалар да, бергә әвәрә килделәр. Укуны тәмамлаганнан соң, Газиз Торна Күзнең кай тарафларга китеп югалуын да искәрми калды. Бар иде — юк булды. Әгәр юлда кабат очрамаса, Газиз аның дөньяда бар-лыгын да белмәгән булыр иде. Еллар агымсу кебек акты да акты. Инде шактый тормыш сикәлтәләрен үтеп, дүртенче дистәсен тутырып барган бер чорда, Газиз урамда хәрби киемле подполковник погонлы, ике ятып бер төшенә кермәгән яшьлек иптәше Тансыкны танып алды. Белсә икән бу күрешүнең үке-нечкә буласын!

Читек чаклы малайдан юан корсаклы, кыска муенлы, төп кебек бер әфисәр чыккан лабаса. Менә бит гомерләр! Торна Күз генә димә, бу вафасыз дөньяда вакытны дөрес файдаланып, хәрби юлны, мун-дирны сайлаган, карьера ясаган. Төрле җирләрдә җилсез-яңгырсыз хезмәт юлын үтеп, ниһаять, туган төбәгенә кайтып төшкән. Һәм кем булып диген әле — каланың хәрби комиссары, олы түрә булып. Тә-линкә тотып үсү ярап куйган үзенә. Ул гына да түгел, училищеда укыган беренче айларында ике авыз да урысча белмәгән Тансык ана телен бөтенләй «оныткан» булып чыкты.

Ике иптәшнең озак еллардан соң очрашып сөйләшүе якынча менә шундый рәвештә барды.

— Тансык, Тансык, бу син түгелме соң? — дип гаҗәпләнеп сорады Газиз.

Торна Күз, Газизне танымаганга, татарчаны аңламаганга салышып:

— Говорите по-русски! — диде.

Газиз:

— Соң, Сарачев бит инде син... — диде, аптырап.

Торна Күз:

— Да, я — Сарычев.

Газиз:

— Тансык...

Торна Күз:

— Нет, Анатолий Иванович.

Газиз:

— Тукта әле, Тансык. Соң син мине танымыйсыңмыни? Мин бит Газиз, Газиз Солтанов. Без синең белән бер партада утырып укыдык техник училищеда, хәтерлисеңме?

Торна Күз:

— Да, вроде припоминаю...

Газиз:

— Да-а, парень, үз-гәр-гән-сең! Сарычев... Анатолий Иванович... Нәрсә, документларыңда да шу-лаймы?

Торна Күз:

— Угадал.

Газиз:

— Алай булгач, хатының да марҗадыр инде?

Торна Күз:

— А что тут удивительного?

Газиз:

— Бик күп удивительного, малай. Артыгы белән удивительно әле бу...

Торна Күз:

— Такова жизнь... Только ты на меня не обижайся. Давай поговорим: как ты, где работаешь, кем стал?..

Сөйләштеләр, әлбәттә. Газиз тәмам онытылып беткән яшьлек иптәше белән сагынганнан түгел, ә гыйбрәт өчен сөйләште.

Менә сиңа Тансык, менә сиңа Торна Күз! Марҗага өйләнеп, теленнән, милләтеннән ваз кичеп, де-неннән язып, иманын сатып, үзе дә тулысы белән сатылып беткән бит. Этлеккә башы җиткән үзенең — Сарачев фамилиясен Сарычевка алмаштырган. Тегеләй татар фамилиясе булып калыр иде, ә болай

урысныкына әйләнгән — сарыч! Елак карчыганы урыслар «сарыч» диләр. Елак булса да, карчыга бит әле ул, тавык яки чебеш кенә түгел. Фамилиясен алмаштырганда, берьюлы исемен, атасының исемен дә үзгәрткән. Имам улы Тансыктан Анатолий Ивановичка әйләнгән. Марҗасы «Тансыккаем!» димәс бит инде. Әйттерерсең син алардан...

Ах, кая бара соң бу дөньялар? Без үзебез кая барабыз? Мондый галәмәт, мондый аяныч хәл бер Тансык белән генә булса икән! Әнә бит Газизнең үзенең якын туганнары да... Туганнан туганы Гариф Саранскийдан мукшы марҗасына өйләнеп, тормышының астын өскә китерде. Гаиләдә ике милләт кешесе арасында уртак тел табып буламыни? Вакыт-вакыт үз милләтең кешесе белән дә аңлашу җиңел түгел бит әле ул. Ике милләт, ике тел, ике дин, ике төрле гореф-гадәт, йолалар. Аларны бер итеп яшәве, айһай, авыр. Әлбәттә, Гариф белән хатыны да уртак тел, аңлашу таба алмадылар, аерылыштылар. Улы Тимур да, кызы Венера да татарча ике сүз дә өйрәнә алмадылар — мукшы аналары татар телендә сөйләшергә рөхсәт итмәде ул сабыйларга. Балалары балигъ булып паспорт алгач та, «милләте» дигән графага аналары «русский», «русская» дип яздырды. Менә бит нинди хикмәтләр бар бу дөньяда: татар белән мукшы марҗасыннан туган ике нарасый урыс кавемен арттырсыннар инде! Тимур Гариф улы Сәгыйтов — урыс, Венера Гариф кызы Сәгыйтова — ул да урыс марҗасы...

Газизнең башка туганнары да шулай йә урыс, йә чуаш, йә белорус белән буталып беттеләр. Аларның да киләчәге юк хәзер, алар да сатылган, алар да үз халкы тамырыннан читләшә, ераклаша барачак...

Тансык-Анатолий Иванович та әнә шул юлны сайлаган. Горур Ак Барс нәселеннән бөтен кыйтгаларга таралган мәшһүр төрки-татар халкының сатлык улы, кирәксә-кирәкмәсә дә, койрык болгап торган нәселсез эт хөкеменә калган. Аның да балалары урыс булырлар. Бүген Толя, Толик, Анатолий Иванович булуга карамастан, Валентина-марҗасы аңа гел үзенең кем булуын искәртеп, мыскыллап «татарин» дип кенә тора. Үзе тапкан балаларга «татарин» димәс бит инде...

Дус-ишкә гомер бакый мохтаҗ Тансык-Анатолий Иванович Газизгә тагын чытырдап ябышты. Балта остасы гына булып калган булса, абруен төшереп ябышмас та иде. Архитектор бит! Андый иптәш белән өстәл артында утырырга да оят түгел. Алар кабат очраша башладылар, хәтта гаилә бәйрәмнәренә, зәмзәм суы эчүле башка мәҗлесләргә дә йөрештеләр, гәрчә бу очрашудан Газиз үзе һичбер рухи канәгатьләнү тапмаса да. Гаиләсендә татулык, аңлашу булмаганга, тормышына ямь кертергә тырышудан гына аралашырга мәҗбүр иде ул үз телен әкренләп «исенә төшерә» башлаган Торна Күз белән.

Әшнәлекнең яңарып, үрелеп барган көннәрендә кинәт кенә килеп чыккан Чернобыль һәлакәте ике танышның язмышлары уртасына төбе черегән агач кебек дөпелдәп ауды. Хәрби комиссарга шушы көннәрдә авариягә утыз кеше җыеп җибәрү бурычы йөкләнгән иде. Сарычев үзенең коллегалары белән, тиресеннән чыгардай булып, халык җыя башлады. Берәм-берәм запастагыларны чакыртып үгетләделәр, тик «атом» дигән сүз күбесен шиккә салды. Берсе дә тиктомалга чыгып китәргә ашыгып тормый иде. Билгеләнгән көнгә утыз кеше түгел, унны да җыя алмадылар. Күрсәтмәнең өзелү куркынычы туды. Өстән исә гел кымтырыклап тордылар: «Чего тянешь? В отставку хочешь?..» Тансыкның төн йокылары качты...

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, нәкъ шул көннәрдә уйламаганда-көтмәгәндә Газиз белән Торна Күз урамда очраштылар.

— Әйдә әле, миңа кереп чыгыйк, — диде Тансык, бик җитди төстә. Бүлмәгә керделәр. Тансык шкафтан бер шешә аракы, рюмкалар алды. Очрашу хөрмәтенә берәрне күтәреп куйдылар. Шуннан соң гына хуҗа: — Пропадаю, малай. Все валится, спаси, — диде һәм хәлен сөйләп бирде. Аннары, нәрсәнедер исенә төшергән кебек: — Архитектор кирәк, диделәр. Какое-то важное сооружение төзергә. Выручи! Әгәр барсаң, мин сиңа, близкому другу, военную пенсию выхлопочу: «За выполнение особого задания перед Родиной». Бездә андый права бар, — дип алдашты. — Шуның өстенә син анда заработаешь на всю жизнь, — дип өстәде һәм, акча санаган итеп, баш һәм имән бармакларын ышкыштыргалап күрсәтте.

Тансыкның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде Газиз. «Якын дустым» дигән кеше алдашмас бит инде? Акчасы да, пенсиясе дә — алары әле суга сәнәк белән язылган. Ә менә архитектор кирәк булуы... Нindiдер мөһим корылма, ди бит. Бәлки, ул чынлап та шулайдыр?..

Гомере буена хәләл көче белән маңгай тирен түгеп тормыш иткән, намуслы яшәгән, гадел, балалар кебек беркатлы, эчкерсез Газиз ялган яшь койган Торна Күзнең хәйләсенә әнә шулай килеп эләкте. Чыкты шобага — төштем тобага...

Торна Күзнең ялганчы, икейөзле кеше булуын Чернобыльгә барып төшкәч тә аңлады Газиз. Кереп ашымны ашый, чыгып башымны ашый, диюләре хак икән. Мөһим архитектура корылмасы төзүме соң анда? Гади эшче, балта остасы, йөк ташучы, бетон салучы, кол кебек башын иеп эшләүче кирәк анда. «Бери больше, кидай дальше» ди урыс бу очракта.

* * *

Фаҗиганең никадәр катлаулы, куркыныч булуы турында Газиз юлда ук белде. Бөгелмә вокзалында поезд көтеп утырганда, алар янына хәрби киемле, капитан погонлы төп кебек таза, киң җилкәле, караtуткыл бер кеше килде. Бер төркем төрле милләт кешеләренең күмәкләшеп: «Чернобыль, Чернобыль», — дип сөйләшүләрен ишетеп торганга килгән икән ул алар янына. Танышып киттеләр. Исеме — Василий, фамилиясе — Емельянов. Шонталы районының Баландай авылында туып үскән чуаш егете икән. Эчке эшләр министрлыгы челтәрендә хезмәт итә. Фаҗига алдыннан гына ул Киевка квалификация күтәрү курсларына укырга җибәрелгән булган. Укулары башланганга ун гына көн үткән, төнге сәгать икедә аларны тревога белән күтәргәннәр. Егерме минут кына элек Чернобыль атом электростанциясендә әллә инде авария, әллә диверсия булуы турында хәбәр иткәннәр. «Шушы минуттан сез Украина ССР Эчке эшләр министрлыгы карамагына күчәсез», — дигәннәр.

Күпмедер вакыт әзерләнергә кушалар. Ләкин ничек әзерләнергә? Беркем белми. Тулай торак ишеге каршына бер-бер артлы дистәгә якын олы автобус килеп туктый. Шуларга төялеп, ике йөз иллеләп илнең төрле почмакларыннан квалификация күтәрү курсларына җыелган халык, ничек әлкте шулай әзерләнеп, юлга чыга. Төркем хәтта махсус химик саклану әйберләре белән дә тәэмин ителми.

Алар Чернобыль шәһәренә килеп җитәләр, шәһәрдән унсигез чакрымдагы атом электр станциясенә якынлашалар, тик аларны якын җибәрмиләр, туктаталар. Бу вакытта гаять зур тырышлык һәм югалтулар хисабына янгын сүндерелгән була. Кая барырга, ни эшләргә? Озата килүче җитәкчеләр авария штабын эзләп китәләр, ә курстагылар, автобуслардан чыгып, күз күремендәге хәлгә аптырап, хәйран калып торалар. Алда гаять зур атом электр станциясе. Ләкин ул инде янган-көйгән, бер блогы җимерелеп, каралып беткән, аннан хәзер дә төтен чыгып тора, унлаган югары вольтлы электр линиясенең терәк баганалары аркылы-торкылы авып төшкән. Тирә-юньдә тәртипсезлек, чуалчыклык. Атом электр станциясе өстендә уннарча хәрби вертолетлар оча, аларның гөрселдәп чыккан каты тавышыннан һава гына түгел, җир дә селкенә, колаклар тона. Һәр җирдә кызыл, сары, яшел һәм башка төстәге түгәрәкләр эленеп тора.

Бу түгәрәкләрнең нәрсә икәнлегенә төшенә алмаган егетләрнең икенче көнне үк үзләренә дә шулар белән мәш килергә туры килде. Аларны ашыгыч рәвештә Полесье дигән бер авыл мәктәбенә урнаштыралар да иртән-иртүк, җимерек блок янына китереп, эш кушалар. Ерактан вертолетларга эленеп куйган төрле төстәге матур-матур түгәрәкләр булып күренгән нәрсәләр гап-гади хәрби техника парашютлары икән. Кешеләр ике көн буе иртәдән кичкә кадәр шул парашютларга ком, чуерташ, доломит калдык-постыклары, кургаш, аккургаш коелмалары салып, вертолетларга тагалар, ә тегеләр аларны дүртенче блок җимереге өстенә парашюты-ние белән илтеп ташлыйлар. Җәһәннәм тишегенә йөкнең кайсы туры килә, кайсы — юк. Иң төп бурыч — тирә-юньгә берөзлексез радиация ташкыны атып яткан реактор коесын томалау. Тик син теләгәнчә генә эшләп буламыни соң? Моның өстенә вертолетлар белән ташланган кургаш һәм аккургаш коелмалары, реактор эчендә эреп, кабат агулы болыт булып тышка чыга, һавага күтәрелә һәм өстәмә мәшәкать тудыра.

Ниһаять, дозиметрия хезмәткәрләре дә килеп төшәләр. Моңарчы җимерек станция тирәсендә мәш килгән халык атом радиациясенең ни дәрәҗәдә булуын да белми.

Аннары Василий Емельянов һәм тагын җиде-сигез кеше авария булган беренче төндә үк ярты сәгать эчендә халкы эвакуацияләнгән энергиячеләр шәһәре Припятьне сакларга җибәрелә. Чөнки, чүлдәге борынгы шәһәрләр кебек, буп-буш калган шәһәр урамнарында мародерлар күренә башлый. Бу — Белоруссия авылларыннан тизйөрешле мотоциклларда килгән, өйләреннән фәкать өс киемнәре белән генә чыгарып җибәрелгән халыкның байлыгына кул сузучы яшьләр булып чыга.

— Безгә, ул малайларны кисәтеп тә тормый, атарга күрсәтмә бирелде, — ди Емельянов. — Ләкин без алай эшли алмадык. Әле бит ялгышу да мөмкин иде, чөнки төнлә өй хуҗалары үзләре дә кием-салым, ятак әйберләре, онытылып калган документларын алырга кайткаладылар. Шулай да «мотоциклчылар» кайбер фатирларны, кибетләрне, аптекаларны таларга өлгергәннәр иде.

Ул көннәрдә ташландык кала урамнарында коточкыч күренеш күзәтелә. Өйдән чыгып китү уңаенда халык суыткычта, кухняда булган бар азык-төлекне балконнардан, тәрәзәләрдән урамга ташлый, чөнки ул инде радиацияләнгән, ашарга ярамый. Аларны яртылаш йоны коелган, параличланган, арт саннарын көчкә өстерәп йөргән этләр, мәчеләр ашап йөри. Бигрәк тә буш урамнарда авыру мәчеләрнең кычкыруы йөрәк өзгеч яңгырый. Парк, сквер, аллеялардагы элек ямь-яшел булып утырган агачлар, декоратив куаклар, чәчәк клумбалары саргаеп, корып төшкән, кибеп беткән. Урамнарда ташлап калдырылган автомашиналар, мотоцикллар, башка техникалар бихисап.

Ә бу вакытта хөкүмәт җитәкчеләре нәрсә эшләргә дә белми аптырап утыралар. Фаҗигадән соң бишенче тәүлек узгач кына СССР Президенты М.С.Горбачев үзәк телевидениедән чыгыш ясап, Чернобыльдә авария булуы турында хәбәр итә. Ләкин авариянең зыяны зур түгел, куркыныч юк, халык тыныч, аварияне бетерү өчен бөтен чаралар күрелә, дип ялганлый илнең иң олы түрәсе.

Әлбәттә инде, катастрофаның масштабы, аның дөньякүләм һәлакәт булуы, беренче этапта да дистәләрчә кешеләрнең ут, радиация эчендә һәлак булуы, шул исәптән берничә станция хезмәткәренең бе-

ренче шартлау вакытында ук җимерек астында кысылып калуы, аларның ярдәм сорап ялвару авазлары, ләкин аларны коткарырга мөмкин булмавы, кысылган килеш калулары турында әйтми ул.

Тугызынчы көнне генә курска килгән хезмәткәрләр алдында атом электр станциясе тирәли утыз чакрым ераклыкта урнашкан авыл халкын башка җиргә күчерү бурычы куела. Башта аларны шушы ераклыктан бүтән җиргә чыгаралар, ниндидер бер авылга күчерәләр.

— Эвакуацияләнәчәк халыкка дөресен сөйләмәскә әйтелде безгә, — дип сөйли Василий Емельянов. — «Сезне без ике-өч көнгә генә китеп торырга сорыйбыз, озакламый яңадан өйләрегезгә кайтырсыз. Берничә көнлек ризык алыгыз да...»

Юк инде, халык моңа ышанмый. Ул Припять шәһәре халкы белән булган хәлне яхшы белә. Белсә дә, башка чара калмый, буйсына. «Сез хет алдашмагыз инде, дөресен сөйләгез. Без дә бит бик үк надан түгел, аңларга тырышыр идек», — диләр аларга. Ләкин буйсынмаганнар да була. Икеме, өчме гаилә урыннан кузгалырга катгый каршы килә, авылда кала: «Монда тудык, монда яшәдек, монда үләрбез», — диләр алар.

— Андагы хәлне сөйләп тә бетерерлек түгел. Үзебезнең дә кычкырып елап җибәрәсе килгән чаклар еш булды. Халыкның йорт хайваннары урамда калды. Дуңгызларын тоталмыйлар, алары чиный-чиный кире якка чаба. Умарта кортлары, ояларын күтәреп алып китәрдәй булып гөжләп, урыннарында калдылар. Кайсылары хәтта этләрен баудан ычкындырырга да онытып киткән иде. Телеграф баганаларында, агач башларында йөзләгән ләкләк, авылдагы шау-шу, ыгы-зыгының сәбәбен белергә тырышкан сыман, тирә-якка аптырашлы караш ташлап, башларын әле бер, әле икенче якка боргалап, моңаеп утыра бирәләр. Коточкыч!..

Поезд килмәгән булса, Емельяновның тагын әллә нәрсәләр сөйләргә исәбе бар иде. Саубуллашканда, ул гадәттәге уртак аралашу теле — урысчадан татарчага күчеп:

— Эх, тутар юлдашларым, зинахар, сак пулыгыс, үсекесне саклакыс! Анта кәлләр пит начар, — дип калды. Ул үзе дә Казанга, госпитальгә тикшеренергә юл тота иде, чөнки шул сигез-тугыз көндә дә радиация алып кайткан икән.

Соңыннан Газиз катастрофаны, андагы аяныч хәлләрне Емельянов сөйләгәннәрдән бик күпкә артык күрде. Күреп кенә дә калмады, үз җилкәсендә, үз тәнендә, үз язмышында татыды. Аның Айсылуга сөйләгән хикәяте исә үзе күргән, үзе татыганнарның чеметеме генә иде әле.

* * *

Чернобыльдән тәмам арып-талып, йончып, авыруга сабышып кайтты Газиз. Бер атна беркая да чыкмыйча ял итте, ваннада җылы суда чупырдады. Шулай тынычланып өйдә ял итеп, суда юыну белән ул һәлакәттә алган авыр тәэсирләрдән, нурланыштан, башка проблемалардан ансат кына арынырмын, бәлки, дип уйлады. Элек сәламәтлеге нык иде аның. Яшьтән физик эш эшләп, спорт белән шөгыльләнеп, буыннарын ныгытып үсте, аннары да көрәк, балта кебек эш коралларын еш тотарга туры килде аңа. «Авырыйм» дип хастаханәгә барганын хәтерләми ул. Бәлки, аның нык организмы бирешмәс?..

Өйдә берничә көн ял иткәч, Газиздә бераз урамга чыгып керү теләге туды. Аның киенгәнен күреп, Сәрмәдия:

— Кая җыенасың? — дип сорады. Күп вакыт ул Газизгә битараф иде: чыгып китсә дә, кайтып керсә дә аңа барыбер. Бу юлы исә нигәдер кызыксынды хатыны. Әллә бер-бер сүзе бар идеме?

— Военкоматка, Тансык дус янына барып кайтыйм дигән идем, — диде Газиз, тыныч булырга тырышып.

— Тансык дус дисең инде. Җыен хәшәрәт белән дус булып йөрисең шунда...

— Каян белдең әле аның хәшәрәт икәнен? Әлегә кадәр син дә аны якын күрәдер идең шикелле?

— Синең күңелең булсын дип үз күргән булып кыланганмындыр. Кабахәт...

— Әйт, нәрсә булды?

— Син киткәч тә күчтәнәчләр тотып килеп керде. Әйдә, икәүдән-икәү калып сыйланыйк әле бер, ди. Бу турыда мин күптән хыялланам инде, ди. Кыскасы, миңа күзе төшкән икән, минем кочакта кунып китәргә иде исәбе. Капкалый дигәч тә, бер азгын дип уйлаган, ахры, хәсис. Коньяк шешәсе белән башын тишеп чыгара яздым, качып котылды. Менә нинди ул синең дустың...

Газиз, салкын суга тыгып чыгарган бала кебек, өнсез калды. Кара инде бу Торна Күзне! Нинди әшәкелек, нинди оятсызлык! Әллә барып үз бүлмәсендә бәреп үтерергәме бу адәм актыгын? Һич югында, кикриген шиңдереп алырга...

Эчендә ут уйнады, кыбырсынды, тик бер сүз дә әйтә алмады. Уйлары чуалган иде аның бу минутта.

— Нәрсә катып калдың? Телеңне аркылы тешләдеңме әллә? Әллә сиңа барыберме? Минем урында бер азгын хатын булса, син нишләр идең? Ишетәсеңме?

— Ишетәм, — диде Газиз, ниһаять, һәм ишектән атылып чыгып китте...

Сарычевның кабул итү бүлмәсенә кызып барып керде ул. Сәркатип кыз аны күптән белә, шуңа күрә тоткарлап тормады. Күтәрелеп: «Ул үзендә», — диде. Ишекне ачып кергәндә, Торна Күз янында икеме-

өчме хезмәткәре утыра иде. Бүлмәдә Газизне күреп, Торна Күз аптырабрак киткән иде, ләкин үзен бик тиз кулга алды. Шунда ук нәрсәдер сизенеп:

— Мы заняты пока, — дип, Газизне туктатмакчы булды.

— Мин дә бик занят. Тем не менее из Чернобыля привез вам горячие приветы, — диде Газиз, хәйләле урысчалатып һәм, кыю-кыю басып, Торна Күз янына килде.

Хуҗа икеләнеп кенә торып басты һәм исәнләшү нияте белән кулын сузган иде, шул мизгелдә Газиз, яшен тизлеге белән кулын күтәреп, Торна Күзнең яңагына сугып җибәрде. Ул шулкадәр көчле чәпәде ки, тегенең күзеннән йолдызлар очты. Бу хәлне күреп торган хезмәткәрләре сикереп торып Газизгә ташланмакчылар иде, Газиз урысчалатып:

— Если не хотите великого скандала, не подходите, — диде, тешен кысып. — Этот подонок заслуживает большего...

Урысча әйтсәң, ярыйсы гына тупас, эт җаннарның зиһененә барып ирешерлек, тәэсирле килеп чыга бит ул: тегеләр шып булдылар.

Газиз, башын горур чөеп, кабинеттан чыгып китте. Башкача ул бу җирәнгеч адәм актыгы белән булган мөнәсәбәтләрне дә, бүгенге хәлне дә һичкайчан искә алмаска, җанны борчымаска, мәңгегә онытырга үз-үзенә сүз бирде. Әйе, биргән иде. Ләкин йөрәк ярасы тиз генә төзәләмени ул?..

* * *

Чернобыльдән кайтканнан соң, барлык дөнья мәшәкатьләрен онытып, Газизнең тынычлап яшәргә иде исәбе. Казанда тикшеренү үтеп, ике ел рәттән курортка дәваланырга барды: берсе соцстрах, икенчесе — үз хисабына. Алып кайткан акчасы шуның белән бетеп тә китте.

Аннан биреп җибәргән белешмә буенча ул егерме дүрт рентген нурланыш белән зарарланган иде. Егерме биш булса, аңа өченче группа инвалидлык бирергә тиешләр. Чынында исә аның утыздан да ким түгел, ә бәлки, кырык, хәтта илле дә булгандыр: Чернобыльдә дозиметрчылар бик нык алдаштылар. Алдашмасалар, аларны анда эшләтмәсләр иде шул. Каһәр төшкән Чернобыль җирендә Газиз үзенә күрә ачыш ясады: элек һәр адымда «Все — во имя человека, все — для блага человека» дип шапырынган совет җирендә бер изге гамәл дә, бер иман да юк икән бит. Барысы да күпертелгән ялган. Һәр җирдә — алдашу, һәр адымда — мәкер, икейөзлелек. Кеше тормышы, кеше язмышы ике тиенгә дә тормый бу башбаштак илдә. Бөтен дөнья җәмәгатьчелеге алдында СССР дигән «бөек» илнең йөзенә кызыллык китермәс өчен, атом-төш һәлакәтен гади авария дип күрсәтергә маташтылар, аның эзләрен яшерер өчен гадел һәм гадел булмаган бөтен чараларны кулландылар, меңнәрчә кешене нурланыш утына илтеп тыктылар...

Һәлакәтне бетерүдә катнашкан һәр кеше инвалид хәзер, чөнки ул анда кырык-илле, аннан да күбрәк рентген нурланыш-радиация алып кайтты. Тик аларның берсенә дә: «Син чынында бик күп, фәлән чаклы рентген нурланыш алдың бит», — дип әйтмәячәкләр, диагнозын да расламаячаклар. Чөнки син ялганчылар, алдакчылар дөньясында яшисең. Эх, йөзен ачасы иде бу алдашулы, эчкерле, икейөзле дөньяның...

Газиз кат-кат уйлый болар турында. Тынычлап яшәүме соң монда?..

Бер кичне ул эштән кайтып, телевизор каршына утырды. Тапшыру Казаннан, Чулман буенда төзелеп яткан атом электр станциясенең расланмаган проект буенча, сейсмик яктан тыныч булмаган тектоник ярылу урынында төзелүе, бу гамәлгә киң җәмәгатьчелекнең, халыкның ризасызлык белдерүе турында иде. Димәк, тагын ялган, тагын мәкер булган. Газизнең янә ачуы чыкты. Ничек түзеп тормак кирәк? Ул яхшы белә: каладамы, саладамы иң зарарсыз корылманы төзер өчен дә синең проектыңның расланган булуын кат-кат тикшереп җаныңа тияләр. Ә биредә дөньякүләм зурлыктагы атом электр станциясе төзиләр, аның инде яртысы төзелеп бетеп бара, аңа исәпсез-хисапсыз халык акчасы тотылган, шул тирәдәге авыл халкы инде булачак энергиячеләр шәһәренә күчерелгән, ә иң гади таләп, ягъни проектны раслау турында уйлап та карамыйлар. Нинди башбаштаклык! Бу бит түзеп тормаслык хәл! Юк, моны болай калдырырга ярамый! Татар дөньясы уртасында шундый куркыныч корылманың төзелеп ятуы турында Газиз элек ишеткән булса да, ул аңа ничектер битараф иде. Бүген исә, Чернобыль мәхшәренең авырлыгын үз җилкәсендә татыган, кайгы-хәсрәтен үз күзләре белән күреп кайткан кеше буларак, әлеге хәбәрне йөрәгенә якын алды. Һәлакәттән гарантиясе, ышанычы булмаган мондый төзелеш Чернобыль җиренә дә кирәк булмаган, Татарстан яки Башкортстан җиренә дә, шулай ук башка җиргә дә кирәк түгел! Чернобыльдә чакта ул үзләренең язмышын хәл иткән мескен иптәшләре белән сүз кузгаткан саен, безнең илдә атом-төш электр станциясе төзү җинаятькә тиң, ә аны төзетүчеләр исә җинаятьчеләр, дип сөйләшә иделәр. Чулман буенда беркемнән дә рөхсәт сорамыйча, бигрәк тә шунда яшәүче халыкның фикере белән санлашмыйча, аның ризалыгын алмыйча АЭС төзи башлау — икеләтә җинаять.

Газизнең төн йокылары качты, шул турыда уйланып, кайгырып чыкты. Аның максаты хәзер ачык — атом электр станциясен төзүгә каршы хәрәкәтчеләр сафына басарга. Ләкин эшне кайдан, кемнән

башларга? Үзенең теләге турында кемгә барып мөрәҗәгать итәргә? Шул турыда уйланып утырганда, кинәт аның исенә хезмәттәше Әнис Җамалиев килеп төште. Милли җанлы, бик зәвыклы, укымышлы бу архитектор Татар иҗтимагый үзәгенең калада оештырылган бүлеге эшендә катнашып йөри. Ул бу төзелеш хакында белми калмас...

Иртән конторага барып керүгә, Газиз озын коридор буйлап Җамалиевне эзләп китте. Ул эшли торган бүлмә коридорның урта бер җирендә. Эш сәгате башланырга шактый вакыт булуга карамастан, Әнис ак күлмәк, чем-кара түбәтәйдән өстәл артында проект өстендә эшли. Уңган, эшлекле кеше шул. Милли хәрәкәт эшендә катнаша башлау белән, ул үзенең татарлыгын таныту, үз халкының мәнфәгатен кайгыртып йөрүче кеше икәнлеген искәртү йөзеннән бик килешле кара түбәтәй киеп йөри башлады. Газиз вакыт-вакыт үзе дә, үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, шундый кара түбәтәй киеп йөрергә кызыга иде.

Әниснең йөзе якты, елмаюы ягымлы. Сөйләшүе дә төпле, мәгънәле.

Газизнең гозерен белгәч, шатланып:

— Менә бусы әйбәт, Газиз, малай! Безгә синең кебек көрәшче егетләр кирәк. Нишләп соң әле синең турыда онытып җибәрдек? Иртәгә безнең оешмада җыелыш була. Кил, тыңлап утыр, эшнең асылына төшенерсең. Аннан соң карарбыз, — диде.

Иҗтимагый үзәк бүлеге әгъзаларының җыелышы театр бинасының кече залында үтте. Анда утызлап кеше җыелган иде. Күбесе олы яшьтә, яшьләр исә санаулы гына — Газиз шуңа игътибар итте. Бүлек җитәкчесе, инде алтынчы дистәсен тутырып килгән озын, какча гәүдәле, пөхтә киенгән, гомере балаларга тарих фәне укытып узган Хәйдәр ага Шәһитов җыелышта сүзне үзе башлады:

— Чернобыль фаҗигасенә быел дүрт ел тула. Без бу көннәрдә йөз елларга кадәр газаплы үлем китерүче, кеше үзе уйлап тапкан дәһшәт көче турында уйлыйбыз, — диде ул, турыдан-туры җитди темага күчеп.

Тәҗрибәле укытучы үгезнең мөгезеннән эләктерергә кирәклеген яхшы белә.

— Үзенә үзе кул күтәрергә аны нәрсә мәҗбүр иткән соң? Кем этәрә аны моңа, нинди көчләр? Хәлбуки бар андый көчләр, халык фикере белән бөтенләй исәпләшергә теләмәгән туң акыллы дәүләт идарәсе тармаклары. Без, хокуклары чикле автономияле җөмһүрияттә яшәүчеләр, аларның көчләп тагылган мәҗбүриятен һәр адымда үз тирәбездә татып яшибез. Әгәр инде социаль гаделлек хакында каршы әйтергә теләп авыз ачабыз икән, чыбыркы гына шартлап куя, аның саен безгә, язмыш хөкеме белән икенче сортлы саналган халыкка, башны түбәнрәк ияргә генә кала...

Хәйдәр ага кыска гына вакытка тынып торды, күзлеген төзәтте, тыңлап торучылар өстеннән күзләрен йөртеп чыкты. Һәм сүзен дәвам итте:

— Бүген татар милләте өстенә җиде башлы аждаһа булып килгән шундый мәҗбүриятнең берсе — Татарстанның гүзәл бер почмагында, зур кала, салалары халык белән кайнап торган урында, горурлыгыбыз Иделгә коя торган, бай тарихыбыз кебек мул сулы Чулман елгасы буенда баш калкытып килә торган атом электр станциясе... Бу үтә хәвефле вакыйганы тагын бер мәртәбә уртага салып сөйләшик әле, җәмәгать! Моның сәбәбе дә бар. Мәгълүм булганча, СССР хөкүмәте күптән түгел Фәннәр академиясе каршындагы Сейсмология буенча эксперт комиссиясе нәтиҗәсенә таянып, Татарстан АЭСын тиз арада сафка кертелергә тиешле корылма сыйфатында финанслау турында карар кабул итте. Ул гына да түгел, республика хөкүмәтенең үтенеч-мөрәҗәгате дә эзсез калды. Әлеге көндә Казанга килеп ирешкән бердәнбер рәсми документта — СССР Министрлар Советының Татарстанда атом электр станциясе төзүгә каршы җәмәгатьчелек хатына биргән җавабында — бу корылманы төзү дәвам иттереләчәк диелгән. Республикабызның Югары Советы АЭСның производство максатындагы объектларын төзүне туктату турында карар кабул итте. Ләкин, ни аяныч, әлегә бу документның да юридик көче юк. Бу уңайдан СССР Министрлар Советының җаваплы әһелләре, академик В.Н.Страхов җитәкчелегендәге дәүләт комиссиясе төзеп, аны янә калкан рәвешендә файдаланырга ниятләделәр. Әлеге комиссия эшендә үзебезнең кеше, нефть берләшмәсе баш геологы, минералогия фәннәре докторы Мөслим Хәлиуллов та катнашты. Бүген ул безнең арада. Комиссиянең эше нинди шартларда һәм юнәлештә барган? Мөслим әфәнде безгә шул турыда сөйләп бирергә җыена. Рәхим итегез...

Мөслим Хәлиуллов та яшь кеше түгел, чәчләренә күптән чал кергән, Шәһитов кебек үк озын гәүдәле, ләкин затлы аксыл-яшькелт костюмнан. Тик бер як җилкәсе бераз төшеп, аның гәүдә рәвешен чак кына бозып тора. Ул да сүзгә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел икән.

— Утыз өч галимнән торган эксперт комиссиясенең эше гаять киеренке шартларда барды, — диде ул, авыр сулап. — Бу эштә республикадан без барлыгы дүрт галим катнаштык. Чулман буенда АЭС төзүнең нинди зур хата булачагын һәм афәткә китерәчәген никадәр генә дәлилләргә тырышсак та, хакимият мәнфәгатен якларга тиешле галимнәр үзләренең безгә көчләп тагарга тырышкан экспертиза актына бернинди төзәтмә кертергә юл куймадылар. Ә дәлилләребез бәхәссез, кисәтүебез төпле иде. Ике көн буена уникешәр сәгать барган «якалашуларда» минем үземә генә дә егерме тапкыр сүз алып сөйләргә туры килде. Иң төп дәлилләребез итеп, АЭСның тектоник ярылу урынында төзелүен, анда махсус тикшеренүләр уздырылмавын, аның сейсмология, геология, гидрология шартлары тиешле дәрәҗәдә өйрә-

нелмәвен күрсәтеп карадык. Ләкин боларның берсе дә Мәскәү тарафдарларына тәэсир итмәде. Бер галим-сейсмолог исә, Татарстан җире Әрмәнстаннан ике мең чакрым ераклыкта урнашкан, анда бернинди дә җир тетрәүләр булырга мөмкин түгел, дигән акылсыз фикер белән чыкты. Станция җирле органнар белән бернинди килешүсез, расланмаган, үзен начар яктан күрсәткән иске типтагы проект нигезендә төзелә, аңа инде ярты миллиард сум акча тотылган. Менә ни өчен тарткалаша атом ведомствосы. Дөресен генә әйткәндә, галимнәрчә бәхәс килеп чыкмады. Безнең аргументларны читкә кактылар. Ахыр чиктә без, комиссия тәкъдим иткән актка кул куюдан баш тартып, аерым фикеребезне язмача бәян итәргә мәҗбүр булдык. Менә шул...

— Мөслим әфәнде, гомумән, сез атом электр станцияләрен төзүгә, атом энергиясен хуҗалыкта куллануга ничек карыйсыз? — дип эндәште аңа залдагыларның берсе.

— Безнең илдә бүген атом энергиясен халык хуҗалыгында куллануга ихтыяҗ юк дип саныйм. Суелгалар, шарлавыклар энергиясен куллану безнең ил өчен күпкә кулайрак, чөнки ил буенча андый елгаларның, андый шарлавыкларның исәбе-хисабы юк. Иң мөһиме — аларны көнкүрештә эксплуатацияләгәндә беркемгә дә куркыныч янамый. Моннан тыш ягулык белән эшли торган станцияләр өчен дә чимал җитәрлек — күмер, мазут... Ә атом электр станцияләре... Әнә Чернобыль катастрофасы үзен күрсәтте инде. Минемчә, бездә атом электр станциясе кебек артык җаваплы корылмаларны төзүгә хәзерлекле көчләр, ведомстволар әлегә юк. Ә катастрофага килгәндә... Бу бик куркыныч. Шуны гына әйтим: атом электр станциясе реакторының аерылгысыз компоненты — плутонийның таркалуы миллиард еллар буена дәвам итә. Күз алдына китерә аласызмы? Шуңа күрә катастрофаның ахыры нәрсә белән бетәсен әйтүе кыен.

Хәлиуллов, сүзен тәмамлап, урынына барып утырды.

Аннары Газизнең хезмәттәше Әнис Җамалиев торып басты. Үзе тыныч булса да, сүзләре тәэсирле иде аның:

— Без коточкыч афәт алдында. Өстәвенә безнең күршебездә генә, үпкәбезгә терәп диярлек, Башкортстан АЭСы төзелеп ята. Кыскасы, бер карыш җирдә ике станция. Шундый ук станцияне төзү икенче бер чигебездә — Удмурт республикасында планлаштырыла. Күрше Ульян өлкәсендә инде андый станция эшли башлады. Чернобыльдәге кебек һәлакәт була калса, бер безнең республика гына түгел, ә бөтен Идел-Каспий бассейнындагы халыклар, гомумән, тереклек юкка чыгачак...

Җыелышка килгән кешеләрнең тынычлыгы бетте. Аларның әле берсе, әле икенчесе торып ярсыйярсый сүзен әйтте, тәкъдимен кертте:

— Төзелешкә каршы халыктан имза җыярга!

— Кисәтү забастовкасы ясарга!

— Һәр җирдә митинглар үткәрергә!

— Халыкны җыеп, төзелеш барган җиргә барырга, анда да митинг оештырырга!..

Татар иҗтимагый үзәгенең бүлек җитәкчесе җыелышка нәтиҗә ясады:

— Фикеребез, теләгебез, позициябез бер безнең. Рәхмәт! Мондый шартларда халыкка каршы юнәлтелгән ведомство мәнфәгатьләре белән без башкача килешеп яши алмыйбыз. Тереклек хакына, килер буыннарның имин язмышы хакына без җитди адым ясарга тиешбез. Әгәр безнең таләпләргә колак салмыйлар икән, беренче чиратта массакүләм митинглар үткәрү мәгъкуль булыр. Кем бу гамәлне яклап тавыш бирә?

Барысы да дәррәү кул күтәрделәр. Газиз исә кулын беренчеләрдән булып күтәргәндер, чөнки җыелыш, аның эчтәлеге, актуальлеге, анда каралган мәсьәләнең кирәкле дәрәҗәдә мөһим булуы аны бик дулкынландырды, дәртләндерде. Менә бит ул ничек: халык йоклап ятмый, халык үз язмышына, киләчәгенә битараф түгел икән, халык көрәш юлына чыгып баскан, ул ярсый...

Әнис, таралышыр алдыннан, Газиз янына килеп басты:

— Ничек?

— Шәп! — диде Газиз, дулкынланып.

— Митингта чыгыш ясый алырсыңмы? Син Чернобыль һәлакәтенең тере шаһиты. Синең чыгыш анда иң көчле яңгыраш табачак...

Бу тәкъдимнән Газиз аптырап, хәтта каушап калды:

— Ә ничек?

— Тегендә күргән-белгәннәреңне бәйнә-бәйнә сөйлә дә сөйлә. Синнән башка нәрсә таләп ителми.

— Риза, — диде Газиз, гәрчә башта икеләнеп торса да.

Газиз митингка көн-төн әзерләнде. Исәбе — Чернобыльдә күргән-белгәннәрен озак итеп, тәфсилләп сөйләп бирергә иде. Ләкин митингта һәр чыгыш ясаган кешегә өч-дүрт кенә минут бирәләр икән. Бу турыда ул каланың үзәк мәйданына килгәч белде. Җирле радиодан, телевидениедән белдерү ясагангадыр, үзәк мәйданга халык күп җыелган иде. Һәр җирдә шигарләр, транспарантлар, плакатлар, карикатуралар: «Икенче Чернобыльгә урын юк!», «Атом корбаннары булырга теләмибез!», «Башбаштаклыкка юл куймабыз!», «Атом — ул һәлакәт!», «Долой АЭС!»...

Мәйданда халык дулкыны әле бер, әле икенче якка чайкала. Менә Мәдәният сараеның колонналар буена куелган микрофон янына кабат Хәйдәр Шәһитов күтәрелде, тамак кырды һәм, оста ораторларга хас алым белән, кабат үгезнең мөгезеннән эләктерде:

— Чернобыль һәлакәте материянең иң бәләкәй кисәкчегә булган атомның бөтен табигатькә чикләнмәгән зур афәтләр китерә алуын күрсәтте, — диде ул, ачык тавыш белән. Мәйдан шаулап, гүләп куйды. — Бу АЭСның бер генә блогында булган авария нәтиҗәсендә таралган радиоактив изотоплар миллионлаган кешеләрнең сәламәтлегенә зур зыян китерделәр һәм бүген дә китерәләр. Әлеге һәлакәт белән көрәшкә дистәләрчә миллиард сум акча тотылды инде. Ә безнең Чулман буенда төзелә торган атом электр станциясендә сигез блок планлаштырылган. Ишетәсезме, сигез!..

Мәйдан кабат җанланып алды, ах-уһ килде.

Митингны алып баручы сөйләргә теләгәннәргә бер-бер артлы сүз бирде. Һәр сөйләүченең чыгышы ачынулы, дәлилле, кайнар иде.

— Түбән Кама ГЭСы суының биеклеге алтмыш метр белән, ә Чулман буенда төзелә торган АЭС илле метр биеклек белән билгеләнә, — диде милли үзәк нәшатлысы*, табиб Ильяс Ямаев. — Димәк, АЭС ун метрга түбән урнашкан. Әгәр буа, әйтик, җир тетрәүдән яисә башка бер очракта ычкына калса, АЭС тулысы белән су астында калачак.

Халык тагын гүләп куйды.

Шулчак микрофон янына урта яшьләрдәге, тәбәнәк буйлы, пеләш башлы, күзлекле бер кеше йөгереп килде һәм микрофонга:

— Җәмәгать, җәмәгать, миңа да ике генә сүз әйтергә рөхсәт итегез, — дип рөхсәт сорады. Җыелган халык арасыннан «Сөйлә, әйдә!», «Бирегез рөхсәт, сөйләсен!» дигән сүзләр яңгырады. Митингны алып барган Шәһитов та, әлеге кеше белән бер-ике авыз сүз алышкач, каршы килмәде.

— Мин үзем, җәмәгать, физика укытучысы һәм, мәгълүмдер, атом-төш энергетикасы турында хәбәрдар. Мин атом электр станцияләрен төзүгә каршы түгел, аларны төзергә кирәк дип саныйм, чөнки дөньяда хәзер алар гына иң арзан электр энергиясен бирә. Экологик яктан да алар иң зарарсызлар...

Физика укытучысының шушы сүзләре дөрләп янып торган учакка бензин сипкән кебек булды — халык шаулаша, кычкырыша башлады:

— Әй, син, физик, нәрсә лыгырдыйсың? Дөньяга күзлегеңне салып кара!

— Чернобыль афәте турында ишеткәнең юкмы әллә синең, пеләш баш?

— Кайтып хатыныңны үрәт, үрәтник!..

— Туктагыз әле, җәмәгать! Мин дә Чулман Аланында АЭС төзесеннәр димим бит. Аның урынын ялгыш сайлаганнар — бусы хак. Ләкин АЭСсыз да булмый, чөнки газ да, нефть тә бик кыйммәтле байлык бит ул, аларның запасы да хәзер күп түгел...

Укытучы тагын нәрсәләрдер әйтергә теләгән иде, тик кызганнан-кыза барган халык аңа сөйләргә ирек бирмәде:

— Кит әле, кит, майламаган арба көпчәге кебек сайрама...

— Син ылучшы кайтып дәресеңә әзерлән, балаларың надан калырлар...

— Җитте, абзый, саескан бүткәсен санап утырма...

— Өйдән торып кибәк сукма...

Мондый мыскыллаулардан соң физика укытучысына микрофон яныннан ничек тә тизрәк шылудан башка чара калмады.

Чират Газизгә җитте.

— Мин — Чернобыльдә, ягъни авариягә дучар ителгән дүртенче блокка саркофаг төзүчеләрнең берсе, — диде ул, тирән дулкынланып.

Митингка җыелган меңләгән кеше шып булды. Меңләгән кеше алдында олы һәлакәтне бетерүдә катнашкан тере шаһит, гап-гади бер кеше басып тора. Ул нәрсә сөйләр? Шуңа да әнә мәйдандагы халык тып-тын калды.

Гомерендә тәүге тапкыр шулкадәр күп кеше алдында чыгыш ясарга микрофон алдына килеп баскан Газиз башта каушады, тирләп-пешеп чыкты, кирәкле сүзләрен тапмый азапланды. Аннары әкренләп тынычлана төште, ул үз-үзен бик тиз кулга алды, чөнки халык аны тын да алмый йотлыгып тыңлый иде. Газиз үзе күргәннәрне дә, Емельянов сөйләгәннәрне дә исенә төшерде: торба астында кысылып калган станция хезмәткәрләре, арт санын көчкә сөйрәгән мескен этләрнең улавы, мәчеләрнең кычкыруы, йоннары коелган әтәч-тавыклар, чәчәктә күмелеп утырган җирендә көеп каткан алмагачлар, караҗимеш, котырып гүләгән умарта кортлары, алдакчы дозиметрчылар, ватылып төшкән вертолет калдыклары... Барысы турында да ашыкмый, исенә төшерә-төшерә сөйләде ул халыкка. Һәм аны беркем, хәтта җыелышны алып баручы да бүлдермәде, тыныч кына тыңлап торды.

— Чернобыль һәлакәте китергән зыянның иге-чиге юк. Без реактор коесын томаладык дип кайттык. Ләкин тынычланырга бернинди дә гарантия юк. Реакторда калган атом кыза, аның температурасы һаман күтәрелә һәм көннәрдән бер көнне өстенә капланган меңнәрчә тонна авырлыктагы «капкач»ны атып бәреп, аның кабат җир өстенә чыгуы мөмкин. Ул чагында һәлакәтнең нинди масштаб алуы турын-

да әйтүе дә кыен. Бәлки, мин ялгыша торганмындыр, ләкин ихтыярымда булса, беркайда да, беркайчан да һәм бер кешегә дә атом электр станциясе төзергә рөхсәт бирмәс идем, чөнки атом — гаять дәрәҗәдә куркыныч, аның ахыры ничек бетәсен дә белүе мөмкин булмаган хәтәр матдә ул. Атом — һәлакәт, үлем, аңа каршы бернинди чара булмаган төрледән-төрле чир, гүзәл табигатебезнең бик озакка зарарлануы, суларга саф һава, эчәргә чиста су җитмәү, тереклекнең тәмам үлүе, иксез-чиксез бәхетсезлек чыганагы ул. Шәхсән мин үзем, Чулман буендагы корылманы төзетмәс өчен, башымны куярга да әзер...

Митингка җыелган халык беренче тапкыр шаулатып кул чапты, кемнәрдер: «Дөрес әйттең, афәрин!», «Халык рөхсәтеннән башка АЭС төзетүчеләрне судка бирергә!» — дигән репликалар ташлады.

Газиз үзе исә җиңел сулап куйды.

Митингта катнашучыларның барчасы атом-төш электр станциясен төзүгә каршы резолюция кабул итте.

— Әйбәт сөйләдең, афәрин! Иң яхшы, иң тәэсирле чыгыш синеке булды, — диде соңыннан Җамалиев Газизгә. Салпы якка салам кыстырудан әйтмәде ул аны, чөнки Әнис ике төрле сөйләүчеләрдән түгел, ихлас кеше.

Шәһитов үзе дә, Газизгә якын килеп:

— Рәхмәт, энем, бик дәлилле, тыңлаучыларның күңел түренә барып җитәрлек итеп сөйләдең, — диде һәм кулын кысты. Аннары өстәп куйды: — Бәлки, тагын сөйләрсең? Митинглар әле башлана гына, чөнки хәл киеренке, үзең дә күреп торасың. Күсәк күтәрми булмый. Күлдән шулпа эчкән синдәй егетләрнең безнең эштә катнашуы зарур. Уйла әле!

— Нәрсәсен уйлап торырга? Әгәр файда китерә алсам, мин риза, — диде Газиз.

— Менә бусына тагын да зур рәхмәт! Алай булса, көтәбез...

Әнә шул сәгатьтән башлап Газиз өчен яңа, чын-чынлап шау-шулы, давыллы, ярсулы тормыш башланды...

* * *

«Тимерне кызуында сугып кал» дигән гыйбарәдән чыгып, Иҗтимагый үзәк бүлеге тагын берничә җыелыш һәм митинг үткәрергә карар кылды. Атом ведомствосының, Мәскәү түрәләренең тиресе калын. Аларга әйттең ни дә әйтмәдең ни. Салган хатларга да, сугылган телеграммаларга да, республика җитәкчелеге җибәргән үтенеч-мөрәҗәгатькә дә исләре китмәде. Үз сүзләре генә дөрес, үз эшләре генә эш. Төбәк халкының тектоник ярылу урынында расланмаган проект буенча АЭС төзелеп ятуына ризасызлыгын ишеткәч, алар төзелешне туктату түгел, киресенчә, аны тизләтү турында кайгырта башладылар. Тизрәк төзеп бетерергә дә: «Юк инде, җәмәгать, эш бетте, соңга калдыгыз, станция сафка басты, хәзер аны җимерә алмыйсыз, телисезме-теләмисезме, ул сезнең җирдә эшләп ятачак, ә сезгә тавышыгызны басарга, авызыгызны йомарга кала», — дияргә бугай исәпләре. Төзелешнең бөтен Идел буе бассейны халыкларына, аларның киләчәгенә һәлакәт китерәчәк афәт чыганагы булуы аларның туң башларына һич барып җитми. Мондый очракта нишләргә? Шайтаннан иман көтеп яту файдасыз, башланган көрәшне дәвам итәргә, күсәкне кулдан төшермәскә кирәк.

Каланың икенче олы мәйданында чираттагы митинг уздырылды. Биредә дә халык күп иде һәм мондагы кешеләр дә митингның башыннан ахырына чаклы умарта күче кебек гөжләп торды. Иҗтимагый үзәк бүлеге АЭСны төзүдә каршылык күрсәтү буенча комитет оештырып җибәрергә өлгерде. Аның рәисе итеп Иҗтимагый үзәк активисты, шәһәр депутаты Гариф Кәрамов сайланган иде. Уртача гәүдәле, әмма елан кебек хәрәкәтчән, көчле тавышлы кырык биш яшьләрдәге бу кешедә милли хислелектән тыш тирән акыл, көчле эрудиция дә бар. Сүзгә дә бик оста. Шуңа да бу юлы сүзне ул башлады:

— Бүген Уфада ике автономияле республика — Башкортстан һәм Татарстан вәкилләренең Иделне саклау комитеты әгъзалары катнашында фәнни киңәшмәсе ачылды һәм шуның белән бергә ике республика җирлегендә ике атом гыйфритенең баш күтәрүенә каршы протест маршы башланды, — диде ул, гөрләп чыккан тавыш белән. Бу хәбәр барып ирешкәч, җыелган халык шаулап куйды. Кәрамов дәвам итте: — Чөнки эш үтә тирәнгә кереп китте һәм бу борчулы шартларда бары тик кискен чаралар гына уңай нәтиҗәгә китерә алырлар...

Бу вакытта Газиз дә Шәһитов белән Җамалиев янында басып тора иде. Аңа бүген дә сүз бирәчәкләр.

— Кәрамовтан соң башта син сөйләрсең. Аннары тагын бер чернобыльче сөйләячәк, — диде Әнис.

— Кем ул?

— Керәшен егете, Питыр Никитин. Ул да һәлакәтнең үзәгендә булган. Әнә ул, танышың түгелме?

Әнис алардан ике-өч адымда гына бер читтә басып торган, үзе буйчан, үзе ябык, нечкә генә кара мыек җибәргән утыз яшьләр тирәсендәге кешегә ымлады. Ул сөйләүчене бик дикъкать белән тыңлап тора иде.

— Юк, белгән кешем түгел, — диде Газиз.

Бераздан аның үзенә дә сүз бирделәр. Бу юлы Газиз халыкка өрәккә әйләнгән таҗиклар язмышын бәян итте. Җиңгәсе татар хатыны булган Әсрар хакында, аның һәм бер төркем башка таҗикларның дүртенче блок өстенә ни кыяфәттә менеп китүләре һәм ни төстә, ягъни кап-кара чәчләре, сакал-мыеклары, кашлары һәм керфекләре коелган килеш шәп-шәрә төшүләре, аларны «ашыгыч ярдәм» машинасына төяп киткән чактагы кызганыч хәл, таҗикларның башкача хастаханәдән кире кайта алмаулары, барысының да вафат булуы турында сөйләде ул...

Аннан микрофон каршына керәшен егете килеп басты. Ул да шулчаклы күп халык алдында чыгып сөйләргә өйрәнмәгән иде бугай, тиз генә сөйләп китә алмады. Аннары, ниһаять:

— Мин Чернобыльдә бетон болгаткычта эшләдем, — диде ул, салмак тавыш белән. Аңа шунда ук: «Начар ишетелә!» — дип кычкырдылар. — Ул «миксер» дип атала, — диде Никитин, тавышын күтәрә төшеп. — Ә безне «смертниклар» диләр иде. Бетон әзерләү заводы АЭСтан унбиш чакрымда, әзер бетон измәсен самосваллардан бетон болгаткычка күчереп төяү пункты сигез чакрымда. Шул бетон болгаткычта без дүртенче блокның стенасы янына килеп эстакадага менәбез һәм бетон измәсен бушатабыз. Шулай һәр көн ике ай буена сигезәр сәгать эшләттеләр безне. Реакторны шул бетон һәм авыр металл катнашмасы белән томалап эшен бетергәч кенә кайтып киттек. Ләкин реактор скважинасын томалап куюэле бөтен бәладән котылдым дигән сүз түгел. Без ясаган капкачның күккә очып, катастрофаның тагын да кабатлануы һәм ул вакытта аның тагын да катлаулырак, фаҗигалерәк булуы мөмкин. Ә андый куркыныч бар, ул Чернобыль катастрофасын үз күзе белән күргән, аны зарарсызландыруда катнашкан һәр кешенең баш миен бораулый. Шулай булгач, кирәкме мондый куркыныч корылма безнең төбәккә, безнең халыкка? Юк һәм юк!

Никитинның чыгышы һичкем уйламаганча төпле, тәэсирле, көчле килеп чыкты. Һәм, иң мөһиме, Никитин да, үткән чыгышында Газиз дә реактор коесының капкачын алып ташлау ихтималын беравыздан әйткән кебек халык зиһененә җиткерделәр.

Митинг дәвам итте. Газиз исә Никитин янына килде. Алар таныштылар.

— Миңа әйткәннәр иде синең турыда, — диде Никитин. — Без шәһәр һәм районда барлык чернобыльчеләрне барлап, үзебезнең ирекле җәмгыятьне оештырырга уйлап йөрибез. Барыбызга да тупланып, социаль яклау дәгъваларга вакыт, чөнки без оятсыз рәвештә алданган, һәм матди, һәм физик, һәм рухи яктан таланган халык. Хөкүмәт тә, җирле хакимият тә, хәрби комитетлар да, безне Чернобыльгә чакырган вакытта, алтын таулар вәгъдә иттеләр. Безгә фатир да, автомашина да, акча да, төрле ташламалар да булырга тиеш иде. Ә кайда алар? Вәгъдәне бирергә, алдап-йолдап йөртергә оста безнең түрәләр. «Родина в опасности, выручайте, ребята, она вас не забудет...» Кая ул! Кем ярты, кем аннан да күбрәк сәламәтлеген калдырып кайтты, ә безгә кәҗә тоягы күрсәттеләр. Мин хәзер дүрт ел квартира сорап йөрим һәм дүрт ел вәгъдәдән башка нәрсәне күргәнем юк...

Никитин үпкәле, ачулы иде. Һәм хаклы иде ул. Сөйләгәне дөрес, ташка баскан кебек хак.

— Оешуны тартырга-сузарга түгел, вакыт уза. Инде күпме егетләребез китте шул дүрт ел эчендә. Аларны да соңгы юлга «вәгъдәле» килеш кенә озаттык...

Газиз егетләрнең кая «китүләре» турында аңлады.

Алар кабат очрашырга, ирекле җәмгыять оештыру турында тагын бер кат сөйләшергә булдылар.

Иҗтимагый үзәк бүлеге, озын-озакка сузып тормыйча, атом электр станциясен төзүгә каршы халыктан имзалар җыюны башлап җибәрде. Шәһитов үзе дә, бүлек әгъзалары да, активистлар да халык арасына чыгып китте. Бу эштән Әнис Җамалиев та, Газиз Солтанов та читтә калмадылар.

Кыска гына вакыт эчендә шәһәр һәм район буенча АЭС төзүгә каршы меңнәрчә кешедән, ягъни унсигез томлык имза җыйдылар алар һәм, рәсми рәвештә, барлык таләпләргә туры китереп, СССР Президенты һәм Министрлар Советы Рәисе исеменә юлладылар.

Шул ук вакытта митинглар, җыелышлар, фәнни конференцияләр үткәрү дәвам итте. Иҗтимагый үзәк җитәкчесе Хәйдәр Шәһитов, аның иң якын көрәштәшләре Әнис Җамалиев, Гариф Кәрамов, Газиз Солтанов һәм башкалар ул көннәрдә җан-фәрманга чаптылар, гәрчә аларның да күңелләрендә вакыт-вакыт шик-шөбһә булса да.

* * *

Атом электр станциясе төзелешенә каршы иң көчле акция — төзелеш җирлегендә үткәрелгән митинг булгандыр. Төбәкнең барлык гаярь егетләре-кызлары, дистәләгән автобусларга төялеп, шул ук шигарләр, плакатлар, телекамералар, фотоаппаратлар белән Чулман буена барып төштеләр. Кызганычка каршы, чыгыш ясарга тиеш булса да, Газиз бара алмады. Алдагы көндә чирләп китте һәм тәүге тапкыр хастаханәгә кереп ятарга булды. Табиблар тикшереп караганнан соң, аның бавыры, бер бөере һәм үнәче шешкәнен, шулай ук ашказанында да шеш барлыкка килүен билгеләделәр. Йөрәк тибеше дә шәптән түгел, кан басымы да югары, сулышы да кысыла. Моның өстенә аякларын көзән җыера башлады. Боларның барысы да, әлбәттә, Чернобыльдә күпләп алган нурланыш нәтиҗәсе иде.

Җамалиев аның янына:

— Көчле акция үткәрдек, Газиз, малай, — дип канатланып килеп керде. — Төзелеш дирекциясе җитәкчеләре куркып качканнар иде, митингка чыкмадылар. Ләкин без үз вазифабызны йөз процентка үтәдек. Көчле-көчле чыгыш ясаучылар булды, шул ук вакытта төзелешнең үзендә катнашкан егетләр дә сөйләде. Төзүчеләр белән аралаштык, вазгыятьне аңлаттык. Алар үзләре дә хәлне аңлый, безнең фикерне, без үткәргән чараларны хуплыйлар. Митингны кассетага төшердек. Бергә-бергә карарбыз, тизрәк терелеп чык...

Ләкин Газиз тиз генә терелә алмады, үзендә бернинди үзгәреш юк иде. Беркөнне Әнис, күчтәнәчләр тотып, тагын аның янына килде. Авызы колагына җиткән, үзе һавалы:

— Җиңәбез бит, малай, җиңәбез!..

— Нәрсә булды? Әйт тизрәк!

— Республиканың Министрлар Советы АЭСта производство өчен билгеләнгән объектларны төзүне туктату турында карар кабул итте...

— Кит инде!.. Менә моңа рәхмәт!

Шатлыклары эчләренә сыймаган ике фикердәш ир-ат кочаклаштылар, аркаларыннан кагыштылар.

Газиз, тынычлана төшкәч:

— Ниһаять, республика хөкүмәте дә үз халкының таләбен ахыргача аңлады, аның хакын хакларга алынды. Димәк, боз кузгалды, — диде уйланып.

— Дөрес әйтәсең, боз кузгалды. Ләкин көрәшне туктатырга иртә әле. Гасырлар буе кыерсытылган, кимсетелгән, җәберләнгән татар җиренә тагын бер һәлакәт китерергә ниятләгәннәр иде. Тәмам бетерик, тамырын корытыйк бу татарның дигәннәрдер. Корытмый гына торыгыз әле, сволочьлар! Ул станцияне, ул һәлакәт чыганагын, бик алай хаҗәт икән, үз җирегездә төзегез! Ә без көрәшне туктатмабыз. Газиз Чулманыбыз буенда ул корылма төзелмәячәк, белеп торыгыз, господалар! — диде Әнис, ярсып, һәм кайсыдыр күренмәс көчләргә йодрык янады.

Алар шулай, шатлыкларын уртаклашып, шактый гына сөйләшеп утырдылар. Газиз, үзенең хастаханәдә вакытсыз ятуына борчылып:

— Чылбырга бәйләнгән эт кебек ятам. Чыгасы иде, сезнең арада буласы иде. Кайнар вакыт бит, — диде.

— Чир сорап килми, Газиз, малай. Терелеп бетмичә чыкма инде. Өлгерербез, АЭСны төзүне дә туктатырбыз, башкасына да өлгерербез. Алда гомер бар әле, — диде ул, Газизне тынычландырырга тырышып.

— Булсын иде дә бит, ләкин... Минем чир, Әнис, терелә торган чир түгел инде ул. Яшисе бик килә... Нурланыш, радиация үзенекен эшли башлады — мин моны шулай сизәм. Аның кая, нәрсәгә алып барганын да беләм. Ләкин киләчәк язмышым ничек кенә булмасын, мин сезнең белән бер сафта атлап, төбәгебездә гаять куркыныч корылма төзүгә каршы үткәрелгән чараларда катнашып йөрүемнән канәгать, бик канәгать, аны мин олы мәртәбәгә саныйм...

— Һәм дөрес эшлисең, Газиз. Мин бит үзем дә шуңа канатланып йөрим. Без бик зур эш эшлибез, — дип, Газизнең күңелен күтәрергә тырышты Әнис. — Фикереңне бүлдем бугай...

— Дөрес, азрак катнаштым, кызганычка каршы... Чир бит... Белмим, киләчәктә сезнең белән бергә була алырмынмы-юкмы, әмма көрәшеп йөрүебез бушка булмас сыман. Аның нәтиҗәсен күрәсе иде. Ул чагында үлсәм дә үкенмәс идем. Татар җиренә дә, башка җиргә дә атом кирәкмәс. Мин моны атомның нинди һәлакәтле әйбер икәнен үз күзләре белән күргән, үз тәнендә, үз язмышында татыган кеше буларак әйтәм. Кирәкмәс!

Берничә көннән Әнис тагын палата ишегендә күренде. Бу юлы үзе генә түгел, Питыр Никитинны да алып килгән иде ул. Никитин үз яңалыкларын хәбәр итте. Чернобыльчеләрнең иректе җәмгыятен төзегәннәр икән. Барлыгы ике йөз иллегә якын кеше җыелган.

— Бер зур булмаган кала һәм район буенча шулкадәр кеше... Ә ил буенча күпме була икән? — диде Әнис.

— Бик күп була торгандыр. Һәм гади генә кешеләр түгел бит алар. Шул исәптән Газиз дә, мин дә, — диде Никитин. — Һәрберебез, сәламәтлекләрен югалтып, олы проблемалар белән кайтты. Шулай булмаса, Газиз менә монда ятар идемени?

Бу сүзләрдән соң алар өчесе дә уйга калдылар. Тынлыкны кабат Никитин бозды, ул, Газизгә карап:

— Үзебезнең исәп-хисапны ачтык, чернобыльчеләр фондын оештырдык. Башкача мөмкин түгел. Безнең турыда партия дә, хөкүмәт тә кайгыртырга ашкынып тормый. Үз-үзебезне кайгыртырга тиешбез. Көчле предприятие, оешма җитәкчеләре белән очрашабыз, сөйләшәбез, ярдәм итүләрен үтенәбез. Безнең максат: иң башта һәр чернобыльчене ел саен курортларга дәваланырга җибәрү, — диде ул һәм кесәсенә тыгылды. — Менә безнең беренче путевканы сиңа алып килдек, — диде һәм аны Газизгә сузды.

Газиз дулкынланып китте.

— Ай, рәхмәт, Питыр! Уйламаган идем, булдыклы егет икәнсең, — диде ул һәм Никитинны кочаклап алды.

Тегесе, үз чиратында:

— Рәхмәтеңне миңа түгел, башта Әнискә җиткер. Ул кайгыртып йөрде, — диде.

— Эх, дуслар белән яшәү күңелле, — диде Газиз һәм берочтан Әнисне дә кочаклады. Күңеле тулды, тик үзен-үзе кулга алды, тыелып калды.

Әнә шушы юллама белән килеп төшкән иде Газиз әлеге курортка.

* * *

Белдерү тактасына «Бию кичәсе» дип язылуга карамастан, ул кичне шифаханәдә бию булмады. Музыка өчен җаваплы кеше авыру әнисе янына авылга кайтып киткән, берничә көнсез килеп җитмәс әле, диделәр. Биергә чыгарга ашкынып торган ял итүчеләр бүлмәдә телевизор карап утырырга мәҗбүр булдылар.

Габделфәтне авыл кешесе генә димәссең — курортка «Тефаль» чәйнеге алып килгән. Буш вакыт булдымы, су тутырып, төймәсенә баса. Ике минут та үтми, су гөбердәп кайнап та чыга. Һәр авыл кешесе кебек, Габделфәт тә чәйсез тора алмый. Чәйне каты итеп эчәргә ярата ул. Газиз үзе дә каты итеп ясаган чәйне ярата. Габделфәтнең савыт белән балы, кайнатмасы, башка тәм-томы өстәлдән өзелми. Әнә бүген дә өстәле тулы сый-нигъмәт, чәе дә тиз кайнап чыкты аның. Газизгә дә, үзенә дә чәй әзерләп йөри-йөри, кыюсыз гына:

— Әллә, дим, яшьтәш, әз генә «кунак булып» алабызмы бүген? — диде ул. — Инде күпме бергә яшибез, әле бер генә чәркә дә тотмадык шул хөрмәткә...

Гаҗәп бу дөнья: гомердә күрмәгән-белмәгән кеше белән очраштыра. Менә алар ничә көн бер бүлмәдә яшиләр. Бүлешәсе әйберләре юк, әлбәттә. Ләкин ике кеше арасында да төрле мөнәсәбәт урнашуы мөмкин. Габделфәт белән Газиз арасында үзенә бер дустанә, уйламаганча җылы, кайгыртучан мөнәсәбәт урнашты. Күбрәк авыру бүлмәдәше турында Габделфәт кайгырта һәм ул моны һич авырыксынмый, зур теләк белән, ниндидер бер тәм табып эшли. Бөтен шифаханәдә иң иртә торучыларның берсе — Габделфәттер. Юынып, ул иң элек шифалы су бүлмәсенә төшә һәм җаны кайсын тели, шул температурадагы суны авыз итә. Зәвык белән мәгарә итеп бизәлгән шифалы су бүлмәсендә төрле «чишмәләр» агып тора. Анда суның салкынчасы да, җылымсарагы да, бик җылысы һәм хәтта кайнары да бар. Аерым бокалда Газизгә дә үзе теләгән суны алып менә Габделфәт. Теләсә, Газизгә кайнар чәй дә әзерләп бирә — һич иренми. Яшьтәшенең хәле начараеп китсә, кизүдә утыручы шәфкать туташлары янына да үзе чаба. Беркөн әнә Газизне көзән җыерды. Габделфәтнең андый хәлне күргәне юк иде әле. Күршесе күм-күк булып катты, үзе тартыша, сызлана, дер-дер калтырый, каты итеп ыңгыраша. Габделфәт, атылып, икенче катка төште:

— Бүлмәдәшемнең хәле начар!

Тегеләрнең дә эшләре тыгыз.

— Үзе төшсен инде...

— Нинди «үзе төшсен», тизрәк, кызлар...

— Нәрсә соң аның?

— Чернобыль! Аңлыйсызмы? Чернобыль һәлакәтен кичергән авыру курортыгызда да бер генә...

Кызларга ике сөйләргә урын калмады. Минут та узмагандыр, алар Газиз янында мәш киләләр иде инде: көчле уколлар кададылар, дарулар эчерделәр, тәнен ышкыдылар, җылы компресс ясадылар, киңәшләр бирделәр.

Әнә шундый киң күңелле кеше Габделфәт. Йөзе нурлы, үзе мәрхәмәтле. Мондый игелекле җанны ничек якын күрмисең дә, ничек хөрмәт итмисең. Шулай булгач, аның тәкъдименә дә каршы килмәде Газиз, чөнки үзенең дә әрнегән җанын, кимсетелгән күңелен бераз күтәрәсе бар иде.

— Әйдә, Габделфәт, беткән баш бетсен инде, сал, булмаса, — диде, моңсу көлемсерәп. — Тик күп түгел, салам чаклы гына. Мин аның белән беркайчан да дус булмадым. Чернобыльгә бик күп ташыдылар аны. Санитар врачлар үзләре дә салдылар, башкаларны да үгетләп йөрделәр: «Радиациягә каршы бердәнбер чара — спирт, аракы. Күпме эчә алсагыз — шуның чаклы эчегез, әгәр вакытыннан алда гүр иясе буласыгыз килмәсә», — диделәр.

Рәсәй болай да сәрхуш, болай да эчкечелек баткаклыгыннан чыга алмый азаплана. Атом һәлакәте булган, атом бомбасын сынаган төбәктәге халыкны кыстый-кыстый аракы чөмертәләр. Бер яктан эчкечелеккә каршы көрәшеп маташкан булалар, ә икенче яктан үзләре кыстап эчертәләр. Менә нинди башка сыймый торган хәл. Тик, беләсеңме, Габделфәт, кайткач үземнең бер таныш врач бөтенләй икенче төрле сөйләде ул спирт, аракылар турында. «Әкият ул, — ди. — Алкоголь нерв системасын җимерә, ә кеше сәламәтлегенең үзәге — нерв системасы. Шулай булгач, радиациягә каршы спирт, аракы эчегез, дигән кеше ул чын-чынлап дошман сүзе сөйли. Бу бахырлар тизрәк аракы сөремендә бетсеннәр дип уйлагандыр. Мондый чакта иң сәламәт тормышта яшәүдән дә яхшысы юк! Минем, Чернобыльдән кайтканнан соң, кан басымы нык күтәрелә башлады, йөрәк тибеше дә рәтле түгел. Моның өстенә эчә торган булсам, әллә кайчан дөньядан киткән идем инде...

— Рәхмәт яхшы сүзеңә, Газиз. Минем үземнең дә артык исем китми бу нәрсәгә. Эч пошканнан гына. Менә чыгып киттем дә сагынам. Авылымны, гаиләмне, карчыгымны-бөрчегемне сагынам. Тукай әйтмешли, эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин... Ярый әле иптәш бар. Сине әйтәм...

— Минем иптәшлек инде... Ярты җан. Күркем бар да, бүркем юк...

— Юк, Газиз, син миңа тугры иптәш, яхшы иптәш. Эчең тулы хәсрәт, моң-зар синең. Мин бит үзем аю кебек, чирнең барлыгын да белмим. Рәисебез: «Бер дә ял итәргә барганың юк, җилләнеп кайт әле», — дип путевка биргәнгә генә чыгып киттем. Икмәк уңды быел, җан тыныч болай.

— Игенченең шатлыгы — икмәк инде. Уңган агроном булырга охшыйсың, Габделфәт. Җитди, төпле...

Габделфәт уңайсызланып куйды. Үзе, эше турында мактанып сөйли торган гадәте юк аның. Эш эш инде. Авыл җирендә аның беткәне дә, бетәсе дә юк, үлгәч тә өч көнлек кала әле ул. Ә менә Газизнең «төпле» дигән сүзе белән килешә. Эшен әвеш-түеш кенә түгел, уйлап, җиренә җиткереп башкара ул. Бу яктан аңарда немец төгәллекләре бардыр. Тик сүз бит бүген аның турында түгел.

— Әйдә әле, Газиз, синең турыда сөйләшик. Әйтсәм әйтим инде, сине минем янга кертмәгән булсалар, мин күптән кайтып киткән булыр идем. Монда миңа, урыс әйтмешли, ничу делать. Аллага шөкер, сәламәтлегемнән зарланмыйм. Син генә менә... Сине күрдем дә: «Тукта, Габделфәт, өеңә ашыкма әле, бәлки, кешегә кирәгең чыгар», — дидем.

— Чын күңелдән рәхмәт сиңа, Габделфәт! Әйдә, шуның өчен булсын!..

Күтәреп куйгач та, Габделфәт тагын урыныннан кузгалды, суыткычтан бер төргәк чыгарды. Аны сүтеп, өстәлгә бик затлы ризык — казылык кискәләп куйды.

— Онытып җибәргәнмен бит, карчыкның күчтәнәче. Әйдә, Газиз, авыз ит, ашап җибәр. Минем Сөмбеләм үзе ясый казылыкны.

Газизгә симез ат итеннән бик чамасын белеп сарымсак, кара борыч һәм башка тәмләткечләр кушып ясалган казылык бик ошады.

— Телеңне йотарлык бит бу, — дип мактап алды ул. — Карчыгың бик уңган, бик булган, ахры. Үзең дә «Сөмбеләм, карчыгым» дип кенә торасың.

— Һи-и, әйтәсең бармы, Газиз, малай. Минем Сөмбеләм мировой хатын ул! Дөрес, әзрәк тиле атын мактар, урта тиле үзен мактар, ә шыр тиле хатынын мактар, дигән әйтем дә бар. Ләкин мин Сөмбеләмне мактаудан курыкмыйм. Ул аңа лаек.

— Кайсы якныкы соң үзе?

— Бер авылда, бер урамда туып үстек без, бер сыйныфта, бер партада утырып белем алдык. Үземә карап үстергән кебек саклап үстердем мин аны. Унны тәмамлагач, читкә укырга китмәде, балалар бакчасында эшли башлады. Гомере буе балалар тәрбияләде ул — авылныкын да, үзебезнекеләрне дә. Киң күңелле, шәфкатьле, кайгыртучан. Шуңамы, бөтен авыл халкы үз итә, хөрмәтли аны.

Инде минем яратуны белсәң... Казанда авыл хуҗалыгы институтында укып йөргән елларда, бер-беребезне бик нык сагынышып бетә идек. Безнең мәхәббәт хатлары әле дә саклана. Китап язарлык материал бар анда.

Ак күбәләк күрдем, ак күбәләк,
Бәхеткәйләр булсын түгәрәк.
Гомер юлларыннан синең белән
Насыйп булсын үтү бергәләп...

Әнә шуңа охшаш шигырьләр, җырлар язып җибәрә иде хатка Сөмбеләм. Шөкер, гомер юлларыннан бергә үтү насыйп булды безгә. Инде егерме җиде ел... Өч балабыз үсте, хәзер исә оныкларыбыз үсеп килә. Аларның «бабай», «әби» дип кочакка килеп керүләре үзе бер зур бәхет ич...

Без бер-беребез өчен туган булганбыз. Беребезнең дә башкага күңеле төшеп йөргән чагы да булмады. Сөмбеләм дә: «Мин сине яратып йөри башлагач та, башка егет сәләмәләреннән кулымны да тоттырмадым, үземә сүз дә куштырмадым», — ди.

— Соклангыч, гыйбрәтле икән тормышыгыз. Бәхетле гомер насыйп булсын үзегезгә, Габделфәт, мең яшәгез!..

Алар шулай матур гына әңгәмә корып, гадәт буенча гына дуслык өчен «капкалап» утырганда, ишек шакыдылар. Айсылу икән. Газиз аптырап китте: ул бит аңа кайсы бүлмәдә торуы турында бер сүз дә әйтмәгән иде.

— И-и, Газиз абый, бүген дә парлап биеп булмады. Кая барып бәрелергә дә белмим. Сине дә югалттым, бүлмәгезне көчкә эзләп таптым. Гафу итегез инде, — диде ул, уңайсызланып.

— Әйдә, сеңлем, үт, утыр, бергә-бергә чәйләрбез. Газиз абыең белән безнең эшләр хутта, Аллага шөкер! Бик вакытында килеп кердең әле...

Габделфәт Айсылуны кыстый-кыстый өстәл янына утыртты, чәй ясап бирде.

— Рәхмәт, Габделфәт абый! Газиз абыйга да рәхмәтем чиксез, — дип, өстәл янына килеп утырды Айсылу. — Тик, зинһар, сагыз кебек ябыша, дип, минем турыда начар уйлый күрмәгез. Мин бит ялгыз

яшим, күңелем китек, кешеләр белән аралашуым да рәсми дип әйтимме инде... Биредән эчемне бушатып кайтып китәсем килә. Туйганчы бер сөйләшеп, серләшеп диюем.

— Андыйларны таба алсаң, — дип сүз кыстырды Габделфәт.

— Хикмәт тә шунда шул. Сер сыярдай кеше табуы җиңел түгел бу заманда. Бәхетемә, Габделфәт абый, андый кешене таптым мин. Ул әнә тыйнак елмаеп каршыңда утыра, — диде Айсылу һәм нәфис кулы белән Газизнең беләген тотып алды да, аңа таба авышып, сыенып торды.

— Белдеңме инде, Газиз, бер миңа гына түгел, башкаларга да кирәк икәнсең бит. Кирәк, димәк, яшисең әле. Бергә-бергә яшибез! Яңа бал өлгергәч тә, киләсе җәйгә кунакка чакырам үзегезне. Безнең Арча яклары матур, ямьле, җырлы-моңлы, шигырьле бит. Ни генә дисәң дә — Тукай яклары! Ә син эч чәеңне, сеңлем, сыйлан. Самавырыбыз шаулап, өстәлебез гөрләп тора. Әллә бераз шәраб та салып биримме? Анысы да бар бездә, — дип, урыныннан торып, суыткычка юнәлде Габделфәт.

— Юк, юк, Габделфәт абый, мин андыйларны авызыма да алмыйм.

— Менә монысы өчен рәхмәт, сеңлем! Шундый хатын-кызны чын күңелдән хөрмәт итәм мин. Минем Сөмбеләмнең дә иснәп тә караганы юк ул шәраб дигәннәрен... Әйе, килегез әле, Газиз, безнең якларга. Умарталыкта бер кошлар сайраганын тыңлап, туйганчы бер серләшеп, җырлап утырырбыз. Ә син, Айсылу сеңлем, беләсеңме Газиз абыеңның ничек җырлаганын?

— Беренче тапкыр ишетәм, ләкин гаҗәпләнмим, — диде Айсылу.

Габделфәтнең сүзенә Газиз аптырап китте:

— Нәрсә, мин бүлмәдә җырладыммыни? — дип, күзләрен текәп карады ул Габделфәткә.

— Юк, җырламадың. Шулай да ике-өч мәртәбә моңланып алдың. Шуннан мин синең әйбәт җырлавыңны сиздем. Мин үзем җырга һәвәс түгел, Газиз, айга карап шыңшыган эт кебек кенә, ләкин җырлаган кешеләргә мөкиббән китәм. Җырла әле, дустым! Ихлас, чын күңелем белән үтенәм — бер генә җыр...

Әлбәттә, Газиз өчен җырлау берни түгел. Җырлы-моңлы гаиләдән булгангамы, җырны яратып, моңланып үсте ул. Тик менә бүген тиктомалга ничек җырлап җибәрәсең? Тавышы да шәптән түгел инде аның соңгы вакытта, тыны да кысыла. Шулай да... Тагын кайчан җырлап утырырга мөмкинлек туар?

Айсылу да аңа көч бирде:

— Газиз абый, бу ямьле кичәдә бер җырлап җибәрсәң дә гөнаһ булмас. Башлагыз әле, үзем дә кушылырмын.

— Ярар алайса, тырышып карыйк. Тик үпкәләштән булмасын, җырның ертыгы юк, — диде Газиз һәм берничә мәртәбә тамак төбен кырып алды. Аннары, ашыкмый гына, ярым ачык тавыш белән сузып җыр башлады:

Күк күгәрчен баласыдай
Күгелҗем булмас инде лә,
Күгелҗем булмас инде;
Сездән аерылып китүләр
Күңелле булмас инде...

Җае чыкса, кушылырга дип уйлаган Айсылу да, Габделфәт тә, Газизгә кушыла алмый гаҗәпкә калып, тын гына тыңлап утырдылар. Җыр аларны әсәрләндереп җибәрде. Үзе ниндидер гади дә, шул ук вакытта моңлы да, аһәңле дә җыр иде бу. Юк, бу көйгә халык та җырламый бугай, моны сәхнәдән башкарган артистлар да юк кебек. Ләкин көе таныш, бик таныш. Әллә соң берәр спектакльдә җырлыйлармы аны? Күңелне яулый торган җиңел, моңлы җыр. Һәм иң мөһиме — Газиз дә аны һәвәскәр җырчы кебек гади генә итеп, Ходай биргән тавышы белән һич кыстатмый, җайлы гына җырлый. Тамак төбеннән чыккан җыр җыр түгел, ә йөрәк түреннән чыккан җыр гына җыр, диләр.

Сездән аерылып китүләр
Күңелле булмас инде...

Тыңлап утыручыларның күңелләре тибрәнде. Габделфәт тә, Айсылу да җырчының нинди аерылып китүләр турында искәртүен бик яхшы аңладылар.

Газиз исә, берни булмагандай, җыр сузуын дәвам итте:

Күпер төбе күк томан,
Бу илләрдә күп тормам ла,
Бу илләрдә күп тормам;
Күп тә тормам, аз да тормам,
Сагынырсыз, мин булмам...

Җырның соңгы юлы елаудан үзен көчкә тыеп утырган Айсылуның әрнегән җанын телгәләде.

Габделфәт исә, чын күңелдән:

— Әйттем бит, әйбәт җырлый, дип. Рәхмәт, Газиз, малай, зур рәхмәт үзеңә, җанга рәхәт булып китте. Мең яшә! — дип, дусларча Газизнең аркасыннан сөйде.

Шулай җыр сузып, эчкерсез сөйләшеп, моңланып, чәй һәм мәй белән сыйланып, алар әле тагын бераз утырдылар.

* * *

Айсылу Газизләрдә кич утырудан, дөнья күргән, аны танып белгән ике сабыр табигатьле, төпле ир-ат белән аралашудан гаять зур канәгатьләнү алып чыкты. Бигрәк тә Газиз абыйсы көчле тәэсир ясады аңа. Аның белән күбрәк бергә булган, аралашкан саен, Айсылу бу кешедә үзе белгән күп кешеләргә хас булмаган үзгә сыйфатлар ача бара. Үзе гади, үзе игътибарлы, үзе мөлаем, шул ук вакытта язмышы катлаулы. Бар бит һәрьяклап килгән, талантлы кешеләр! Сөйли башласа, авызына каратып тота, җырлый башласа, сине моң дәрьясына алып китә, бии башласа, ут уйната, дәртләндерә, җилкендерә. Үзе архитектор — зиннәтле сарайлар, матур йортлар проектын төзи.

Әйе, искиткеч кеше. Һәм, иң гаҗәбе, шундый кешегә дә чын бәхет йөзен күрү насыйп булмаган. Айсылуның үзенә дә бәхет кояшы елмаймады. Бәлки, бар көчен биреп көрәшмәгәнгә елмаймагандыр ул? Ә Газиз аның өчен көрәшкән бит югыйсә. Бүген дә көрәшә. Яшәү өчен көрәшә! Яшәү — үзе бер олы бәхет, ди ул. Мондый кеше белән тормышыңны бәйләү дә куркыныч булмас иде. Тик... Кем соң әле аңа, бергә булыйк дип, тәкъдим ясаган?

Эх, белмәссең бу дөньяны! Син теләгән кешеләр әллә кайда йөри, син теләмәгәннәр юлыңа аркылы төшәләр. Күзеңне ачыбрак йөрсәң, Газиз кебек гади, самими кешене таба алган булыр идең әле син дә, Айсылу ханым, юк, Айсылу туташ! Йа Ходa, чыннан да, кем соң инде ул бүген?!

...Медицина училищесын тәмамлаганнан соң, Айсылуны Чулман буендагы зур булмаган бер авылга фельдшер итеп җибәрделәр. Тыныч кына барып урнашты кыз, училищеда алган белемен барлап, яхшы гына эшли башлады. Иң мөһиме — сырхаулап килгән кешеләргә игътибарлы була белде. Бәлки шуңадыр, авыл халкы аны үз итте, яратты.

Шулай тыныч кына эшләп ятканда, колхозга яңа инженер кайтып төште. Әле генә институт тәмамлаган егет шушы авылныкы икән. Зифа буйлы, киң күкрәкле, мәһабәт буйлы егет. Ниндидер йомыш белән медпунктка да икеме-өчме кагылды ул. Тик сөйләшүләре нигәдер тупас килеп чыкты. Шуңамы Айсылу егетне өнәп бетермәде. Инженер дигәч тә, борынын чөя бугай дип уйлады ул. Ләкин егетнең медпунктка кагылуы сәбәпсез булмаган икән. Беркөнне ул кереп Айсылуны концертка чакырды — Казаннан җырчылар килгән, диде. Ә Айсылу бармады. Егет, үз теләгенә ирешү өчендер, аның янына тагын да ешрак кереп йөри башлады. Ә беркөнне Айсылуның кулын сорарга ата-анасын җибәрде. Кыз уйланмады түгел, күп уйланды һәм ризалыгын да көттереп кенә бирде. Егетнең үзенә караганда, кызга күбрәк аның ата-анасы ошады. Олы башларын кече итеп, алар абруе күтәрелеп барган фельдшер кыз янына кат-кат килделәр. «Бик яратабыз үзеңне, киленебез бул, бергә-бергә матур итеп гомер итәрбез», — диделәр. Нишләсен, авыл зур түгел, сайланып булмый, яшь тә бара, утырып калуың мөмкин...

Шаулап туй үтте, тик зөфаф кичәсе булмады.

— Син гафу ит мине, Айсылу, — диде кияү егете. — Алдан әйтергә кирәк санамаган идем. Безнең институтның хәрби кафедрасы булмаганга, мине бер елга армиягә алалар, запастагы офицер итеп әзерләячәкләр. Бер ел күп вакыт түгел, үтәр дә китәр. Син дә сагынып торырсың, мин дә сагынып кайтырмын. Әлегә мин сиңа тимим. Шулай яхшырак булыр.

— Гаҗәп, — диде Айсылу. — Бәлки, мин балага узармын һәм син кайтканчы табып куярмын?

— Юк, мин риза түгел. Мин куркам...

— Нәрсәдән?

— Хыянәт итәрсең дип.

— Атаң-анаң, туганнарың янында яшәп тәме?

— Барыбер.

Айсылуның күңеле төште, кимсенде, кыбырсынды. Сәер хәлдә иде ул. Иргә чыгып, ир хатыны исемен йөртеп шундый хәлдә яшә инде! Дөресен генә әйткәндә, ул бит бу кешегә тормышка чыгарга да теләмәгән иде. Нәрсәседер ошамады, ышаныч, өмет чаткылары бик аз шәйләнде аңарда. Айсылу ялгышты бугай. Сайлаган сазга, очраган тазга. Инде нишләргә? Әйберләрен җыеп чыгып китәргәме? Ичмасам, барысын да уртага салып сөйләшергә, киңәшергә янында бер якын кешесе дә, киңәшчесе дә юк. Чыгып китсә, авылда әнисе белән апасы ни әйтер? Әллә бераз түзәргәме?

Ир буласы кеше армиясенә китеп барды, тик Айсылу елап калмады. Өмете өзелгән, үзе төшенкелеккә бирелгән иде.

Армиядән хатлар килеп торды. Башта еш килде алар, эчтәлекләре дә матур гына иде. Аннары хатлар сирәгәйде. Инде кайтырга вакыты җитеп килә, бәлки, шуңа сирәк яза торгандыр дип уйлады Айсылу. Үзе исә бернинди тел-теш тидерерлек гамәл кылмады. Зур булмаган авылда барысы да күз алдында. Медпункттан кайта да тавык та чүпләп бетерә алмаслык йорт эшләренә керешә. Каената белән каенана киленнән канәгать, «кызым» дип кенә торалар. Ләкин Айсылуның беркемгә дә күңеле ятмый, ышанычы да юк. Рәтле тормыш булмас, ахры, бирелә. Аның күңеле нәрсәдер сизенә иде. Һәм дөрес сизенгән икән ул. Инде бер ел үтте. «Озакламый кайтам» дип язган кеше һаман юк.

Беркөнне каенигәче* аның эш урынына медпунктка килеп керде һәм иренең аларга язган хатын бирде. Ул анда үзенең авылга кайтмаячагын, армиядә офицер булып калачагын, хезмәт иткән җирдә башкага өйләнгәнен язган иде. Айсылу шул көнне үк туган якларына кайтып китте. Аннары медицина институтына укырга барып керде...

Газизгә «Берәү белән торып карадык та, с характерами не сошлись» дигәне шул иде инде аның.

Яратусыз кавыштылар, үкенечсез аерылыштылар...

* * *

Иртән Газиз төш күреп уянды. Сәрмәдиясе ап-ак киемнән ниндидер коймамы, әллә бурамы артында басып тора, аңа кул изи һәм: «Кил инде тизрәк, нишләп озакладың?» — дип, ап-ачык итеп эндәшә, имеш. Әйтерсең лә өстенә салкын су койдылар — Газиз иләс-миләс торып утырды. Йөрәге ашкынып тибә, үзе шабыр тиргә баткан, суларга һава җитми, башы чатнап ярыла. Гомерендә бер дә төш-мөш, ырым-шырымга ышанмый торган Газиз әлеге төштән исәнгерәп китте һәм тәүге тапкыр үзенә хәтәр хәбәр юрады. Шулай ук... Ах, нәләт... Нәрсә соң инде бу тагын?..

Габделфәт сабый бала йокысы белән изрәп йоклый иде әле. Сәламәт кеше шул! Тәмам шөбһәгә төшкән Газиз, йөрәк ярсуы басылмасмы дип, полиэтилен шешәдән бокалга шифалы су салып эчте. Тагын ятып йоклау турында уйлап та булмый, чөнки йокысы качкан, күзләре шар кебек ачылган иде. Шулай да, курортның бер якка ямьшәеп төшкән бәләкәй мендәрләрен төзәткәләп, кабат урынына менеп ятты. Һәм аны шунда ук очсыз-кырыйсыз уйлар чолгап алды.

Соңгы вакытта ул Сәрмәдияне төшендә еш күрә. Уйланганга күрә керә торгандыр инде ул аның төшенә. Уйламаса, кермәс иде. Ә ничек уйламыйсың? Утыз ел бергә яшә дә...

«Ах, Сәрмәдия, Сәрмәдия... Бәрәкәтсез үткәрдек шул бергә булган гомерләребезне. Әллә ничек булды безнең тормыш: син мине ир итеп күрмәдең, мин сине аңлап бетерә алмадым. Өйләнештек, бергә тордык, әмма бер-беребезгә гомер юлдашы була алмадык. Үкенечкә калды барысы да...»

Гомеренең соңгы айларында Сәрмәдия үткән тормышын кайтып-кайтып уйлады. Беркөнне Газиз эштән кайтып кергәндә, хатынының елап утырганын күрде. Тезләрен кочаклаган һәм тавыш-тынсыз күз яшьләрен түгә. Салган баштан балавыз сыгып утырадыр дип уйлаган иде Газиз, ләкин Сәрмәдия ап-аек иде.

— Нигә мышкылдап утырасың әле, нәрсә булды? — диде Газиз, йомшак кына, һәм аның янына барып утырды.

— Төш күрдем, бик куркыныч төш...

— Соң, сөйләп җибәр...

— Үләм мин... — диде Сәрмәдия һәм кабат яшенә тыгылды.

— Ташла әле юкны! Соңгы вакытта артыгын җибәрәсең, ә ул психикаңа бәрә. Беренчесе түгел, соңгысы да булмас...

— Юк, Газиз, эчем поша. Элеккеге кебек түгел, бөтенләй башкача поша. Күңелдә өметсезлек, бушлык, җанда упкын... Төшем рас килсә, күп тормам, ахры. Аннары... Син дә миннән соң озак яши алмассың кебек...

Бу сөйләшү авыр таш булып ятты Газизнең йөрәгенә. Уртак тел табып, аңлашып, яратышып, хөрмәт итешеп, чөкердәшеп яши алмадылар. Тик ничек кенә булмасын, Сәрмәдиянең үлүен теләми иде ул. Үзе белән бер-бер хәл килеп туса, Сәрмәдия, ниһаять, айныр һәм аларның бердәнбер кызларына терәк булып калыр дип уйлаган иде. Тормышны танып белергә өлгермәгән, дөньяны әле бөтенләй күрмәгән унҗиде яшьлек кыз бала шулай ук атасыз да, анасыз да калыр микәнни? Шыр ятим булып...

Кинәт аның исенә чынбарлыкны искиткеч төгәл итеп тасвирлаган бер җыр килеп төште. Моңлы җырлары белән халык күңелен яулап килә торган бер яшь җырчы кыз башкара аны. Гаҗәеп моңлы тавыш ул кызда.

> Яшәү, үлем — бары тик бер сукмак,
> Нигә башка сукмак юк икән?
> Адаштым дип кайтып китәр идем,
> Яшьлегемә кайсы юл илтә?..

Үзе генә калган, уйландырган-моңландырган минутларда Газиз дә бу җырны сузып җибәрә, күңелен юата, җанын тынычландыра.

Эх, кайтып китәсе иде дә яшьлеккә, барысын да яңабаштан башлыйсы, кылган ялгышлыкларны читләтеп үтәсе иде. Юк шул, анысы булмас хәзер. Инде Ходай тагын гомер бирсә, калган елларын ничектер башкача, бәрәкәтле, мәгънәле тормыш көтеп, якыннары белән аңлашып яшәр иде...

* * *

Сәрмәдиянең юраганы, кызганычка каршы, юш килде. Сентябрьнең җылы, кояшлы, матур көннәреннең берсендә, Газиз иртән шәһәр читендәге җиләк-җимеш бакчаларына китеп барды. Ял көне иде ул. Сәрмәдия әле тормаган да иде. Кичтән дә: «Йөрәгем чәнчә», — дип, дару кабып яткан иде. Иртәнге якта да Газиз аңа йөрәк даруы белән су эчерде. Үзе, озак тормам, дип чыгып киткән иде, тик бакчага бер барып җиткәч, тиз генә эшеңне бетерә алмыйсың, көнең үтә. Ул көнне дә шулай булды. Инде төш үтте, кичкә авышты. Шулчак Газизнең күңеленә кинәт пошаман төште һәм: «Син нишләп һаман монда йөрисең, хатының авырып калды лабаса», — дип, өенә ашыкты. Сәрмәдиянең күңеле булыр дип, бер кочак кашкарый, гладиолус, хуш ис чыгарып, аңкып торган флокс чәчкәләре алды.

Автобуста кайткан ярты сәгать аңа ярты көн булып тоелды, аннан төшү белән өенә ашыкты, өйгә якынайган саен, күңеле тынычсызлана, сабырсызлана барды, әллә ничек хәтәр барын сизенде.

Ишекне ачып керү белән:

— Сәрмәдия, Сәрмәдия, мин кайттым, — дип кычкырды. Әмма җавап бирүче булмады. Ул, кабаланып, йокы бүлмәсенә узды. Сәрмәдия җиңел халат белән идәндә, карават янындагы келәмдә утыра, башын исә караватөстендәге мендәргә салган. Башын әллә ничек уңайсыз салган ул. Бер кулы да шул мендәрдә... Йоклыймы, әллә уйланып кына утырамы? Газиз аңа килеп кагылды...

Ул инде суынып беткән иде...

Бакчадан алып кайткан бер кочак чәчкәләр Газизнең Сәрмәдиягә соңгы бүләге булды.

* * *

Минераль ванналар блогында ашыкмый гына үз чиратын көтеп, ял итеп утырганда, Газиз янына аның белән вальс биегән яшь хатын килеп утырды. Соңгы кичне биергә зәңгәрсу өрфия күлмәк белән чыккан иде, ә бүген өр-яңа аклы-яшелле спорт костюмыннан, үзен танырлык та түгел.

— Исәнмесез, абый! Хәлләрегез ничек?

— Ә, әйбәт әле, сеңлем. Син дә ваннагамы?

— Әйе. Менә бераз соңга калганмын, вакыт җитми. Берәү белән танышкан идем дә...

— Егет белән дисеңмени?

— Әйе, монда барысы да егет инде. Сез дә менә егет. Вальсны да гаҗәп матур биисез. Егетнең дә асылы! Теге кичне биюдән соң үзегезгә кич утырырга чакырмадыгыз бит. Чакырган булсагыз, мондагы буш вакытларны да бергә генә үткәрер идек. Хәзер вальска да чыгып булмас инде, теге көнләшеп маташа: «Беркөнге кавалерың белән танцевать итсәң, смотри», — ди.

— Гаҗәп икән.

— Былтыр «Казан» санаториенда берәү белән йөрдек, бер грамм да көнләшмәде. Әле икенчесе белән дә танышырга өлгердем...

— Ирең көнләшәме соң?

— И-и, бер бозау инде шунда. Көнләшә дә, ярата да, назлый да белми. Аннан кем соң әле аңа кайтып сөйләгән? Повод бирмибез инде...

— Яшәгән җиреңдә дә бармы «егетләр»ең?

— Ә нәрсә?! Ба-ар! Хәзер кайсы хатынның сөяркәсе юк? Жизнь дается один раз, диләрме әле?

— Димәк, «коллекция» җыясың?

— Җыела инде, — диде ул һәм кеткелдәп көлеп куйды.

— Алай дөресме соң ул, сеңлем? Әхлак, намус, әдәп дигән төшенчәләр дә бар бит әле тормышта, — диде Газиз, көрсенеп.

— И абый, исең киткән икән иске чикмәнгә. Менә мондый мәзәкне ишеткәнең бармы? Курортка килгән бер ир белән бер хатын танышканнар. Тәүге кичне сөйләшеп утырганнар, икенчесендә ир хатынның кулын тоткан, өченчесендә кулын биленә салган. Хатын түзмәгән: «Син нәрсә, мине курортка бер елга килгән дип уйлыйсыңмы әллә?» — дигән. Шулай итеп, мин дә курортка өч кенә атнага килдем. Дөньясында да ике гомер яшәргә язмаган. Әнә телевизордан рекламаларны күрә торгансыңдыр «Бери от жизни все!» диелгән. Мин дә шул принцип белән яшим. Һәм бер мин генә дә түгел. Кем миңа ошый, йә булмаса кемгә үзем ошыйм — шуның белән көн, төн уздырырга риза. Тик «мәхәббәт», «сөям» дигән сүзләрсез генә, буш сүзләр алар. Тән җылысы, тән ләззәте барысыннан да кадерлерәк. Кысып кочакла, суырып үп, төн буе назла...

— Кем белән булса да барыбер, дисең инде алайса?

— Барыбер.

— Ә хис?

— Кочаклашып яткач, хис үзеннән-үзе килә ул.

— Сеңлем, болай яшәп үзеңне бик тиз туздырмассыңмы соң?

— Туза ди... — Хатын шаркылдап көлеп куйды: — Мин сезнең кебек ир-атларның күбесенә җитәрмен әле. Яшәп калырга кирәк, яшәп... — дип өстәде һәм урыныннан кузгалды.

Бу вакытта минераль ванналардагы шәфкать туташы, дәваланучыларның фамилияләрен атап, ваннага керергә чакыра башлады. Газизнең чираты җитмәгән иде әле. Ул беравык уйланып утырды. Тезгеннән ычкынган, намус төшенчәләрен оныткан, аларны уйлап та карамаган бу яшь хатын белән сөйләшүдән аның хәтере калды, кәефе төште, җаны бимазаланды. Әгәр мәхәббәт хисен тулысы белән татый алмыйча яшәгән, тәүге тапкыр чын ярату, кайнар сөю белән шашынып, гомерендә бары бер тапкыр иренә хыянәткә барса — башкача уйлар идең, андыйны аңларга тырышыр идең. Бу бит тәмам барып чыккан. Мондый азган-тузганның кытыгын качырырдай кеше кирәк тә бит, андыйлар юк, күрәсең. Ирен дә «бер бозау» гына ди бит, дөрес булса. Дөрес булмавы да мөмкин. Андый хатыннар сәбәп табарга осталар.

Ах, бу хатын-кызлар! Һич аңламассың аларны. Теләсә, ул синең башыңны да катыра, йөрәк маеңны да эретә, күңелеңнең иң серле, иң ләззәтле кылларын да чиертә белә, теләмәсә, инде һичбер нәрсә булмагандай, тупас рәвештә тибәреп тә ташлый, төп башына да утырта, маңгаеңа «мөгез» дә куя. Син аны шашып сөясең, ә ул сине якын да китерми яки син аннан туеп качарга телисең, ә ул сине арканлаган бозаудай йөрәгенә бәйләп куйган да җибәрми...

Газиз теге кичне әлеге тотнаксыз хатын белән вальс биюенә дә үкенә башлаган иде. Тик аның шундый икәнен каян беләсең? Кем икәнлеге маңгаена язылмаган шул...

* * *

«Тәүге тапкыр чын ярату, кайнар сөю белән шашып, гомерендә бары бер тапкыр иренә хыянәткә барса — икенче хәл булыр иде» диюе белән Газиз үзен акларга маташа иде бугай. Бар ярату, сөю бар. Бу инде йөрәк эше. Йөрәккә боерык биреп булмый, диләр бит гөнаһсызлар. Инде гөнаһ икән... Әйе, хатадан беркем дә хали түгел бу дөньяда, булса да шул сабыйлар гына гөнаһсыздыр.

...Газиз Сәрмәдиясеннән калып, ялгыз каз кебек каңгырап йөргән көннәрендә, архитектура бүлегенә яңа сызымчы алдылар. Күрше шәһәрдә педагогика-сәнгать техникумын тәмамлап, берничә ел мәктәптә рәсем һәм сызым дәресләрен укытып йөргән, шул арада кияүгә чыгып бала табарга өлгергән, курчак кебек нәфис, нечкә билле, эшне һич иренмичә эшли торган бер яшь хатын иде ул. Өстендә гади генә ситсы күлмәк, аягында арзанлы туфлиләр, бөдрәләнеп торган тузынкырак кара чәчле, кыр чәчәге кебек зәп-зәңгәр күзле, битенә кершән-иннек сөртеп, күзенә сөрмә тартмаса да, күңелләрне тибрәндерә алырдай сөйкемле йөзле. Буянып-ясанып тормаса да, бүлектәге унлап сөрмәле күзле, битенә олтан калынлыгы чит илдән кайткан кыйммәтле иннек-кершән сылаган асыл затлар арасына килеп керде һәм якты йолдыз кебек җемелдәп, кояш кебек җылытып, ай кебек уйландырып үз эшен белеп эшли башлады. Инде дүртенче дистәсе белән баруына карамастан, төсе-бите һәм тышкы кыяфәте белән ул шактый яшь күренә иде. Кергән-чыккан, килгән-киткән, үткән-сүткән мут ир-атның күзе гел шул хатында иде, тик ул гына беркемгә дә игътибар итми, ул гына башын аска — өстәлгә, ватманга игән һәм тырышып-тырышып сызым сыза, күрәсең, яңа урында үзен күрсәтәсе килә.

Сөйкемле хатын-кызга битараф булмаса да, әлеге хатын — Нурсибә — Газизнең күңел күзенә беренче көннәрдән үк чалынмады. Аның кайгы-хәсрәтле, уйлы-моңлы, моннан тыш өстенә бүлек җитәкчесе вазифаларын кабул итеп алган мәшәкатьле көннәре иде.

Беркөнне аңа яңа проектның сызымнарын керттеләр. Газиз игътибар белән карап чыкты һәм сызымнарда шактый төгәлсезлекләр тапты.

— Кем сызды моны?

— Әнә яңа сызымчы, — диделәр аңа.

— Чакырыгыз әле!

Бүлмәгә түгәрәк йөзле, нәрсәгәдер гаҗәпсенгән сыман карашлы зәңгәрсу күзле яшь хатын килеп керде.

— Сеңлем, нигә бу проект начар сызылган?

Хатын эндәшмәде, аның асылташ күзләре генә челт-мелт итте.

— Син сызган идеңме? Менә кара әле...

Хатын, сызымнарын карар өчен, Газиз утырган өстәлгә якынрак килде һәм «әйе» дигән мәгънәдә башын изәде. Ул дер-дер калтырый иде. Моны күреп торган Газиз шунда ук тавышын йомшартты:

— Мә, сеңлем, ал, төзәт! Эшең беткәч, яңадан алып керерсең...

Эшен ул кичке якта гына бетерде һәм һаман шулай бер сүз эндәшмичә, сызымнарын тотып, Газиз янында басып тора иде. Бүлек мөдире аңа каршындагы урындыктан урын күрсәтте, тик хатын утырырга теләмәде, басып торуын дәвам итте.

— Утыр, акыллым, утыр! Аяк өстендә дөреслек юк, диләр...

Сызымчы, кыюсыз гына, урындыкның кырыена килеп утырды. Газиз сызымнарны кабат тикшереп чыкты: «Бусы ярый, бусы да булган, бусы да әйбәт...»

— Менә бит, булдыргансың. Әйбәт итеп эшләп була, димәк? Иртән нәрсәдәндер курыккан идең, ахры?

Хатын бу юлы да башын гына селкеде.

— Мин талəпчəн, лəкин кеше ашамыйм. Менə шулай пөхтə итеп эшлəсəң, минем сиңа дəгъвам булмас. Килештекме?

Хатын тагын башын какты, лəкин, бер сүз эндəшмичə, бүлмəдəн чыгып китте.

Бу — Нурсибəнең Газиз белəн якыннан торып очрашу, танышу көне булды. Шул көнне үк бүлектəге хатыннар җитəкчелəре турында гайбəт тə сөйлəп алдылар. Янəсе, ул кайчандыр Зөлфия белəн очрашкан. Зөлфия дə шушы бүлектə эшли, лəкин хəзергесе вакытта төзелешкə чыгып киткəн һəм хатыннарга аның «сөяген юарга» җайлы вакыт туган иде. Нурсибəнең күзлегеннəн чыгып караганда, Зөлфия үзеннəн берничə яшькə олы булса да, аның җитəкче белəн буталуы чиктəн тыш гаҗəпкə калдыра торган хəл.

— Шул карт белəнме? — дип сорап куюын сизмичə дə калды ул.

Күңеле белəн Нурсибə бу сүзгə бик үк ышанып та җитмəде. Дөрес булса сизелер иде, ə тегелəрнең арасында кыңгыр эш сизелмəде. Утсыз төтен чыкмый, димəк, ут булмаган. Хатыннарның усаллык яки көнчелек белəн сөйлəгəн чираттагы гайбəтлəре генə иде бугай ул.

Лəкин тормышта син һич тə уйламаган, акылыңа да китермəгəн хəллəр дə була икəн.

Кыска гына вакыт эчендə Нурсибə үзенең оста сызымчы икəнен танытты. Газиз үзе ясаган проектларны гел аңардан гына сыздыра торган булып китте. Эшенə һəрвакыт иҗади яктан якын килгəн җитəкченең проектлары да мавыктыргыч, кызыклы була. Моннан автор үзе генə түгел, сызымчы Нурсибə дə канəгатьлəнү хисе таба башлады. Эчтəн генə ул үзенең җитəкчесе биргəн проектларны сызганына горурланып та куя, чөнки алар гади генə, төссез генə түгел, ə катлаулы, югары дəрəҗəдəге камил эшлəр. Ə кайбер вакытта сызымчы үзе проектны тагын да камиллəштерү юлын күреп ала һəм бу турыда Газиз абыйсы белəн уртаклаша, аңа тəкъдимен əйтə.

— Кара син аны! Үзең дə чын архитектор икəнсең бит, афəрин, — ди Газиз абыйсы һəм җиңел генə аркасыннан сөеп ала. Аннан үзе белəн утырып чəй эчəргə кыстый...

Əнə шушы иҗади бердəмлек аларны шактый якынайтты, дуслаштырды. Башта кырын күз белəн генə караган Нурсибə дə Газиздə əкренлəп күркəм сыйфатлар тапты. Игътибарлы, кешелекле, сабыр, каты бəрелми. Кайчагында кызып алса да, ачу сакламый, шуның артыннан ук нинди дə булса кызыклы сүз əйтеп, мəзəк сөйлəп, көлдереп, кəефеңне күтəреп җибəрə. Инде азау тешен ярган хезмəткəрлəр генə түгел, Нурсибə дə җитəкче янына һич тартынмыйча, үз дəрəҗəсендəге кеше, иптəше янына кергəн кебек керə башлады. Хəтта аны бер-ике көн күрми торса, Нурсибəнең юксына башлавы да сизелə иде: «Газиз абый нигə күренми соң əле? Берəр кая китте микəнни? Эше күптер инде...»

Кешегə булган мөнəсəбəтеңнең үзгəрүе кайвакыт вак кына нəрсəлəрдəн тора. Уңае да, тискəресе дə шулай. Берəү сиңа бəлəкəй генə игътибарлылык күрсəтсə дə, синдə аңа карата рəхмəт хислəре ташып чыга, йөзең кояш кебек балкый.

Сентябрьнең бер көнендə аларны колхозга бəрəңге алырга булышырга җибəрделəр. Иртəн көн коры, кояшлы иде. Шуңа да Нурсибə җиңелчə генə киенеп чыкты. Бəрəңге басуына барып төшкəч тə, төньяктан салкынча җил исə башлады, кинəт күк йөзе караңгыланды һəм вак яңгыр сибəлəргə тотынды. Кызып-кызып эшлəсəлəр дə, салкын җил Нурсибəнең юка киеме аша үтеп өшетə башлады. Шулчак Газиз өстендəге күн курткасын Нурсибəгə салып бирде. Нурсибə, уңайсызланып, алмаска маташты:

— Мин аны пычратам бит, — диде.

— Ки, ки, өшисең...

Газиз курткасын аңа үзе кидерде. «Менə начальник булдың», — дип шаяртып, бəлəкəй Нурсибəне кочагына алды. Моны Нурсибə һич көтмəгəн иде. Шулай да аңа шулхəтле рəхəт булды ки, мондый лəззəтле хисне аның инде күптəн татыганы юк иде. Газизнең курткасы бик җылы булып чыкты, Нурсибə аны киеп көн буе рəхəтлəнеп эшлəде.

Иртəн Газиз Нурсибəгə сызарга тагын бер проект кертте.

— Эшлəр ничек? Бүген син тагын да матуррак. Бөтен бер бүлекнең күңел бизəге син...

Бер-ике җылы сүз адəм баласын əллə нишлəтеп җибəрə. Күңелне эретə торган йомшак, ягымлы сүзлəр. Нурсибəгə шул җитə калды: ул, энҗе кебек ак һəм тигез тешлəрен күрсəтеп, елмаеп җибəрде, əйтерсең лə бүлмəдə бүлек сызымчысы түгел, ə кояш үзе балкыды.

Көннəр үткəн саен, бүлек мөдиренең Нурсибəгə булган игътибары арта, көчəя барды. Бу аның гүзəл һəм яшь хатын белəн чын-чынлап мавыга башлавы иде. Үткəндə дə, сүткəндə дə, аулак вакытны сайлап, Газиз аңа ягымлы сүзлəр əйтə, чəчлəреннəн сыйпый, аркасыннан сөя, ягымлы елмая.

Беркөнне эш ахырында кызлар чəйлəп алдылар — кайсыдыр туган көнен билгелəп үтте. Лəкин озак утырмадылар, таралыштылар, чөнки һəркемнең өйдə гаилəсе көтə. Газиз үзе генə калып, нинди дер бер проектны сызгалап уйланып утыра иде. Ишек шакыдылар. Караса — Нурсибə.

— Син, матурым, кайтып китмəгəн идеңмени?

— Əзрəк эшем бар иде, шуны төгəллəдем. Кайтып киткəнче сезне күреп чыгыйм дидем...

Əйтерсең шушы сүзлəре белəн Нурсибə Газизне сихерлəде. Димəк, «карт» Газиз абыйсы Нурсибə өчен һич чит-ят түгел, якын, үз кеше икəн. Газиз дулкынланып урыныннан торды һəм, магнит тарткан

кебек, Нурсибәгә тартылды. Ә ул, күк йөзендәге болыт кебек, зәп-зәңгәр күзләрен Газизгә төбәп карап тора, әйтерсең лә Газизнең кысып кочаклавын, иркәләвен, назлавын көтә. Газизнең үзендә дә шул ук уй, шул ук тойгылар, шундый ук теләк иде. Курчак кебек нәфис, нечкә билле Нурсибәне ул ашкынып кайнар кочагына алып кысты һәм, шашып, чәчләреннән, маңгаеннан, күзләреннән, битеннән үбәргә тотынды. Шуны гына көтеп торган кебек, Нурсибә дә йомшак куллары белән аның муенына сарылды. Шулчак Нурсибә үзен әлегә кадәр һичкайчан татымаган сәер, әмма ләззәтле халәттә калганын сизде. Газизнең кайнар тәненнән ургып чыккан ниндидер сихри көч аның бөтен гәүдәсен чолгап алды да, аны дәртле ашкындырып, аяк бармакларыннан башлап чәчләренә чаклы рәхәт, татлы, кайнар чымырдау үтте. Бу — табигатьтә сирәк очрый торган хәл — биокыр галәмәте, биотоклар көчеше иде. Нурсибә аны бик озак вакыт үткәч кенә аңлады һәм һәрвакыт: «Менә сиңа карт!» — дип сокланып искә ала, рәхәт уйларга чума торган иде. Ничә ел ир белән яшәп тә мондый татлы мизгелне татыганы булмады аның. Бәлки, ирен яратмый чыкканга шулайдыр ул? Ире үзенең дусты, Нурсибәнең яраткан егетеннән тартып алды аны һәм көчләп диярлек өйләнде. Бәлки шуңадыр, ул үзенең иренә карата битараф яшәде һәм кайчан да булса берәүне сөеп алу белән хыялланды. Өлешенә чыккан көмеше аның әнә бүлек мөдире Газиз Солтанов булды.

Күпмедер вакыттан соң бүлек хатыннарының Газиз турында Зөлфия белән булган имеш-мимеше Нурсибәнең кабат исенә төште. «Шул карт беләнме?» — дип гаҗәпләнгән иде ул теге вакытта. Менә хәзер үзе «шул карт»ны ярата башлады, «шул карт» аның яшь йөрәген тәмам биләп алды, «шул карт» көндезен дә, кичен дә аның уеннан чыкмый, ә төннәрен төшләренә кереп газаплый. Сөйкемле сөякләре бар икән бит, ничек яратмый түзәсең...

Ә бит нинди яшь булганмын икән,  
Илле-алтмыш тулган елларда.  
Илледә ил гиздем, алтмышта да  
Гашыйк идем әле кызларга, —

дигән шагыйрь хаклы булган икән. Гаҗәп, искиткеч гаҗәп бу дөнья...

Ләкин... Алар шулай якын итеп, дуслашып, очрашып озак йөри алмадылар. Нурсибә, гаиләсен алып, башка калага күчеп китте. Гүзәл ханым үзе айнып акылына килдеме, әллә Газиз суга тирән керүдән шикләндеме — ниндидер без белмәгән хәл булды алар арасында. Тик Газиз әле дә бер көрсенеп, бер сызланып Нурсибә турында очсыз-кырыйсыз уйлар уйлый, шул уйларында аңа чиксез сораулар бирә, сөйләшә, аннары озын төннәрдә төшләрендә күрә. Өзелеп сагынган көннәрендә аңа атап моңлы җырлар суза.

Белми калдым, күрми калдым,  
Киттең... Хушлашмадың да.  
Эзең генә калды миңа  
Йөргән сукмакларыңда.

Кая киттең? Кемнәр алды —  
Давылլармы? Сулармы?  
Эзләреңдә ак чәчәкләр —  
Истәлеккә шулармы?..

* * *

Инде китте, югалды, башкача очрата алмам, дип йөргән көннәрнең берсендә, алар тагын очраштылар. Андый хәлләр могҗизага тиң һәм булса да бик сирәк була торгандыр.

Күрше шәһәрнең баш архитекторын лаеклы ялга озаттылар. Хакимият башлыгы тантаналы озату кичәсенә, бүләк тоттырып, Газизне җибәрде. Зур ресторанга алты-җиде дистә кеше җыелган, шау киләләр, музыка уйный. Тантана шулай шаулап үтте. Ялкынлы нотыклар, затлы бүләкләр, җыр һәм бию, төрле уеннар... Тәнәфес вакытында кунаклар биеп алдылар. Газиз дә һәрвакыттагыча бу тылсымлы мизгелне кулдан ычкындырмады — күрер күзгә чибәр генә бер ханым белән биергә чыкты. Һәм шунда биючеләр арасында Нурсибәне күреп ах итте. Нурсибә дә аны күптән күреп, күзәтеп тора икән. Күзгә-күз очраштылар да, бер-берсенә карашып, сөенечләрен һич яшерә алмыйча, дустанә елмаештылар.

Музыкантлар тангодан соң вальс уйнап җибәрде. Нурсибә, кемнең дә булса аны чакырып килүен көтеп тормастан, ашыгып-ашкынып Газиз янына килеп басты. Бу минутта аларның икесе дә чиксез дулкынлану кичерделәр. Биергә парлашу мизгеленнән файдаланып, Газиз Нурсибәне кочагына алды. Нурсибә дә җавапсыз калмады — залда кеше күп, күрерләр, гайбәт сүз сөйләрләр дип куркып тормады, бер мизгелгә Газизнең муенына сарылды. Аннан сүзләрен тезеп китте, чөнки аны сагынган, аның белән сөйләшергә сусаган иде ул:

— Әллә кемнәр белән танцы итеп... Ә үземнеке янда гына икән. Нинди генә булмасын, үземнеке тек үземнеке! Моңлы карашы да, чиксез күп җыерчыклы йөзе дә, ягымлы елмаюы да, йомшак кулларының җылысы да — үземнеке. Сагынып беттем. Һичкемнекенә охшамаган җанга рәхәт тылсымлы тавышың-

ны, күңелне алгысыта торган сөйләшүеңне сагындым. Вакыт-вакыт мин аларны ишетәм сыман. Әллә исәрләнәм инде? Синме соң әле бу, ялгышмыйммы?..

Газиз рәхәтләнеп бер көлеп куйды, һәм:

— Мин, мин бу — Газиз абзаң Солтанов, — диде.

Шатлыгы эченә сыймый, дәрте ташып тора, рәхәт иде аңа бу минутларда.

— Нигә соң шунда син бераз яшь, мин исә бераз олырак булып, элегрәк очрашмадык та, бергә була алмадык? Нинди бәхетле гомер кичерер идек...

— Чыгып качтың бит әле, бер дә бергә булу турында уйламадың.

— Шулай кирәк булды. Шулай кирәк! Миңа үпкәләмә. Газапларга түзә алмый качтым. Яшерен сөю газапларына... Икегә ярыла алмадым. Ярылып та булмый. Ир хатыны бит мин! Ир хакы бар. Ир хакы — Тәңре хакы. Шуның белән бергә яшә, шуннан тапкан балаңны үстер, тәрбиялә, ә үзең башканы сөй... Килешми ул алай, һич килешми! Аңлыйсыңмы?

— Аңлыйм, аңлыйм. Мин бит бер сүз дә әйтмим сиңа. Әйтә дә алмыйм, әйтергә хакым да юк...

— Әллә ничек килеп чыкты шунда. Һич уйламаган идем синең белән мавыгырмын дип. Үземне сихерләдең. Күңелең киң синең, йөрәгеңдә миңа урын бар, ә үзең назлы. Чын күңелем, җаным-тәнем белән яраттым үзеңне. Бүген дә яратам. Тик минем хәлдә сөю-сөелүләр бик мәшәкатьле. Уйланам, сызланам, тәүбә итәм, Ходайның ярлыкавын сорыйм, ә үзем... Хәзер бетте. Тынычландым. Әгәр яшьлегемдә ирем мине яратканымнан тартып алмаган булса, мин шул яратканыма чыккан булсам, бу адымга бара идеммени? Ә син миңа үпкәләмә...

— Юк, үпкәләмим. Мин барысын да аңлыйм. Синең хәлеңне дим. Тормышым гына авырайды. Синсез боегам, суга сусаган чәчкә кебек шиңә барам. Авыр миңа синсез...

— Үзеңә тиң бер кеше тап, җаным, өйлән, бәлки, син дә тынычланырсың. Һәм... сиңа зур рәхмәт! Бәхетле айлар бүләк иткәнең өчен рәхмәт сиңа. Һич онытасым юк...

Залда музыка көчәйгәннән-көчәя барды. Ул, дулкын-дулкын булып, биючеләрне өере белән залның әле бер ягына, әле икенче ягына күчереп әйләндереп йөртте. Вальс биючеләр арасында пөхтә, килешле костюм кигән Газиз белән аның курчак кебек бәләкәй, бал кортыныкы кебек нечкә билле, бер йотым су белән йотарлык нәфис Нурсибәсе барысыннан да аерылып тора иде. Әллә инде бер-берсен сагынудан алар бу кичне вальска аерым күтәренкелек, илһам, дәрт белән биеделәр. Музыка тактын нечкә тоемлап, һич ялгышмый, киң урын биләп, залның әле бер башына, әле икенче башына барып чыктылар, алар тирәсендә биючеләргә һич комачауламый, ялгыш та кагылмый, оста биючеләргә генә хас төгәллек белән, әле бер, әле икенче якка тыелгысыз әйләнделәр дә әйләнделәр. Зур залда бу кичне Газиз белән Нурсибәдән дә остарак биючеләр, шулкадәр дә пар килгән кеше юк иде.

Кичәнең ахырына кадәр алар бергә булырга тырыштылар. Рәхәтләнеп биеделәр, сөйләштеләр-серләштеләр, күзгә-күз карашып, моңаеп бергә басып тордылар.

Инде кичә дә тәмамланды.

— Озатам, — диде Газиз.

— Юк, озатма, — диде Нурсибә.

Аннары Газизне кочаклап, битеннән генә үбеп алды.

— Хуш, сау бул! Сәламәтлегеңне сакла! Мин сиңа шуны телим. Даими телим мин аны сиңа — иртән дә, көндезен дә, кичен дә. Синең сау-сәламәт булуың миңа да көч бирә...

Һәм, артына да борылып карамыйча, ефәк күлмәк итәген җилфердәтеп, коеп куйгандай нәфис, төз аяклары белән җил-җил атлап китеп барды.

Ай күрде, кояш алды...

Калага кайтып, ялгыз башын кырын салып өенә таба атлаганда, Газиз үзенә бик таныш бер җырны көйләп алды:

> Хушлаштың да китеп бардың,
> Аерылу авыр бит...
> Күзләреңнең нурын
> Йөрәгемә салыйм,
> Тукта, дустым, сабыр ит!

Юк, туктамады аның Нурсибәсе, сабыр итмәде. Биек үкчәле туфлиләре белән, тек-тек басып, китте дә барды...

* * *

Курорт... Шифаханә... Дәвалану, сихәтләнү, ял итү урыны. Тик кемгә ничектер инде ул? Җан тынычлыгы таба алмаган кешегә кайда да уңайсыз. Кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмый, чирең дә, хәсрәтең дә, авыр уйларың да сине озата баралар. Адәм баласын эш түгел, кайгы-хәсрәт бетерә, дип белми генә әйтми торганнардыр.

Көн буена билгеләнгән дәва-процедураларын алып бетергәч тә, Газиз кабат ишегалдына һава суларга, Табигать-ана кочагына ашыкты. Бүлмәдә тар, кысан, тынчу иде аңа бүген. Күңеле дә тыныч түгел. «Эч поша, яна йөрәк...» Ә диңгез кебек җәйрәп яткан дәрья буенда иркенлек, дөнья киңлеге. Һәм су буеннан һәрвакыт саф, талгын җил исә. Су исе үзенә бертөрле тәмле, тәнгә рәхәт бирә торган ис ул.

Газизнең туган авылы Зирекле Чишмә уртасында мул сулы кизләү бар. Бик борынгыдан килгән кизләү. Авыл аксакаллары аның турында төрле риваятьләр сөйлиләр. Имеш, авыл халкы килеп урнашканчы, бу урында үтеп йөри алмаслык кара урман булган. Анда аюлар, бүре-төлкеләр, поши-боланнар, башка күптөрле кыргый җанварлар, җәнлекләр яшәгән. Аларның барысы да әнә шул ургып аккан чишмә-кизләү суын эчкәннәр. Ләкин тора-бара бу төбәккә килеп йөргән күчмә халык, урманны кисеп, агачларны төпләп, иген игәргә җир ясаган, кизләү тирәли йортлар салып, утрак тормыш башлаган.

Башка урыннарда бик сирәк була торган хәл — кизләү суыннан бераз гына күкерт тәме, күкерт исе килеп тора. Бәлки, аның әнә шулай күкертле булуы аны тагын да саф, эчеп туймаслык тәмле итәдер. Ә аның хуш исе бөтен кизләү тирәсенә тарала.

Биредәге су исе дә авылның кизләү тирәсен хәтерләтә. Газизнең җанын бимазалаган, күңеленә авыр йөк булып сарылган уйлар шул киңлектә, шул хуш исле саф җилдә таркалып китәләр һәм бераз онытылып торалар...

Соңгы вакытта Газиз үзе дә дөньяда яшәү мәгънәсе турында еш уйлана. Еш кына үткәннәрне искә ала. Яшьлек — киләчәк, картлык үткәннәр белән яши, диләр. Яшь чагыңда гел киләчәгең турында гына уйлыйсың, аның турында кайгыртасың. Олыгайгач исә күбрәк үткәннәр турында уйлыйсың, шулар белән яшисең, балачагыңны, яшьлегеңне, дусларыңны, сөйгәннәреңне искә аласың, дөрес яшәдемме икән, дип, үз-үзеңә сорау бирәсең, шуңа җавап эзлисең. Кайчандыр ул урыс язучысы Борис Горбатовның әсәрләрен яратып укыган иде. Бер геройның: «Двадцать два года, двадцать два года, а для бессмертия ничего не сделано», — дип пошынганы Газизнең хәтерендә уелып калган. Егерме ике яшьне үтеп, илле яшькә җитте ул, тик үлемсезлек өчен берәр нәрсә эшли алдымы соң?! Атасыз үскән ачлы-туклы балачак, кимсетелгән үсмер чак, кием булмаганнан кызлар янына чыгалмый үткән егет чак... Беренче мәхәббәт Сәрмәдия... Армия хезмәте... Архитектура факультеты... Проект бүлеге... Чернобыль... Нурсибә... Никадәр каршылыклы хатирәләр! Тик аларның берсе генә дә үлемсезлеккә нигез бирә алмыйлар. Хәтта Чернобыль дә. Киресенчә, ул синең үлемеңне тизләтә генә, Газиз туган!

Әллә ни ерак китмичә, ишегалдында шулай уйланып йөргәндә, Газиз таныш тавыш ишетте:

— Газиз абый!

Болай да тузынкы чәчләрен җилдә туздырып, җил-җил атлап Айсылу килә икән. Йөзе үзгәргән, күзләре дә нидәндер курыккан кеше күзләре төсле. Ул ашыгып килде дә, ишегалдында йөреп торган курортчылардан да тартынмыйча, Газизнең күкрәгенә капланды.

— Нишләп бер дә күренмисең?.. Үзеңне бөтенләй югалта яздым...

Газиз бу ханымның хискә бирелүчән, тойгылы булуына күнегеп килә. Шулай да аның бу мизгелдә нәрсә әйтергә теләгәнен бик үк аңлап бетермәде.

— Мин бит монда...

— Бүген процедуралардан арып кердем. Бераз ял итеп алыйм дип яткан идем, йокыга киткәнмен. Ай, шундый куркыныч төш күрдем! Төшемдә сине күрдем. Зур су, имеш, син көймәдә, ә мин яр буенда. «Көймәңә мине дә утырт инде», — дип кычкырам, имеш. Син ишкәкләрең белән ишәсең, ишәсең, ә көймәң миннән ерагая бара. Агым сине каядыр өстери дә өстери... Уянып киттем — йөрәгем дөп-дөп тибә. Әллә синең белән бер-бер хәтәр хәл булдымы дип торам. Сикереп тордым да сезгә чаптым. Габделфәт абый: «Ул һава суларга чыгып китте», — диде. Шуннан соң гына бераз тынычландым...

— Һи-и, тавык төшенә тары кергән инде, — диде Газиз, елмаеп. — Әнә диңгез, әнә көймәләр, баржалар, теплоходлар, меңтөрле башка суднолар... Телисең икән, яр кырыена төшәбез дә, берәр балыкчының көймәсен алып, хәзер үк диңгезгә чыгабыз.

— Юк, юк! Елга буена төшәргә риза, ә көймәгә керергә — юк. Куркам мин. Үзем өчен түгел, синең өчен куркам. Шундый сәер төш...

— Нәрсә, бүредән куркып, урманга бармаска дисеңмени?

— Юк, урманга да бармыйм, елгага да төшмим. Мин элек тә урманнарга да, елга-күлләргә дә йөрмәдем. Әйдә дип чакырган кешем дә булмады, аңа үкенмим дә. Минем башта хәзер башка уйлар.

— Нинди уйлар инде алар, Айсылу ханым? Сер булмаса, сөйләп җибәрегез, зинһар өчен, — диде Газиз, шаян тон белән.

Айсылу да аның шулай вакыт-вакыт шаяртып сөйләшүенә күнегеп килә. Шаярта икән, бик әйбәт, димәк, кәефе шәп, күңеле күтәренке.

— Мин сине шефлыкка алырга уйлап торам.

— Ничек була инде ул?

— Бик әйбәт була. Син авыру кеше, ләкин синең сәламәтлегең турында кайгыртучы кешең юк. Ә мин — табибә. Башка аргументлар да бар.

— Алары нидән гыйбарәт?

— Күрүемчә, төпле, ышанычлы кеше син, Газиз абый, — диде Айсылу, ярым шаяртудан җитди сөйләшүгә күчеп. — Син миңа чын-чынлап ошыйсың. Юк, ошау гына аз, әлбәттә. Мин хәзер гел синең турында гына уйлыйм. Ярата башладым бугай үзеңне. Чын менә... Ләкин бел: мин сиңа тагылырга уйламыйм. Мин бүген үземә тиң кешене таптым дип уйлыйм. Инде ялгышам икән — әйт!

Айсылу Газизнең беләгеннән кысып тотты. Газиз исә уйга калды, аңа ничек итеп хәлен аңлатырга белмәде. Юк, Айсылуның үзе турында ул яхшы уйда. Әгәр сәламәт булса, ул аңа бүген үк тәкъдим ясар иде. Ә болай... Айсылуны өметләндереп ялгышмасмы ул? Эх, теге җырдагы кебек, тагын гомер булса икән.

Гомер уза, аккан сулар кебек,
Йөрәкләрдә кала ярасы;
Кемнәр әйтер, кемнәр санап бирер —
Тагын күпме калды барасы?

Тагын күпме калды икән соң барасы? Булсын иде хет дүрт-биш ел. Ул чагында Газиз үзе дә каршы килмәс иде, чөнки ул бу асыл затны үз итә...

— Син дә миңа ошыйсың, Айсылу акыллым. Ләкин мин сине бәхетле итә алырмынмы соң? Гәрчә мин үзем моңа ышанмыйм, турысын әйтәм. Күреп торасың бит хәлемне. Шулай да мин синең белән бәхетле бүген...

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, тагын яшь каен урманына килеп җиткәннәр иде. Сентябрь кояшы инде киң елганың теге як яры артына яшеренгән, анда кызгылт офык кына күкне бизи. Елга ягыннан һаман талгын җил исә, татлы су исе борыннарны татлы кытыклый. Ничек кенә булмасын, Газиз белән Айсылу тормышында искиткеч матур, хәтта күпмедер дәрәҗәдә хәлиткеч кич иде бу. Шуңамы Газиз Айсылуны тынычландырып кочагына алды. Айсылу каршы килмәде. Бу вакытта аларның баш очында яшь каен яфраклары гына, шыбыр-шыбыр килеп, нәрсә турындадыр сөйләшәләр иде...

* * *

Ниһаять, курортның музыка өчен җаваплы кешесе эштә күренде. Бу форсатны беренче булып Айсылу файдалангандыр:

— Ринат матурым, вальс кичәсе үткәрик. Халык вальс тели. Туйдык без синең кыргый музыкаңа сикерүдән. Адәм рәтле бер кичә булсын әле. Музыкаңны әзерлә. Иң яхшы классик вальслар булсын. Чайковскийны да онытма, үзебезнең татар композиторларын да керт...

«Халык вальс тели» дигән сүзгә музыкант каршы килә алмады. Аның эше — ял итүчеләр мәнфәгатен кайгырту, аларның теләген үтәү. Иртән-иртүк игъланнар тактасында эре хәрефләр белән «Вальс кичәсе» дигән белдерү эленде. Баянын фәкать бер төркем ял итүчеләрнең иртәнге гимнастикасы вакытында гына кычкырткалап йөргән егеткә курортчыларны тәмам туйдырып бетергән репертуарны алыштырырга туры килде. Шкафта, әрдәнәдәге утын пүләннәре кебек, өсте-өстенә өелгән дистәләгән кассеталар арасыннан кайсыдыр бер вальс сөюче курортчының бүләк итеп калдырган өр-яңа кассетасы килеп чыкты. Бу — «Классика шедеврлары» сериясеннән егерме иң яхшы вальс кергән кассета иде. Анда Штраус, Шопен, Григ, Сибелиус, Чайковский, Брамс та бар иде. Кызганыч, егетнең татар вальслары тупланган кассетаны әлегә кадәр күргәне булмады, югыйсә ул кичен татар композиторлары иҗат иткән вальсларны да уйнатасы иде. Хәер, әлеге кассетаны табуына да бик шат иде ул, чөнки музыкаль зәвыгы булмаган бу яшь егетнең «әрдәнәсе»ндә җыен юк-бар кассеталар гына аунап ята. Татар вальсларын чыгарган очракта да андый байлыкның бу егет шкафында булуы икеле иде.

Айсылу иртәдән вальс кичәсенә әзерләнде. Ул көнне аның дәвалануы дәвалану булмады, гел ашыкты. Ваннасында да, массажында да, башкасында да озак тоткарланмады. Бүлмәсенә кайтып, чемоданда бөгәрләнеп яткан яңа күлмәген үтүкләде, чәчтарашка төшеп, тузгыган чәчләрен төзәттерде. Аннары көзге каршына утырды, тик үзе белән алып килгән иннеген дә, кершәнен дә сөртмәде, сөрмәсен дә тартмады, чөнки утыз өчтә дә ул әле кияүгә чыкмаган кызлар кебек яшь, сылу иде.

Менә кич булды, вальс кичәсенә төшәр вакыт җитте. Ә залда... һичкем көтмәгәнчә халык күп, барысы да сихерләнгәндәй кичәгә җыелган, чөнки әлегә кадәр мондый кичәнең бу курортта булганы юк, киләчәктә дә булуы шикле иде. Бу гади вальс кичәсе генә түгел, ә чын бәйрәм кебек — кыз-кыркын да, егет-җилән дә, гүзәл-гүзәл ханымнар да, ир-атлар да иң күркәм, иң пөхтә киемнәрен киеп төшкәннәр. Алар арасында Айсылу исә барысыннан да аерылып тора. Ул үзенә бик килешеп торган, әле беркайчан да кимәгән, гәүдәсенең сылулыгын аермачык күрсәтеп торган, затлы тукымадан тегелгән ап-ак күлмәктән, шундый ук ап-ак биек үкчәле туфлидән. Кара чәчләре җиңелчә бөдрәләнеп тора — хан кызы кебек сылу, кызлар бәйгесендә җиңү яулаган туташ кебек гүзәл иде.

Айсылу залдагылар арасыннан Газизне эзләде. Иш ише белән дигәндәй, гөлт итеп торган якты, һәрьяклап бәйрәм төсе кергән зур залда һәркем үз парын барлап, сөйләшеп, вальска әзерләнә иде. Яшьләр дә, урта яшьтәгеләр дә үз ишләрен караштырдылар. Айсылу исә биредә бер генә кешене үзенә лаек пар итеп таный. Хет биш дистәсен тутырган булсын, хет авырсын, ләкин аның күңеле фәкать шул ке-

шедә генә. Курортта гына түгел, бәлки, бөтен төбәктә, юк, бөтен бер илдә, бөтен җиһанда бердәнбер кеше ул хәзер аның өчен. Һәм башка кеше аңа кирәк тә түгел...

Әмма Газиз күренмәде. Ул да биергә төшәргә тиеш иде бит. Айсылу нишләптер аларның бүлмәсенә кагылырга уңайсызланган иде. Керәсе калган икән. Ул борчылып көтә бирде.

Залда вальс яңгырады. Ашкынулы музыка тавышы бөтен бинага таралды, залга җыелган барлык курортчыларның игътибарын җәлеп итте, күңелен күтәреп, хәрәкәткә китерде. Кайберләре инде парлаша да башлады.

Нәкъ шулчак залның киң итеп ачып куелган ике яклы ишек уртасында Газиз күренде. Мәһабәт төз гәүдәле, арыслан ялы кебек күпереп торган дулкын чәчле, фәрештә кебек ап-ак киемнән — ак күлмәк, аксыл чалбар, ак оекбашлар белән шундый ук ак туфлиләр. Айсылу, аны күрү белән, талпынып куйды. Газиз дә зал тулы халык арасыннан үз кешесен тиз табып алды. Ул һәрвакыттагыча тыйнаклык һәм олы сабырлык белән, ашыкмыйча гына атлап, Айсылу янына килеп басты. Һәм, ни гаҗәп, шул мизгелдә бер мәртәбә авызы пешкән ирнең күңеленә кинәт шик төште: ә бәлки, ул бүген дә «юк» дип башын чайкар, ышан син хатын-кызга! Бар нәрсәгә әзер булып тору яхшы...

Юк, бу юлы Айсылу күндәм иде. Алар парлашуга, залдагылар бер нәрсәгә игътибар иттеләр: кавалер белән дама икесе дә пөхтә, матур, ак киемнән, икесе дә төз, сылу гәүдәле, икесе дә җилкенеп вальска биилә һәм аларның биюе залдагы башка биючеләрнекенә караганда күпкә дәртлерәк, нәфисрәк, сыгылмалырак иде. Вальсны болай чын күңелдән яратып, аның һәр нечкәлеген белеп, бар күңелләрен биреп, уңга да, сулга да тигез һәм җиңел әйләнеп биючеләр дә фәкать алар гына булгандыр. Ул гынамы соң әле. Музыканың иң күтәренке бер мизгелендә Газиз Айсылуны кочагыннан ычкындырды да, сул кулыннан алып, аны үз әйләнәсендә әйләндерә башлады, аннары капма-каршы якка үзе дә әйләнеп китте һәм, өч-дүрт әйләнеш ясап, бикәсен кабат биленнән алды һәм аны сул беләгенә салды. Бу вальсның кульминациясе иде һәм аны, әлбәттә инде, бары тик Газиз белән Айсылу гына башкара алгандыр...

Айсылуның күптән вальска болай биегәне юк иде. Бу минутларда ул үзен чиксез бәхетле сизде һәм, кулын Газизнең җилкәсенә салган килеш, шатлыклы елмаеп, коңгырт күзләрен Газизгә төбәде. Ә җиңел туфлиләр кигән төз, нык аяклары үзенекен эшләде. Вальска артыгы белән һәвәс Газиз белән бию аңа җиңел дә, рәхәт тә, залдагылар арасында абруйлы да иде...

Дулкын-дулкын булып агылган музыкага җилләнеп әйләнү уңаенда, Айсылу:

— Газиз абый, сиңа чын күңелдән рәхмәт! Бәйрәм бүләк иттең син миңа. Болай матур итеп күптән вальс әйләнгәнем юк иде. Мин бүген бик бәхетле! — диде.

— Вальсны да бәхеткә саныйсыңмыни?

— Саныйм, Газиз абый. Синең белән танцы итүем мине тирән рухландыра, бәхетле итә. Һәм нинди бәхет әле!..

Айсылу кабынып, дәртләнеп, хисләнеп әйтте бу сүзләрне.

Тик...

Әнә шундый чиксез хозур белән вальс әйләнгәндә, Газизнең кинәт күз аллары караңгыланды, ул сөрлегеп китте һәм бер якка ава башлады. Ярый әле Айсылу аны тотып калды һәм, нидер сизеп, Газизне тиз генә уртадан алып чыкты.

Газиз:

— Ах, на-чар... — диде өзеп-өзеп һәм, күзләрен йомып, диварга терәлде.

Гөләп торган залдагы халык моны күрми дә калды. Айсылу аның хәле шәптән түгеллекне аңлады һәм, тотыштыргалап, залдан алып чыкты да бүлмәсенә чаклы озата менде. Бу вакытта Габделфәт тә — каян белеп алган диген син аны? — арттан йөгерә-йөгерә менеп җитте һәм Газизне күтәреп алып урынына салды.

— Син, Айсылу, монда кал инде. Мин шәфкать туташларын алып менәм, — дип, ул кабат аска йөгерде.

Шәфкать туташлары, тиз генә килеп, Газизгә укол кададылар, аның кан басымын үлчәделәр. Айсылу да үзенчә ярдәм итеп карады. Ләкин моннан авыруның хәле үзгәрмәде, «ашыгыч ярдәм» чакырырга мәҗбүр булдылар. Ярты сәгать дигәндә, күрше каладан, кош кебек очып, «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җитте. Табиблар төрле ысуллар белән авыруның хәлен яхшыртырга маташтылар, тик ул уңайга үзгәрмәде.

— Мондый хәлдә калдырып булмый, алып китәбез, — диде соңыннан өлкән табиб. — Җыенырга кирәк...

Газизнең шундый хәлгә таруыннан аптырап, каушап киткән Габделфәт бу минутта нәрсә эшләргә дә белмәде: тәмам хәлсез яткан бүлмәдәшенең яланаякларына оекбашлар кидерде, йә күлмәгенә, йә спорт костюмына тотынды. Аннан хастаханәдә иң кирәк булачак киемнәрен бер полиэтилен пакетка җыя башлады. Аның Газизне озата барырга иде исәбе. Моны чамалаган Айсылу, катгый итеп:

— Юк, Габделфәт абый, үзем озатам, — диде.

— Ә сез кеме буласыз аның? Без беркемне дә утыртып йөрмибез мондый вакытта, — диде «ашыгыч ярдәм» табибы.

Күпне күргән, күпне белгән Айсылу-табибә, шартлатып:

— Мин аның хатыны, — диде һәм ике сөйләргә урын калдырмады.

Габделфәт Газизне носилка белән күтәрешеп чыкты.

— Тиз терелеп кайт, Газиз, малай, мин китмим әле, сине көтәрмен, — диде ул һәм күзләренә бәреп чыккан яшьләрен сөртеп алды. Тик Газиз аның әйткәннәрен әллә ишетте, әллә юк — күзләре йомык иде.

Айсылу машинага кереп утырды һәм носилкада яткан Газизнең өстенә одеял япты. Нәрсә генә, ничек кенә булмасын, ул аны күз уңыннан ычкындырмаячак хәзер. Газизне озата чыгып Айсылу дөрес эшләде. Ниһаять, ул шуны аңлады: Газизнең хәле авыр, чиксез авыр. Берничә көн аралашканнан соң, ялгызлыктан гаҗиз булган Айсылуның үзе кебек үк ялгыз Газиз белән уртак тел, аңлашу табып, соңыннан аңа сыену мөмкин булмасмы дип уйлаган иде. Әллә ничек шунда, бөтен нәрсәдән бәйсез, ирекле бу кеше аның бар игътибарын үзенә җәлеп итте, бөтен ягы белән аңа ошады, аны аңлый алды, дәртен уятты, күңелен җилкетте-җилпетте, җанын эретте. Авылда туып үсеп, соңгы вакытта калада яшәсә дә, холык-фигыле, гадәтләре, саф күңеле белән һаман авыл кызы булып калган Айсылуның Газиз белән аралашкан кыска вакыт эчендә өметләре кабынган иде. «Мин үземә тиң кеше таптым бугай» дип уйлаган иде Айсылу. Әйе, сәламәтлеге шәптән түгел. Күп нурланыш алган кешенең хәле ничек икәнен, киләчәктә дә ничек буласы турында бер генә уйламады табибә. Ләкин нурланыш алганнар арасында да төрлесе бар. Әнә ничек җилкенеп, дәрт белән вальс әйләнә бит Газиз, авыру кешегә һич охшамаган. Әгәр ул исән калса, терелеп китсә, алар, шәт, бергә калырлар, кушылырлар, Ходай биргән гомернең ахырына чаклы гөрләшеп-чөкердәшеп бергә яшәрләр. Тик Газиз белән генә бер-бер көтелмәгән хәл булмасын. Ә Айсылу-табибә үз чиратында аның сәламәтлеге өчен киләчәктә бөтенесен эшләячәк, барлык көчен куячак. Исән генә булсын!!!

Айсылу, одеял астына тыгылып, авыруның салкынча кулын җылы учына алды. Газиз шунда авырлык белән генә күзләрен ачты, Айсылуга карады һәм көче җиткән чаклы аның кулын кыскандай итте. «Рәхмәт сиңа!» дидеме ул, әллә Айсылуның аны якын итеп, үз итеп озата баруыннан канәгать калдымы? Һәрхәлдә, бүген ялгыз түгел ул, аның янында ышанычлы кеше — үз кешесе бар. Хәтта үлә-нитә калса да янында якыны була. Ә үлем... Ул бар, аннан барыбер котылып булмас, ахры. Иртәме-соңмы — барыбер котылып булмас.

Яшәү, үлем — бары тик бер сукмак,
Нигә башка сукмак юк икән?..

Нигә башка сукмак юк икән соң? Һич югында, нигә ул сукмак бераз озын түгел? Алда никадәр эше бар иде Газизнең. Төгәлләнмәгән проектлар, барасы, чыгыш ясыйсы митинглар, көрәсе, сөйләшәсе кешеләр, тагын әллә нәрсәләр...

«Чи-у, чи-у, чи-у...» «Ашыгыч ярдәм» сиренасы Газизнең колагында хәвеф хәбәрчесе булып түгел, ә нindидер музыка булып яңгырый. Тик ул музыка нишләптер ике тактлы гына, вальс кебек өч тактлы түгел. Ике тактлы гына булса да, аңа вальс әйләнергә мөмкин сыман. Әнә... бииләр бит әле кешеләр... Нindидер якты зал. Яп-якты. Көпә-көндез. Тәрәзәләрдән кояш нурлары сирпелеп тора, Газизгә әлегә кадәр һич таныш булмаган зал. Залның әле түшәме дә юк, шуңа якты икән. Кайда соң ул, нишләп йөри һич күрмәгән, белмәгән җирләрдә? Зал тулы халык, барысы да ак киемнән. Һәм «чи-у, чи-у» дигән музыкага котырынып вальс әйләнәләр. Шул халык арасында әнә Сәрмәдия дә биеп йөри. Гаҗәп хәл: Газиз элек хатынының вальс әйләнгәнен хәтерләми иде. Сәрмәдиянең өстендә һинд хатын-кызлары киеменә охшаган эленке-салынкы ак тукыма кием. Чит-ят кешеләр белән ут чыгарып биеп йөргәнгә күрә, Газиз аны күрмәмешкә салыша, хатыныннан кача, имеш. Ләкин кача алмый кала — Сәрмәдия аны күреп ала һәм биергә чакыра: «Синең дә вакытың җитте», — ди ул. Нинди сүз бу, нәрсәгә «вакытың җитте» дип әйтә ул?

Менә алар Сәрмәдия белән вальс әйләнәләр. Кара инде, Сәрмәдия дә бик оста бии икән бит! Тик аның кием генә нигәдер асылынып-асылынып төшә һәм биергә комачаулый. «Монда тыгыз, әйдә, күккә менәбез», — ди Сәрмәдия. Һәм алар, шулай әйләнә-әйләнә, ачык түшәмнән иркен күккә менеп китәләр...

Машина юл сикәлтәсендә сикереп куйды һәм Газиз бер мизгелгә генә аңына килде. Аннары, упкынга тәгәрәгәндәй, кабат аңын җуйды. Күпмедер вакыттан соң ул тагын аңга килде, тагын каядыр убылды.

Кызыл Хач билгесе белән бизәлгән ак машина, олы юлда барлык утларын яктыртып, һаман шулай чыелдый-чыелдый, гаять зур тизлек белән алга чабуын дәвам итте.

Бу минутларда Айсылуның башында очсыз-кырыйсыз уйлар чуалды. Йа Хода, шулай ук яңа бөреләнеп килгән хыяллары, канатланып барган өметләре өзелер микәнни? Тагын бәхет читләтеп үтәрмени соң инде? Нигә шулай мәрхәмәтсез аңа бу язмыш?..

Газиз янында чүгәләп утырган Айсылуның мөлдерәп тулган күзләреннән агарып киткән бите буйлап тыелгысыз кайнар яшьләр тәгәрәде...

# Каеннар юлы

Гашыйклар юлы каен,
Каеннар юлы кайгы...

*Әнгам Атнабаев*

## Беренче кисәк

### I

Каенлы Чишмәгә яңа урман каравылчысы куйдылар. Бу зур авылның үз урман каравылчысы беркайчан да булмады. Сугыш һәм сугыштан соңгы елларда әлеге хезмәттә Әнтәй авылы чуашы Пайморза торды. Яше олы иде — сугышка алмадылар. Ир-атсыз, теләксез калган татар авылында карт чуаш азынды, авыл өстенә ишелеп торган урман була торып та халыкны утынга тилмертте, гел үз урманы сыман кыланды. Сәрхуш урман каравылчысына бер чөллисез якын килмәле дә түгел. Утын сорап барган кешегә аның беренче сүзе: «Пер чиртук», — булды. Сугыш хәсрәте белән генә түгел, ачлык-ялангачлык, авыр колхоз эше белән дә тәмам йончыган, чыгырдан чыккан, очын очка ялгый алмый интеккән, сугышта ирен югалткан хатынга каян килсен инде ул чиртук? Сугышта һәлак булган ире өчен ишле балаларга тигән юк-бар пенсия дә кулга тими, йә заем, йә салым дип тотып калалар.

Бик салкын бер кышта үз урманында буранда адашып калды исерек Пайморза, гәүдәсен яз көне генә таптылар. Ләкин үзен кызганучы булмады, халыкның канын бик нык эчкән иде шул. Эзләгәнен тапты, дип, каенлылар җиңел сулап куйды.

Яңа урман каравылчысы да читтән, Таллы Елга авылыннан, сугыштан исән-имин әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән, уңып беткән гимнастеркасын да салырга өлгермәгән яшь керәшен егете иде. Исеме — Микулай. Кайдадыр урманчылыкка да укып кайткан.

Микулай үзеннән бик яшь Сандрасы белән башта авыл очындагы ялгыз картлык кичергән Миңлезифа карчыкта фатирда яшәде.

— Өемә чукынмас булсагыз гына кертәм, — диде бакый дөньясы турында кайгырта башлаган әбикарчык.

— Жук, жук, Минзипа әби, без җәшләр бит әле, савитча җәшибез, — диде Микулай, һәм әби кертергә риза булды. Кертми ни... Мичкә ягарга әрәмәдән чыбык-чабык ташый-ташый арып-талып беткән карчык Микулайдан «Утынга аптырамабыз» дигән сүзне ишетү белән үк риза иде инде аларны фатирга кертергә. Урманчы, урман каравылчысы ла! Каены бар кайгырмас, тимере бар тилмермәс. Утынга аптырамаслар әле, Аллаһы боерса!

Микулай белән Сандра өйләнешкәннәр генә, балалары юк иде әле. Яңа гына уналтысын тутырган керәшен хатынын күреп, Каенлының ир-егетләре аһ итте. Гүзәлләрнең дә гүзәле иде Сандра! Ул зифа каендай буй-сыны, ул алсу-ак көләч йөзе, ул болыт кебек күпереп торган аксыл куе чәчләре, шаян очкын сирпеп торган зәңгәр күзләре, кыйгач-нечкә кара кашлары, энҗе кебек тезелеп киткән ап-ак тешләре, зәңгәр бизәкле ситсы күлмәгеннән изүенә сыеша алмый яртылаш ташып чыккан йомры-йомры күкрәкләре... Аһ, аның шул матур күкрәкләрен килешле селкетеп, авыл ир-атларын чиксез дәртләндерепымсындырып, җиңел адымнар белән авыл урамыннан уйнаклап үтүләре! Табигать биргән мондый да сылулыкка ия яшь кызны ничек үзенә карата алгандыр кипкән балык кебек ябык, какча гәүдәле, очлы борынлы, тәмәке тарта-тарта саргаеп беткән төксе йөзле, эре тешле урман каравылчысы — анысы халыкка сер булып калды.

Ләкин Микулай да төшеп калганнардан түгел икән — бер ел да узмады, Миңлезифа карчык янәшәсендә генә, кыр капка төбендә урын алып, шалкан кебек таза, ап-ак усак бүрәнәләреннән өр-яңа өй салып куйды. Үзенең дә кулыннан килмәгән эше юк икән: бурасын да бурады, кыегын да ясады, тәрәзәләрен-ишеген дә куйды, аларга яңаклар һәм кысаларны да үзе кысты, түшәм белән идәнне дә үзе җәйде. Аның уңган-булган, тырыш урманчы гына түгел, кул эшенә дә бик сәләтле, һәвәс кеше икәнен Каенлы халкы әнә шунда белде.

Миңлезифа карчыкның сөйләвенә караганда, ирле-хатынлы керәшеннәр әйбәт кенә, тавыш-тынсыз, аңлашып яшиләр иде. Тик бер генә борчулары бар иде аларның — Сандра балага узмый торды. Бер ел, ике ел үтте. Бергә яшәүләренә өч ел тулып килгәндә генә, Сандраның көмәне барлыгы беленде. Яңа туган малайга керәшеннәр үзләренчә Данка дип исем куштылар, ләкин Каенлы балалары арасында ул Данил булып үсте. Биредә Сандраны күптәннән Сания дип йөртәләр иде.

### II

Гадәттә, авылда сер саклау мөмкин түгел. Барысы да бер-берсенең тормышын бөтен нечкәлекләренә, энәсеннән җебенә кадәр белеп, күреп тора. Каенлы Чишмәдә исә өч ел элек кенә килеп яши башла-

ган керәшеннәр гаиләсенең тормышы гына бик озак сер булып кала бирде. Миңлезифа әби дә сер саклый торган карчыклардан иде — үзе үлгәнчегә кадәр беркемгә бернәрсә җиткермәде. Үләр алдыннан гына...

Ярый әле Микулай белән Сандра янәшәсендә Миңлезифа карчык яшәгән. Ул булмаса, кем саклаган булыр иде ул серне дә, аны соңыннан булса да кем ачкан булыр иде?!

**III**

Сандра-Санияне күргәннән соң аның матурлыгына сокланып, дөньяларын онытып аңа гашыйк булып йөргән ир-егетләр арасында Каенлының тимер остасы Сафуан да бар. Көмешсу елгасына барып кушылган мул сулы Тирәкле инеш буенда, авыл артындагы аулак, тәбәнәк алачыкта ут көйрәтеп, бер кулына кыскыч белән кып-кызыл булып кызган тимер тоткан, икенче кулында бозау башы чаклы чүкеч уйнаткан, Алып батыр кебек таза, инде вакыты күптән җиткән булса да һаман өйләнмәгән, сазап барган егет иде Сафуан. Төскә-биткә дә Ходай аны мәхрүм итмәгән, телгә-сүзгә дә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел, түше дә, һушы китәрлеге дә бар. Осталыгы белән исә үз авылында гына түгел, тирә-якларда да дан тоткан, Лесков сулагае кебек борчаны дагалардай тимерче иде ул. Тимер эшеннән тыш оста калайчы да, агач эшенә дә, мич чыгарырга да — һәрнәрсәгә кулы ятып тора. Бер кимчелеге бар иде Сафуанның — сул аягына сизелер-сизелмәс кенә чатанлый иде ул. Балачакта бишектән егылып төшкән дә аягын имгәткән икән. Шуңа күрә, яше җитсә дә, иптәшләрен өере белән сугышка алып киткән вакытта аны алмадылар. Бәхетенә, егылып төшкән, бәхетенә, аягын каймыктырган диярсең, чөнки сугышка киткән зур бер төркем иптәшләре арасыннан авылга әйләнеп кайтканнар өч-дүрт кенә кеше иде. Аның каравы шул афәт елларында Сафуан чын тимерче булып өлгерде. Алай гына да түгел, ярлы колхозның, авыл халкының олы терәге иде ул. Кемгә нинди тимер-томыр, корал кирәк, Сафуанга гына килә. Бу карусыз, киң күңелле, шат йөзле егет эшләп бирмәгән корал булдымы икән кайсы да булса бер йортта? Юктыр.

Сафуан гүзәл Сандра белән якыннан аларның бураларын күтәргән көнне, өмәдә танышты. Миңлезифа карчыкның тәбәнәк киртә белән әйләндереп алынган хәтфәдәй чирәмле ишегалдына туксан чыгып, туксан керде Сандра, чөнки өмәдәгеләр өчен аш әзерли иде. Аннары шул чирәмгә җәймә җәеп, шуңа тиз-тиз аш-су, чәй-мәй, тәм-том ташыды, дистәгә якын ир-атны кыстап-кыстап ашатты, эчертте. Сафуан аның һәр хәрәкәтен күзәтеп, аңа кызыгып карап-карап алды, гәрчә мондый карашын башкаларга сиздерергә теләмәсә дә. Ләкин Сандра сизде, фәкать гүзәл затларга гына хас сизгерлек белән сизде тимерченең өмет белән өртелгән карашын.

Төшке аштан соң савыт-сабаны җыеп, аны юып куйды да беравык тәрәзә аша гына ирләрнең эшләүләрен карап торды. Әллә ничек, аның күзе гел озын буйлы, таза гәүдәле Сафуанга төште. Юан-юан бүрәнәләрнең бер башыннан ике-өч кеше күтәрсә, икенче башыннан Сафуан берүзе генә күтәрә, һәм ул аны уйнап кына, җиңел генә күтәрә сыман. Тимерчегә күзе төшеп, сокланмый кала алмады Сандра.

Сафуан исә соң гына өенә кайтып, урынына аугач та Сандраны искә алып ятты. Менә пөхтә иттереп киенгән яшь хатын, җәлт-җәлт атлап, аш-су ташый... Менә ул, башкаларга сиздермичә генә, Сафуанга аяз күк кебек зәңгәр күзләрен сирпи. Шул чагында аның алсу-ак йөзендә елмаю чагыла...

Иртән алачыгына барганда да ул кабат Сандра турында уйлады, аны тагын күрәсе килеп китте. Ләкин аңа байтак вакыт Сандраны күрү насыйп булмады. Инде яшерен сөйгәненә әйләнгән хатын турында уйлаулар бераз онытылып торган беркөнне, әллә яңа өйгә төрле тимер җиһазлар кирәк булганга, әллә соң башка бер мөһимрәк сәбәп белән Сафуан алачыгына, җил уйнатып, Сандра үзе килеп керде:

— Арулармысез, Сапуан абый...

Авыл мунчасы кебек бәләкәй, кар базыдай тар, сөремнән каралып, тимер тузанына батып беткән алачыкка саф һава, дөнья яме, көләч йөз, якты нур, әлегә кадәр Каенлының яшь кызларында да булмаган гүзәллек алып керде Сандра. Сафуан бу хәлдән башта өнсез калды — яшь хатынның сәламен алырга онытып, шактый вакыт авызын ачып, сокланып туялмыйча, аның аяз көндәге күк йөзе сыман зәңгәр күзләреннән, алсуланып пешкән алма кебек түгәрәк йөзеннән, чия кебек карасу-кызгылт иреннәреннән, изүеннән тулып ташкан күкрәкләреннән күзен алалмый карап торды. «Чибәр, ай-һай, чибәр, каһәр, бер кашык су белән йотып җибәрерсең...» Һәм аның күңел түрендә кабат татлы, ләкин гөнаһлы теләк кымырҗый башлады: «Әллә бар нәрсәгә кул селтәп, бер яратып, сөеп, татып калыргамы соң бу гүзәлне?»

Ниһаять, Сафуан телгә килде:

— Әйдә, Сания матурым, түрдән уз! Утыр дияр идем, урын тузанлы. Әллә соң тезләремә генә утыртып торыйммы үзеңне? — диде ул, шаяргандай итеп.

— Алай озак торырга бүгөн бакыт җук шул, Сапуан абый.

— Ни йомыш соң, матурым?

— Миңа, Сапуан абый, җәмки* кирәк эйе, шуны җасап бирә алмассың микән?

Сандраның үзен күрмичә дә, тавышыннан гына да сихерләнерсең! Йомшак һәм искиткеч ягымлы иде аның тавышы. Бу тавыш аның күкрәгеннән ниндидер моң булып чыкты. Бирсә дә бирер икән гүзәллекне Ходай кешегә һәрьяклап!

— Җәмки дисеңме? Ярар, ясармын мин аны, Сания матурым, ясармын...

— Качан җасарсың икән?

— Иртәгә көндез бер арада әйләнә, ясап куярмын. Көтеп торам дисәң, хәзер үк ясап бирәм...

— Жук шул, әйтәм бит, бакыт жук, диеп. Иртәгенәк килермен алайса.

— Кил, кил, «эһ» дигәнче ясап бирермен мин аны сиңа, Сания.

— Җарар алайса, Сапуан абый, килермен. Ару бул!

Сандра тәмледән-тәмле хуш ис калдырып чыгып китте. Ай күрде, кояш алды. Сафуан исә әкияти бер халәттә калды. Йа Хода! Үзе, Сандра үзе килеп керде ич аның янына! Нинди бәхет! Бирим дисә колына... Ничек мөлаем сөйләшә! Нәрсә диде әле? Сафуан «Әллә тезләремә генә утыртып торыйммы?» дигәч, Сандра «Алай озак торырга бөгөн бакыт жук» диде түгелме соң? Димәк, башка көнне аның озаклап торырга, хәтта тезгә килеп утырырга да уе юк түгел булып чыга...

Сафуан пәри куышы кебек алачыгында гүзәл Сандра белән көн буе, кич буе женләнде. Уйламаган уе, хыялланмаган хыялы калмады.

Икенче көнне иртән-иртүк ясап куйды Сафуан җәмкине. Ясап куйды да, тынычсызланып, Сандраның килеп керүен көтә башлады. Тизрәк килсен иде, тик кеше юк чакка туры килсен иде. Алайса монда юк-бар йомыш белән йөрүче эшем кешеләре бетмәгән.

## IV

Сафуанның теләгәне-юраганы юш килде: Сандра чыннан да аулак вакытта килеп керде. Кичә аның өстендә гадирәк кием иде кебек, ә бүген ялт итеп торган матур бәйрәм күлмәге. Керәшен хатын-кызлары гына оста итеп тегә белгән, борынгыдан калган милли үрнәкләр белән бизәлгән, әйтерсең салават күперендәге барлык төсләргә буялган өлгеләрдән җыелып тегелгән — Сандраның төз гәүдәсенә сыланып торган гаҗәеп килешле күлмәк. Аягында ап-ак йон оеклар һәм ялтыравыклы, очлы тирән башмак, башында өчпочмаклап бәйләнгән күзләре кебек үк зәңгәрсу яулык, күкрәгендә көмеш тәңкәләре ялтырап, чыңлап торган түшлек, муенында төрледән-төрле бизәкле муенса, колакларында көмеш алкалар. Алачыкка җәмки алырга гына түгел, ә Япрак бәйрәменә утырмага килгән хатыннарга охшаган Сандра. Аны шушы таң калырлык матур кием-салымда күреп, Сафуанның исе-акылы китте. Мондый да күркәмлекне, мондый да зәвыклылыкны аның әлегәчә күргәне юк иде. Шушы киемдә Сандраның энҗе кебек тигез ак тешләрен күрсәтеп елмаеп торуы барлык хатын-кызлардан да матуррак, сөйкемлерәк һәм сихерлерәк иде.

Шул елмаюлы килеш ул:

— Арулармысез, Сапуан абый. Мин килдем, — диде.

— Сәламәт кенә әле, Саниякәй гүзәл. Ә мин көттем, түземсезләнеп көтеп тордым синең килгәнеңне, ипидер менә, — диде тимерче, каушый-каушый, ләкин эчендәгесен яшерми, чын күңеленнән әйтте.

— Шолай бик сагынып көттенмени, Сапуан абый? — Сандра чытлыкланып елмаеп куйды.

— Ә нигә? Сагынып көттем. Әллә нишләттең бит әле син, Сания, Сафуан абыеңны. Юксындырасың, сагындырасың...

— И-и, Сапуан абый... — Сандра тирән итеп сулап куйды. — Үзем дә сагындым. Начылый килеп життем...

— Менә ошармы инде үзеңә? — диде Сафуан һәм яшергән җиреннән җәмкине алып бирде. Матур булсын дип, җәмкинең сабын сырлап ясаган иде тимерче.

Сандра аны кулына алып кыскалап та, тегеләй-болай да итеп карады, аннары, Сафуанга күз сирпеп, тагын сөйкемле елмайды:

— Бик матур, җайлы итеп җасагансын, Сапуан абый, рәкмәт! Мына әниләр күчтәнәч — каклаган каз җибәргәннәр эйе, — дип, кырыйлары чачаклы-чуклы итеп бизәлгән ак тастымалга төрелгән әйбер сузды.

— Миңа синнән бернәрсә дә кирәкми, Сания, әйбереңне алмыйм, үпкәләмә, — диде тимерче йомшак, ләкин катгый итеп.

— Ал инде, Сапуан абый, мин бит сина җаратып бирәм бу җазулы бистәрне*, истәлек итеп, — диде Сандра, үпкәләргә җыенган кыз кебек.

— Нинди бистәр? — Сафуан өчен бу сүз таныш түгел иде.

— Мына бу бистәр инде, — дип төртеп күрсәтте Сандра кулындагы чачаклы-чуклы тастымалга.

— Язуы да бармыни?

— Бар, җазуы да бар.

Сандра, бистәрен сүтеп, Сафуанга күрсәтте. Ак тастымалның бер читендә тамбур энәсе белән шундый сүзләр язылган иде: «Сапуан абыйга истәлек». Һәр сүз төрле төстәге чигү җебе белән язылган. Бу

инде кадерле бүләк, аны алмый калып булмый. «Истәлек» дип язылуы инде хәлне бөтенләй үзгәртә. Димәк, Сафуан гына Сандра турында уйламый, Сандра да уйлый аның турында...

— Тагын ничек бәкыйлләтим сун сине, Сапуан абый?

Сандраның бу сүзләре тимерчене тәмам исәрләндереп җибәрде.

Ул, кыюланып:

— Бер кочаклат, Сания җаным! Бигрәк матур, бигрәк ягымлы, бигрәк татлы инде үзең, гел акылдан яздырасың, — диде.

— И-и, Сапуан абый, кеше килеп керсә, мыскылга калабыз бит...

Әй Сандраның тел төпкәйләре! Мин кочаклатырга риза, Сафуан абый, тик без кочаклашып торган вакытта кеше генә килеп кермәсен дигән сүз бит бу...

Сафуан, алачыкның ишеген ачып, тышка карады. Аның бәхетенә, алачык тирәсендә яки бирегә таба килүче берәү дә күренми иде.

— Юк, беркем дә юк, — диде ул әллә ничек, тыны кысылып. Йөрәге күкрәктән чыгардай булып тибә, каны кайнарланып килә иде. Шул кайнарлану белән тузанлы алъяпкычын салып атты һәм кызу тәнле Сандраны кочагына алып кысты. Сандра исә калтыранып куйды һәм җылы, йомшак куллары белән үзе дә Сафуанның муенына сарылды... Вакыйга Сафуан көтмәгәнчә килеп чыкты. Шушы яшькә җитеп мондый да бәхетле мизгелне татыганы юк иде әле Сафуанның. Сандрасын әйт әле: Болгар ханбикәсе кебек затлы, матур киенеп, тузанга батып беткән тимерчедән кочаклатырга алдан ук уйлап килгән диярсең. Шулай ук җиңел-җилбәзәкме, әллә соң Алып гәүдәле, ягымлы тимерче артык ошап китеп гыйшкы төштеме аңа?

— Син мине бик азындырма, Сапуан абый, артыгын җараттырма, — диде Сандра, тимерченең кочагыннан чыкмыйча гына. Аннары өстәп куйды: — Үзеннен дә җараткан кызын бардыр әле, көннәшә башласа...

— Яратканым хәзер куенымда. Ә башканы белмим мин. Элек бер кызга күз төшеп йөри иде, кияүгә чыкты. Беләсең килсә, минем әле синең кебек кочакка алган кызым гомергә булмады.

— Сап җегетмени?

— Саф.

— Мин дә сап кыз бит, Сапуан абый...

— Ничек саф? Кияүгә чыгып та саф яшәп буламы?

— Була икән шул...

## V

Моннан соң Сандра Сафуан алачыгы бусагасын еш таптады. Җәмки генә түгел, аңа әле соскы да, күмер савыты да, мич капкачы да, тагын әллә нәрсәләр кирәк булып чыкты. Һәм килгән саен Сафуанның кочаклап алуыннан, иркәләүләреннән тәмам исереп кайтып китә торган булды.

Шушы кайнар очрашулар вакытында Сафуан үзенә сәер булган сорауларга җавап тапты. Теге юлы Сандра үзенең кияүгә чыгып та саф яшәве турында әйткән иде. Ничек була соң ул?

Микулайның Сандрага өйләнүе болайрак булган икән. Сугыштан соң бик озак госпитальдә дәваланып, тагын күпмедер вакыт урманчылыкка укып кайткач, егет гаиләдә өйләнү турында сүз кузгата. Әнисе Праскый түтәй, аның бу теләген күптән белгән кеше сыман:

— Мин сина килен карап куйдым, Микулай. Мына дийгән, асубый килен, — дип куя.

— Кем сун ул?

— Карга Гөргөри Сандрае. Бер җегет белән дә җөрмәде, чиста кыз. Андыен да асыл керәшен кызы безнен аулда гына төгөл, бөтөн керәшен дөнҗәсендә бер генә. Асыл да, пырастуй да...

— Ул бик җәш төгөлме сун?

— Җәше җиткән, уналтысы тулган, кияүгә чыгарлык булган, — дип тезеп китә Праскый түтәй.

Микулай анасы сайлаганга риза була. Кызга яучы җибәрәләр. Микулай яучыга Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәйгә әйтәсе сүзен дә әйтеп җибәрә:

— Мин казер урман куҗасы. Аларнын җорты тузып кәкрәйгән. Сандраны бирсәләр, аларга җана җорт салырбыз, — дигән.

Әллә шуңамы, кыздан егеткә барырга ризалык тиз килеп җиткән. Ярәшкәннәр кызны. Бөтен керәшен йолалары буенча ипи-тоз, бал да май, каклаган каз-үрдәк, башка төр күчтәнәч һәм бүләкләр, кадерхөрмәт белән Таллы Елга урамнарын тутырып, шаулап-гөрләп, җырлап-биеп туй үткән.

— Яратасыңмы соң син аны? — дип төпченде Сафуан.

— Анын кайсы төшөн җаратасын? Үзе җабык, үзенен хале җук.

— Ничек хәле юк?

— Ул бит сугышта кантуж булган, казер мужиклыгын итә алмый, — диде Сандра, керәшен хатыннарына гына хас турылык, эчкерсезлек белән, һич боргалап-сыргалап тормыйча.

— Шуңа балагыз юкмыни?

— Жук шул. Мин ун бала табар ыйем да, ул бит...
Сандра көрсенеп куйды.
— Ә-ә, алаймыни? — дип сузды Сафуан. — Имәндә икән чикләвек. Киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың соң син аның белән?
— Белмим шул ничек җәшәргә, ич уйлый алмыйм...
Тимерче Сафуан тимерне кызуында сугарга өйрәнгән, монда да аптырап калмады, үгезне мөгезеннән эләктерде:
— Син, Сания матурым, артык борчылма. Үзең сылу, бер кашык су белән йотып җибәрерлек сылу. Теләсәң, бер җаен табарбыз. Синең өчен минем җаным фида...
Сандраның да башын карабодай саламы белән япмаган, зирәк, Сафуанның тел төбен тиз аңлады.
— И-и, Сапуан, куркам шул мин. Кеше ишетсә, нишләрбез?
Сафуан Сандраның абый димичә генә эндәшүенә игътибар итте. Димәк, үз итә, якын күрә, үз тиңе итеп саный. Бу хәл аны канатландырып җибәрде. Керәшен гүзәленең анык булуга өмет көннән-көн зурая, ара якыная бара ич.
— Белдермәскә инде аны, Сания җаным. Авыл урамы буйлап сөйләп йөрмәссең бит инде минем сине якын итүем, яратуым турында.
— Жук та бит. Кырын эш кырык җылдан сун да беленә...
Шулай диюенә карамастан, дәрте ташып торган яшь хатын давыл кебек башланган гыйшык уенын туктатырга исәпләми дә иде. Сафуан аңа таба омтылган һәр мизгелдә, Сандра да кабат атылып аның кочагына керде, аның сөю хозурында ләззәтләнде.
— И-и, Сапуан, сине җарата башладым бугай. Ә син мине җаратасыңмы?
Сандра, түгәрәк зәңгәр күзләрен Сафуанга төбәп, наян караш ташлады.
— Мин дә яратам шул, яратмасам шулай йөрер идемме? Яратмасам, сагынып көтәр идемме?
— Мужикларга кыз-кыркыннан бер генә нәрсә кирәк, аларга җаратмасалар да була.
— Алай димә, Сания. Мәхәббәт бар ул, аннан башка тормыш та ямьле булмас иде. Әнә нинди авыр тормышта яши халык. Минеке дә аларныкыннан җиңел түгел. Ә менә сине ярата башлагач, бөтен дөньям онытылды. Хәзер мин сине уйлап яшим. Һәм мәшәкатьле дөньям да бераз түгәрәкләнде сыман...
— Безнекеләргә дә авыр, — диде Сандра, уйланып.
— Кемнәр турында әйтәсең?
— Безнен семья — әтиләр, безнең Таллы Җылга авылы калыгы, бөтөн керәшеннәр...
— Дөрес әйтәсең, Саниякәй, хәзер барысына да бик авыр: татарына-керәшененә дә, чуашына, мукшысына да, урысына да. Тик бу турыда кычкырып йөрүдән файда юк, алай гына да түгел — төнлә килеп алып китүләре дә мөмкин. Әнә Галәметдин абзыйны олактырдылар бит. Мыеклы абзый турында мәзәк кенә сөйләгән булган. Эзе дә юк хәзер...
Алар беравык кочаклашкан килеш уйланып, эндәшми басып тордылар. Шулай бер-берсенең йөрәге типкәнен, кан тамырларыннан тыныч кына кан хәрәкәтен, тән җылысын тоеп басып торудан да яхшысы юк икән.
— Минем сиңа бер соравым бар, Сания матурым, — диде Сафуан, нәрсәнедер исенә төшереп.
— Нинди сорау ул?
— Гади генә... Керәшеннәр кемнәр алар, каян килеп чыкканнар, син беләсеңме? Ату карап-карап торам... Син дә, Микулаең да — икегез дә яхшы кешеләр. Барлык керәшеннәр дә шулаймы?
Мондый мактау сүзләреннән соң Сандраның күңеле булды, ахры, энҗе тешләрен күрсәтеп, елмаеп җибәрде.
— Җакшы булмый ни, җакшы... Тулькы мына керәшеннәр каян килеп чыкканнар? Мин мыны җакшылап белмим шул. Марпа әбинен бер җыруы бар барын.
— Җыр? Нинди җыр ул?
— Җырлыйммы сун?
— Әлбәттә, әлбәттә... Мин бик телим синең җырлавыңны, Саниякәй... Минемчә, син бик әйбәт җырларга тиеш — тавышың йомшак, моңлы. Чиләккә савылган җылы сөт кебек агып чыга күкрәгеңнән синең матур тавышың...
— Тулькы башта ишекне ачып кара, Сапуан, кеше-кара килеп кермәсен.
Сафуан ишекне ачып карады — якын-тирәдә кеше күренми иде.
Сандра тамагын кыргалап алды һәм әкрен генә сузып җырлый башлады:

Ургый гына ургый урак урдым —
Ата-бабаларның кәсебе;
Керәшеннәр кемнәр, дип сорасаң:
Болгарлардан килә нәселе.

Соңгы ике юлны, тавышын күтәрә төшеп, кабатлап җырлады Сандра:

Керәшеннәр кемнәр, дип сорасаң:
Болгарлардан килә нәселе.

Сафуан аның җырыннан чын-чынлап әсәрләнде. Әйе, ул ялгышмаган: Сандра бик моңлы җырлый икән бит. Кайсыдыр бер елны Каенлы авылының бәләкәй клубында Казан артистлары концерт куйганнар иде. Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлахова, тагын кемнәрдер килгән иде. Алар да матур, бик әйбәт җырлаганнар иде. Ә менә Сандраның җырлавы үзәкне өзгәләп-өзгәләп алды.

— Рәхмәт, Сания җаным, күңелне кузгаттың. «Болгарлардан килә нәселе...» Гаҗәп, бик гаҗәп! Син, Сания, тагын җырларсың әле, башка җырларны, дим, башка керәшен җырларын...

— Җырлармын, җырлармын, Сапуан җаным. Бүген кайтып китим инде. Бик озак җуандым синен менән. Җаратам шул, бик җаратам! Сине җаратып, бу дөнҗәдә бөтөннәй җугалмасам җарар иде инде.

Сандра, Сафуаннан һич аерыласы килмичә, артына борылып карый-карый китеп барды.

## VI

Берничә көн Сандраның алачыкта эзе дә булмады. Юк та юк. Килми дә килми. Сафуан сагынып бетте. «Әллә бер-бер кирәкмәгән сүз әйтеп үпкәләттемме, шуңа килмиме?» дип тә уйлады тимерче.

Ниһаять, беркөнне кичке якта күренде Сандра. Кулына бер кочак матур төрледән-төрле урман, кыр чәчкәләре тоткан. Аларның яртысын аерып, Сафуанга сузды.

— Җаратканга бирәм, бик сагындым үзеңне, — диде Сандра һәм Сафуанның муенына сарылды, аны суырып-суырып үбеп алды.

— Кая югалдың, нигә килми тордың? — диде тимерче, сабырсызланып һәм үпкәләгән итеп.

— И-и, җаным, мине Микулай питомникка эшкә куйды, мин казер эшкә җөрим бит.

— Нинди эш ул?

— Орлыклар чәчәбез, җәш үсентеләрне карыйбыз, аларга инештән ташып су сибәбез. Эш бик күп, арып-талып кайтам. Бөгөн дә арыдым, тик сине күрәсем килде, керми булдыра алмадым.

Сандра питомникта тагын нәрсәләр үстергәне һәм ничек эшләгәне турында сөйләде. Чыршы, нарат, карагай, каен үсентеләре үстерәләр икән алар, аннары аларны төрле җирләргә илтеп утырталар, шулай урман мәйданын арттырырга тырышалар.

— Сапуан, урманда шундый да җәмле. Ташла әле шул алачыгынны, кил әле минем җанга эштән сун. Бергә-бергә сүләшеп, каеннар белән серләшеп, җырулап утырырбыз бер. Җырак төгөл бит моннан, тауга гына күтәреләсе. Каеннар җулына барырбыз. Синен Каеннар җулын күргәнен бардыр инде. Биграк җәмле анда...

Сафуанның чыннан да күптән урманга чыкканы юк. Быел яз каен суына барырга җыенды, тик вакыты җитмәде. Әллә соң чыннан да Сандра янына барып чыгаргамы бер? Сандра да аның әнә урманга, Каеннар җулына килүен тели.

«Мәхәббәт ул сугыш кебек: көтмәгәндә генә барлыкка килә, ләкин аны туктатуы җиңел түгел», — дигән кайсыдыр бер акыллы баш. Сафуан белән Сандра арасындагы мәхәббәт тә шуңа охшый, туктарга уйламый да...

— Кил инде, Сапуан җаным!

— Ярар, барырмын.

— Иртәгәме?

— Иртәгә...

Икенче көнне Сафуан алачыкта баш күтәрми эшләде. Эшен намус белән төгәлләп, алачыгын иртәрәк япты һәм әрәмәдән генә турыга тауга таба, Каеннар юлына ашыкты.

Менә Каеннар юлы... Кайсы тапкыры аны шулай атаган? Шигырьле-моңлы исем. Сафуанның элек бу турыда уйлаганы да юк иде. Ләкин төз, ап-ак киемле каеннарның рәт-рәт булып тезелеп торуына соклана иде ул: «Алар ничек шулай тигез булып үскәннәр, ничек шулай туры килгән?» Сандраның питомникта эшлибез дигән сүзеннән соң аңлады: Каеннар юлын тигез итеп кешеләр утыртканнар, үзләре генә үсмәгән икән алар.

Каеннар юлы... Әйе, каеннарны ике якка аерып юл да үтә аннан, урман юлы. Ләкин аны Каеннар юлы дип түгел, ә Каенлы юл дип атарлар иде. Хикмәтле исем...

— Начылый эшебезне бетердек, сунга кала җазганмын, син килеп тә җиткәнсен икән, Сапуан бәгырем, — дип, тынына каплана язып, Сандра да килеп җитте. Бер-берсен кочаклап, ап-ак халатлы зифа каеннарга сокланып, урман һавасын сулап шактый йөрделәр алар. Аннары бер бәләкәй генә алан кебек җиргә барып утырдылар, татлы итеп үбештеләр, сөештеләр. Кәефе күтәрелгән Сандра сузып җырлап җибәрде. Тик тавышын артык күтәрмичә, кеше ишетерлек булмасын дип, салмак кына җырлады ул:

Җафрагын җарган җәш каеннар
Җәшнәп утырадыр җылгада;
Берләр аерылгач күрешалмабыз
Айларында түгел лә, җылда да.

Ак та каеннарны җәмле итә
Җафыракай белән туз гына;

Бу дөнҗәдә чиксез уйлар уйлый
Җегеткәен сүгән кыз гына...

«Җегеткәен сүгән кыз гына» дип сузганда, Сандра Сафуанга сыенды, аны ике куллап кочаклап алды. Бу җырны аның Сафуанга атап җырлавы иде. Керәшен җырулары алар әнә шулай аерым берәүгә яки берәүләргә атап җырлана — Сафуан шуны аңлады.

Ягымлы тавышлы Сандраның күкрәгеннән моң ташыды. Сафуан аны ихлас күңел белән, тын калып, бирелеп, уйланып тыңлый бирде. Ә Сандра бер җырдан икенчегә, өченчегә күчеп җырлады да җырлады. Аның күптән шулай ләззәт табып җырлаганы юк иде бугай.

Гөл бакчаларына гөлләр чәчтем,
Гөл бакчалары ла, ай, тулганчы;
Гөл-гөлләргә былбыл, ай, кунганчы,
Аерылмыйык, җаным, ай, үлгәнче...

Сандра кабат Сафуанга елышты, башын аның күкрәгенә салды һәм җырның ахырын кабатлады:

Гөл-гөлләргә былбыл, ай, кунганчы,
Аерылмыйык, җаным, ай, үлгәнче...

Ул тынып калды. Аның җыры белән сихерләнеп, Сафуан да сүзсез калган иде. Каенлыкта өздерепөздереп сандугач сайрый. Яшь каен яфраклары җилдә җилферди. Ә Сандра, тимерченең күкрәгенә түгәрәк башын салып, мышык-мышык килеп кайнар яшьләрен түгә. Тимерче аны сүзсез генә, көчле куллары белән яшьле битләреннән, аркасыннан сыйпый-сыйпый сөя-юата. «Аерылмыйык, җаным, ай, үлгәнче...» Сандра җыруының шушы сүзләре аның җанын телгәли.

* * *

Беркөнне Сандра кичке якта ашыгып кына тагын Сафуан янына, алачыкка килеп керде.

— Микулай тагын Акташка лесничий янына китте. Тагын, кунам, диде. Киләсеңме? Эңгер төшкәч тә кил, көтәм, сүләшеп утырырбыз...

Сафуан караңгы төшкәнне ашкынып көтте. Нишләптер караңгы бик озак, көттереп төшкән кебек булды аңа бу кичне. Күз бәйләнгәч тә, өйдәгеләргә: «Күршеләргә кереп чыгыйм әле», — дигән булып, бәрәңге бакчалары аша сөйгәне янына ашыкты. Авыл башындагы яңа йортка тиз барып җитте ул. Өй тәрәзәләрендә ут күренми, Сандра аны сүндереп куйган иде, ахры. Тирә-якны тикшереп карап чыкканнан соң, зур гәүдәсе белән кысыла-кысыла, ике киртә арасыннан йортка керде, инде караңгы төшсә дә, ерактан аксыл булып күренеп торган яңа баскычка менеп, әкрен генә ишекне шакыды. Бу минутларда Алып кебек таза Сафуан, тәүге тапкыр караклык кылырга чыккан кеше шикелле, калтырый, йөрәге дөп-дөп тибә, аркасыннан су ага, үзе исә ялт-йолт як-якка карана. Шул мизгелдә кем дә булса берәү: «Һайт!» — дип кычкырса, торып басса, түбәсе түшәмгә тиярдәй Сафуанның нишләгәнен күз алдына китерү авыр түгел. Шөкер, алай кычкыручы булмады. Әкрен генә ишек ачылды. Берничә секундтан Сафуан кайнар тәнгә матур йокы күлмәге кигән Сандра кочагында иде инде. Аулак өйгә пөхтә киенеп килгән Сафуан, күкрәгенә гүзәл Сандраны алып, аны шашып-шашып назлый, иркәли башлады, җылы куллары белән аның мулдан-мул тыгыз күкрәкләренә, кайнар һәм йомшак аркасына, нечкә биленә, аннан да аскарак җирләренә кагылды. Сандра исә карышмады, Сафуан кайдан тотса, шуңа риза булып, ләззәтләнеп, эреп китте.

— Сапуа-ан... Бу синме, җаным? — дип пышылдады Сандра, ниһаять.

Сафуан әле күзләре ияләшергә өлгермәгән караңгы өйдә аның түгәрәк матур йөзен дә, зәңгәр күзләрен дә күрми, фәкать кочагына кереп поскан кайнар гәүдәсен генә тоя иде.

— Көтәм, көтәм... Әллә килмисен инде дип уйлый башлаган ием, — дип дәвам итте Сандра.

— Менә килдем бит...

— Бик сагындым...

Икесенең дә йөрәкләре күкрәк читлегеннән чыгып атылырдай булып тибә, тәннәре калтырый, сулышлары кысылган иде.

— Җа-ны-ым...

Тимер сугып мускуллар ныгыткан Сафуан көчле куллары белән кочаклый гына белә, яхшылап, оста итеп, тәм табып үбешергә өйрәнергә әллә вакыты җитмәгән, әллә җае туры килмәгән иде. Бу «эшкә» Сандра аны үзе өйрәтте: татлы, кайнар иреннәре белән суырып-суырып үбәргә кереште. Сафуанның болай «котырып» суырып үбешкән хатын-кызны тәүге тапкыр күрүе иде. Тора-бара ул үзе дә Сандраның битләреннән, озын керфекле күзләреннән үбә башлады. Аннары аның зур бармаклары Сандраның күпереп торган куе чәчләренә кереп батты. Шулай ул аның түгәрәк йомры башын кочаклап, үзенең күкрәгенә кысты, сыйпады, иркәләде; гәүдәсе-күкрәге белән Сандраның җиңел ситсы күлмәге аша бөтен тән җылысын тойды, аннары, шашып, сөеклесенең кайнар муенына капланды.

— Шаштырасың мине, Сания бәгърем, шаштырасың... Әллә ничек шунда, яхшы түгел...

Ләкин Сандраның йомшак куллары аның муенына сарылган, һәм ул аларны җибәрергә уйламый да. Кияүгә чыгып та ир назын татый алмый яшәгән, һаман гыйффәтле булып калган Сандра бөтен нәрсә турында онытып, әхлак киртәләрен сындырып, үз теләгенә ирешү максатын куйган иде.

Ул, шуңа ишарәләп:

— Сапуан җаным, мин синеке казер, — диде.

Сафуан эндәшмәде, бары Сандраның күкрәгенә башын куйды һәм тынып калды. Аннары башын күтәрде һәм тәрәзә аша әллә кайдан төшкән сүрән яктылыкта шәйләнгән яшь хатынның очкынлы күзләренә карады. Сандраның иреннәре түземсезләнеп кабат аның иреннәренә кушылды. Шул килеш ул сөйгәнен кулларына алды һәм йомшак мендәрләр түшәлгән агач караватка илтеп салды. Сандра, бер кулын баш астына куйган килеш, яртылаш һушсыз ята иде. Сафуан кабат аны кайнарланып үбәргә, кочарга, назларга тотынды. Түзмәде, сикереп торды да үзен-үзе белештермәс хәлдә чишенә башлады. Күлмәген салып атты, чалбарын салганда бер төймәсе өзелеп чыкты һәм ул каядыр агач карават астына тәгәрәде. Бу вакытта Сандраның да сабырлыгы тәмам төкәнгән иде, ул кузгалып куйды һәм ситсы күлмәгенең итәкләрен күкрәгенә кадәр күтәрде, ә Сафуан аны бөтенләй салып ташларга булышты. Түзәрлеге калмаган Сафуан Сандраның каршылыксыз тәненә сыланды, аяклары аякка кушылды.

— Сания бәгърем, Саниякәем... Аһ...

Бермәлне Сандраның тәне дерт итеп китте, ә үзе ыңгырашып куйды...

Күпмедер вакыттан соң өйдә тынлык урнашты. Ләкин Сандра үзенең йомшак кулларын тимерченең муеныннан әле бик озак ычкындырмыйча торды, әйтерсең лә шушы кочаклавы белән ул аны мәңгегә үзенә бәйләп куйган иде.

— Ай, карап иттен, Сапуан җаным, бетерден...

— Үзең теләдең бит, Саниякәем, үзең теләдең...

— Теләдем шул, теләдем. Җазыклы булдым инде. Мына казер Микулайга ничек җавап бирергә? Сикерләден, гел ырымнадын син мине. Җараттырдын, сүдерден үзенне... Казер нишләргә инде? Башым эшләми, — дип берөзлексез сөйләнде Сандра һәм кинәт: — Әй, беткән баш бетсен инде — тагын килерсен, җаным, — дип әйтеп салды.

— Килермен, килермен. Тик хәзер кайтып китим, Сания, мине югалтканнардыр.

— Кем жугалтсын сине, катынын жук ла. Тан алсуланганчы тор инде, җаным, китмә, мин үзем генә куркам бит, — диде Сандра.

Ләкин Сафуан калмады, чөнки ул белә: өйдә аны чыннан да югалтулары бар. Өйләнмәгән егеткә ярты төнгә чаклы йөрү ярый әле, ә инде иртә таңда кайту... Юк, анысы һич калыпка сыя торган эш түгел.

Сөю назы белән тәмам юләрләнгән, әсәрләнгән Сандра, һаман балаларча беркатлы тәтелдәп, Сафуанны кайнар, сусыл иреннәре белән суырып үбә-үбә, гаҗизләнеп чыгарып җибәрде...

## VII

Сандра тимерче белән, үзе әйтмешли, чыннан да «сикерләнде». Уналты яшенә чаклы туган авылында аның гыйшкы төшәрлек егет-җилән булмады. Таллы Елганың менә дигән егетләре сугышка китеп, бик сирәге генә яраланып кире кайтты. Карга Гөргөринең гүзәлләрдән гүзәл булып өлгергән Сандрасы артыннан йөрергә кеше дә юк иде. Дөрес, сугыш бетәр алдыннан гына армиягә алынган күршеләре Дранча Ычтуп малае Җәгүр кызга берничә хат язды, ләкин аларда ярату турында ике сүз дә юк. Үзе дә балалыктан чыгарга өлгермәгән, бары унҗиде яшьтә генә иде егет һәм мәхәббәт турында кайнар-кайнар хатлар язарга әле өйрәнмәгән, ул хис аңа таныш та түгел иде. Шулай да бер хатта аның «Сандрай, үсә тор, минем кайтканны көт!» дигән сүзләре бар иде. Ләкин соңыннан Җәгүрнең Сандрага хатлары сирәгәйде. Чөнки ул Төлке Аннугы белән еш хат алыша башлаган — бу турыда аңа Пушты Татук җиткерде.

Әнә шулай, уналтысына җитеп сөю назын татырга туры килмичә, Микулайга кияүгә чыкты Сандра. Ләкин Микулайга карата аз гына да ярату хисе тумады. Бәлки, бергә тора-тора яратырмын дип уйлаган иде, юк, анысы да булмады.

Һәм менә, ниһаять, тимерче. Бер аягына чатанлый торган мөселман татары. Кечкенә чакта анасы Начтук та, атасы Гөргөри дә, башка керәшеннәр дә нигәдер мөселман татарларын эттән алып эткә салып хурлыйлар иде. Ә менә Каенлы Чишмәдә яманларлык бер генә кеше дә тапмады Сандра. Барысы да, Миңлезифа әбидән башлап, якты чырайлы, киң күңелле, мәрхәмәтле-шәфкатьле. Ә инде Сафуанга килгәндә... Аның кебек шәп егет турында Сандрага хыялланырга да туры килмәде. Аның бәхетенә, Микулай белән алар Каенлыга күчеп килделәр, Сандраның бәхетенә, Тирәкле инеше буендагы тәбәнәк алачыкта Сафуан дигән таза тимерче эшли торган булып чыкты. Менә бит ул язмышлар! Анысы хак, бер аягына чатанлый ул тимерче, ләкин сугыштан соң ике ирнең берсенең йә аягы, йә кулы, йә күзе юк. Алар тирәсендә Сафуанның аксавы — бөтенләй пүчтәк. Аның караву ул төскә-биткә дә, гәүдәгә дә, сөюгә дә Микулайдан ике башка өстен. Сафуан сызгырса, ул аның белән җир читенә китәргә дә риза югыйсә, әмма җир читенә китү турында Сафуанның сүз кузгатканы юк әле. Тәүге ташкын хисләр, тәүге

сөю... Инде ике елдан артык ир белән яшәгән хатын дип һич уйламассың Сандраны. Әнә ничек хозурлы була икән ул чын сөю. Сандра шул ялкында бөтен дөньясын онытты, тулысы белән Сафуан иркенә бирелде.

Шул көннәрдә яшь хатынның уйламаган уе, янмаган-көймәгән сәгате булмады. Бер әрләде үзен, бераклады, бер яңа өенең почмагында торган изге сурәт каршына тезләнеп: «Кодаем, кылган җазыкларым өчен кичер мине, җазыклы мәндәнне ярлыка», — дип тәүбәгә килде. Аннары тагын уйланды.

...Берничә ел элек читтән килгән бер укытучы Сандраларда фатирда яшәгән иде. Начтук түтәй кибеткә барган җиреннән ияртеп кайтты аны. Күпне күргән, күпне белгән бу ялгыз хатын зирәк акыллы, һәрнәрсә белән кызыксынучан Сандраны үзенең сердәше итте. Ләкин язмышы көнләшерлек түгел иде аның.

Сугыш алдыннан педтехникум тәмамлаган яшь кызны күрше районның бер авылына укытучы итеп җибәргәннәр. Берничә ел шунда укыткан ул. Сугыш елларында җидееллык мәктәп директоры итеп билгеләгәннәр. Шунда чатнап киткән дә инде аның тыныч тормышы. Район күләмендәге төрле чаралар вакытында еш-еш очрашу-сөйләшүләрдән соң, район башкарма комитеты рәисе моңа үзенең мәхәббәтен белдергән. Ир-егетләрнең барысы да сугышта, сайланыр чак түгел. Рәиснең хисләре чындыр дип, кыз бәхетен сынап карарга уйлый. Очрашулар, сөешү-назлашулар кайнар була.

Берзаман кызыбыз үзенең «борчак белене» ашаганлыгы турында сизенә, бу турыда борчылып сөйгәненә дә җиткерә. Районның иң олы түрәсе, йөзенә битарафсызлык чыгарып: «Анысы синең проблема, мин хатыным өстенә сине алып кайтып киталмыйм бит инде», — ди. Түрә, әвеш-түеш итеп, бәлагә тарыган сөяркәсен икенче авылга күчерә, шунда ул кызын таба. Моннан соң инде ул: «Ирем сугышта һәлак булды», — дигән уйдырма белән яши башлый. Кызын үз туган авылына анасы карамагына кайтарып куя.

Укытучының белмәгән нәрсәсе юк, сөйли башласа, теле телгә йокмый. Тик фәлсәфәсенә генә бик үк төшенә алмады җитлегеп килгән Сандра. Шулай да укытучының бик күп сүзләрен йөрәгенә сеңдереп калды:

— Яшәсәң, чын хис белән яшә, сеңлем. Хатын-кыз өчен мәхәббәт еш кына кайгы да хәсрәт кенә ул, ләкин мәхәббәттән дә татлырагы юк шул бу дөньяда... Ах, Сандра, гүзәл син, бик гүзәл! Бәхетле булсаң иде, мин сиңа шуны телим. Ләкин, сеңлем, шуны да бел: гүзәл хатын өчен шатлыклы чор кыска була. Уналтыда-унҗидедә аның янына ялагайланып киләләр, ә берничә елдан инде ташлап та китәләр. Димәк, бу елларның һәр сәгатен бәхетле, истә калырлык итеп үткәрергә тырышырга кирәк. Аннары соң булыр. Терсәгеңне бик тешләргә теләрсең дә, әмма соң булыр...

Бу сүзләр Сандраның йөрәк түренә уелып керде. Алар аның яшәү кагыйдәсе сыман. Шуңа да бит инде ул Микулае өстенә Сафуанны үз итте...

## VIII

Каракның бүреге яна, диләр. Сафуан белән булган төненнән соң Сандра ут йотып, тын алырга да куркып йөрде. Микулайның күзләренә күтәрелеп карый алмады хатын, ире барысы турында да сизәдер, беләдер кебек тоелды. Ләкин Микулай ул-бу сизенмәде, ахры. Әллә эше бик күп идеме — ул ике-өч көнгә бер Акташка, баш урманчы янына чапты. Инде Акташка киттеме, ул бу кичне кайтмый, куна кала. Ара якын түгел, атка да ял кирәк. Моннан тыш Микулай белән урманчының борчаклары да пешә. Дуслар, төн ката көмешкә белән сыйланып, күңел ачып чыгалар.

Сандра белән Сафуан өчен исә Микулай Акташтан бөтенләй кайтмаса да ярый. Аларның икесенең дә ташлары кызганнан-кыза барды, дөньяларын онытып очраша, яратыша-сөешә тордылар.

Шундый хозурлы атналарның берсендә Сандра үзенең балага узуын сизде. Бу хәлдән ул бөтенләй куркып калды. Микулай белсә нишләтер?! Ничек карар ул моңа?! Пыр туздырып аерып җибәрерме, әллә измәсен генә изәрме? Хәер, өч ел бергә яшәп Микулайның әле бер генә дә тузынганы юк, хәтта ачулана да белми. Әнә Сандраның үз атасы атна саен бер тузынып ала, атна саен «ил аера», түшәмнән туфрак коя. Дөрес, ул моны салган баштан эшли. Ләкин Микулай да салмый тормый ла. Әнә беркөн Акташтан ничек кайтып җиткәнен дә хәтерләми, лаякыл исерек иде. Ярый әле Акбәкәл ышанычлы ат, арбада йоклап яткан исерек хуҗасын тартып, туп-туры үз йортларына кайтып керде.

Икенче яктан Сандраның шатлыгы эченә сыймады: ул бит балага узды, аның баласы булачак! Өч ел бит инде аның якын туганнары, ата-анасы, бергә үскән ахирәтләре, күршеләре туган авылына кайткан саен күз ачырмыйлар: «Нигә бала тапмыйсың?» — дип, авырткан җиренә кагылалар. Бер Микулай гына бу турыда сүз кузгатмый, авызына су капкан диярсең. Әйтә дә алмый, аның хәле җиңел түгел. Олы авылда сылу бер кызга өйләнә һәм аның күңелен күрә алмый яшә. Оят та, хурлык та...

Юк, алай дип әйтү дә дөрес булмас. Микулай гаеплеме соң аңа? Сугыш, каһәр төшкән сугыш гаепле. Шул сугыш булмаса, япь-яшь Микулай контузия алып тәмам гарипләнеп кайтмаган булыр иде. Ул бит үзе дә моңа бик нык борчыла, төн йокыларын йоклый алмый уфтанып чыга. Ә үзе эндәшми. Йокысыннан торгач та эндәшми, өстәл артында ашап утырганда да ялгышып бер сүз дә әйтми, эшкә чыгып

китә, эндәшми, эштән салмыш кайтса да авыз чайкамый. Дәшмәкигә әйләнеп бетте инде. Сандра аны кызгана, әлбәттә, ләкин аннан ни файда?

Сафуан белән бәйләнеп, Сандра үз тормышын катлауландырды бугай. Ләкин дәрте ташып торган яшь хатын үзенең бала табарга сәләтлеме-түгелме икәнен белергә тиеш иде, шуңа ул тәвәккәл адым ясады.

Иргә чыгып та кыз булып сазамас бит инде. Ул бит хатын-кыз: балалар табып, ана булырга, киләчәк турында кайгыртырга — үзенә алмаш буын тәрбияләп үстерергә тиеш кеше. Әгәр балалар табуда ир заты үз вазифасын үти алмый икән, үзенә үпкәләсен. Мондый вакытта хатыны иренә хыянәт итә икән, аның хыянәте изгедән саналырга тиеш. Әйе, изге хыянәт!

Ниндидер бер мизгелдә Сандраның башына ярыйсы гына уй килде. «Әллә соң Микулайның теге көнне лаякыл исерек кайтуын файдаланып, хәйләләп алыргамы? Балага синнән уздым, син исерек булсаң да, эшеңне эшләдең дияргәме?..» Ләкин беркатлы, урлашырга-алдашырга өйрәнмәгән Сандраның йөрәгә болай эшләүне хуп күрмәде, кабул итмәде. Микулай начармы-яхшымы аның ире. Язмыш тарафыннан болай да рәнҗетелгән, кимсетелгән ирен алдауны ул намуссызлык, зур гөнаһ дип санады һәм тыныч хәлдә барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирергә, аптыраганнан кылган гөнаһысы өчен гафу үтенергә, иренең ярлыкавын сорарга ниятләде. Ничек булса — шулай булыр. Куып җибәрә икән — китәр, илдә чыпчык үлми. Бер баланы ничек тә үстерер, әнә сугыш вакытында биш-алты баласын ялгыз үстергән хатыннар булды авылда. Бүген дә үстерәләр...

Ләкин Сандра, ничек кенә борчылмасын, Микулайга авыз ачып сүз әйтә алмады. Шулай көннәр, атналар үтте. Сандраның көмәне күзгә күренеп үсә башлады. Аны Микулай да күреп торды. Күреп торды, тик сорашмады, сүз катмады. Ничектер бик тыныч кабул итте ул бу хәлне: гаҗәпләнмәде дә, шатланмады да, тузынмады да. Әллә инде үзенең чарасызлыгы, көчсезлеге белән килешкән иде. Әллә җәнҗалның аның файдасына булмаячагын аңлады, әллә ялгыш үземнең эшемдер дип уйладымы? Кемнеңдә булса башка берәүнең аның түшәген бүлешүе башына да килмәде, ахры, Микулайның. Югыйсә Сандра олы тавыш чыгасын көткән иде, шул чакта аңлатып, ачыктан-ачык әйтеп бирермен дип уйлаган иде, тик боларның берсен дә эшләргә туры килмәде аңа.

Ә Сандраның көмәне үсә торды. Хәзер инде үз авылына кайткач та авырткан сөяленә басучы юк. Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәй исә туачак оныкларына — нишләптер алар Сандраларын малай таба дип уйлыйлар иде — исем дә эзли башладылар. Шунысы хак: ике авылның берсендә дә Сандраның көмәне үз иреннән түгел, ә башка кешедән булуы турында башларына да китермиләр иде.

## IX

Җыйган балга шөпшә ияләшкән кебек, Сафуан да бер татыган Сандраны тиз генә ташлый алмады. Төрле мөмкинлекләр килеп чыгу белән, төрле тапкыр яки хәйләле юллар белән алар очраша тордылар, бер-берсенә тартылдылар, иркә сүзләр әйтештеләр, татлы сөештеләр. Микулайның шалкан кебек ак усак агачыннан салынган яңа өенең һәр почмагы таныш иде хәзер Сафуанга. Оста куллар чутлаган бүрәнәләр, кырып ясаган ишек һәм тәрәзә яңаклары, нарат такталарыннан кысып китергән гәрәбә кебек сары түшәм, сайгаклар, өр-яңа өйдә исереп китәрлек агач исе, тәрәзә һәм ишек башларында оста куллы керәшен хатыннары суккан һәм чиккән сөлге-бистәрләр, кашагалар, өйне икегә бүлгән төрле төстәге чаршаулар, тәрәзәләрдә ак кәтүк җебеннән бәйләгән нечкә челтәрләр... Сандра да бик уңган, булдыклы, тормыштан ямь табып яши торган хатын икән ләбаса.

Бер нәрсә күңеленә ошамый иде Сафуанның — ул да булса алъяпкыч белән каплаган «тәре почмагы». Әйе, күңеле кабул итми иде аның әлеге урынны, ләкин аның кочагында гүзәл Сандра булганда аның турында онытa, почмакка карамаска, уйламаска тырыша иде. Гыйш-гашрәт хозуры күп нәрсә турында Сафуанны да, Сандраны да онытгыра иде. Вакыт-вакыт аларның үз язмышлары белән уйнау чигендә, тормышларына куркыныч янаган тәвәккәллекләр ясаган көннәре дә булды...

Шулай беркөнне Микулай тагын Акташка, баш урманчы янына китте. Сандра кабат тиз генә алачыкка барып килде. Сафуан, күз бәйләнгәч тә, сөяркәсе янына йөгерде. Караңгы өйдә назлаша гына башлаганнар иде, капка төбендә арба шыгырдаганы ишетелде.

— И Кодаем, Микулай бит бу! Кунып калмаган, ахры, — диде Сандра борчылып һәм, ашыгып-кабаланып, Сафуанны тизрәк чыгарып җибәрү ягын карады.

Микулай атын тугарып, абзарга кертеп маташкан җайлы бер мизгелдә, Сафуан ишектән чыгып шылды һәм өй артына яшеренде. Аннары, Микулай өенә кереп киткәч, киртә аша сикереп чыкты һәм, сөяркәсенең ире белән күзгә-күз очрашмауга сөенә-сөенә, өенә кайтып китте.

* * *

Бу хәлдән соң Сафуан айнып киткән кебек булды. Караклыкта, бурлыкта әләгә язган кеше хәлендә иде ул. Кырын эш кырык елдан соң да беленә, диде бит Сандра да. Берсендә котылырсың, икенчесендә

дә... Ләкин кайчан да булса барыбер тотылырсың. Тотылгач соң булыр. Эш җәнҗалга китсә, бөтен авылга таралса, хурлыгын кая куярсың? Җир тишегенә кереп качарсыңмы? Качарсың, җир ярылса... Кинәт кенә ташып киткән дәртен, дөрләп кабынган ялкынын үз вакытында баса алмый ир хатыны кочагына ташланган абруйлы тимер остасы бермәлне акылына килә башлады. Әйе, Сандраның гүзәллеге, аның карусызлыгы, Сафуанның үзенең исә артык хислелеге аны кинәт гыйшык дәрьясына алып ташлады — бусы бәхәссез. Бүген дә ул татлы кичерешләрдә яши бирә. Каенлы егетләре арасында әле берсенең дә төшенә кермәгән, фәкать чиксез ымсындырып кына торган гүзәл Сандра-Саниянең игътибарын үзенә җәлеп итте, мәхәббәтен яулады, аның иң ләззәтле назына иреште бит ул. Моның белән ничек горурланмыйсың да моңа ничек сөенмисең? Сандра белән булган ләззәтле көннәрдән соң ул: «Хәзер инде үлсәм дә үкенмим», — дигән иде. Мондый сүзне кеше бер дә юкка гына әйтми торгандыр.

Ләкин икенче яктан караганда, Сафуанның башында борчулы уйлар да тулып ята: бу сөю-сөешүләрнең ахыры ничек бетәр, хәерлегә булырмы? Очы бер булырга тиеш ич моның... Әнә бит Сандра, балабыз була, ди... Балабыз!..

Шундый борчулы уйлар белән корымлы алачыгында ялгыз башы эшләп ятканда, һич тартынусыз бусагада кабат Сандра пәйда булды. Йөзендә шатлыклы елмаю. Нигә елмаймасын, нигә шатланмасын ул? Үз кешесе, яратканы, сөйгәне янына килгән лә! Керү белән Сафуанның муенына сарылды.

— Сагындым, тыным белән тартып алыр идем үзеңне. Гел сагынам, — диде ул, кайнар сулап.

Сандраның кулында тәүге килүеннән соң Сафуан ясап биргән сырлы-мырлы җәмки иде.

— Менә җәмкием кәкрәйгән иде, шуны гына төзәтеп бир әле, Сапуан җаным, — дип, төп-төзек җәмкине сөйгәненә сузды.

Сафуан җәмкине алып карагач, гүзәленең хәйләсеннән елмаеп, аны тезләренә утыртты һәм, башын бер якка кырын салып, яратулы-аптырашлы караш ташлады.

— Үзеңне дә, мине дә гөнаһка батырып бетердең инде шушы матур елмаюларың, килешле кыланышларың белән, — диде ул, уйчанланып. Аннары, алай-болай кеше килеп керсә дип, җәмкине утлы күмергә куйды — кыза торсын, суккалап бирер, янәсе...

— Шулай шул, үзем дә бик уйланам, үзем дә бик борчылам. Шуңа килдем дә әле, әйтәсе сүзем бар...

— Сөйләп кара, гүзәлем, нинди сүз, нинди киңәш инде ул? Урманга менеп, ак каен ботагына асылынырга кушмыйсыңдыр бит? — дип шаяртты тимерче.

— Жук, сина аны эшләү кирәк төгөл. Мин дә эленергә җыенмыйм әле, — диде Сандра, бик җитди итеп. — Минем көмәндә синен балан үсә. Мона шатланырга, мәнын менән гайрәтләнергә кирәк, Сапуан җаратканым. Тик син аны эчтән генә минеке дип җөр, беркемгә дә белгертми генә. Мина Кодай Микулай белән җәшәргә җазган, мин анын закунный катыны. Сина әйтерем шул: син дә катын ал, Сапуан җаным. Син үләнсән, минем җанга килеп җөрүдән туктарсын. Мин бөтөннәй үк килмә димим. Сине ничек җаратуымны беләсен, сине күрми җәшәве миңа да җинел төгөл. Тик башка чарабыз жук безнен — үлән син...

Шулчак алачык ишегеннән ике ир-ат килеп керде. Сандраның сүзләре ярты юлда өзелеп калды. Сафуан җәмкине уттан алып сандалга салды да, суккалап, Сандрага сузды. Сандра: «Рәкмәт!» — дигән булып чыгып китте.

## X

Сандра Сафуанга төпле сүзен әйтте. Ай-һай, акыллы хатын икән! Мондый хатынны гомерлек юлдашың итеп алсаң да начар булмас иде дә бит...

Әйе, дөрес әйтә Сандра: өйләнергә кирәк, «катын алырга»... Һәм мыштым гына яши башларга. Юк, бер көйгә мыштым гына яшәп булмас, ахры, Сандра аның күңелендә мәңге яшәр сыман. Бала да тапса, яши дә яши инде ул аның күңел түрендә...

Сафуанның өйләнергә вакыты күптән җиткән. Тик иске, җимерелә башлаган тугыз терәүле өйгә ничек килен алып кайтасың?

Атасы сугышка киткәнче өй салырга җыенган булган, өлгерә алмаган. Сафуанның исә өй салырга акчасы юк. Фәкыйрьлек, хәерчелек, ачлык-ялангачлык белән көн күргәндә яңа өй салу турында уйлыйсы да юк. Менә шуңа да өй салу һаман кичегә килә. Шулай ук өйләнү дә. Хәзер нишләргә? Өем иске дип, гомер буе өйләнми дә яши алмыйсың...

Сандраның чираттагы мәртәбә алачыкка Сафуанны күрергә килүендә, ул үзенең әлегә өйләнә алмау сәбәбен әйтте.

— Курыкма, җаратканым. Кемнең кулында — шуның авызында. Урманга Микулай кужа. Мин ана әйтермен, сина бер җортлык агач бирер. Бөтен тимер коралларны бер тиенсезгә җасап бирде, ул бик җакшы мужик диярмен, — диде Сандра җиңел сулап, матур елмаеп. — Ә җорт салганчы катын ала тор. Җортынны безнен кебек катынын белән бергә салырсыз...

* * *

Озын-озакка сузмыйча, Сандра кебек үк чибәр һәм сөйкемле булмаса да, эшкә уңган күрше кызы Гөлмәрфугага Сафуан башкода кертте. Болай авылда җиткән кызлар күп иде. Егетләрнең күбесе яу кырында башын салды, кызларга хуҗа сирәк чыга иде. Арада кызларның асыллары да җитәрлек. Тик асылларның да төрлесе була. «Дөнья тулы чибәр кызлар, кайдан чыга соң бу явыз хатыннар?» — дип әйтерлек булмасын. Әнә шул явызларга тарымас өчен, Гөлмәрфугага башкода кертте дә инде Сафуан. Күз алдында үскән эшчән, күндәм, киң күңелле кыз ул Гөлмәрфуга. Башка егет-җилән белән йөргәне дә булмады бугай — үзен тыйнак тотты, азмады, тузмады. Һәрхәлдә, Сафуан шулай дип уйлады.

Ай-ли, Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсын да...

Анысы дөрес. Эшкә талымсыз Гөлмәрфуга суга көненә ике-өч барып кайта. Тик, күрше кызы булса да, барысы турында сөйләшергә генә туры килгәне булмады Сафуан белән Гөлмәрфугага. Сафуанның үзе кебек сазаган, кияүгә чыгып калу турында хыяллану гына түгел, инде төн йокыларын качырып, борчылып арыган кыз уңган-булган егеткә чыгу бәхетенә ирешүгә куанып бетә алмады. Кияү егетенең чатан булуын ул уйламый да иде. Күршедә яшәгән Сафуанның гариплеген кыз күптән күреп, әйтерсең шулай булырга тиеш сыман тоела иде аңа.

Коры гына никах ашы белән алар уртак тормыш башлап җибәрделәр. Табында күбрәк ярмалы ярка бәрәңге иде. Шөкер, бакчада җимертеп эшләгән Сафуанның бәрәңгесе мул иде. Иртә бәрәңге, кич бәрәңге...

Хәзер кызларның мәһәре —
Бер подаука бәрәңге, —

дип җырлый торган еллар иде ул...

Яз җитеп, карлар эрегәч, юмарт урман каравылчысы Микулай биргән диләнкедән Сафуан берничә авылдашы белән үгез җиккән арбаларга төяп агач кайтарды, ашыкмый гына бура бурый башладылар.

Бу игелекле эштә күбрәк Сандраның өлеше булуын бер Сафуан гына белә иде. Сафуанны бик яратканга, Микулаеннан аңа урман бирдертте бит ул.

## XI

Җәйнең соңгы, ләкин әле кояшлы, җылы аенда уңган балта осталары Сафуанның бурасын бурап бетерделәр дә, өмә җыеп, мүкләп-чутлап өеп тә куйдылар. Нәкъ шул көннәрдә Сандра малай тапты. Тагын берничә айдан Гөлмәрфуга кыз тапты. Озын гомерле, тыныч холыклы булсын дигән теләктән, аңа Даимә дип исем куштылар.

Колхозда көзге эшләр тәмамлангач, авыр тормышта чиләнгән колхозчыларга сугыштан соң тәүге тапкыр ярыйсы гына икмәк бүлеп бирделәр. Авылда бердәнбер тимер остасы, ару белмәс, ел әйләнәсенә корымлы алачыгыннан чыкмый тимер суккан Сафуанга икмәкне гади колхозчыларга караганда өч тапкырга арттырыбрак китерделәр. Яңа өй салып маташкан кешегә ул бик ярап куйды.

Сафуан белән Гөлмәрфуганың көч-хәл белән яңа өй салып керүенең икенче елында, атна-ун көн генә авырып, сиксәнен тутырып килгән Миңлезифа әби җан бирде. Якты дөнья белән хушлашырга икеөч көн калгач, ялгыз карчык кемдер аркылы Гөлмәрфуганы чакыртып алды. Миңлезифа әби белән әллә ни аралашмаган, үткәндә-сүткәндә генә хәлен сорашып йөргән Гөлмәрфуга башта ничектер гаҗәпсенсә дә, аннары күңелен ниндидер шик биләп алды, куркып кына керде ул карчык янына. Берничә күрше карчыгы ясин укып утыралар иде. Гөлмәрфуганың килгәнен күргәч, Миңлезифа әби һич үләргә җыенмаган, авырып кына яткан кеше сыман, көч-хәл белән булса да торып утырды һәм:

— Кызыма аерым сүзем бар, корткалар, безне калдырып торыгыз әле, — дип әйтте.

Карчыклар чыгып киткәч, ул яңадан ястыгына авып төште.

— Борчыдым инде үзеңне, кызым, — диде ул, авыр сулап. — Миңа бәхиллегеңне биреп кит. Гаепле мин синең каршыңда...

— Нишләп гаепле, Миңлезифа әби? Булмаганны... Минем каршымда синең бернинди гаебең дә юк. Бәхил, мәңге бәхил...

— Алай димә әле, кызым. Гөнаһлы мин, ярлыка, зинһар өчен...

Һәм карчык Гөлмәрфугага Сафуанның өйләнгәнче Сандра-Сания белән очрашкалавы, аның үсеп килгән малаен Сафуаннан табуы турындагы кыйссаны җиткерде.

— Каян беләсең син боларны, Миңлезифа әби? — дип сорады Гөлмәрфуга.

— Беләм, кызым. Сания серләрен үзе сөйләп торды. Ә мин, гөнаһ шомлыгына каршы, хуплап яшәдем аның гыйшык-мыйшык турындагы саташуларын. Тик, кызым, зинһар өчен, дип әйтәм, үзең дә сер итеп сакла боларны. Әйтмә беркемгә дә, гакыллы бул. Сафуаның да, балаларың да, Сания үзе дә, малае

да белмәсеннәр. Гөнаһымнан котылдым, теге дөньяга тыныч күңел, саф иман белән китим дип әйтергә булдым, балам, кичер мине.

— Тыныч бул, Миңлезифа әби, борчылма. Рәхмәт әйткән сүзеңә, сереңне саклармын. Бәхил, бәхил...

— Менә бусына рәхмәт, кызым, мең рәхмәт, — диде әби һәм хәлсез куллары белән озак кына Гөлмәрфуганың кулын тотып торды.

## XII

Шул көннән башлап Гөлмәрфуга эченә бикләнде. Шулай да ир хакын хаклап яшәде ул, чөнки ир хакы — Тәңре хакы. Үз вакытында ашатып эчертте, юындырды-киендерде, артыннан карап калып эшкә озатты. «Кайттыңмы?» — дип каршы алды, ләкин ачылып китеп сөйләшүләрдән тыелып яшәде. Сандра белән буталганын башына да китермәгән иде ул. Авыл халкы да белмичә калган, белсә, гайбәтләрен чәйнәми калмаслар иде. Булса да булыр икән! Менә ышан... Тыныч күлдә пәри була, дип, бер дә юкка гына әйтмиләрдер шул!

Ул бу турыда торып-торып уйланды. Бер Сафуан белән Сандраны эченнән генә эт итеп орышты, бер Сафуанын яклап Сандраны гына әрләде, бер Сандраны жәлләп, Сафуанны уттан алып суга салып сүкте...

Шулай да Гөлмәрфуга язмышына буйсынырга булды. Яшьлегендә кем ничек шаярмый да, кем кемне яратмый. Сандра артык чибәр хатын шул, бигрәк тә килеп төшкән мәлне бик күп егет-җиләннең аңа кызыгып селәгәе акты. Ул турыда ачыктан-ачык әйткәннәрен дә ишеткәне булды Гөлмәрфуганың. Ә менә Сафуан белән гыйшык-мыйшык уйнаулары аның өчен көтелмәгән яңалык иде. Ләкин нишләмәк кирәк? Булган-беткән, өстенә мүк үскән. Ахыры хәерле булсын! Сандра дип чапмый бит әле. Үз вакытында алачыгына китә, үз вакытында өйгә кайта...

## XIII

Тын күлдә пәри була... Ай-һай, дөрес әйтә Гөлмәрфуга. Ләкин таяк ике башлы. Ул үзе дә бит шул тын күл, үзе дә серле бер дөнья. Һәм аның сере җиде кат җир астына яшерелгән. Авылда җор телле, умартачы Бөкре Фәтхетдин абзый үзенең бердәнбер кызы Гөлмәрфуганың бу гамәле турында башына да китермәде, сизенсә, үз вакытында хатыны Бибисара гына азрак сизенде бугай.

Барысына да шул Бибисараның туганнан туганы Шакир малае Минзәки гаепле инде. Шакир үзе, мескен, сугышта хәбәрсез югалды. Хатыны кыз чактан ук хаста иде, бердәнбер улы Минзәкине калдырып үлеп китте. Шакир тагын өйләнергә җыенып йөрде йөрүен, тик өлгерә алмады — сугыш башланды. Шып-шыр өйдә ятим малай берүзе калды. Ашарына ашы, кияренә киеме, ягарга утыны юк. Иң якын дигән туганы да Бибисара гына иде. Киңәш-табыш итешеп, унбер яшьлек малайны үзләренә сыендырырга булдылар. Бердәнбер кыз янында малай булуы Бөкре Фәтхетдин абзый өчен дә начар түгел иде. Үгез җигеп урманнан утын ташу, кырдан салам төяп кайту, бәрәңге бакчасын сөрү, малларны карау, башка йорт эшләрен башкару тулысы белән Минзәки җилкәсенә төште. Ә җәй көннәрендә ул умартачының алыштыргысыз булышчысына әйләнде. Эшен эшләгәч, малайның тамагы тук, өсте бөтен — Фәтхи йортында иске-москы бетмәгән.

Колхозның умарталыгы бик зур түгел, булган балына да хуҗалар күп — дәүләткә дә, түрәләргә дә алып китәләр, умартачының үзенә шул чәйлек кенә кала. Шуңа күрә гомер буе ярлы, ачлы-туклы тормыштан шактый тәҗрибә туплаган Фәтхи абзый бәрәңгене булдыра алганча күп утырта иде: үзебезгә дә, малларга да, орлыкка да җитәрлек булсын, сатарга да калсын. Кырда нинди буш җир бар, шунда Фәтхи бәрәңгесе үсә иде. Җирне үгез белән сөрәләр, утыртканда да үгез. Ә эшкәртү... Бусы инде Минзәки белән Гөлмәрфуга җилкәсенә төшә. Тәпкеләргә, бәрәңге арасын өяргә йөри-йөри ике үсмер хәлдән таеп бетәләр иде. Иртән-иртүк тәпкеләр, ярты чиләк чи бәрәңге алып китеп, кичке якта гына кайтып төшәләр. Кырдагы коры-сарыны җыеп, учак ягалар, шунда бәрәңге пешереп ашыйлар. Наратлы чишмәсенә төшеп су эчәләр.

Ләкин бу авыр эштә дә җитлегеп килгән яшүсмерләр үзләренә кызык таба беләләр иде. Бераз гына Минзәкидән олы Гөлмәрфугага, кызларга хас булганча, иртә ис керә башлады. Ерак кырда алардан башка беркем дә юк, өстә, кайдадыр күз күрмәгән җирдә, тургай гына бертуктаусыз сайрый. Матур сайрый тургай, күңелләрне тибрәндерә, дәртләндерә, хыялландыра. Бераз эшлиләр дә, ызанга чыгып, яшел чирәмгә яталар, ял итәләр йә чишмә буена төшеп китәләр. Менә шундый иркле минутларның берсендә Гөлмәрфуга Минзәкигә:

— Әйдә, үбешергә өйрәнәбез, — диде.

Минзәки андый эшнең бик үк ярамаганын да белә, чөнки Фәтхи абзый ишетә калса малайның җиде кат тиресен салдыруы мөмкин. Ләкин Гөлмәрфуга монда аннан олырак, шуңа Минзәки аны тыңламый булдыра алмый.

— Ә ничек? — диде ул, кыюсыз гына.

— Менә...

Гөлмәрфуга Минзәки янына килеп басты һәм малайны үбәргә тотынды. Ләкин малай үбешә белми иде. «Менә син минемчә, минемчә ит», — дип, кыз малайны өйрәтә башлады. Бераздан малай да ярый-сы гына үбешә башлады. Үбешә-үбешә алар чирәмгә егылдылар. Ике үсмер үбешүнең татлы нәрсә икәнлегенә, тәнгә рәхәтлек биргәненә, әллә ничек, күңелне җилкендергәненә төшенделәр. Бигрәк тә Гөлмәрфуга ләззәт белән үбешә иде. Аннары ул, эндәшми-нитми, Минзәкинең кулын алып эчкә кертте һәм калкып, йомрыланып килгән күкрәгенә терәде.

— Син аны тот, сыйпа, миңа аннан бик рәхәт, — диде кыз.

Малай кушканны эшләде. Бу вакытта аның үзенең дә дәрте кузгалып килә иде.

Моны күреп торган кыз:

— Кая, күрсәт әле, — диде.

Малай башта тартынып торды, ләкин әрсез кызның кушканын тыңламый чарасы юк иде. Гөлмәрфу-га шактый озак кызыксынып, кулы белән тотып-тотып, әйләндерә-әйләндерә карап торды тәүге тапкыр күргән әйберне.

— Ә син үзең минекен күрергә телисеңме? — диде аннары кыз, Минзәкинең күзенә карап.

Малай җилкәләрен җыерды: «Күрсәтәм дисәң күрсәт!» — диюе идеме шунда...

Бүгеннән соң алар арасында иң ышанычлы дуслык, бер-берсенә тугрылык, фәкать икесе генә белгән сер урнашты. Шулай да Гөлмәрфуга:

— Кара аны, беркемгә дә сөйлисе булма, икебез генә белгән сер булсын. Ишетәсеңме? — дип ки-сәтте.

Малай башын чайкады. Ятим малай сер сакларга өйрәнгән, аның бу күпмедер дәрәҗәдә хәтта яшәү ысулы да иде.

Икенче көнне дә алар бәрәңге җиренә килделәр, үзләренә билгеләнгән хәтле тәпкеләделәр, учак ягып, бәрәңге пешереп ашадылар, чишмәгә төшеп су эчтеләр, ятып ял иттеләр, кабат үбешергә өйрән-деләр. Ләкин бүген Гөлмәрфуганың үбешеп кенә каласы килмәде, чөнки җитлегүгә таба барган кызның дәрте күәс кебек кабара бара, күңеле алгысый, җилкенә башлаган иде.

— Әйдә, ир белән хатын булып уйныйбыз, — диде ул малайга.

Күндәм малай карышмады, кызның һәр теләген үтәргә тиеш иде ул...

«Олылар уены» аларга тәмам ошап китте.

Ике елдан артык уйнадылар алар бу уенны. Тик бу турыда беркем дә белмәде диярлек. Бибисара гына бер кышкы караңгы кичтә соң гына мунчага киткән Минзәки яныннан кызы Гөлмәрфуганың ки-леп чыкканын күреп алды. Ах, мәлгунь, бер сыйныфта укыган Рәхилә янына барам, дип чыгып киткән иде бит. Ә ул ятим малай белән мунча керә, имансыз...

Ләкин Бибисара тавыш-фәлән чыгармады. Дуамал Фәтхинең мондый очракта нәрсә кыласын белгән хатыны авызына су капты.

Уналты яшендә Минзәкине ФЗӨгә укырга алып киттеләр. Бибисара: «Котылдым!» — дип калды. Гөлмәрфуга кеше күрмәгәндә Минзәкинең муенына сарылып елады. Минзәки: «Кайткач өйләнешербез, Фәтхи абзый риза булмаса, качып китәрбез», — дип юатты. Урал якларына китеп барган егеттән сирәк-мирәк хатлар килде. Соңыннан хатлар да тукталды...

Уеннан уймак чыга. Юк, бу очракта Минзәки белән Гөлмәрфуга уеныннан «уймак» чыкмады. Шуңа да Гөлмәрфугага шөкрана кылып, сөенеп яшәргә кирәк иде. Һәм ул шөкрана кылып яшәде, бүген дә ба-рысыннан да канәгать. Минзәкиең үзе кебек юантык, яссы битле, бәрәңге кебек зур борынлы бер малай ясап калдырган булса, Бөкре Фәтхи йортындагы тавыш яман булган булыр иде.

Гөлмәрфуганың бөтен шөлләгәне Сафуан иде. Кызлык сафлыгын җую әнә шул тимерчегә кияүгә чыкканда исенә төште дә бит, тик гыйффәтлелек кызларда ике булмый шул. Мәгәр Гөлмәрфуганың ул нәрсәсе ике генә түгел, егерме ике булса да кияүгә чыкканчы барысын да җуеп бетергән, саклап калал-маган булыр иде.

Бәхетенә, судан коры чыкты. Бикәчкә кергән кичне Фәтхи абзый ике «Бөгелмә малае»н алып кай-тып куйды. Моның өстенә аның бераз әче балы да бар иде. Мондый олы вакыйганы кияү-балакай белән бик шәплэп билгеләп үтәргә кирәклеген чамалый иде Фәтхи. Бибисарасы да аның бу гамәлен хуплады, чөнки хәтер төбендә хәтәр булу ихтималын кыз анасы сизенә иде. Элегрәк чуаш көмешкәсеннән аз-маз авыз иткәләгән Сафуанның чын аракыны эчеп караганы булмады.

Фәтхинең, карлыккан тамак төбе белән:

— Әйдә, кияү, икегез дә пар килгәнсез, бәхетле тормыш насыйп итсен сезгә Ходай, — дип кыстый-кыстый эчерүе, шуның өстенә аракыны әче бал белән бутау тимерчене тәмам исертте. Ул кайчан һәм ничек мәлҗерәп, оеп киткәнен, ничек чыбылдыкка кәләш янына кергәнен, төнлә кәләш белән эшләре ничек булганын белми дә калды. Гөлмәрфуганың тозагы тозак кына булмады. Бер хатынның хәйләсе кырык ирнең хәйләсеннән дә артык, дип бер дә юкка гына әйтми торганнардыр. Бикәч төнен үзенең

«вакытсыз вакытына» туры китергән мут Гөлмәрфуга иртә белән айнып, уянып киткән Сафуанга кызыл таплы җәймәне күрсәтте. Янәсе, кара, син үз эшеңне эшләдең, ә мин саф идем...

Бу — кияүгә чыкканчы ук каймагын алдырган кызларның борынгыдан килгән хәйләләренең берсе генә әле. Кызының үсмер чакта ук Минзәки белән шаяруын сизенгән хатын аны алдан ук кисәтеп куйды:

— Төбең тишек булса, әйт, чарасын күрергә кирәк. Үзем өйрәтермен, — диде ул. Гөлмәрфуга анасына аңлатып, сүз куертып тормады. Бераз тын торганнан соң: — Әйтәсеңне әйт, — дип, сүзен тәмамлады. Анага барысы да аңлашылды. «Уйладым, уйладым аны: теге тәкәрлек битле мыштым малай башына җиткәндер, дип...»

Бибисара чарасын күрде: ул-бу булмагае дип, алдан ук кызын өйрәтеп куйды. Аның бу эштә тәҗрибәсе бар иде. Кыз чагында үзе дә шундый хәлгә тарыган иде. Бибисараның туган ягында мондый гадәт бар: яшьләр аулак өйләргә йөриләр, уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Аннары кызлар белән егетләр кочаклашып ятып йоклыйлар. Егет кочагында тәнгә тән, аякка аяк куеп йоклаган кызларның күбесе харап була. Бибисара да артык дәрткә бирелеп, үзен-үзе тота алмыйча, чит авылдан кунакка гына килгән бер әрсез алабайның корбаны булды. Югыйсә бик кәттә, чибәр иде ул вакытта Бибисара, Бөкре Фәтхигә генә чыга торган кыз түгел иде.

Гөлмәрфуга әнә шулай төп башына утыртты зуп-зур авылда дан тоткан тимер остасын. Әлбәттә, анасы белән берлектә утыртты. Шуңа да Сафуанның Сандра белән булган шухыр-мухыр хәлләре өчен баш авырттырып торасы килмәде Гөлмәрфуганың. Исәп бергә-бер иде. Әле белеп булмый, бәлки, ул Гөлмәрфуга файдасына артып та китәр...

## XIV

Сандраның баласы үсеп тернәкләнә башлады. Тәпиләп киткән чорда тәтелдәргә тотынды. Шул бала белән бергә усак бүрәнәсеннән салган керәшен өенә ямь керде. Сандра үзе дә яратты баланы, игътибарын шуңа юнәлдерде. Ни гаҗәп, Микулай да, гадәтенчә, бик үк сиздермәсә дә, малайны ярата. «Улым, улым», — дип кенә эндәшә, аның белән уйный, азмы-күпме булса да йомшак, иркә сүзләр дә ычкындыра иде. Моңа Сандра аеруча игътибар итте. Чыннан да, үземнеке дип уйламыйдыр бит ул? Ләкин вакыт-вакыт Микулай Сандрага да, балага да бөтенләй илтифатсыз була. Андый көннәрдә аның йөзе уйчан, кырыс, үзе исә беркемгә дә эндәшми, үз эченә бикләнеп йөри.

Таллы Елгага бер кайтканда, Гөргөри дәдәй белән Начтук түтәй тагын бер бала табу кирәклеге турында сүз башладылар. Бергә-бергә үсәрләр, малайга да туган, иптәш булыр. «Ике бала бер урынында, берсе җук урынында, Кодай сакласын, дөнҗә хәлен белеп булмый», — дигән булды алар. Бу сүзне өч яшен тутырып килгән малай да эләктереп алды: «Миңа уйналга теле бәбәй киләк, ул минем энем була», — диде. Күршеләр дә: «Тагын кайчан бәбәй алып кайтырга җыенасыз, озакламагыз инде, малаегыз үсеп бара», — диештеләр. Бу сүзләрне Микулай да, Сандра да колак аша уздырып җибәрделәр. Ләкин барыбер Сандраның күңеленә кереп калды ул сүзләр, чөнки хатын тагын бала табу турында уйлана башлаган иде.

— Нишлибез сун, Микулай? — диде Сандра, икәү генә калгач.

— Нәрсә, «нишлибез?» — диде Микулай, төксе генә.

— Бала турында, дим...

Микулай эндәшмәде, Сандрага сынап кына карап торды. Аннары:

— Адресын беләсен, — дип ярып салды.

Сандра аптырап китте, ләкин югалып калмады, җиңел сулап куйды. Бу инде ачыктан-ачык сөйләшү иде.

— Рөксәт итәсен? Мин табарга риза, — диде ул, күңеле күтәрелеп һәм ябык гәүдәле Микулаен кысып кочаклады.

— Ярар, ярар, бик нитмә... — диде Микулай. Аннары: — Тулькы онытма, чабуны җыеп җөр, кеше сизәрлек булмасын. Кеше теленә бер керсән...

— Юк, Микулай, кермәм, сак булырмын. Рәкмәт, җаным...

— И тагын... Тимерчедән башканы белмә! Беренче ана җарылдын, бусын да тулькы анардан тап, әллә кемнәрдән төгөл...

Сандра бер кызарынды, бер агарынды — дулкынлануының чиге булмады. Кара инде, Микулай барысын да белеп торган икән бит. Белеп торган, тик әйтмәгән, эндәшмичә түзгән. Тешен кысып түзгәндер инде, бичара. Менә язмыш нишләтә кешене! Башка чарасы юк шул...

Бу минутларда Сандра Микулайны чиксез кызганды да, шул ук вакытта аңа бик рәхмәтле дә иде. Әйе, ул үзенең бөтен кайгы- хәсрәтен эченә җыеп барган һәм тора-бара көчсезлеге, чарасызлыгы белән килешкән. Ә үзе барысы турында да белеп торган. «Тимерче» ди бит. Каян белгән диң син аны? Эчтә җыелып ятканның барысын да бәйнә-бәйнә әллә кайчан сөйләп бирәсе, гафу үтенәсе, шулай кирәк булды бит, дип акланасы калган икән. Ә болай Микулайны тагын да кимсетү, рәнҗетү кебек килеп чыкты.

Ләкин шундый хәлдә дә ул күтәрелеп бәрелмәде, тыныч, сабыр булды. Сабырлык сары алтын шул. Ничек кенә булмасын, Микулай әйбәт кеше икән бит. Әнә ничек булды бит: барысын да Сандраның үз иркенә куйды. Тик каян белде икән соң ул беренче баласының атасы тимерче икәнен? Инде барысы да билгеле, сөйләшү дә ачыктан-ачык икән, Сандра бу турыда да Микулайның үзеннән белешергә булды.

— Минзипа карчык сүләп калдырды, — диде Микулай. — Сер итеп әйтәм, катынын тимерче белән сүрәлә. Данканын атасы да ул бугай, үзе әйтте, диде. Гөнаһымны теге дөнҗәгә алып китәсем килми, әйтеп калдырам, диде.

— Мин аның белән сүрәлмәдем, Микулай, бер-ике генә очраштык. Көмәнем беленгәч тә туктадым мин, — дип акланды Сандра.

Микулай моңа ышандымы-юкмы, кабат сүз кузгатмады. Мәгәр Сандра өчен моның хәзер әһәмияте юк иде инде. Алда бит әле тагын бала табасы, ә моның өчен тагын Сафуан янына барасы, муенына сарыласы, кочасы-үбәсе, назлыйсы-назланасы бар. Сафуанда, фәкать Сафуанда гына бөтен өмет, бөтен ышаныч...

## XV

Җәйге матур көннәрнең берсендә Бөкре Фәтхи абзый йортына бик пөхтә киенгән таза бер егет килеп керде. Фәтхи абзый күрше авылга барырга җыена — аны анда умарта карашырга булышырга чакырганнар иде. Килгән кешегә ул бик текәлеп карап торды, ләкин танымады.

— Нәрсә, Фәтхи абый, танымыйсыңмы әллә үги малаеңны? — дип гөрелдәде кунак егет, калын тавыш белән.

— Йа Хода, Минзәки, синме бу? Менә сиңа мә! Бибисара, дим...

Алар кочаклашып күрешкән арада, кайдандыр Бибисара апа да килеп чыкты. Кунакны өйгә алып кереп киттеләр, анда да шау-шу килделәр, сөйләштеләр-гөрләштеләр. Минзәки туганнарына алып кайткан бүләкләрен, күчтәнәчләрен тапшырды:

— Бусы, Фәтхи абый, сиңа... Бусы, Бибисара апа, сиңа... Бусы Гөлмәрфугага... Ә Гөлмәрфуга нигә күренми? — дип сорап куйды кунак.

— Гөлмәрфугабыз күрше Сафуанга чыкты бит, дүрт ел инде, кыз үстерә, бик матур кыз, — дип тезеп китте Бибисара. — Көненә йөз кереп чыга, әле синең кайтканны белми торгандыр, хәзер кереп җитәр.

Бибисараның ишектән: «Гөлмәрфуга, Гөлмәрфуга!» — дигән тавышы ишетелде. Ерактан: «Ишетәм, нәрсә бар?» — дигән аваз килде.

— Минзәки кайтты, — дип кычкырды Бибисара кызына.

Шул сүзне ишетү белән, Гөлмәрфуга атылып килеп тә керде һәм киң җилкәле, таза гәүдәле егетнең муенына асылынды.

— Күрер көнем бар икән, — дип пышылдады ул кунакның колагына.

Әлбәттә, Фәтхи моны туганнарча кочаклашу дип аңлагандыр, әмма Бибисара өчен ул алай түгел иде.

Унбиш яшендә чыгып киткән үсмер танымаслык булып үзгәргән, тазарган, яшенә караганда олырак та күренә кебек. Нәрсә генә дисәң дә, ун ел вакыт узган. Шул елларда Минзәки Магнитогорск шәһәрендәге бер заводта гади эшчедән мастер дәрәҗәсенә чаклы үскән, шунда фатир да алган. Хәзер исә өйләнергә исәбе. Бәлки, берәр кызны үзе белән алып китәр...

Гөлмәрфуга ак күлмәкле, кара костюмлы таза егеттән күзләрен ала алмыйча карап торды. Аның өчен бер дә көтелмәгән, ләкин сагынычлы очрашу иде бу.

Фәтхи абзый үз эшләре белән күрше авылга китеп барды. Бибисара апа самавырына су, күмер тутырып, аны таш келәткә чыгарып куйды, чөнки көннәр кызу, коры тора, янгын чыгу куркынычы бар иде. Гөлмәрфуга белән Минзәки икенче якка кереп китте. Гөлмәрфуга өчен үсмер чагында ук ләззәтле көннәр бүләк иткән егетнең хәзер каршында басып торуы төшкә кермәслек хәл иде. Аулак өйдә ул кабат Минзәки кочагына ташланды һәм аңардан һич тартынмый, шашып-шашып үбә башлады. Болай назланышу турындагы әлеге мизгелне Минзәки дә, күптән хыялланып, сабырсызланып көткән иде — мөмкинлекне ычкындырмады, үбешү уңаенда кайнар кулы белән Гөлмәрфуганың яртылаш ачык изүеннән йомшак тулы күкрәкләренә кереп китте. Алар, ун ел үтсә дә, бер-берсен бик сагынышканнар, ныклап тансыклаганнар иде.

Кичен бәйрәм өстәле әзерләнде. Фәтхи абзый суеп калдырган тавык инде пешеп табынга чыккан. Минзәки күчтәнәчләре дә өстәлдә. Фәтхи абзый да кунак хакына эшен бүлеп кайтып җиткән. Минзәки ак шешәнең сургычлы бөкесен ачканда гына, кияү-балакай Сафуан да ишектән керде. Каршында үзеннән таза, озын буйлы тимерчене күргәч, Минзәкинең күңеленә нindидер шом төшеп, әллә ничек тәне чымырдап куйды. Ләкин Сафуанның елмаюлы йөзен күргәч, тынычланды. Өстәл әзерләшеп йөргән Гөлмәрфуга исә боларга әйләнеп тә карамады, янәсе, ул үз эше белән мәшгуль, боларда гаме дә юк.

Ашап-эчеп бераз сөйләшеп утыргач, Сафуан: «Эшем күп, комбайннарны, чапкычларны уракка әзерлибез, кабат алачыкка барып кайтасым бар», — дип чыгып китте. Эштән арып кайткан Фәтхи абзый ярты стакан аракы эчүдән оеп китте, мендәргә ауды. Бибисара апа: «Минзәки, мунча әзер, бар, кереп чык», — дип, кунакны мунчага озатты. Гөлмәрфуга анасына өстәлне җыештырышты да: «Киттем», — дип чыгып шылды. Һәм ул, ике дә уйлап тормыйча, сөяркәсе янына ташланды. Бибисара аны үз өенә чыгып китте дип уйлагандыр, ләкин кызы, ашыгып-кабаланып, Минзәки янына мунчага барып керде һәм мизгел эчендә чишенеп тә ташлады. Ун ел буена бик сагынган, хыялында йөрткән, төшләрендә күреп саташкан, гомеренең иң сизгер, иң дәртле башлангычында ике ел вакытын бизәгән ир-егетнең кайтып төшүе аны тәмам алгысытып, дәртләндереп җибәргән иде. Иң элек ул аны ун елдан соң анадан тума хәлендә күрергә теләде. Ундүрт-унбиш яшьләрендә анадан тума исәпсез күрде ул аны, мунчаны да аз кермәделәр бергә, табигать кочагында да булгаладылар. Ә менә хәзер...

Кайнар пар җибәреп, яңа каен себеркесе исе белән тулган кызу мунча ләүкәсендә әвен хәтле булып утырган Минзәки теге вакыттагы малай-шалай гына түгел икән. Киң җилкәле, таза бәдәнле бу кеше бик мәһабәт күренә иде. Гөлмәрфуга иң элек Минзәкинең ирлек горурлыгы белән кызыксынды. Бу инде элеккеге «шырпы» түгел, чын-чынлап шәп коралга әйләнгән иде. Шул коралы һәм тагын әллә кайсы яклары белән егет нәсел үгезенә охшап китте. Гөлмәрфуга аңа карап сокланып туялмады: «Менә ичмасам егет, астыннан җиде көн, җиде төн чыкмассың...»

Кинәт кенә кавышу хозурыннан ниләр генә эшләп, нәрсәләр генә кылып, ничек кенә назланышып бетмәделәр алар шул сихри кичне. Һәм, җае чыккан саен, үсмер чакларын сагынып искә алдылар: «Хәтерлисеңме, теге җирдә тегеләй, бу җирдә болай иткән идек...» Бигрәк тә Гөлмәрфуга өчен татлы иде инде ул вакытларны кайтып-кайтып искә алулар...

Өч көн, өч төн кунак булды егет. Һәм шул өч тәүлектә һәр минутны Гөлмәрфуга белән Минзәки бергә үткәрергә тырышты. Өч көндә дә мунча ягылды.

Фәтхи абзаларына кайтып, мондый да абруйлы кунак булудан Минзәки канәгать иде. Бибисара апаның пешкән тавыклары да, коймагы да, өстәлгә чыккан аракылары да — барысы да күңелгә бик хуш килде. Ә менә Гөлмәрфуга белән икәүдән-икәү калып үткәргән минутлар... Ах, аларны мәңге онытып булмас, мәңге истә калырлар, ахры...

Минзәки, кайткан көннән башлап, Гөлмәрфуганы үзе белән китәргә кыстады.

— Мин бит сине алырга кайттым, — диде ул. — Синнән башка китмим...

— Ә элек нәрсә уйладың соң? Иртәрәк, һич югында, дүрт ел элек кайтасы идең, мин Сафуанга чыкканчы. Ул чагында уйлап та тормаган булыр идем. Аннары... Без бит синең белән туганнар, ярыймы соң безгә өйләнешергә?

— Нишләп ярамасын? Ярыйбыз бит әле бер-беребезгә. Ун ел элек тә ярады, хәзер дә... Теләк, дәрт туганмы дип сорамый...

— Юк, Минзәки, анысы аның башка хәл. Азгыннар без синең белән, артык азгыннар. Түшәктә ярашабыз да бит, бергә яши башлагач, бала табасы була. Ә ике якын туганнан туган балалар гарип булалар.

— Ну да!.. Безнең заводта үзбәкләр эшли. Алар әнә, чтобы кәләш атасына калымны күп түләмәс өчен, даже двоеродныйларына өйләнәләр.

— Шуңа күрә аларның күбесенең баласы аңгыра, акыш-макыш була да. Минем дә ишеткәнем бар ул турыда.

— Ә бит без только троеродныйлар...

— Юк, Минзәки, болай ярамый, уйларга кирәк.

— Озак уйларга вакыт юк. Мин бит сине городка алып китәм, тирес оясында күпме яшәргә була?

— Юк, хәзер соң инде, безнең монда да тормыш җайланып килә.

— Җайлана ди! Колхозда тормышның беркайчан да яхшырасы юк. Аны гына беләбез инде. Идет беспощадная эксплуатация колхозного крестьянства. Ул элек тә булган, бүген дә продолжается с такой же жестокостью. Без бит тоже сөйләшәбез заводта. Әзме-күпме башы эшләгән кешеләрнең барысы да авылдан чыгып кача, ибо тут концы можно отдать. Скажи менә, былтыр күпме зерно бирделәр трудоденьгә сезнең колхозда?

— Былтыр ярты кило бирделәр, ә элек ике-өч йөз граммнан артмый иде. Быел тагын да күбрәк бирәләр дип ишеттек, әгәр иген уңса.

— Ну что это ярты кило? Синең ничә трудодень бар инде?

— Мин бит фермада эшлим, сыер савам. Ел әйләнәсенә 350 хезмәт көне төшә инде.

— Так стало быть... Давай посчитаем... Значит, синең ел буена баш күтәрми бил бөгеп эшләгәнеңә 175 килограмм хлеба. Да-а, не густо. Күп булса, өч капчык... Мәсхәр бит бу! А на заводе мин бер айга ике-өч мәртәбә больше получаю, чем ты за весь год. Давай, поехали! Тут нечего думать...

— Юк, Минзәки, соң, дим бит.

— Нишләп соң булсын? Әле син дә, мин дә по-настоящему яши генә башладык...

— Ә бала? Кызым үсә бит минем. Өч яшьтә. Аның анага иң кирәк вакыты.

— Анысын үзеңә карыйсың. Хочешь — возьмешь, не хочешь — оставишь... Можно на время калдырып торырга, соңыннан кайтып алырсың. Кайтып алмыйм дисәң, мин сиңа үзем бер куча бала ясап бирермен. Так что, озак уйларга вакыт юк. Забираешь самые нужные документы, еще кое-что...

— Әтиләргә-әниләргә әйтми булмый бит инде...

— Ты что, с ума сошла? Может, алачыкка барып Сафуаннан да разрешение сорарсың?

Башта бик нык икеләнсә дә, соңыннан Минзәкигә ияреп качарга ниятләде Гөлмәрфуга.

— Мин Минзәкине юлга хәтле озата чыгам, — дигән булды ул анасына.

— Әни, мин дә балам синең белән, — дип, күлмәгеннән тарткалады өч яшьлек тупырчык кебек матур кыз.

— Кызым, анда ерак, арырсың. Мин хәзер кайтып җитәм, — диде ул, кызын юаткан булып. Һәм аны кочып үбеп алды. Бу аның кызын — йөрәк парәсен соңгы күрүе, соңгы кочуы, соңгы үбүе иде.

Шушы китүдән Гөлмәрфуганың Каенлыда эзе дә булмады.

## XVI

Микулай белән ачыктан-ачык аңлашкач, сөйләшкәч, Сандра канатланып китте, рухланып, җанында ниндидер җиңеллек тоеп йөри башлады. Элек ул үзен караклыкта йөргән кеше сыман хис итә иде. «Кайчан минем Сафуанны җаратуым турында сизәрләр, кайчан Микулайга болар билгеле булыр һәм ул нәрсә әйтер?» Ә хәзер бу авыр тойгылардан ул азат. Микулае аңа тулы ирек куйды.

Ул соңгы вакытта Сафуанны сирәк күрә. Сафуан өйләнгәннән соң акылына килде, басылды бугай. Сандраның үзенә дә басылырга вакыт иде. Ләкин менә яңа хәл килеп туды бит әле. Сафуан белән аңлашып сөйләшми булмый инде.

Ләкин бу юлы Сандра бик сак булырга тырышты, чөнки аңа хәзер үзен дә, Сафуанны да уңайсыз хәлдә калдырырга ярамый, һич ярамый. Шуңа күрә ул Сафуанның алачыгына соң гына, инде кич җиткәндә генә, кеше-кара күргәнче кереп чыгарга булды.

Сафуан, бичара, һаман шул сандалы янында, аның кулында олы чүкеч һәм ул тиргә батып эшли дә эшли.

Сандраны күрү белән, тимерченең арыган йөзе яктырып китте.

— Син дөньяда бармыни әле, Сания җаным? Һич күренмисең, сагындырыпмы сагындырасың, — диде ул, моңсу елмаеп.

— Мин дә бик сагынам да бит... — диде Сандра. — Мына килдем әле. Җомышым бар...

Сандра, озын-озакка сузмыйча, фикерләрен сөйләп бирде. Сафуан Микулайның Сандра белән аның арасындагы хәлләрне белеп торуына чиктән тыш гаҗәпләнде. Тагын да гаҗәбе — Микулайның Сандрага тимерчедән икенче бала табарга рөхсәт итүе булды. Билгеле, бу бөтен кәртне ачып салу дигән сүз түгел, сер сакланырга тиеш. Авыл хатыннары гайбәтне эләктереп кенә алырга тора. Аллам сакласын!

Сүз арасында Сафуан Сандрасын күзәтте. Әлбәттә, ул элеккечә үк чибәр, сылу — һич үзгәрмәгән. Бала табу аңа килеште, ахрысы, ул тагын да чибәрләнеп киткән кебек тоелды тимерчегә. Бер дә юкка гына әсәрләнмәде инде ул аның белән, мондый гүзәл җанны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың.

Сандра бала турындагы тәкъдимне Сафуан кабул итмәс, өйләнгәннән соң андый адымнан сакланыр, шикләнер дип уйлаган иде, ләкин Сандраның аңлатуы дәлилле, нигезле булды — Сафуан каршы килмәде.

Микулайның кабат Акташта куна калган кичендә Сафуан, теге еллардагыча дулкынланып, Сандраның утсыз өенә барып керде. Бу тимерченең: «Эшем күп, комбайннарны, чапкычларны уракка әзерлибез», — дип, бабасы Фәтхи абзыйның аш өстәлен калдырып чыгып киткән киче иде. Юк, ул ялганламады. Башта чыннан да алачыгына төште, ясыйсы әйберләрен ясап, эшен бетереп, әзерләп куйды. Шуннан соң гына Сандрасы янына китте. Сандра, һәрвакыттагыча, аны сагынып һәм ашкынып көтә иде. Яратышу, иркәләшү-назлашу гадәттәгедән һич тә ким булмады. Ләкин, мин өйләнгәч, төн кыскарды дигәндәй, вакыт тиз үтте. Сафуан өенә соң гына кайтса да, Гөлмәрфуга атасы-анасы йортыннан чыкмаган иде әле. Моңа Сафуан сөенде генә, чөнки аңардан: «Нигә озак тордың?» — дип сораучы булмады. Белсә икән ул бу вакытта хатынының ике арадагы читән буенда салынган мунчада Минзәкие белән рәхәтләр гизеп ятканын! Юк, ул аны башына да китермәде. Чишенде дә ятып йоклады.

## XVII

Гөлмәрфуганың өч яшьлек нарасыен, бөтен авылга абруйлы тимерчесен, картаеп барган анасын һәм бөкре атасын ташлап сөяркәсе белән качуын ишеткән Каенлы Чишмә халкы ах итте. Авылда бер дә булган хәл түгел иде бу. Акылга сыймаслык, кеше ышанмаслык сәер эш. Бигрәк тә Сафуан моны авыр кичерде, хурланды, кимсенде, хәтта чигәсендәге чәчләренә чаклы чалланды. Шулай да үзен кулга алды. Иң элек сабыена үзенең анасын алыштырырдай кеше кирәк иде. Моның өчен аның каршына һич кичек-

мәстән өйләнү мәсьәләсе килеп басты. Бу урында ул Сандра турында да уйлап карады, ләкин аның Микулаен кая куясың?

Нәкъ шуны сизгәндәй, бер иртәне алачыкка урман каравылчысы үзе килеп керде. Элек аның беркайчан да алачыкка юлы төшкәне булмады. Ә бүген... Кул бирмәде, керәшеннәрчә, арулармысез! димәде. Ишектән керүгә сүз башлады, кеше-фәлән килеп кергәнче әйтәсемне әйтеп бетерим дип уйлады бугай.

— Синен хальне ишеттем. Но Сандрайга ырасчут тотма! Ул акмак катыннын синен белән күзе-башы әйләнгән. Андый ырасчутын булса, плохо будет. Онытма, миндә ыружье бар...

Тимерче сөяркәсенең ире сөйләгәнне каушамыйча тыныч кына тыңлап бетерде. Һәм шулай ук тыныч җавап бирде:

— Мин дә яхшы беләм синең хәлне, Микулай. Ләкин борчылма, мин Сандраңа исәп тотмыйм, синең хәләл өлешеңә керергә уемда да юк. Яшермим: булганы булды, син аны үзең дә беләсең. Инде моннан соң... Тыныч яшәгез! Ә мин үземә табармын...

Урман каравылчысы ничек килеп кергән булса, шулай тиз чыгып та китте. Ару бул димәде, сөйләштек-аңлаштык димәде.

Шулай да Сафуан Микулайның бу кереп чыгуыннан тынгысызланып калды. Нигә кирәк булды урман каравылчысына мылтык белән янарга? Сафуан аннан курыкмый ич. Яхшылап аңлашу аларның икесе өчен дә кулай иде югыйсә. Ләкин Микулайны да аңларга кирәк. Ул Сандрасын югалтудан шөлләде булса кирәк. Язмыш тарафыннан кимсетелгән, кыерсытылган мескеннең бердәнбер якын кешесе, бердәнбер өмете, ышанычы — Сандра. Ул иреннән китеп барса, Микулайның бу дөньяда яшәвенең мәгънәсе дә калмый. Ә Сандра аныкы, бөтен гөнаһлары, «җазыклары» белән аныкы. Алачыкка килеп дөрес эшләде урманчы, үзенең характерын күрсәтте. Сугышчан характер! Утны-суны кичкән кеше характеры...

Ир — хатынсыз, үрдәк сусыз тора алмый. Берничә көннән Сафуан кызына яңа әни, үзенә икенче хатын алып кайтты. Бу — Сафуанның үзе белән мәктәптә бер сыйныфта укыган, кияүгә чыгу өмете өзелеп барган Мөршидә иде. Колхоз эшенең кайсына гына тотынмасын, җимертеп эшли торган, беләкләре, йөзе кояшта янып, кызарып беткән уңган авыл кызы иде ул. Гәүдәгә дә, төскә-биткә дә Гөлмәрфугадан бер дә ким җире юк, ә бәлки, күркәмрәк тәдер әле. Йомшак нечкә күңелле, сабыр холыклы кыз беренче очрашуда ук өч яшьлек Даимәне сөя-сөя елап кочагына алды, аңа иркә сүзләр әйтте. Шул күрешүдә үк бәләкәй кыз аңа чытырдап ябышты, яныннан китмәде, еш кына «әни, әни» дип эндәште. Аларның шулай матур чөкердәшүен күзәтеп торган Сафуанның да күңеле тулып китте, берсенә дә күрсәтмичә генә күзләрен сөртеп-сөртеп алды. Һәм эченнән генә, «үз гөнаһларымның җимешен татыйм инде мин, үз гөнаһларымның» дип уйлады.

Тагын ике-өч көннән Сандра, алачыкка килеп, үзенең авырга калу сөенечен алды...

Вакыйгалар берсе артыннан икенчесе алмашына барды. Авылда: «Керәшеннәр китәләр икән», — дигән хәбәр таралды. Моны алачыкка килгән кешеләр Сафуанга да яңалык итеп сөйләп калдырдылар. Ә аның йөрәккәйләре өзелеп төшә язды.

Чынында исә Микулайны Акташка лесничий итеп күчергәннәр икән. Теңкәсенә тигән Каенлы Чишмәдән тизрәк китүне кулай күргәндер Микулай, икенчеме-өченчеме көнне үк, бар булган өй җиһазларын ике арбага төяп, Сандрасы белән Данкасын утыртып китеп тә барды.

Сандраның таң атар-атмас алачык янына килеп, ишек ярыгыннан эчкә ташлаган хатын Сафуан укыганда, алар Акташ юлына чыкканнар иде инде. *«Сапуан, бәгырем!»* дип башланган иде бу хат. Сафуаннан отып калган «бәгырем» сүзе яшь керәшен хатынына да бик ошый иде, шуңа ул сөяркәсенең иң иркә, иң нечкә хисле сүзен кулланмый булдыра алмады. *«Сапуан, бәгырем! Мына айрылышабыз да. Сине уйлап, сине күрәлмәуемә офтанып җөрәккәйләрем өзгәләнә. Бигерәк тә җараттым шул сине, Сапуан җаным! Бүтәнне беркайчан да шолай җаным-тәнем белән җарата алмам, көнелемдә син генә булырсын инде гүмергә. Булдыра алсаң, Акташка килергә тырыш, мин сине сагынып көтәрмен. Онытма, минем корсагымда синең тагын бер сабыең җанланды.*

*Сапуан, җаным! Син минем җыруларымны җаратадыр иен. Булары сонгы җыруларым булсын.*

*Сахраларга чыгып җөрсәм дә мин,*
*Җал булмыйдыр җанган җөрәккә;*
*Әкрен генә тирән уйга чумам,*
*Башым куеп җалгыз тирәккә.*
*Сары ла чәчәк ата көнбагыш,*
*Синсез күнелемдә тулы сагыш.*

*Син беренче булып җафрак җардын*
*Җырларымда, минем күнелемдә;*
*Син бердәнбер чәчәк аттын*
*Гөлләр төсле үрелеп җөрәгемдә.*
*Сары ла чәчәк ата көнбагыш,*
*Синсез күнелемдә тулы сагыш...*

*Хуш, ару бул, Сапуан бəгырем! Җаза алмыйм, күзлəрем җəшлəнə...»*

Сафуанның да күзлəре яшьлəнде, тик аларны беркем дə күрмəде — алачыкта ул ялгыз иде.

## XVIII

Көзгə таба Каенлы Чишмəгə генə түгел, ə бəлки, бөтен тирə-якка җирле халык өчен көтелмəгəн яңа хəбəр таралды: «Нефть, кара алтын тапканнар!» Озак та үтмəде, Миңлезифа карчыкның тəрəзəлəре кабык белəн каплаган иске ызбасын бораулау конторасы иттелəр: аралыкны, сəкене сүтеп ташладылар да, өстəллəр, урындыклар, хəтта бер шкаф та кертеп урнаштырдылар. Лəкин бораулау конторасы өчен бу ызба гына җитмəде. Җитəкчелəр Акташка Микулайны эзлəп киттелəр: «Йортыңны безгə сат!» — дип. Микулайга шул гына кирəк тə иде. Сүтеп, Акташка күчереп салырга дип уйлап тора иде йортын, бəхете бар икəн, һич уйламаган зур бəягə сатып та калдырды ул аны. Кулыннан килмəгəн эше юк, уйламаганда-көтмəгəндə кулга кергəн бу акчага берне түгел, ике йорт та җиткерер əле ул Акташта.

Яңа вакыйгалар Каенлы Чишмəнең дə язмышын төбе-тамыры белəн үзгəртте. Ярлы колхозның җирлəрен алып, исəпсез-хисапсыз төрле йортлар, биналар, гаражлар, цехлар төзи башладылар. Колхозчыларга да төшемле, акчалы эш җитəрлек булды. Иртəгəсе көн өчен кайгырып, янып-көеп яшəгəн авыл крəстиəннəре өчен яңа тормыш башланды, алар җиңел сулап куйдылар.

Озын буйлы, таза гəүдəле Сафуан, Тирəкле инеше буендагы алачыгын ташлап, буровойга китеп барды. Үсмер чактан ук язмышын шушы алачык белəн бəйлəде бит ул. Шушы алачыкта эшкə өйрəнде, тəҗрибə туплады. Шушы алачыкта тəүге тапкыр сөю хисенə бирелде, сөю хозурын татыды: Сандра-Санияне кочып сөйде, аның белəн күп мəртəбəлəр очрашты, аның аяз күк кебек зəңгəр күзлəре, алсу-ак көлəч йөзе, пешкəн чия кебек карасу-кызыл иреннəре, моңлы тавышы белəн сихерлəнде.

— Рəхмəт, алачыгым, рəхмəт сиңа, тик гаеплəп калма инде, гафу ит, — диде Сафуан ишектəн чыккач һəм бер якка кыйшайган, корымга баткан алачыгына башын иде. Бу мизгелдə Алып батыр кебек таза, мəһабəт буйлы ир-егетнең күзлəреннəн кайнар яшь бөртеклəре тəгəрəп төште...

## Икенче кисәк

### I

Дөньяны шаулатты бу нефть, кара алтын дигән галәмәт. Элек тып-тын булган урман-кырларда, текә тау итәкләрендә, елга буйларында хәзер гөрләп буровойлар эшли, алар бораулап киткән кое-скважиналардан ургып-ургып нефть чыга, ә ул очсыз-кырыйсыз нефтьүткәргечләр аша еракларга агып китә.

Юк, нефть дөньяны шаулатып кына да калмады. Күрә торып ярлы авыл халкы тормышын үзгәртте ул. Кичәге колхозчылар буровойларга, нефть чыгарырга, төзелешкә ашкынып киттеләр. Салам түбәле татар авыллары янында матур-матур яңа торак йортлар, оешмалар, цехлар, автобазалар калыкты. Иң мөһиме: кеше дигәнең тырыш хезмәтенә күрә, ниһаять, акчасын да алу бәхетенә иреште. Шулай булгач, аның шәхси тормышында да уңайга үзгәреш китте.

Ул гына да түгел, тормышның шушы өметле яклары халыкны яктылыкка тартып чыгарган кебек булды. Адәм баласы инде шатланып башка кимәлләрдә уйлана, фикер йөртә, гәп, фәлсәфә кора.

Әнә Микулайны гына карагыз: үзе урманын ташламаса да, җиткән улы Данканы нефть институтына укырга җибәрде. Ә бит үз вакытында ул Данканы үзе кебек үк урманчы булыр дип уйлый иде. Әйе, улын югары белемле урманчы итәргә иде аның исәбе. Күреп-белеп тора: хәзер дөньялар үзгәрә. Урман, урман... Аның белән хәзер исәпләшмиләр дә. Буровойга урын кирәк, нефтьүткәргеч сузарга трасса кирәк, диләр дә гасырлар буе тын гына үсеп, күккә ашкан нарат, чыршы, каен, имән, юкә урманнарын дөбер-шатыр актарып, кисеп-тапап, яндырып китәләр. Урманнардагы барлык җәнлекне, кош-кортны пыран-заран китереп, атып-куркытып бетерделәр. Элек кеше аягы да басмаган чәчәкле аланнарны кара мазутка батырдылар. Нефть кенә байлыкмыни? Гомер-гомергә кешене җылыткан, ашаткан-эчерткән дә, киендергән, сөендергән дә урман байлык түгелмени?.. Кара мазут хәзер көмеш кебек сулы урман инешләре белән агып елгаларга төшә. Бу комсыз кешеләр, бер байлыкны алабыз дип, икенче байлыкны харап итә бугай.

Әле өченче ел гына, ике зур урманны кушу ниятеннән, Коры елга артындагы өч гектар буш мәйданга каен үсентеләре утырткан иде. Яздан алып көзгә чаклы тырышып эшләде питомниктагы хатыннар. Җәй коры килде, үсентеләр һәлак булмасыннар дип, күпме су ташыдылар. Шахмат тактасындагы шашкалар кебек тигез итеп, әйбәтләп утыртканнар иде. Агачлар үсеп, көчәеп, тамыр җәеп җибәргәч, шуннан да матуррак каен урманы булмас, урманга килгән һәр кеше сокланып туя алмас дип уйлаганнар иде. Ә күптән түгел... Йөрәк ярасы белән искә ала аны Микулай да, Сандра да, питомникта эшләгән башка хатыннар да. Тернәкләнеп киткән шул яшь үсентеләр мәйданын урталайга кисеп, нефтьүткәргеч төзүче җансызлар киң һәм тирән чокыр-траншея казып чыкканнар.

Микулай Данканы үз теләгенә каршы җибәрде. Җибәрмәс тә иде, дөнья үзгәрә. Атасы белән бәләкәйдән үк урман хуҗалыгының мәнфәгатьләрен кайгыртып үскән, аны чиксез яраткан сары башлы малай үзе дә башта урманчы булу хыялы белән яши иде. Ләкин анасы һәм атасы белән озак уйлашканнан соң, ул бүгенге тормышка кулайрак белгечлекне сайларга булды.

### II

Институтны тәмамлап кайткан Данилны эшкә Аккүл нефтьчеләр бистәсенә җибәрделәр. Зур калалар кебек шаулап тормаса да, Аккүл егетнең күңеленә ошады. Ике-өч катлы йортлар, нефть идарәсе урнашкан олы бина, культура йорты, кинотеатр, төрледән-төрле башка биналары, торак йортлары белән тигез булып сузылган урамнар да бар монда. Тротуар, урамнарда, мәйданнарда асфальт. Һәр җирдә яшеллек. Исеменә җисеме туры килә дигәндәй, бистәдән түбәнрәк, иске авылның көньягында искиткеч зур күл җәйрәп ята. Бистәсе бер хәл, шушы күлне бик яратты Данил. Әллә көнчыгыштан биек таулар уртасында булгангамы, әллә ботаклары су өстенә авып үскән карт тирәкләр; ак кәүсәле, куе яфраклы каеннар, төрледән-төрле куаклар һәм тыныч, җилсез көндә дә кыштырдашкан камыш белән уратып алынгангамы, бирегә җил дә үтеп керми, һәм шуңа күл өсте һәрвакыт тыныч, көзге кебек тигез һәм якты. Су өстенең тынычлыгын сирәк-мирәк йөзеп үткән кыр үрдәкләре һәм авыл казлары гына бозып куялар.

Мәһабәт тирәкләр һәм каен аллеясы астында күл буйлап тар гына сукмак сузылып ята. Дистәләгән әлеге тирәк һәм каен ботаклары сукмак өстендә дугаланып килгән мәгарә гөмбәзен хәтерләтә. Рәхәтләнеп бер саф һава сулыйм, җаныма тынычлык табыйм, тәнемә сихәт алыйм дигән бистә кешеләре шушы күл буена чыга, тирәкләр ышыгында сукмакта йөри, уйлана-моңлана, таныш-белешләрен очрата, сүз-фикер алыша. Бигрәк тә кичке якта, эңгер төшкән чакта су буенда халык күп була. Яңа бистәнең әлегә паркы да, сквер-бакчасы да юк, халыкның ял урыны әнә шул бердәнбер ыгы-зыгысыз почмак — күл.

Еш булмаса да, тулай торактагы бүлмәдәше Тимеркәй белән Данил да күл буйларын бер әйләнеп кайткалыйлар. Эш эш инде, анысы үзе бер мәшәкатьле дөнья. Тимеркәй буровойда гади бораулаучы. Ә Данилны промыселга мастер итеп алдылар. Эше дә, шартлары да, кешеләр дә яңа әле аның өчен. Барысына да төшенәсе, өйрәнәсе, бөтен яктан да тәҗрибә туплыйсы бар.

Эштән соң егетләрнең дүрт яклары кыйбла — кая барырга теләсәләр, шунда чыгып китәләр. Күбрәк кино карыйлар. Кайбер кичләрне культура йорты янындагы танцы мәйданына да сугылалар. Ни дисәң дә, яшь чак, гайрәтле чак, кызлар күзли торган чаклары бит аларның. Ә кызлар... Һи-и, алар кайда гына юк! Бию мәйданында да, күл буенда да, урамда да очратырга буладыр җаның теләгәннәрен. Тик Данил өчен бередә андый кызның очраганы булмады әле. Гомумән, кызлар дигәндә, Данилның беркайчан да онытылып китеп бәйләнешкә кергәне юк. Институтта бергә укыган кызлардан беренче елда ук гайрәте чикте аның. Ата-ана канаты астыннан чыгып күз уңыннан ычкынган, ирекkә сусаган, күзе-башы тонган бу чәчбиләрнең кыланмаганы калмады: хәмерне дә чөмерделәр, тәмәкене дә пыскыттылар, итәк асларын да җилләттеләр. Хәтта уйнаштан бала тапканнары да булды. Һәм Данилга югары уку йортында укыган барлык хатын-кыз тотнаксыз, әхлаксыз кебек тоелды.

Ләкин кызлардан, гомумән, хатын-кыздан башка да яшәп булмый. Данил да бер тыйнак, югары әхлаклы кыз турында хыяллана да бит... Насыйбы язган микән соң?..

* * *

...Җылы, якты, саф һавалы бер кичтә Данил белән Тимеркәй тагын күл буена төштеләр. Үз җайлары белән һич ашыкмый, сөйләшә-сөйләшә тар сукмактан барганда, каршыларына әлегә кадәр алар белмәгән-күрмәгән, һич таныш булмаган, бүгенгә чаклы бистәдә күренмәгән бер кыз килеп чыкты. Ул да ашыкмый, салмак кына атлап килә. Түгәрәк ачык йөзле, дөнья чибәрләрендә дә сирәк була торган төз, сылу гәүдәле. Аяклары да зифа, матур. Коңгырт-кара чәчләрен пөхтә итеп икегә аерып тараган да калын толымнарын аркасына ташлаган. Өстендә исә гәүдәсенә сыланып, аның сылулыгын аерым билгеләп торган бик килешле, затлы тукымадан теккән аксыл күлмәк, аягында биек үкчәле ак туфли. Гәүдәсен туры тотып, ышанычлы нык адымнар белән атлап килә кыз. Уртача буйлы гына булса да, килешкилбәте белән һәркемне таң калдырырлык бу фәрештә егетләрнең каршына килеп чыккач та, алар, бу могҗизадан дөньяларын онытып, телсез-өнсез калдылар.

Кыз алар яныннан тыныч, күбәләктәй җиңел талпынып, төз басып, һичбер тавыш-тынсыз үтеп тә китте. Әйтерсең лә егетләрне күрмәде дә. Аннан бары искиткеч тәмле ислемай исе генә калды.

— Менә сиңа мә-ә, — дип пышылдады Тимеркәй. — Каян килеп чыкты соң әле бу асыл кош? Әлегә кадәр күренми иде түгелме соң? Әл-ләл-лә...

— Юк, күренгәне булмады бугай шул.

— Әйдә, борылыйк, Данил, артыннан барыйк, — диде Тимеркәй, сабырсызланып.

Данил талпынып куйды, артына, ягъни кыз киткән якка борылып карады. Кыз, төз адымнар белән, алардан шактый гына ераклашырга өлгергән иде.

— Тукта, Тимеркәй, ашыкма! Болай бөтен эшне бозып ташлавыбыз бар. Сабырлык — сары алтын. Бала-чага уены булмасын. Бу кыз андый-мондый гына түгел.

— Соң, китә бит...

— Китә дип... Инде бер күргәнбез икән, тагын очратмый калмабыз әле. Монда, бистәдә бит ул.

Шулай диде Данил. Әйтүен әйтте, тик үзенең дә эченә ут капканын иптәшенә белгертмәде.

Икенче көнне эштән кайткач, Данил белән Тимеркәй ашханәгә кереп бераз капкаладылар һәм һичбер сүзсез аска, күл буена төшеп киттеләр. Икесенең дә башында бер уй: кичәге кызны очрата алмаслармы күл буендагы сукмакта? Килерме бирегә? Төшсә, бу юлы телсез калырга ярамас, ничек тә булса сүз кушу, сөйләшеп алу әмәлен табарга кирәк булыр. Һәм сорашырга: кем син, каян, кайсы төбәктән, кайсы елга аръягыннан килеп чыктың? Озакка килдеңме, әллә кунакка гынамы? Тормышта бит мондый очраклыклар да бик күп. Тик килгән-килгән бик озакка килсен, кунакка гына булмасын иде...

Эштә көн буе Данилның күз алдыннан китмәде фәрештә кебек ак, матур йөзле, аксыл күлмәкле сылу кыз. Әллә ничә кат аның йөзен, күзләрен бар нечкәлекләре, бар гүзәллекләре белән исенә төшерергә тырышып карады, тик хәтерли генә алмады. Бик тиз үтеп киткән иде шул ул алар яныннан. Чыннан да, нинди төстә иде соң әле аның күзләре: коңгыртмы, зәңгәрсумы, әллә башка төстәме? Ләкин, нинди генә булмасын, матур һәм... моңсу иде алар. Әйе, күзләренә генә түгел, йөзенә дә чыккан иде аның моңсулыгы, уйчанлыгы. Нигә шундый икән ул?

Алар тирәк һәм каен агачлары янында озак йөрделәр. Күлнең теге башына да бардылар, бу башына да килделәр, тагын әйләнделәр. Тик таныш кызны гына очрата алмадылар. Суга чумган кебек юк булды ул.

— Менә әйттем бит мин сиңа, артыннан барыйк, дип. Киткәндер инде. Ничә тиенемә кирәк аңа синең Аккүлең? Бистә, имеш. Олы-олы калаларда йә булмаса зәңгәр диңгез буенда яшиләр андый матурлар, синең бака күлең буенда түгел, — дип мыгырданып кайтты Тимеркәй, юл буе Данилның болай да уттай янган йөрәген әрнетеп.

Иртәгесен дә сөмсерләрен коеп, бер-берсенә эндәшмичә, кызны очрата алмый кайтып керделәр алар тулай торакка. Соң иде инде. Чишенделәр дә урынга яттылар.

Инде йокыга гына китәм дигәндә, Данилга Тимеркәйнең тонык тавышы ишетелде:

— Юк, ул бик акыллы. Матур, ләкин горур. Югарыдан, Асылъяр кебек морзалар нәселеннән. Аксөяк! Минем ишегә карыймы соң ул? Тот капчыгыңны, Тимеркәй! Үсәсең бар әле, буровойда эшләп чабатаңны алыштырасың, өстеңә бер рәтле кием алып киясең, аннан буровоеңны ташлап укыйсың, кеше буласың бар... Әнә инженерга бара ул. Ишетәсеңме, инженер галиҗәнаплары? Буй-сының үзеңдә, затың бүтән, сүзгә дә оста, мәкальләр һәм әйтемнәр белән генә сиптерәсең. Ычкындырма син моны, малай! Алай-болай кабат очрый калса, сразы бар янына, оялып торма! Валлаһи! Тимеркәй кушты, ул минем дустым диген. Күктән төшкән, Тәңредән иңгән бүләк бит бу, Данил-малай...

— Йә инде, юкны сөйләмә, Тимеркәй, — диде Данил, бүлмәдәшенең күңеленә каты кагылмый гына. Әмма серле кызны күрәсе килү теләге тагын да көчлерәк сыман тоелды.

### III

Тимеркәй буровойга кичке вахтада йөри башлады. Ул шулай эшкә йә иртә таңнан, йә кичке якта, йә төн уртасында чыгып китә. Данилга, бүлмәдә үзе генә калгач, ямансу булып китә.

Бүген ул эштән соң күл буена төшмәскә, үз җанын үзе үртәмәскә, булмастай хыяллар белән җенләнмәскә уйлаган иде: «Ичмасам, бер рәхәтләнеп кино карап кайтыйм...»

Барып җитеп билет алганчы, кино инде башланган иде. Данил, тамашачылар арасыннан капшанып, бер буш урынга барып утырды. Тик тынычлана алмады. Үзе кино карый, ә үзенең күңеле күл буенда: ул төшкәндер инде, берьялгызы йөри торгандыр... Әй, бетмәс лә бу кино, иртәгә дә, аннан соң да була бит әле ул.

Күңелне сизә, диләр. Данилның да күңеле тыныч түгел иде ул көнне. Кинотеатрдан чыкты да, ешеш атлап, күл ягына китте.

Әмма төшәргә өлгермәде, каен аллеясыннан аңа каршы ике кеше килеп чыкты. Берсе ул иде — Данил аны шунда ук танып алды, гәрчә бүген аның өстендәге киеме дә гадирәк, аягында да биек үкчәле туфлиләр түгел, ә җиңел чүәкләр генә. Икенчесе какча гәүдәле, озын буйлы, ябык йөзле, таякка таянган, бераз аксый төшеп атлаучы ир кеше иде. Чәчләре сирәк, чигәләренә бәс кунган олы яшьтәге бер агай. Кеме ул аның: атасымы, олы туганымы, әллә?..

Данилның үзеннән-үзе атлавы салмакланды. Алар әкрен генә атлап узып барганда, ул кызның күзләренә карады, аларның төсенә игътибар итте. Зәңгәр, карасу-зәңгәр икән аның күзләре, болытлы көндәге Идел суы кебек карасу. Моңсу, кайгылы иде бу күзләр. Аларда әйтеп тә, сөйләп тә бетергесез яра, әрнү бар сыман.

Данилның шатлыгы эченә сыймады: «Ул китмәгән, ул биредә. Ә Тимеркәй киткәндер инде дип пошына...»

Моннан соң да Данил күл буена өч-дүрт төште, кызны теге ир-ат белән дә, ялгызын гына да күрә, очрата торды, ә кыз аңа игътибар да итми, гүя белергә дә теләми — күзен дә сирпеп карамый.

Танышу-белешү кинәт кенә, һич уйламаганда, ни чарадан бичара кебегрәк килеп чыкты.

Данилның күл буена чираттагы төшүендә каенлы сукмакта кешеләр җыелышкан иде. Шаулашалар, ыгы-зыгы киләләр. «Ниткән хәл бу?» — дип, Данил да аларга якын килде. Караса, җирдә озын буйлы, какча гәүдәле, сирәк чәчле кеше ята. Төсе киткән, күзләре йомык, үзе ыңгыраша да кебек. Данил аны шунда ук таныды, чөнки ул кешене күтәрмәкче булып азапланган әлеге кыз да шунда иде. Данил хәлгә тиз төшенде. Кемдер: «Ашыгыч ярдәм» чакырырга кирәк», — дип торганда, ул якындагы урамга йөгереп менде һәм ике-өч минуттан юлда тоткан бер җиңел машина белән күл буена төште. Авыруны күтәрешеп машинага салучылар да табылды. Аның башын кызның тезләренә салдылар. Данил да артларыннан калмады — автомашина хастаханәгә очты. Анда табиблар авыр хәлгә тарыган әлеге иргә беренче ярдәм күрсәткәнче, диагноз куеп, хастаханәгә салганчы шактый вакыт үтте. Данил авыру яныннан китмәде, мәш килде — күтәреште, төшерешге. Ул тулай торагына тәмам караңгы төшкәч кенә кайтып керде.

Хастаханәдә Данил шуңа төшенде: бу авыру ир аларның даими пациенты икән һәм ул Данил әлегә төшенә алмаган бик катлаулы чиргә юлыккан булса кирәк. Ә кыз... Ул бу ирнең хатыны, ахры. Данилга шулай сыман тоелды. Аның йөзендәге моңсулык, борчылу билгеләренең сәбәбе дә әнә шул авыру ир, күрәмсең.

Бу хәлдән соң атна-ун көн узгандыр, Данилга күл буена төшәргә җай туры килмәде.

Җәй. Яңа скважиналар өлгереп кенә тора. Данил эшләгән промыселда исә шул яңа скважиналарны бораулаучылардан кабул итеп, үзләштереп, нефть чыгару мәшәкатьләрен җайга салу эшләре белән мәшгуль иде. Көнне-төнне белми эшләгән вакытлар. Яшь белгечнең әлегә аз файдаланган энергиясенә мәйдан киң.

Берьюлы әллә алты, әллә җиде скважинаны үзләштерделәр — мерниклар тулып кына торды. Аларны даими карап торырга, күз уңында тотарга кирәк, чөнки тулып ташуы бар. Ташый калса — эш харап: бөтен тирә-юнь нефтькә, мазутка батачак. Бу инде олы җәнҗал белән бетәчәк, хәтта сине мастерлыктан алып атулары да бар.

Ләкин Данил коры холыклы ата кул астында тәрбияләнде, аның белән иңгә-иң торып эшләп үсте. Җаваплылык дигән төшенчәнең дә нинди кыйммәткә ия булганын яхшы белә. Шуңа да ул бу киеренке көннәрдә кулыннан эшен ташламады, тырышты, ары чапты, бире чапты. Шушы кызу көннәрдә үзеннән күпкә олы яшьтәге, ләкин нефть чыгаруда шактый тәҗрибә туплаган оператор абзыйлар белән дә уртак тел тапты.

Тыныч холыклы, үзе алдан башлап йөгерә торган яшь инженер аларга да ошап куйды. «Моның белән эшләргә була», — дигән нәтиҗәне алар әнә шул җаваплы көннәрдә чыгарганнардыр, мөгаен.

Эш-мәшәкате күп булса да, Данил ара-тирә күңелен давылга дучар иткән сылу кызны да искә ала торды. Ә бер кичне эштән кайтканда, ул аны тулай торак каршында очратты. Бүген дә ул тәненә сыланып, үзенә килешеп торган аксыл күлмәктән, биек үкчәле ак туфлиләрдән. Тик күзләрендә генә моңсулык, борчылу билгесе һаман бетмәгән. Берүзе арлы-бирле йөренә.

Данилны күрү белән, аның йөзе бераз ачыла төште.

— Хәерле кич! Мин бит сезне көтәм, — диде ул.

Хәлнең мондый юнәлеш алуын Данил һич көтмәгән иде.

«Сезне көтәм...» Егетнең эченә җылы йөгерде, күңелендә өмет ялкыны кабынды.

— Хәерле кич...

— Зинһар өчен, гафу итегез. Сез беркөн безгә шундый да зур кайгыртучанлык күрсәттегез... Ничек дип әйтергә дә белмим инде... Рәхмәтемне әйтергә килдем... Сезне монда яшисез дип әйткәннәр иде. Кичә дә килгән идем. Менә алыгыз әле шуны, — дип, кыз Данилга кульяулыкка төргән бернәрсә сузды.

— Нәрсә соң ул? — диде Данил, нигәдер шиккә төшеп, әйбергә һич кагылмыйча.

— Булышканыгыз, хезмәтегез өчен... Автомашинага да түли алмый калдык... Ирем түләргә кушты.

Данил бу төргәкчектә акча икәнлеген аңлады, һәм аның кинәт башыннан төрле уйлар узды, җаны рәнҗеп, кәефе китте. Ләкин сабырлыгын җуймады, салкын канлылык белән:

— Сез мине кимсетәм дип уйламыйсызмы? — диде.

Каршысында басып торган моңсу күзле гүзәл хатынның кинәт чырае сытылды, ә башы, сизелер-сизелмәс кенә, бер якка селкенеп куйды.

— И-и Ходаем... Зинһар өчен, зинһар өчен, гафу итегез! Бу турыда мин үзем дә шулай килеп чыкмасмы дип уйлаган идем. Әллә ничек шунда... Ирем бит...

Аның әрнүдән моңсуланып киткән күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты. Данил моны көтмәгән иде, аның үпкәсе шунда ук җилгә очты.

— Җә, җә, тынычланыгыз. Сезгә борчылырга ярамый, үзегезне сакларга кирәк, — диде ул. — Иregезнең хәле ничек соң әле, тереләме?

Бу вакытта хатын бәләкәй кульяулыгы белән яшьле күзләрен сөртеп маташа иде.

— Терелә дип... Терелә торган түгел инде, — диде ул, авыр сулап. — Ята әле. Больницада һаман. Үзем дә менә сезне күрер өчен генә чыккан идем. Яныннан киткән көнем сирәк...

Аның тавышы йомшак, ягымлы һәм... хәсрәтле. Яшь кенә хатын һәрхәлдә Данилдан олырак түгел, ә кайгы-хәсрәтне капчыгы белән татырга өлгергән, ахры.

— Мин сезнең турыда көн-төн уйлыйм: кем сез, кайдан килеп чыктыгыз? — диде Данил, уйланып кына, гади итеп. — Ләкин күреп торам, бу турыда аңлашырга вакытыгыз юк. Шулай да исемегезне әйтсәгез иде. Мин үзем Данил атлы. Әгәр бер-бер ярдәм кирәк булса, эндәшегез, мин кулымнан килгәнне эшләргә тырышырмын.

— Ай, рәхмәт! Мин — Дилә. Ә ирем Наил исемле. Кызганыч, биредә безнең беркемебез дә юк. Иремнең туган авылы ерак түгел түгелен... — Ул кулындагы сәгатенә карады. — Соңга калам инде. Очрашмый тормабыз әле. Сезгә бик зур рәхмәт... Сау булыгыз!..

Ул ашыга-ашыга китеп барды.

## IV

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дигәннәр борынгылар. Диләне тәүге тапкыр күргән көннәрдә, Данилның күңелендә давыллар уйнады, хисләре ташкын булып ташты, татлы хыялларда гизде. Ләкин соңгы очрашудан соң, ул басынкыланып калды: Дилә ир хатыны лабаса. Ничек башта бу турыда аның башына килмәде? Яшьрәк шул әле, тәҗрибәсе аз: чибәр кызларга хуҗа тиз табылганын белеп җиткерми. Менә моннан соң белә башлар инде. Әйе, чибәрләр, көмеш акча кебек, җирдә ятмыйлар, аларны тиз күреп алалар...

Басынкыланса да, Данилның күңеленнән чыкмады гүзәл хатын. Очрашып, танышып киткәннән соң, аның тагын күрәсе, сөйләшәсе килде. Дилә белән күрешеп сөйләшү үзе бер гомер булыр иде. Юк, гади генә кеше түгел ул. «Югарыдан, Асылъяр кебек морзалар нәселеннән, аксөяк», — диде бит әле бораулаучы Тимеркәй дә. Каян уйлап тапкан диген син андый чагыштыруны: морзалар нәселеннән...

Эштәме, юлдамы, өйдәме — Данил әнә шулай гел Дилә турында уйлап йөрде. Ир хатыны турында шулай җенләнергә тиеш тә түгел югыйсә. Бу дөньяда бөтен нәрсә дә булырга мөмкин. Күңеле тартылгач, нишләсен соң?

Бер-бер артлы көннәр үтә торды. Данилның эштә тагын мәшәкате артты, бистәгә кайткан чаклары бөтенләй сирәгәйде. Шулай да бәхете бар икән, шушы сирәк кайткан кичләрнең берсендә ул Диләне тагын очратты.

Диләнең йөзе һаман уйчан, моңсу. Тик үзен бик тыныч тота.

— Бераз больница исен таратыйм, саф һава сулыйм дип төштем. Әле кибеткә кереп Наилгә фруктылар да аласым бар...

Дилә күптәнге танышы белән сөйләшкән кебек сүз башлады:

— Сезгә рәхмәт инде, теге вакытта бик булыштыгыз, игелекле егет икәнсез...

Сүз артыннан сүз чыгып, алар күп нәрсә хакында сөйләшергә өлгерделәр.

Дилә үзе авыл кызы икән. Үзенә әле егерме өч кенә яшь, ә ире бишенче дистәсен тутырып килә. Яшь чак — җүләр чак дип, тикмәгә генә әйтмиләрдер.

Урта мәктәпне тәмамлаган елны, бәхетен эзләп, ул Урал якларындагы әнисенең туганнан туган апаларына китеп бара — исәбе йә укырга керергә, йә эшкә урнашырга. Әмма институтка керү имтиханнарын бирә алмый. Әллә каян килгән татар кызын институтка кабул итәргә ашкынып тормый Уралдагы урыслар. Билеттагы сораулардан тыш өстәмә сораулар яудырып, аны батыралар.

Эшнең дә ошаганы табылмый. Апаларына җизнәсенең дусты, ул хезмәт иткән полк командиры килеп йөри икән. Шонталы мишәре.

Ике татар бергә кич утыралар, шахмат уйныйлар, чәй эчәләр, серләрен уртаклашалар.

Дилә Уралга килгәннән соң, мишәр якташ һәр көн күренә башлый. Ул вакытта әле сәламәтлеге нык. Төз, таза гәүдәле, иңнәрендә полковник погоннары.

Яшь кызны ул йә киного, йә концертка алып бара. Тик үзе турында артыгын сөйләми. Дилә апасыннан аның кайчандыр кемгәдер өйләнгән булуы, нindидер бер мөһим сәбәп аркасында аерылышулары турында да ишетә.

Үгезнең мөгезеннән эләктерергә күнеккән хәрби җитәкче озынга сузмый, кызның кулын сорый.

— Синең укуың да, эшләвең дә кирәк түгел миңа. Мин тапкан мал икебезгә генә түгел, туачак балаларга да җитәр. Син бәхетле тормышта яшәячәксең, тик синең миңа тугрылыклы хатын булуың кирәк, — ди ул. Нигәдер «тугрылыклы хатын» дигән сүзгә аерым басым ясый. Әллә инде авызы пешкән бахырның?

Олы яшьтәге дәрәҗәле хәрбинең дәгъваларына башта хөрмәт йөзеннән генә каршы килмәгән кыз, буар елан тарафыннан сихерләнгән куян сыман, үзе дә төшенеп җиткермәстән, аның ирегенә буйсына. Бу хәлдә аңа апасы да төпле киңәшче була алмый.

Ул, киресенчә, хәрбинең сүзен куәтләп:

— Нәрсәсе ярамаган? Чибәр, таза ир уртасы кеше, кулында малы бар. Балда-майда йөзеп, үз кадереңне үзең белеп кенә яшәрсең, — ди.

Бәлки, ул артык кашык сеңлесеннән, аның мәшәкатьләреннән тизрәк котылу өчен шулай әйткәндер?!

— И-и, апа, яратмыйм бит мин аны. Һәм ярата да алмаячакмын — эти белән бер яшьтәге кеше бит ул, — дип ачыргалана яшь кыз.

— Әллә мин җизнәңне яратып чыктыммы? Өлешеңә тигән көмешең инде. Барысы да яратып кына чыкмый тормышка. Хатын-кызның язмышы шундый: кем туры килә. Ошаганны көтәм дип, бөтенләй утырып калуың бар. Бер яши башлагач яратып та куярсың әле...

Озак уйлана кыз, озак баш вата, әмма башка чара калмый — полковникка чыгарга риза була.

Алар тыныч, имин, мул тормышта өч ел яшиләр. Ләкин болай яшәү яшь хатынны канәгатьләндерми, чөнки Дiләгә апасы өметләндергән «яратып кую» хисе килми. Рәсәйнең башбаштак армия тәртипләрен сеңдереп, шуның явыз рухы белән көн үткәргән олы яшьтәге офицерның иксез-чиксез хыял белән яшәгән яшь хатынында артык гаме дә булмый. Хезмәтенә иртә чыгып китә, соң кайта, көне-көне белән кайтмый калган вакытлары да була: хәрби өйрәнүләр, тревога, тагын әллә нәрсәләр... Ирнең бар таләбе — бала тап!

Дилә моңа каршы түгел, бала табарга риза, берне түгел, икене, өчне дә табар иде ул, ләкин авырга уза алмый. Ул, сәбәбен эзләп, табибларга да мөрәҗәгать итеп карый. Алар исә яшь хатынны сәламәт дип табалар. Ике арада ризасызлык туа, болай да тулы аңлашу, җылылык, гармония җитенкерәмәгән тормышта тынычлык бетә. Әллә соң ирен дә, Уралын да, туганнарын да ташлап, туган-үскән якларга кайтып китәргә һәм тормышны яңабаштан башларгамы дип тә уйлый Дилә. Тик шушы киеренке көннәрнең берсендә полк саклаган үтә яшерен объектта көтелмәгән хәл — зур һәлакәт була. Әлеге фаҗига булып ике-өч сәгать узуга, Диләнең ире атылып өйгә кайтып керә.

— Давай, тиз генә җыен да поездга чап! — ди.

— Нигә?

— Авария, страшная авария...

— Булса ни? Сине ташлап кая китим мин?

— Юк, Дилә, немедленно җыенып китәргә кирәк. Җизнәңнең гаиләсе дә, башка бик күпләрнең гаиләләре дә китә. Монда ун минутка да калырга ярамый...

— Нишләп? Нәрсә булды соң? — дип, һаман аңламыйча сорауларын яудыра хатын.

— Авария, дим бит, страшная авария...

— Соң, аның нинди зыяны бар миңа синең янында калырга?

Эшнең асылын аңламаган яшь хатынның гамьсезлеге ирен чыгырыннан чыгара:

— Син нәрсә, тинтәкме, әллә тинтәк булып кыланасыңмы? Әллә атом радиациясенең нәрсә икәнен белмисеңме? Или жить надоело? — дип кычкыра ире, шартлый язып.

Шуннан соң гына Дилә хәлнең җитди булуын аңлый.

— Кая китим соң мин хәзер?

— Теләсәң кая кит! Әйтик, туган авылыңа, лишь бы подальше отсюда, лишь бы подальше. И побыстрее!..

— Ә син?

— Мин дә китәр идем, бик китәр идем. Но не могу — служба...

Дилә өч айлап авылда, атасы-анасы йортында яши. Өч ай иреннән бернинди хәбәр килми. Дилә аптырашка кала, аның төн йокылары кача, инде нәрсә эшләргә дә белми.

Ниһаять, беркөнне ире кайтып төшә. Типсә тимер өзәрдәй ирнең шәүләсе генә калган. Атом-төш кораллары җитештерү оешмасындагы аварияне бетерүдә катнашкан хәрбиләр, шул исәптән Диләнең ире дә, күп микъдарда радиация-нурланыш алганнар икән. Өч ай буена ул госпитальдә яткан, тик сәламәтләнүгә өмет зур түгел. Башка чара юк — полковникны да, башка күп кенә хәрбиләрне дә, инвалидлык группасы биреп, пенсиягә озатканнар.

Ык буенда туган отставкадагы полковник, туган авылыма якынрак булырмын дип, Башкортстан җирендә, Аккүл бистәсенә тукталырга, шунда фатир алып төпләнергә карар кыла. Озаккамы? Анысы инде Аллаһы кулында...

Алар әнә шулай килеп чыкканнар Аккүлгә.

Хәзер ир көннән-көн сулып бара. Элек тә авыр холыклы кеше, хәзер бөтенләй үз эченә бикләнгән, көн буена бер сүз катмый, чырае караңгы. Күрәмсең, уйлары өметле түгел. Үзенең каты авыруга тарыганын белә, аңлый һәм үлеп китүдән курка. Шуңамы ул еш кына хатынына сынау катыш аптырашлы күзләре белән озак итеп карап тора, тик эндәшми. Ә Дилә, күңелсез, боек булса да, зур сабырлык һәм түземлек белән, үз-үзен аямыйча аны карый, аның турында кайгырта, чөнки һәр намуслы хатын өчен ир хакы бар. Ир хакы — Тәңре хакы...

— Тормышның бер яме калмады. Барысы да ишелә, җимерелә, челпәрәмә килә. Белсәгез иде миңа ничек авыр булганын, — диде Дилә, кайтып китәр алдыннан.

## V

Бораулаучылар нефть чыгаручыларга берьюлы тагын бер төркем скважина тапшырдылар. Аларның барысын да яңа оештырылган участокка бирделәр. Участокның җитәкчесе итеп яшь инженер Данил Субаев билгеләнгән иде. Ул үзе дә, аның оешып килгән яңа коллективы да муеннан эшкә чумды. Көнләп кенә түгел, тәүлекләп китмәделәр нефтьчеләр яңа скважиналардан.

Бу вакытта эш башында торган яшь белгеч бистәгә кайтып ял итүне бөтенләй онытты.

Шул киеренке көннәрнең берсендә участокка Данилны эзләп Тимеркәй килеп төште. Буровойда бергә эшли торган бер иптәшенең мотоциклына утырып, Данилны иртәдән бирле эзлиләр, тик таба гына алмыйлар икән.

— Менә кайда югалып ятасың икән, җәһәннәм тишегендә, һич эзеңә төшәр хәл юк, — дип битәрләп алды Тимеркәй дусларча.

— Нәрсә булды, әйт тизрәк...

— Юньле хәбәр түгел, малай. Теге чибәр хатын сиңа язу җибәргән. Менә укып кара үзең, — дип, ул Данилга песи теле кадәр генә кәгазь сузды. Анда: «Данил! Наил вафат. Булышчым юклыгы сезгә мәгълүм. Кая барып бәрелергә дә белмим. Иртәгә үзенең авылына алып китәргә, шунда җирләргә уйлаштык. Тик ярдәмчеләрем аз. Дилә», — дип язылган иде.

«Иж» мотоциклына алар өчәүләшеп утырып кайттылар. Бистә зур түгел — полковникның фатирын тиз таптылар. Хәрби комиссариаттан вәкилләр дә килгән, тик чирек гасырдан артык гомерен, бар көчен данлыклы Совет Армиясе сафында, илнең сугышчан куәтен ныгытуга ахыргача үзен кызганмаган өлкән офицерны соңгы юлга хөрмәт белән озатырга мөмкинлекләре юк икән. Мәрхүмнең ярлы авылдан килгән туганнары да, тирән кайгыдан суырылып төшкән яшь хатыны да бөтенләй югалып калганнар.

Ишектә Данил күренгәч, Дилә ничектер талпынып куйды һәм елап җибәрде. Шул мизгелдә Данил үзенең мәрхүмне соңгы юлга озату мәшәкатьләре өчен тулы җаваплы кеше икәнлеген аңлады.

Тагын ун-унбиш минуттан ул промысел җитәкчесе янында иде. Олыгаеп, чәчләре көмешләнеп килгән промысел җитәкчесе Евгений Иванович дөньяда барысын да күргән тәҗрибәле кеше иде. Данилның йомышын бик тиз аңлады. Бөтен йолаларны истә тотып, шундый зур дәрәҗәдәге хәрбине соңгы юлга хөрмәт белән озату өчен кирәк булган бар мөмкинлекләрне эшләде: матди ярдәм дә күрсәтте, оркестр, транспорт турында да кайгыртты, өстенә кызыл йолдыз беркеткән кабер ташы да әзер булды, такталар да озатылды.

— Җирләүне үзең оештыр, йөзебезгә кызыллык килерлек булмасын, — диде ул Данилга.

Мәрхүмне соңгы юлга матәм маршы белән озаттылар. Җирләгәч тә, карабиннардан шатыр-шатыр атып, гимн уйнадылар.

Данил да нефтьчеләр йөзенә кызыллык китермәде. Авыл халкы мең рәхмәт әйтеп калды аңа.

Зираттан алар Дилә белән иң соңыннан чыктылар. Данил аны бераз озата барды. Шул арада хатын кайгыларын сөйләде, иренең соңгы көннәрдәге хәлен, сөйләгән сүзләрен искә алды.

— Ах, үләсе килмәде аның... Егерме җиде ел армиядә хезмәт иткәненә уфтанып бетә алмады. Үз башыма җитәр өчен генә сайлаганмын икән хәрби хезмәтне, диде. Без укыган елларда балаларның бар теләге укытучы булу иде бит. Наил дә тарих укытучысы булырга хыялланган, ләкин университетка конкурстан үтмәгән. Үзе кебек вуздан мәхрүм бер иптәшенә ияреп, хәрби училищега барып кергән. Анда аларны бишкуллап каршы алганнар. Гомере армиядә хезмәт итеп үтсә дә, йөрәгендә тарих укытучысы булу хыялы сүнмәгән иде. «Менә отставкага чыгам да мәктәпкә укытучы булып барам. Рәсәй тарихы чын тарих түгел ул, барысы да уйдырма, фәкать урыс дәүләте, урыс халкы интересларын гына истә тотып язылган тарих ул. Урыс дәүләте, урыс халкының баскынчылык идеяләрен аклап, ерткычлыгын, мәрхәмәтсезлеген батырлык, патриотлык төшенчәләре белән буяп һәм бутап биргән ялган, шапырынкы-күперенке, зыянлы тарих. Әнә шул тарих белән ничәмә-ничә гасырлар буе яшь буыннарның миен агулыйлар хәзер...» — дия торган иде. Теләге тормышка ашмады, әйткәне фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәгән, күрәмсең...

Дилә, саубуллашыр алдыннан, күзләрен Данилга төбәде:

— Рәхмәт сиңа, Данил, бик зур рәхмәт! Кайгымны уртаклашасың, мәшәкатьләремне күтәрешәсең. Уйламаганда-көтмәгәндә миңа терәк булдың. Хәзер минем Аккүлдә синнән дә якын кешем юк...

Данил аның кулларын учына алды. Ни гаҗәп, куллары кайнар иде Диләнең. Аның карасу-зәңгәр кайгылы күзләреннән тагын энҗе бөртегедәй яшь атылып чыкты. Аннары түгәрәк матур, ләкин таҗ кебек авыр башы, ниндидер бер газаплы көчкә буйсынып, егетнең күкрәгенә салынды.

## VI

Юл буе Данил Дилә турында уйланып кайтты. «Хәзер минем Аккүлдә синнән дә якын кешем юк...»

Моннан берничә атна элек бу ханым аның төшенә дә кермәс кеше кебек иде. Күл буенда тәүге очрашу вакытында башын күтәреп күзен дә сирпемәгән гүзәл хатын бүген бөтен кайгы-хәсрәте, мәшәкатьләре белән аның каршында. Ул һич уйламаган иде болай килеп чыгар дип. Күңелендә берничә көн давыл уйнады да, кинәт кенә басыла да башлады. Шулай да Дилә кадерле аңа, әнә шул кайгы-хәсрәтләре, мәшәкатьләре белән кадерле. Диләнең бу бистәдә якын кешеләре булмаган кебек, Данилның да якыннары юк. Бүлмәдәше Тимеркәй белән дустанә мөнәсәбәттә яшиләр, ләкин бу әле якын дус дигән сүз түгел.

Ләкин Данил яратамы соң Диләне? Бу сорауга егет әле анык кына җавап та бирә алмый. Ул, шуны ачыкларга теләп, учы белән битен кат-кат ышкып алды. Фикере чуалды аның.

Диләне очраткан көнне Данил да, Тимеркәй дә аның ир-егет кулы кагылмаган кыз булуын теләгәннәр иде. Ләкин болай булмады. Үз кыйммәтен, үз кадерен белмичә, атасы яшендәге өйләнеп аерылган кешегә ул кияүгә чыккан, алтынын бакырга саткан.

Кызлар күрсәм, кызамын,
Уң кулымны сузамын;
Кыз дигәнем хатын булса,
Якка карап узамын...

Тимеркәй беркөнне сөйләшеп утырганда, әнә шушы такмакны такмаклап алды. Җор да соң үзе! Сүз сөреше, тел төбе, уе егерме яшьлек егетләрнеке кебек түгел, ә гомер иткән аксакалларныкы шикелле.

Тик ни генә димә, Данилның күңеле бүген әнә шул хатынга тартыла. Әллә соң артык чибәр булгангамы? Ир-атның, матур хатын-кыз күрсә, башы-күзе әйләнә анысы. Һәр ялтыраган нәрсәнең алтын булмавын да онытып җибәрә ул кайчакта...

Кайта-кайта егетнең уйлары икенчегә күчте. Әллә ничек туган авылы, ата-анасы, сеңлесе исенә төште аның. Күптән кайтканы юк шул. Бер кайтасы, барысын да күрәсе, урманга кереп чыгасы, һавасын сулыйсы, Якты аланга барып күл буенда балык чирттерәсе килеп китте. Өсте-өстенә өелгән эш, төрле мәшәкать белән ул туган якларына кайтып килүне бөтенләй онытып җибәргән бит.

Урманчы малае Данилны урманда үсте дип әйтергә була. Ул урманда кышкы айларда сирәгрәк булса да, җәен ике-өч көнгә бер, ә кайвакыт көн саен була торган иде. Атасының яраткан сүзе малайның күңеленә уелып калды:

— Урманда кешегә дүрт агач кирәк: нигезгә — имән, бурага — нарат, себеркегә — каен, чабатага — юкә...

Дөрес, Данил моның белән бик үк килешеп тә бетми, аның үз фикере дә бар. Атасы бурага нарат диде, ә аларның өе усак, мунчалары юкәдән. Ә утын? Авыл кешесе утынсыз бер көн дә яши алмый: аш пешерәсеме, чәй кайнатасымы, ипи саласымы — утын кирәк! Инде чатнама суык кышкы айлар турында әйтәсе дә юк — өйдә җылы булсын өчен, мичкә ягарга атнасына бер олау коры утын кирәк.

Малайның беләкләре бераз ныгый башлау белән, атасы аны урманга утын алып кайтырга, аны бушатырга, кисәргә, ярырга үзе белән ияртә башлады. Утын, печән, себерке әзерләү; җиләк, гөмбә җыю; юкәдән кабык салдыру, анасы белән зелпе каерысы җыю, питомникта яшь агач үсентеләре утырту, аларга чиләк белән су ташып сибү, карап үстерүләр... Малай барысына да өлгерергә тырыша иде.

Әйе, урман ямьле ул. Һавасы саф, үзе бай — кешегә тормыш итәр өчен күп кирәкле нәрсәләр бар анда. Ләкин хезмәтне дә күп куясы бар шул, эшләмичә генә килми ул нәрсәләр.

Данилның иң яратканы — күрше малайлары белән Якты аландагы урманчы өе — кордонда берничә көн кунып, күлдән балык тотып яту. Менә кайда ул дөнья рәхәте!

Хәзер үстеләр шул, тормыш мәшәкатьләренә чумдылар, ул рәхәт көннәрне сагынып искә алырга гына калды. Әле институтта укыган елларда да Якты аланда балык тотып яткалады. Ә менә хәзер бетте. Аккүлгә килгәннән бирле аның тормышы китекләнә башлаган сыман булды — урманны еракган гына күреп йөри. Шулай да бер кайтасы килә аның авылга, бер утырасы килә Якты алан күле буенда.

Ләкин хыялы тиз генә тормышка ашмады. Эшне җиренә җиткерим дип, тагын атна-ун көн узды. Ниһаять, промысел җитәкчесе яшь белгечкә өч көн ял бирде.

Күчтәнәчләр алып юлга җыенып маташканда, тулай торак ишеген кагып, Дилә килеп керде. Данилның авылга кайтып китәргә җыенганын белгәч, башта сөмсерләре коелып аптырап калган иде, аннары, җитди итеп: «Мине дә калдырма, үлек чыккан фатирда ялгыз башым яшәп акылымнан шашам», — диде.

Бөтенесе берьюлы хәл ителде. «Әйдә кайтсын! Әллә ияртеп кайтмаслыкмы? Мондый чибәрне күреп өйдәгеләр аһ итәчәкләр әле. Яраткан кызым диярмен. Хәзер кем ияртеп алып кайтмый йөргән кызын яки сөйгән егетен? Урманга Якты күл буена да бергә барырбыз. Дилә дә кайгысыннан, хәсрәтеннән, авыр уйларыннан бераз арыныр...»

## VII

Акташта кунакларны шатланып та, бераз гына гаҗәпсенеп тә, куркыбрак та каршы алдылар. «Әллә эшкә барып урнашмас борын үләнергә дә җыенамы бу Данка?» — дип баш ватты аның анасы. Атасы исә: «Әй, үләнсә үләнер инде, белемен алды, эшен башлады, катын алса, тормышы түгәрәкләнер, оныклар үстерербез», — диде ул, йөзенә битарафлык чыгарып. Төсе-бите, буе-сыны белән анасына охшаган сеңлесе генә нәрсә буласын белми иде әле, урысча сукалый башлаган ерык авызлы институт студенткасы: «Ой, какая замечательная пара, поздравляю!» — дип, абыйсын да, Диләне дә берьюлы килеп кочаклады. Аннары өч хатын-кыз шау килеп аш, өстәл әзерләделәр. Микулай өстәлгә каяндыр бер сургыч башлы «малайны» да чыгарып куйды.

Инде участок җитәкчесе булып киткән улының уңышларын билгеләп үтмәү гөнаһ булыр. Ата белән ул чәкешеп берәрне тотып та куйдылар. Атасының улына сораулары күп иде: нинди эш, авыр түгелме, җитәкчеләр белән мөнәсәбәте ничек, фатир бирерләрме?.. Данил, сорауларга һич авырыксынмыйча, җиңел генә бәйнә-бәйнә җавап бирде.

Сандра нефть эшендә җитәкче булып киткән улының үз эше турында төпле итеп сөйләвенә соклынып утырды. Тик соңыннан Данилның: «Без Якты күлгә балыкка, ял итәргә барабыз», — дигән сүзләре генә аны аптыраштa калдырды. Тормыш юлыннан мөстәкыйль атлаган бу егетнең теләгенә каршы килүче булмады.

Бераз ризык, тоз-шырпы, кармаклар, төнлә салкынча булыр дип одеяллар алдылар да урманга менеп киттеләр. Аларга Данилны сагынып көтеп торган Актүш тә иярде.

— Әйдәгез сун, ат белән менгереп төшим үзегезне, — диде Микулай улына, алар чыгып барганда.

— Юк, юк, әти, без үз җаебыз белән, җәяүләп кенә менәрбез, — диде Данил. — Син ял ит...

* * *

Җәй үтеп тә бара — июль ахыры. Зәңгәр күк йөзе, бүз тарткан кебек, аксылланып тора. Тып-тын, тик үлән арасында чикерткәләрнең чер-чер итеп чәрелдәшүе генә ишетелә.

Ярты чакрым үттеләрме-юкмы, урманга килеп җиттеләр. Урман сихри тынлыккка чумган. Ылыс, гөлҗимеш чәчкәләре, абага һәм башка үләннәрнең исе сеңгән арба юлы борыла-сырыла сөзәкләп эчкә

үтә. Купшы төклетуралар, чәчкәдән чәчкәгә кунып, бал җыялар. Куе чыршы ботаклары аша үтеп кергән кояш нурлары алтын сыман пәрәвезне хәтерләтәләр.

Инде көн кичкә авышкан. Кошлар сайраудан туктаган. Җәнлекләр дә өннәрендә ята. Данил белән Диләгенә, тирә-якка карана-карана, һич ашыкмый сукмактан алга таба баралар. Ә Актүш алардан да алдарак элдертә. Ул юлның әле бер ягындагы куаклар арасына, әле икенче ягындагысына кереп-кереп китә, иснәнә, аяклары белән җирдә тырнана да кабат юлга чыга, туктап, Данил белән Диләнең аңа якын килгәнен көтеп тора. Аралар якыная башлагач, тагын үз юлын дәвам итә.

Бу юл Данилга күптән таныш. Дөрес, соңгы ике-өч елда аның биредә йөргәне булмады, чөнки Чалкантауда яңа урманчы өе салдылар, ә элеккеге урманчы өе ташландыкка әйләнгән сыман булып калды, аңа урманчылар да, аучылар да юлны оныта башладылар. Ә Данил өчен иң кадерлесе — Якты күл, андагы керкә балыгы, шул балыкның комсызланып чиртүе, аны су өстендә уйнатып тартып чыгару.

Диләгә исә бу урман да, аның юлы да таныш түгел иде. Ул карасу-зәңгәр күзләре белән яшел дөньяны күзәтә, эчтән генә гаҗәпләнә, соклана. Аның йөзендә кайгы төсмерләре бераз югалган төсле булды, кыяфәтендә кызыксынучанлык барлыкка килде, һәм хыялга бирелеп уйлану чаткылары күренә башлады. Аның йөзе вакыт-вакыт яктырып китә, һәм елмаю чалымы абайлана. Данил аңа борылып, туктап күзләренә карап тора, әйтерсең лә: «Күрәсеңме, мин сине нинди матур урманга, нинди хозурлы дөньяга алып чыктым!» — ди сыман.

Диләнең башы тулы уй. Үзенеке кебек үк зәңгәр күзле, дулкын-дулкын сары чәчле, төз һәм таза гәүдәле бу егет аның тормышына һич көтмәгәндә-уйламаганда килеп керде.

Данил беренче күргән көннәрдә кыз күзен сирпеп карамады дип уйласа да, Дилә аның кыяфәтен күрми калмады. Хатын-кыз ул, текәп карамаса да, чит карашны җаны-тәне белән сизә. Бигрәк тә үзе белән кызыксынганнарның карашын тиз сизә ул. Данилга, бәлкем, беркайчан да әйтмәс, ләкин үзеннән яшерә алмый: бу егет аңа беренче көннән үк ошаган иде. Карашы ук ниндидер өмет бөркегән сыман тоелды аңа. Иренең көннәре санаулы, ә аңа әле яшисе дә яшисе. Ире белән ул-бу була калса, кем аны юатыр да, үзе кем җилкәсенә барып таяныр? Ялгыз башың яшәү, ай-һай, авыр бу дөньяда. Шуңа да ул бу салам кебек сары башлы егеткә өметен баглады. Тик акларлармы ул аның өметен, алып килерме аңа көткән бәхетен?

Бүген иртән Аккүлдән аңа ияреп чыгып китү, бәлки, дөрес тә булмагандыр. Бераз тыйнаксызрак, әрсезрәк килеп чыкты. Ахыры гына хәерле булсын! Шулай да бүген Дилә үзен таш дивар артындагы кебек сизә. Гомер буена гел шулай булса икән!..

Урман һавасы исертердәй саф. Дилә, күкрәген киереп-киереп, үпкәләренең иң эчке якларына барып җитәрлек итеп, шул шифалы һаваны сулады.

Алга таба юл тарая төште һәм Данил аркасындагы биштәрен бераз төзәтеп алдан китте. Дилә исә арый башлады бугай:

— Барып җитәбезме әле? — дип сорады.

— Юк әле. Арыдыңмы әллә? Хәзер ял итеп алабыз...

Алар ике-өч ашъяулык чаклы гына бер аланда тукталдылар. Данил биштәреннән одеял алып аска җәйде. Телисеңме-теләмисеңме, Данил белән Дилә хәзер икесе дә шул одеял киңлегендәге урынга елыштылар.

— Менә кайда ул дөнья рәхәте! Сиңа ничек, ошыймы? — диде Данил.

Дилә, озын кара керфекле күзләрен йомып, «әйе» дигән мәгънәдә башын селкеп куйды һәм Данилның җылы кулларын учына алды. Бу — рәхмәт сиңа, миңа барысы да ошый, синең белән миңа бик рәхәт, син миңа хәзер бик кадерле, тик Ходай гына мине синнән аермасын дигән ишарә иде. Һәрхәлдә Данил шулай аңлады. Һәм үзе дә җавапсыз калмады: Диләне кысып кочаклады, башта моңсу күзләреннән, аннары кайнар иреннәреннән суырып үбеп алды.

Дилә әз генә дә каршылык күрсәтмәде, әйтерсең лә ул аны күптән көткән иде. Шушы үбешү мизгелендә аларның йөрәкләре шашынып типте, сулышлары ешайды, дөньялары онытылып торды. Ләкин бер-берсенә ике генә дә сүз әйтмәделәр алар. Мәгәр сүз әйтү кирәк тә түгел иде, ике яшь йөрәк бер-берсен болай да бик яхшы аңлады.

Кеше аягы басмаудан үлән белән капланып беткән тар юлдан алар тагын ун-унбиш минут бардылар һәм зур булмаган аланга килеп чыктылар. Аланы бер хәл, аның бер ягы аксыл күлмәктән, чуклы-чуклы яшел шәл бөркәнгән кызлар кебек зифа каеннардан торса, икенче ягында баһадирлар кебек нык тамырлар өстендә үсеп утырган юан-юан кәүсәле нарат һәм имән агачлары ышыгында көзгедәй урман күле җәйрәп ята. Күлдән өстәрәк, авыл мунчасыннан аз гына зуррак, ике бәләкәй тәрәзәле, бер ишекле, түбәсе юкә кабыгы белән ябылган иске генә өй тора. Өй тирәсе киртә белән әйләндереп алынган. Ишек төбеннән алып шул күл буена чаклы кабык сукмак салынган булган, ләкин урыны-урыны белән кабык череп, таркалып беткән. Бу урман каравылчысы өе иде.

Ниһаять, алар, өйнең ишеген ачып, эчкә керделәр — ишек йозакта түгел иде. Кеше аяк басмагач, өй бөтенләй ташландык хәлгә килгәндер дип уйлаган иде Данил, ләкин, бәхеткә, алай булып чыкмады. Аучы-сунарчылар монда еш тукталалар, күрәсең, эчтә савыт-саба, пычкы һәм балта, чалгы, кармак та-

яклары, мичкә ягарга утын, бер кап шырпы, бер савытта шактый гына тоз, тагын башка кирәк-яраклар үз урыннарында, хәтта дивардагы кадакта балык җәтмәсе эленеп тора. Бер як дивар буенда кечкенә генә өстәл, ә икенче ягында сәке.

Данил җилкәсеннән биштәрен салды. Дилә дә кулындагы әйберләрен өстәлгә илтеп куйды һәм килеп Данилга елышты. Данил аны тагын кочагына алды. Берничә секундтан алар кабат үбешү хозурына бирелделәр. Ләкин онытылмадылар. Бергәләшеп өйнең идәнен юып чыгардылар, пөхтәләделәр. Данил ишегалдында электән калган ут ягу урынын рәткә китерде: урманнан ботаклар кисеп чыкты да, казык ясап, аларны кагып куйды. Имән казыклары беркеткән өстәлне, аның ике ягындагы эскәмияләрне дә рәтләде. Кабат урманга кереп, кочак-кочак коры чыбык-чабык ташыды. Бер кергәндә череп яткан усак агачы кайрылары астыннан биш-алты корт табып, кармакларын караштырып, күлдән балык тотарга төшеп китте.

Данил кая гына бармасын, Актүш аңардан калмады, хәтта яр кырыена балыкка төшеп утыргач та ул аның янына, су кырыена килеп ятты. Көзгедәй якты су өсте, кармак таяклары, калкавычлар Актүштә үзенә күрә бер кызыксыну уята булса кирәк. Данил белән аның Көмешсу буена күп тапкырлар балык тотарга төшкәннәре бар. Ә менә урман уртасындагы күлгә соңгы вакытта килгәннәре юк. Урам эте генә булса да, Актүштә аучылык сизгерлеге, аучылык хисе җитәрлек. Шуңа да ул кармак ташлаган су өстенә карап, әледән-әле сабырлыгын җуеп чинаштырып ала. «Әйдә, тартып чыгар инде тизрәк, бәлки, миңа да өлеш чыгарырсың, ашыйсы да килә башлады», — дип әйтә сыман.

Якты алан — Данилның иң яраткан җире. Микулай бирегә, хатынын һәм балаларын атлы арбага утыртып, җәенә биш-алты мәртәбә алып килә торган иде. Баш урманчы итеп куйгач, аның гаиләсенә вакыты җитми башлады, эше күбәйде. Җиләк вакытында — җиләккә, җылы яңгыр явып үткәч, тегендә дә монда башын калкыткан симез аяклы ак гөмбә җыярга, аннары мунчага каен себеркесе әзерләргә, август ахырында исә чикләвеккә килми калмыйлар иде.

Данил өчен иң хозурлысы — күлдән балык тоту. Бу күлне гади күл дип тә әйтеп булмый. Аның суы — көмеш кебек чиста, кристалл кебек үтә күренмәле, чөнки күлдән биш-алты йөз метрда гына өстә, тау итәгендә, унлап чишмә агып ята. Гаҗәп хәл: тау астыннан түгел, ә бәлки, аның урта бер җиреннән агып чыга ул чишмәләр. Сулары салкын. Шуңа да күлнең дә суы җылы түгел, эссе көннәрдә дә су керәм, коенып чыгам дия алмыйсың. Әмма балыгы күп. Әллә ничә төрле балык бар анда, ләкин иң затлысы — хан балыгы, ягъни керкә, форель. Кайбер җирләрдә аны ала балык дип тә атыйлар.

Күл өсте тын. Биек нарат, каен, юкә, усак агачлары аша бирегә җил дә үтеп керә алмый. Шул агачлар ышыгында ап-ак төнбоек чәчәкләре белән бизәлгән күл өсте зур, якты көзгене хәтерләтә. Әледән-әле эре-эре балыкларның шул тынлыкны бозып чупылдап сикерүеннән яр буендагы эре яфраклы әрекмән өстендә тын гына утырган энә караклары куркып очып китәләр дә, күл өсте тынычлангач, кабат әрекмәнгә килеп куналар.

Җанга рәхәт һәм тыныч. Данил кармагын суга ташлады. Ташлады да, дулкынланып, балык капканын көтә башлады. Каз каурыеннан ясаган калкавычның очлы башы яшькелт су өстендә тырпаеп тора. Ул менә-менә су астына чумар сыман. Шул калкавычка карап торулары үзе бер хозурлык. Менә калкавыч кинәт дерт итеп селкенеп куя, бер якка кыйшая һәм шул көе хәрәкәтләнә башлый. Бу вакытта инде авыз ачып тормаска, балыкны каптырып, тартып чыгарырга кирәк.

Керкә балыгының чиртүе — үзе бер гаҗәп! Башта ул салган җимеңне каракларча гына, сиздермәскә тырышып тартып карый. Бу вакытта тәҗрибәсе булмаган балыкчы, балык капты дип, кармагын тартып та чыгара, ләкин балык эләкмичә кала. Әгәр беренче тартуда ук ашыкмасаң, керкә икенчесендә җимне комсызланып тартып китә. Бу вакытта ул инде чын-чынлап капкан була.

Данил яшь булса да, керкәнең бу хәйләсен яхшы белә. Атасы белән алар Якты күл буенда да, Көмешсу буенда да балык тотып аз утырмадылар. Иң бәхетле мизгелләр — эләккән балыкны, дулкынлана-дулкынлана кармактан ычкындырып, чиләккә салу вакытыдыр.

Әнә шундый һәркемгә дә аңлатуы мөмкин булмаган ләззәтле минутларда Данил биш-алты балык тартып чыгарырга өлгерде. Бу вакытта Дилә дә, өйдә эшен бетереп, Данил янына чыгып утырган иде. Аннары алар икәүләшеп учак ягып, балык чистартып, өйдән алып килгән бәрәңге һәм ярманы да салып, балык ашы пешереп ашадылар. Аш бик тәмле булды, ул үзләренә дә, Актүшкә дә җитте.

Кояш үсеп утырган мәһабәт агачлар артына төшеп югалды. Сиздермичә генә эңгер төште. Әле һаман пыскып янган учакка Данил әледән-әле утын һәм чи үлән ташлаштырды. Чөнки чи үлән төтен хасил итә һәм черки болытыннан сакланырга менә дигән чара.

Шул учак янында Данил белән Дилә, бер-берсенә сыенып, төн булганчы утырдылар, уй-фикерләре белән уртаклаштылар, назлаштылар.

Инде йоклап ял итәр вакыт та җитте. Данил әле караңгы төшкәнче үк алан уртасыннан иң хуш исле үләнне чабып алып кергән иде, сәкегә шуны җәйделәр дә, өй эчен ябып торган кисәү белән төтәтеп, черкиләрне качырып, ишекне ябып куйдылар. Шул секундтан алар икесе дә караңгыда калдылар. Икәүдән-икәү! Буй җиткән тап-таза ир һәм яшь, ирсез калган гүзәл хатын. Икесенең дә каны кайнап, теләге ташып торган чаклары. Чишенеп йокларга яттылар.

— Икебез бергә ятабызмыни? — дип пышылдады Дилә, Данилны үчекләгән сыман.

— Аерым ятам дисәң, әнә идәнгә җәй урыныңны, — диде Данил да, хәйләкәр елмаеп, ләкин караңгыда аның йөзен, әлбәттә инде, Дилә күрмәде.

— Юк, мин анда куркам, — диде ул чытлыкланып һәм, башкача сүз куертмыйча гына, Данилга аркасын куеп килеп ятты.

Данил аның өстенә япты, аннары көрәк кадәр куллары белән үзенә таба борып яткырды. Өй эчендәге караңгылыкка күзләре күнеп килә иде. Бәләкәй тәрәзәләрдән төшкән сүрән яктылыкта Дилә Данилның иреннәрендә назлы елмаю, күзләрендә шаян очкыннар шәйләде. Данил, иелә төшеп, Диләнең кайнар иреннәреннән суырып-сурып үбәргә тотынды. Дилә үзе дә җавапсыз калмады: егетнең муеныннан кочаклап алды, аны назлады. Бу вакытта Данилның бер кулы, Диләнең эчке күлмәге аша кереп, боты буйлап аска шуышты. Дилә, аның кулын эләктереп алып, каршы торып маташты, ләкин Данилның кулы көчлерәк булып чыкты.

Дилә:

— Бүген тимә миңа, Данил җаным, — дип пышылдады.

— Син теләмисеңмени? Чыннан да теләмисең? — дип пышылдады Данил да. Данилның татлы иреннәре Диләнең муенына, җилкәсенә тиеп-тиеп алды...

Дилә җавап бирмәде. Аның эндәшмәве үзе җавап иде. Инде берничә ай ир назын татырга туры килмәде аңа, шуңа да ул бүген бөтенесенә риза иде.

Данил Диләнең эчке күлмәген салдырды һәм аның сул күкрәгеннән кайнар учына алды, бармаклары белән назлы гына бөртеп киткән имиен кысты да аны имә башлады. Дилә татлы ыңгырашып куйды, аңа чиксез рәхәт иде. Аның түземлеге бетеп бара иде, Данилның колагына:

— Тизрәк... — дип пышылдады. Әле яңа гына карышып маташкан хатынның холкы шулай тиз үзгәрүгә Данил игътибар да итмәде — аның үзенең дә ташы кызган иде...

Июль аеның соңгы төне аларга очсыз-кырыйсыз булып тоелды. Алар бу төндә керфек тә какмадылар, моңа вакытлары да булмады: сөештеләр, назлаштылар, иркәләштеләр. Тәмам арып-талып, хәлдән таеп, сызылып таң аткач кына кочаклашып йоклап киттеләр. Инде йокы сөреме белән аңы томаланып барган бер мизгелдә, Данилның: «Менә кайда ул дөнья рәхәте!» — дигән сүзләре исенә төште. Әйе, Дилә өчен дөнья чиксез рәхәт иде...

Алар уянып киткәндә, көн кичкә авышкан иде инде. Ләкин торып китү уйларына да кермәде: тагын бер-берсенең кочагына ташландылар, тагын ләззәтле һәм татлы сөешү дәртенә бирелделәр...

## VIII

Акташка алар өченче көнне генә кайттылар. Юл буе икесе дә Якты аланда үткәргән хозурлы көннәр, төннәр турында искә алып, рәхәт уйлар кичереп, әледән-әле кочаклашып, үбешеп, назланышып кайттылар. Данил Диләне үзенчә бәяләде. Ул аңа бик ошады. Институтта укыган елларында аның түшәгенә җылыткан кызлардан артык күрде ул аны: кайнар, дәртле, тәҗрибәле. Дилә исә парын үзенчә бәяләде: таза, көчле, ару-талуны белми, эшкә уңган. Данилга бигрәк тә: «Иремнән соң син минем икенче кешем», — дигәне ошады. «Димәк, иренә тугрылыклы булган, үзенә өйләнә-нитә калсам, миңа да тугрылыклы булыр», — дип уйлады егет. Белсә икән ул үзенең чынында ничәнче икәнлеген — сәкедән тибеп кенә төшергән булыр иде. Хәер, төшергән булыр идеме икән? Миргә яраган иргә дә ярый, диләр бит.

Дилә җиденче сыйныфта укыганда ук алдырды каймагын. Ул елларда бер сыйныфта укыган балаларның җыйнаулашып табигать кочагына чыга торган гадәтләре бар иде. Ял көнендә палаткалар, азык-төлек, савыт-саба, чиләк-казан алып, бер-ике көнгә урманга яисә елга, күл буена чыгып китәләр. Ашлар әзерләп, уеннар оештырып, җыр-бию бәйгеләре үткәреп, яңа тәэсирләр, көч һәм илһам алып кайталар иде алар. Һәрхәлдә балаларның ата-аналары шулай дип уйлый иде. Ләкин аларның күбесе шушы культпоходларның, пионерлагерьларның бик күп кызларның башына җиткәнен белмиләр йә булмаса вакыт үткәч кенә сизенәләр иде. Әмма инде соң була. Иртә өлгергән яшүсмерләр мондый форсатны ычкындырмаска тырышалар.

Бик тиз кызлар исе керә башлаган Эдик та ычкындырмады бу форсатны. Уйнап-көлеп биеп туйгач, ул кызлар арасында аерым матур Диләне агачлар арасына алып кереп китте, кочаклады-үпте, әле яңа гына калкып килгән күкрәкләренә кагылды, дәртләндерде, шашындырды, һәм алар, ниһаять, юан кәүсәле каен артына авып төштеләр...

Ләкин Дилә артык кайгырмады, чөнки класста чиләк төбе төшкән кыз бер ул гына түгел иде.

Бу вакыйгадан соң кызга тынгылык бетте. Ачык авыз Эдик сертотмас үрдәк булды, ахры, Диләне үз класс малайлары гына түгел, югары классныкылар да музыка тыңларга, елга буена балык тотарга, урманга җиләк яки гөмбә җыярга чакыра башладылар. Ә бер чыгуда Диләне хәтта берьюлы өч егет чиратлашып яратты. Унынчы сыйныфны тәмамлаганчы да, аннан соң да, иргә чыкканчы да аның артыннан йөрүчеләр аз булмады. Дилә Данил белән бергә үткәргән хозурлы көннәргә кадәр татыган, якаларын

иснәштергән ир-атларның исәбен дә оныткан иде инде. Данил исә аның киртәдән чыккан хатын булуы турында башына да китермәде.

* * *

Ишекне ачып кергәч тә, Сандра, тавышын күтәреп:

— Сез кая җугалдыгыз? — диде.

— Балык тоттык, — дигән булды Данил.

— Ә балыгыгыз кайда?

— Тотканын ашап бетердек, тотмаганы күлдә калды...

«Тотмаганы күлдә калды...» Ах, мур кыргырлары!..

Бу көннәрдә Сандраның уйламаган уе калмады. Данилга ияреп кайткан, аның белән ялгыз башы урман уртасындагы кордонда кунып-төнеп калган чәчбинең нинди кеше булуы турында сорашырга вакыты җитмәгәнгә бик үкенде. Алар кайтып кергәч тә, ул бу хатасын төзәтү ягын карады. Ашын салып, чәен ясап өстәлгә чыгаргач, икесенә дә әкрен-әкрен генә сораулар бирә башлады. Сөйләшергә дә җайлы вакыт — Микулай өйдә юк, ул эштә иде.

— Данка, улым, моны ничек анларга сун инде? Үләнешергә уйлыйсызмы, әллә болай гына җөрисезме? Бер дә килешә торган эш төгөл бит әле бу.

— Анысын үзебез карарбыз әле. Без бер-беребезне күзәтәбез, характерларны өйрәнәбез... Хәзер шулай бит инде, әни. Син безне ачуланма, — диде Данил, анасын кочаклап.

Йомшак күңелле Сандраның бөтен ачуы, үпкәсе шунда югалды да калды. Шулай да ул кунак кызына әзерләгән сорауларын бирде.

— Кызым, кайсы җакныкы сун үзен?

— Минем туган авылым моннан ерак түгел, апа. Каенлы Чишмәне беләторгансыздыр?

— Каенлы Чишмә? Җа Кода! Без үзебез дә җәшәдек бит ул авылда. Данкага өч кенә җәш иде без уннан киткәндә.

— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнде Дилә.

— Шолай шул! Кем кызы сун син алайса?

— Кем кызы дип... Хәзер анда безнең беркем дә юк, әтиләр шәһәрдә яшиләр.

— Сун бит Каенлыда мин белмәгән кеше җук иде теге җылларда. Атан-анан кем?

— Минем әти — танылган бораулау мастеры. Тимәшевләр без...

— Тимәшевләр?

Сандра нилектәндер Сафуанның исемен генә белә, фамилиясен әллә хәтерләми, әллә бөтенләй белми иде.

— Әйе, Тимәшев Сафуан...

— Са-пу-а-ан? — дип, чиксез гаҗәпләнү белән сузды Сандра.

Бу минутта ул ничектер уңайсызланып, калтырап куйды. Бер мизгелгә бөтенләй каушады.

— Ә нигә? Әйе, Сафуан Тимәшев, — диде кунак кызы, салкын канлылык белән. — Яшьлегендә бик оста тимерче булган минем әти, ә хәзер танылган бораулау мастеры.

— Тимерче Сапуан кызы дисен инде. Син анын ничәнче кызы сун?

— Мин, апа, аның беренче кызы. Тагын сеңлем бар.

— Ә нигә сун алайса син үзенне Дилә дисен? Сапуан кызы булсан, син бит Даимә булырга тиеш!

Кунак кызы коелып төште. Болай фаш булуны көтмәгән иде ул: Сандра, чыннан да, аның әтисен бик яхшы белә икән бит. Данил да Диләгә үзенең аптырашлы карашын төбәде. Хәзер инде яхшылап аңлатырга кирәк иде.

— Әйе, минем чын исемем Даимә. Ләкин мин ул исемне беркайчан да яратмадым, чөнки мәктәптә урыс малайлары мине «дай!», «на!», «дай!, «на!» дип үчеклиләр иде. Шуңа да мин үземне Дилә дип йөри башладым, — диде кунак кызы, ниһаять, көчен җыеп.

Бер караганда барысы да аңлашыла кебек. Ләкин Сандраның сораулары бетмәгән иде әле.

— Алайса, кызым... Данка, безнен икебезне генә калдыр әле, сүзем бетмәде, — диде ул.

Данил ишегалдына чыгып китте.

— Алайса, кызым, дөресен әт: Якты аланда Данка белән ничек булдыгыз?

— Ничек, ничек... Мин, апа, тол хатын. Ирем күптән түгел генә үлде. Инде аңлый торгансыздыр, тол хатынга бернәрсә дә тыелмый бугай...

Сандра, сөйләшә-сөйләшә, өстәлдәге савыт-сабаны җыештыра башлаган иде, бу сүзләрдән соң кабат лып итеп утыргычка килеп утырды һәм өнсез калды. Фикере чуалган иде аның.

— Апа, сүзегез беттеме? — диде шулчак чая хатын.

— Җук, кызым, бетмәде әле. — Сандра үзен кулга алды. Ләкин сүзне ничек дәвам итәргә белмәде, аптырап калды. Гомере буе күңелендә саклаган, һичбер кемгә ачарга тиеш булмаган олы серне ачарга

мәҗбүр иде ул. Шулай да сүзне башкачарак башлады. — Кызым, сез Данка белән бүтән очрашырга тиеш түгел...

— Нигә?! Ул миңа ошый, мин — аңа. Без бер-беребезне яратабыз. Бу беркемгә дә тыелмый. Әгәр эш өйләнешүгә барып җитә икән, мин моңа каршы түгел. Инде әйттем: ирем үлде, үзем тол, бала-чагам юк — ялгыз. Аккүлдә ике бүлмәле фатирым, иремнән калган запасым бар. Төсем-битем, буем-сыным бар, дүрт саным төгәл. Улыгызга, кирәк дисә, ун бала табып бирермен. Тагын нәрсә кирәк?

— Анысы шолайдыр да, тик...

— Син кыз түгел, хатын, ә без Данилга кыз алырга уйлыйбыз дияргә телисезме әллә? Белмим, апа, сезнең заманда ничек булгандыр, ләкин хәзер кызларны көндез чыра яндырып эзләсәгез дә таба алмыйсыз. Юк алар, андый кыйммәтле товарны озак тотмыйлар безнең заманда...

Ах, каһәр! Үзен Сафуан кызы, ди, ә үзе ничек чәтердәп тора. Юк, бу бөтенләй Сафуанга охшамаган, ә анасы Гөлмәрфуга гадәте моңарда. Ул үз сүзен бирә торган кеше түгел, үзенекен чәтердәп тора торган хатын иде. Шул бит инде Сафуанны төп башына утыртты — баласы белән ирен ташлап, сөяркәсенә ияреп чыгып качты.

Сандра түзмәде, сүзне икенче яктан, аңлатыбрак әйтергә булды. Тик монда да сак булу кирәк иде аңа.

— Тукта әле, кызым, тынна әле мине җакшылап. Синен берәр качан бер атадан туган ике баланын үләнешеп җәшәгәнен күргәнен бармы?

— Ничек, ничек? — Сафуан кызының күзләре шар булды.

Сандра сүзен кабатлады.

— Ничек була инде ул алай?

— Мына шолай булды инде, кызым. Зур грехымны ачтырдын син минем. Ун бала табам, дисен. Анысы җакшы. Тик үз братын Данкадан сәламәт бала тапмассын — белеп тор! Җа Кода... — дип уфылдады Сандра.

Дилә-Даимә сүзсез калды. Ниһаять, ул төшенде булса кирәк. Ике хатын, бер-берсенең хәлен аңлап, шактый гына карашып тордылар. Тынлыкны Даимә бозды:

— Шулай да, апа, кайсыбыз кемнең баласы соң без?

Сандра, елый-елый, яшьлегендәге хәлләрне Даимәгә дә сөйләп бирде.

— Тик, зинакар, кызым, Данкага әйтмә мин сүләгәннәрне, жәллә мине, — диде ул. — Сүз бир!

— Аңладым, Сандра апа, борчылмагыз, әйтмәм, — диде Даимә.

Бераздан Данил белән Даимә җыенып Аккүлгә китеп бардылар. Юлда Данил Даимәдән анасы белән нәрсә турында сөйләшүләрен белергә теләгән иде, Даимә: «Ул — хатын-кыз арасында гына була торган сер, сорашма, әйтергә ярамый», — дигәч, Данил башка бу турыда сүз кузгатмады.

Аккүлгә кайткач, Данил эшенә чумды, Дилә-Даимәсе турында аңа бераз вакыт онытып торырга туры килде. Берничә көннән соң ул аны эзләп фатирына сугылды. Ишекне яшь кенә бер хатын ачты.

— Сезгә кем кирәк?

— Дилә кирәк иде, — диде Данил.

— Ә ул юк, китте. Без фатирларны алмаштырдык аның белән.

— Ничек китте, кайсы якка?..

— Мин аны сезгә әйтә алмыйм, чөнки ул әйтмәскә кушты. Ул, мине эзләп бер егет килер, әйтегез, килмәсен дә, сорамасын да, эзләмәсен дә, очрашуыбыз ялгыш булган, диде.

Данил аңламады. Күпме баш ватса да аңламады ул Дилә-Даимәнең шулай яшертен китеп баруының сәбәбен.

* * *

Күп тә үтмәде, Данилның тормышында тагын бер вакыйга булып алды. Бер кичне эштән өенә кайтып керсә, яшь кенә кыз аларның бүлмәсендә җан-фәрманга идән юып йөри. Күрер күзгә уналты-унҗиде яшьләрдәге томрап торган тузынкырак кара чәчле, коңгырт-кара күзле, алсу ачык йөзле бик матур кыз. Өстендә зәңгәр халат.

Идән уртасында чиләк белән су. Кыз шул суга чүпрәкне салып тыгып ала да, бөгелеп, бөтен идәнне иңләп, дәртле хәрәкәтләр ясап, идән юа. Күренеп тора, бик уңган кыз.

Данилны күрү белән, кыз бер мизгелгә туктап калды, кызарып каушап китте һәм шул халәтендә:

— Исәнмесез, — диде.

— Исәнмесез... Әллә син яңа җыештыручымы?

Кыз елмаеп куйды:

— Юк.

— Ә кем соң син, кайсы як җилләре ташлады сине безгә? — дип тезеп китте Данил, ниндидер бер күтәренкелек һәм шаянлык белән. — Бәлки, танышырбыз? Мин — Данил.

— Ә мин сезнең турыда ишетеп беләм.

— Кемнән?
— Тимеркәй абыемнан.
— Алайса, син Тимеркәйнең сеңлесе.
— Әйе. Исемем — Фәридә.
— Бик матур икән исемең. Фәридә Кудашева кебек җырчы булыргамы исәбең? Мондый да чибәр сеңлесе барлыгы турында абыеңның бер дә сөйләгәне юк иде.
— Ә ул сезнең турыда гел сөйләп тора.
— Нәрсә сөйли инде?
— Әйбәт егет, ди.
Сүз иярә сүз китеп, алар бер-берсе турында бераз мәгълүмат та алдылар.
Фәридә быел урта мәктәпне тәмамлаган икән, кая да булса укырга керергә исәбе, тик кая керергә генә белми.
— Сез кайтканчы бүлмәне чистартыйм дидем. Кизүдә торучы апа, чиләк, чүпрәк, күлмәгеңне чылатырсың дип, халатын бирде. Бүлмәгез бик үк пөхтә түгел, урыннарыгызны җыймагансыз, — дип, Фәридә егетне бераз битәрләп алды һәм иртән җыештырылмый калган ятак урыннарын җыештырып, рәтләп куйды.
Озакламый Тимеркәй дә буровоеннан кайтып керде. Сеңлесе килүгә бик шат иде ул. Тимеркәй чишенеп, юынып алгач, алар кунак кызын ияртеп ашханәгә киттеләр, аннан соң клубка кереп кино карадылар, кинодан чыккач, бию мәйданына сугылдылар. Бию мәйданында музыка уйный, яшьләр шуңа шау-гөр килеп бииләр. Данил да Фәридане биергә чакырган иде, ләкин кыз: «Мин бии белмим», — дип чыкмады.
Тамашаны карап тору уңаенда Данил Тимеркәйне Фәридәдән читкәрәк алып китте һәм:
— Мондый гүзәл сеңлең барлыгы турында нигә элек бер сүз дә әйтмәдең? — диде, үпкәләгәндәй итеп.
— Сөйләгәнмендер. Тик күреп торасың, яшь әле ул, укыйсы, белем аласы бар, аннан һөнәр сайлыйсы бар. Аннан... Әле егет кулын тидергән кыз түгел ул, син үпкәләмә. Синең әнә Диләң бар, барысына да берьюлы борыныңны сузма, дустым.
Данил Тимеркәйгә Диләнең суга чумгандай югалуы турында сөйләмәгән иде әле. Әллә гарьлек иде аңа бу турыда сөйләргә, әллә үз җанын бимазалыйсы килмәде.
Бу юлы түзә алмады, әйтте:
— Диләюгалды, Тимеркәй дустым. Фатирын алмаштырып, каядыр китеп барган ул, миңа адресын да калдырмаган. Безнең аның белән очрашуыбыз, танышуыбыз ялгыш булган, дип әйтеп калдырган.
— Чынмы бу, әллә шаяртасыңмы?
— Юк, һич кенә дә шаяртмыйм. Үзем дә аптырап калдым: нәрсә булды, ни ярамады ул хатынга? Үзем дә бер ахмак: ничә тиенемә кирәк иде миңа тол хатын? Эх, бу сукыр хисләрне... Әйтерсең лә кызлар беткән бу дөньяда.
— Да-а, парень, жәл.
— Нәрсә жәл?
— Диләнең китеп баруы, дим. Хатын булса да, шәп хатын иде ул, кайсыбер кызларың бер якта торсын. Сиңа гына түгел, миңа да бик ошаган иде — яшермим. Да-а, жәл... — дип кайтып-кайтып уфтанды Тимеркәй.
— Күрәсең, икебезнең беребезгә дә насыйп булмаган икән ул, — диде Данил, үзенчә нәтиҗә ясап.

* * *

Фәридә Тимеркәй абыйсы янында өч көн булды. Уңган кыз, абыйсы белән Данил эшкә чыгып киткәнче, таңнан торып гомуми аш бүлмәсендә аларга ашарга әзерләде, чәен кайнатты. Алар эшкә чыгып киткәч, якалары катып беткән күлмәкләрен, майкаларын юып, киптереп, төшкән сәдәфләрен кадап, үтүкләп куйды. Егетләр биреп калдырган акчага кибеттән төрле ризыклар алып кайтты. Хәтта бистә кырыена чыгып, болыннан зур бер бәйләм төрледән-төрле матур һәм хуш исле чәчәкләр дә өзеп керде һәм, пыяла банкага су салып, аны өстәл өстенә утыртты. Фәриданең бу кыланышлары егетләрне таң калдырды. Бигрәк тә Фәриданең уңганлыгына Данил сокланды.
Ниһаять, өчәүләшеп алар кызның киләчәген дә хәл иттеләр. Моңа уңай форсат та килеп чыкты. Нәкъ шул атнада Аккүл бистәсендәге эшче яшьләр өчен Октябрьский нефть техникумының кечке филиалы ачылды. Югары белемле яшь белгеч Данил Субаевны шул филиалны оештырышырга, аннары төп фәннәр буенча дәресләр бирергә чакырдылар. Фәридә дә шунда укый башлады. Данил аны үзләренең промыселларына лаборант итеп эшкә урнаштырды. Кызга тулай торактан урын да бирделәр.
Тимеркәй дә шул ук филиалда укый башлаган иде, тик аны көзен хәрби хезмәткә алдылар. Тимеркәйне поездга Бөгелмә вокзалына чаклы Данил белән Фәридә озата бардылар.

— Кара аны, Данил, Фәридә сеңлемне обижать итмә, саклап кына тор, — диде Тимеркәй. — Син аңа хәзер абый да, укытучы да, башкасы да...

Тимеркәйнең тел төбен аңлавы авыр түгел иде. Кыска гына вакыт эчендә еш аралашу, бер-берсенең хәленә керү, уй-фикерләрне, дөнья мәшәкатьләрен уртага салып сөйләшү аларның өчесен дә бик нык якынайтты. Белемле, төпле акыллы Данил белән өлгереп килгән, киләчәккә якты хыяллар белән яшәгән Фәридә исә бер-берсенә егет белән кыз буларак тартылдылар. Сөттән ак, судан пакь күңелле Фәридәдә шул айларда тәүге сөю хисе бөреләнде. Данил да бер мәртәбә янып-көйгәч, хәзер инде тәмам акылга утырып, тормыштан сабак алгач, җитди итеп: «Миңа хәзер Дилә дә, Милә дә кирәкми, Ходай мине Фәридәдән аермасын, ул минем өчен гомерлек яр булсын», — дип яши башлаган иде.

Көзге көннәрнең берсендә яшь белгечкә фатир бирделәр. Данилның шатлыгы эченә сыймады. Һәм бу шатлыкны аның кем беләндер уртаклашасы килде. Тик кем белән?! Кызганыч, Тимеркәй дусты армиядә. Ә, юк! Фәридә, Фәридәкәй бар ич...

Ул Фәридәнең тулай торагына чапты.

Бу тулай торакка Данилның Фәридә янына тәүге килүе түгел иде. Фәридә юып, үтүкләп куйган күлмәк-майкаларын алырга еш килә ул.

Кыз яңа гына эштән кайткан иде. Бүген чәршәмбе — укырга барасы юк, чөнки кичке укуга эшче яшьләр атнасына дүрт кенә көн йөриләр. Ашыгып-кабаланып килеп кергән Данилны күреп, Фәридә аптырап китте, аның башыннан бер-бер котелмәгән хәл килеп чыктымы әллә дигән уй сызылып үтте.

— Киен әле, Фәридә, барасы җир бар! — диде Данил.

— Кая?

— Баргач үзең күрерсең.

— Куркыныч түгелме соң ул җир?

— Юк, юк, куркыныч түгел. Гаҗәп җир!

Кыз абыйсына ышанган кебек Данилга ияреп чыгып китте. Шулай да:

— Кая барабыз соң инде? — дип сабырсызланды.

— Шүрәлеләр янына, — дип шаяртты Данил.

Яңа төзелеш барган квартал ерак түгел иде. Әле хуҗалар яңа фатирларга күченергә өлгермәгән, әле утлары да кабызылмаган ярым караңгы ике катлы кирпеч йортның икенче катына күтәрелделәр. Данил кесәсеннән ачкычлар тартып чыгарды да, капшанып ишекне ачты һәм утларны кабызып җибәрде. Буяу исе аңкып торган ике бүлмәле өр-яңа якты фатир иде бу. Патша сарае диярсең...

— Менә шул! — диде Данил, Фәридәгә тантана итеп.

— Әллә синеке? Әллә сиңа бирделәр? — диде Фәридә, шатлыклы елмаеп.

— Икебезгә бирделәр, Фәридә җаным, и-ке-без-гә!

Кыз бераз аптырап, уңайсызланып китте, бер кызарды, бер агарды. Дөрес, хәзер Данил аның йөрәгендә, ләкин мәсьәләнең болай чишелешен ул уйламаган иде. Данил исә, кыяфәтенә битарафлык чыгарып, сүзен дәвам итте:

— Без хәзер икебез бербөтен. Мин беләм: син мине яратасың. Мин дә сине бик яратам. Әйдә, язмышларны бергә кушыйк, син — миңа, мин сиңа гомерлек яр, терәк булып яшик. Миңа синнән башка кеше кирәкми...

Кыз, башын күтәреп, коңгырт-кара күзләрен Данилның зәңгәр күзләренә төбәде. «Барысын да дөрес сөйлисеңме соң син, алдашмыйсыңмы, ышанырга буламы сиңа? Мин бит әле бик яшь, тормыш итәргә тәҗрибәм дә юк, укыйсым да, һөнәр-белгечлек тә аласым бар», — дип уйланды ул.

Нәкъ шул уйларын белгән кебек, Данил, Фәридәне кочагына алып, аны иркәли башлады.

— Икеләнмә! Укуыңны дәвам итәрсең, мин сиңа булышырмын. Һәрвакыт, һәрбер эштә булышырмын мин сиңа, кирәк дисәң, ант итәм. Ышанасыңмы?

Фәридә башта дикъкать белән аның күзләренә карап торды. Аннары «ышанам» дигән мәгънәдә башын селекте. Данил аны кысып кочаклады. Ике яшьнең кайнар иреннәре бергә кушылды.

## IX

Бер мең дә утыз җиденче буровойны Акташ авылы янына китереп утырттылар. Геологик карта буенча скважина авыл уртасында булырга тиеш иде. Шул ноктага авыл кырыеннан торып бораулап төшәргә булдылар. Бораулау бригадасы җитәкчесе, девон катламына кыеклап юл салу эшендә азау ярган, танылган оста Сафуан Тимәшев иде. Шул көннән башлап авыл халкының тыныч йокысы күккә очты. Буровой көнне-төнне белми, гөлдер-гөлдер, дөбер-шатыр килеп эшли, ә әрсез борау каты тау токымын кимерә, җимерә башлады.

Беренче метрларны үтеп, кондуктор дигән юан торбаны аска төшереп, цемент белән катыргач һәм эшне башлау мәшәкатьләрен тәмамлагач, бораулау остасы һәрвакыттагыча җиңел сулап куйды. Хәзер инде бертуктатмый бораулыйсы, җиргә тишек ясыйсы гына кала. Эш бетте, көлтә җыясы гына калды

дигән кебек инде бу, чөнки кыек скважинаны бораулау үзе бер мәшәкать: әледән-әле кирәкле азимутны билгеләргә кирәк. Моның белән, әлбәттә инде, оста үзе мәшгуль.

Сафуан бу эшләргә күптән инде күнгән. Ике дистәдән артык ел эчендә гади эшчедән, бөтен баскычларны үтеп, тәҗрибәле бораулау остасы булып җитешкән, өстәвенә шактый вакыт курсларда белем алган Тимәшев үз эшен җиренә җиткереп һәм белеп башкара. Шуңа күрә эше дә гөрләп кенә бара.

Бүген Сафуанның бердәнбер борчуы — Сандра. Буровоен Акташ янына куйган көннән башлап ул яшьлек мәхәббәте — Сандра-Саниясе турында уйлый. Ул белә: аның сөйгәне шушы авылда. Тик йортлары кайсы тирәдә икән соң? Әллә ничек шунда бер очрашасы, күрешәсе, сөйләшәсе килеп китте аның гүзәл Сандра белән. Юк инде, Сафуан аны эзләп йортына барып керергә җөрьәт итмәячәк. Кинәт кенә урамдамы, әллә кибет тирәсендәме очратса гына...

Шундый өмет белән берничә мәртәбә кибет тирәсен әйләнде ул. Юк, Сандра күренмәде. Бәлки, хәзер танып та бетерми торгандыр? Аларның китүенә егерме елдан артык вакыт узды бит инде. Ул бит аны моннан җиде-сигез ел элек шәһәр базарында очратты, ләкин сөйләшә генә алмадылар. Сафуан үзенең Мөршидәсе, Сандра исә Микулае белән иде. Бер-берсенә күз генә сирпештеләр. Сандра яшьлегендәге кебек үк чибәр, тик бераз юаная төшкән иде.

Беркөнне Сафуан кибет тирәсендә йөргән бер малайдан баш урманчы Микулай йортының кайсы тирәдә икәнлеген белеште.

— Әнә, абый, буровой бар бит? — диде теге малай, бармагы белән төртеп. — Микулай абзыйлар нәкъ шул буровойга каршы, авыл кырыенда яшиләр...

Сафуанның исе-акылы китте. Дөньяда була бит гыйбрәтле хәлләр! Инде бер атна Сандра йорты каршында, аннан йөз-йөз илле адымда гына җир бораулый Сафуан бригадасы, ә ул аны әллә кайдан эзли. Ул аларны әнә шул буровое аша гына күргәләде дә әле. Яньчелеп беткән ак «Запорожец»ы белән хуҗасы кайтып-китеп йөри ул йортның, бер юан хатын, ана үрдәк кебек ике якка чайкалып, бер чыга, бер керә. Йорт каршында аларның еш кына әтәч-тавыклары, каз-үрдәкләре үлән чемченеп йөри. Кайбер көннәрне шул драндулетка алар икәүләшеп утырып китәләр. Микулай белән Сандра икән бит алар. Ә балалары кайда? Зур үскәннәрдер инде, шәһәрдә укый торганнардыр.

Бер хәерле иртәдә, ак «Запорожец» чыгып киткәч, Сафуан шушы йортка барып керде. Һәм, алдынаартына каранмыйча:

— Хуҗалар өйдәме? — дип эндәште.

Челтәрләп-нәкышләп ясаган кәрнизле тәрәзәдән эчтә бер хатын күренде. Бераздан ул, болдырны ачып, ишегалдына чыкты.

— Кем кирәк сезгә?

— Гафу итегез, тавыкларыгызның күплеген күреп кергән идем мин. Бер-ике дистә йомырка сатмассыз микән? Без менә бу буровойда эшлибез, — диде Сафуан.

— Җомырка гына бар инде анысы, — диде Сандра һәм Сафуанга текәлеп карап тора башлады. Ниһаять, аның йөзе ачылып китте.

— Сапуан, бу син төгөлме сун? Мынатырак җавыз... Җомырка сораган була тагын...

— Таныдыңмы?

— Танымый ни...

— Өйдә үзең генәме?

— Үзем генә булсам ни?.. Керик әйдә. Курыкма, сине тотып ашамаслар. Безнең кайда җәшәгәнне күреп чыгарсын...

— Да-а-а, — дип сузды Сафуан. — Син дә, Сания, үзгәргәнсең. Минем хәтердә бөтенләй икенче Сания яши. Шулай да танымаслык түгел. Матурлыгыңны саклагансың әле, гәүдәгә генә бераз юанаеп киткәнсең.

— Син дә теге вакыттагы җегет-җилән төгөл инде. Буен зифа иде, казер аня бөкрәя башлагансын. Буровой бөкрәйтәдер инде, авыр эш. Җөзен дә сырланган...

— Барысы да бар инде, Сания җаным, барысы да бар. Шулай да хәтердән һич чыкмыйсың. Кил әле, элеккечә бер кысып кочаклыйм әле үзеңне шуның өчен, — диде Сафуан һәм юан, ләкин нилектәндер җиңел гәүдәле Сандраны кочагына тартып китерде.

Сандра һич карышып тормады, яшьлегендәге тимерче кочагына рәхәтләнеп кереп посты. Ә үзе:

— Жук, жук, Сапуан! Җанымны да, тәнемне дә кожгытма, — дип ризасызлык белдергән булды. — Болай да гүмерем буена синен азапларын менән җәшим, синен турыда уйлыйм, сине сагынам, гүмерем буена синнән тапкан балаларны җаратып үстердем. Җаным болай да күп таланган. Гүмер җулымда син очрамаган булсан, болай таланмас идем...

Сандра, йомшарып китеп, яшьләренә тыгылды. Ләкин Сафуанның кочагыннан чыгарга уйлап та карамады. Ә Сафуан теге еллардагы кебек үк кайнар тәнле, дәртле яшьлек сөяркәсенең аркасыннан сөйде, битенә агып төшкән яшьләрен сөртте. Тик бер сүз дә эндәшмәде.

Бераздан Сандра сүзен дәвам итте:

— Шунда алам димәден бит. Алам дигән булсан, Микулайдан китәдер идем дә сине генә җаратып җәшидер ийем. Җавыз! Беләм, керәшен катыны дип алмадын син мине...

— Син нәрсә, Сания! Мин — Микулайның законлы хатыны, аны ташламыйм, аны рәнҗетмим, дидең ич. Гәрчә икенче яктан син хаклы. Бар ул безнең мөселман татарларында керәшеннәрне өнәп бетермәү. Керәшеннәр үзләре дә мөселман татарларын өнәмиләр, гәрчә кайчандыр үзләре дә ислам динен тоткан булсалар да. Ә мин сиңа, Сания җаным, беркайчан да кимсетеп карамадым. Сине үлеп яраттым мин! Бүген дә шул яратуым, шул хис белән юанып яшим.

— Үзем дә бик җараткан ийем шул, Сапуан бәгерем, үзем дә бик җараттым. Казер мына шушынын гонаһлары, грехлары менән, гонаһ шонныгы булып җәшибез!

— Нинди гөнаһ, Сания җаным?

— Икебез дә, Сапуан бәгерем, икебез дә. Аня Данка синен Даимәне алып кайткан ыйе. Ике көн Якты аланда, кордонда кунып-төнеп җаттылар. Ир белән катын кебек. «Без бер-беребезне җаратабыз», — диләр. Курлык бит бу!..

— Тукта әле, Сания. Каян килеп чыкты соң Даимә? Ул бит тормышта, отставкадагы ниндидер полковник аның ире, хәзер исә кайдадыр Уралда.

— Үлгән бит инде ул палкауник. Әллә шоны да белмисен?

— Йа Хода! Каян белик без аны? Менә ничәнче ел инде ул кыз безгә үпкә саклап яши. Шул карт полковникка чыгуына ачуланган идек. Шуннан бирле ул безнең барлыкны да белергә теләми. Бер киребеткән нәрсә булды. Кайда очрашканнар-танышканнар соң алар Данил белән?

— Аккүл бистәсендә. Данка бит нефть институтын бетерде. Шонда аны эшкә җибәрделәр. Даимә дә ире менән шунда җәшәгәннәр. Иренен үлгәненә әле ун гына көн. Шул арада аня чыдые да беткән, өстерәлә дә башлаган. Данканы әйтер ием... Чытырлый җабышкан.

— Менә сиңа мә, Сафуан! Иске авыздан яңа сүз. Ишетмәсәң ишет, киле тишек! — дип, үз-үзен битәрләп ташлады Сафуан. — Хәзер кайда инде алар?

— Күптән түгел китеп бардылар.

— Соң син аңлаттыңмы аларга берәр нәрсә?

— Анлаттым! Курлык булса да сүләп бирдем барысын да. Әйттем: аналарыгыз аерым булса да, сез икегез бер атадан, дидем. Инде казер корсагын да күтәрсә... Курлыгыннан кая барырбыз? И-и Кодаем, грехларымны җарлыкасана!..

Сафуан белән Сандраның очрашуы күңелле генә башланган иде. Ташкын кебек яңалык икесенә дә үтергеч тәэсир ясады, зиһеннәрен бутады, кәефләрен төшерде. Шулай да Сандра Сафуанга бер иләк йомырка тоттырып чыгарырга онытмады. Тегесе: «Мин бит сылтау илтеп кенә сораган идем, бернинди дә йомырка кирәкми, йомыркадан үтте монда», — дип каруланып маташкан иде, Сандра, тәмам үпкәләп: «Әллә минем сина, җаратканыма, җомырка бирерлегем жукмы?» — дип көчләп биреп чыгарды. Аннары буровойга таба китеп барган Сафуан артыннан моңаеп карап калды. Сафуанның кабат пәйда булуы аның күңелен кузгатты, сагышларын көчәйтте, хисләрен яңартты. Ярты гомер бит инде аларның очрашып бер-берсенә сүз дә ката алганнары юк. Ходай бар икән: Сандра төшендә ак ат күргән иде. Әрәмә ягыннан бик матур, бик пөхтә ак ат килеп чыкты да, кешни-кешни, аларның киртәләре янына килде һәм, шул киртәгә башын салып, тәрәзәләренә карап торды. Сафуан белән очрашуга, күрешеп сөйләшүгә булган икән бу матур төш. Иллә дә ягымлы, иллә дә күңелгә җиткереп, ягымлы сөйләшә белә аның Сафуаны. Сүз саен: «Сания җаным»,— дип кенә тора. Шулай дип торгач сагынырсың да шул!..

Буровоена җиткәч, Сафуан артына борылып карады. Сандра һаман да капка төбендә, алъяпкычына кулларын төреп баскан килеш, аның китеп барган ягыннан күзен алалмый тора. Сафуанның чиктән тыш күңеле булып куйды: сөйгәне басып карап калды ла!.. Кулын болгарга теләгән иде, әмма буровойда торган эшчеләрнең күреп әллә ниләр уйлаулары бар дип, кулын күтәрергә кыймады, сагышлы карашын Сандра ягына тагын бер кат ташлады да будкасына кереп югалды. Сандра бу минутта: «Нигә инде, тагын кер, дип әйтмәдем шунда», — дип, үзен битәрләп алды. Аннары әкрен генә җырлап җибәрде:

Француз җаулык киштәдә,
Бөгелә дүрткә, бишкә дә шул;
Синен белән бергә булу
Кермәс инде төшкә дә шул...

Шулай үз җыры белән үзе моңланып, төрле уйлар уйлап, сагышланып Сандра әле тагын күпмедер капка төбендә басып торды. Күзләре һаман буровой ягында иде. Сафуан чыкмасмы, тагын күренмәсме дип басып торды ул. Тик Сафуан күренмәде. Ул бу вакытта Сандрасын будка тәрәзәсеннән күзәтә иде. Тәрәзәгә бик үк якын килмичә, будка уртасында басып торган килеш күзәтте ул аны. Капка төбендә, кулларын алъяпкычына төреп баскан килеш, тора да тора аның Сандрасы. Бигрәк куанычлы була икән якын кешеңнең шулай синең тарафтан күзләрен алалмыйча карап торуы! Алар бер-берсенә бик якын, үз икән бит. Аерылышуларына никадәр вакыт үткән, ләкин барыбер бер-берсенә тартылалар. Якын булмый ни?! Икесенең әнә уртак балалары үсеп җиткән — йөрәк парәләре дөнья иңләп киләләр. Берсе вуз тәмамлаган, икенчесе әлегә укый. Бер-берсен чын күңелдән яратып, кайнар сөеп, икесенең дә риза-

лыгы, теләге белән дөньяга аваз салган балалар. Шуңа да Сафуан торып-торып Сандрасы турында еш уйлана. Әйе, Сандра-Сания аның тормышының иң татлы, иң серле, иң кадерле, мәңге онытылмас мизгеле. Сафуанның беркайчан да, беркемгә карата да Сандра-Саниягә булган кебек саф хисе булмады. Шуңа күрә дә ул аны оныта алмый, бөтен уйлары-хыяллары нәкъ шул яшьлек мәхәббәте, аяз күк кебек зәңгәр күзле, алсу-ак йөзле, якты елмаюлы Сандрасы турында. Бүген исә Сандра аны тагын гаҗәпкә калдырды: ул да Сафуанны уйлап яши икән бит. «Болай да гүмерем буе синен азапларын менән җәшим, синен турыда уйлыйм, сине сагынам, гүмерем буе синнән тапкан балаларны җаратып үстердем...» Яратмаса шулай дияр идеме ул?..

Ах, язмыш! Бар күңелен биреп яратышкан-сөешкән, ләкин кавыша алмый калган, гомер буе йөрәге тулы сагыш, эче тулы моң белән яшәгән кешеләр бер Сафуан белән Сандра гынамыни бу дөньяда?!

Агыйделкәйләргә безләр төшәрбез,
Колачларны җәеп йөзәрбез;
Кычкырыр да кәккүк, сайрар былбыл —
Шул чагында ничек түзәрбез?

Сары ла чәчәк ата көнбагыш,
Сөйгәннәрне уйлау куаныч.
Җанкашларны сагыну куаныч...

Сафуан моннан соң да тагын күрер әле Сандраның капка төбенә чыгып басканын һәм, моңсу күзләрен төбәп, үзенең дә, Сафуанның да йөрәген яндырып, аның шаулы буровоена карап торганын...

## X

Бу вакыйгадан соң да шактый күп җилләр исте, кар-яңгырлар яуды, сулар акты. Көмешсу елгасында да сулар бер шаулап, бер тын калып, гүя уйланып, аның матурлыгына сокланып туялмаган кешеләрне моңсуландырып-сагышландырып акты.

...Талгын җилле җылы көзге көн. Әйе, көзен дә була шундый рәхәт, җылы, коры көннәр. Соң гына яуган яңгырлардан соң һава аязып китте. Кояш нурлары, көньяктан искән әрсез җил белән җир өсләре кипшерде. Шулай да Даимә юлга чыгар алдыннан кыска кунычлы итекләрен киде. Аның елга буена чыгасы, тауга менәсе, урманда йөрисе килә иде.

Аның яшьлек әрәмәсе танымаслык булып үзгәргән. Әле егерме биш-утыз ел элек кенә Көмешсу буенда шаулап үсеп утырган биек-биек тал-тирәкләрнең хәзер эзе дә юк. Ах, гомерләр! Куе таллык, баланлык, гөлҗимеш куаклары белән капланган, шаулап үлән үскән, киек казлар, башка күптөрле кошкорт авазы белән ямьле булып хәтердә сакланган әрәмәне бөтенләй бозганнар, үзгәрткәннәр, елга буена әллә ниткән корылмалар төзеп бетергәннәр, саф сулы, моңлы Көмешсуны буып, болганчык бер сусаклагыч иткәннәр.

Даимә, туктап, сагышлы карашын тагын сусаклагыч өстенә ташлады. Алар үскәндә чыр-чу килеп су керә торган тирәкле яр да су астында калган. Әй биек тә соң иде ул тирәкләр! Мәһабәт биек, нык тамырлы, юан кәүсәлеләр. Ботаклары да бөтен Көмешсу өстен, аның яр буйларын каплап тора, хәтта көчле яуган яңгыр вакытында да алар астында ышык була иде.

Әле шул тирәкләргә бәйле бер фаҗига дә хәтерендә Даимәнең. Сөйгән гармунчы егетеннән алданган, авырга калган Маһинур исемле бик матур бер яшь кыз әнә шул озын тирәкнең берсенә асылынып үлгән иде. Гарьлеге көчле булган, күрәмсең, бичараның. Ә хәзерге кызлар...

Даимә Көмешсу елгасы аркылы салган зур таш күпер аша чыкты һәм тигез асфальт юл кырыеннан Аю төбәге тавына чаклы җиңел генә атлап үтте. Күңелендә сагыш булса да, адымнары ышанычлы иде аның.

Аю төбәге тавы текәрәк. Текә булса да, балачакта күрше кызлары һәм малайлары белән йөгерә-йөгерә, ярыша-ярыша өскә менәләр иде алар. Ә хәзер йөгерү түгел, атлап менүләре дә җиңел түгел икән. Даимә тау битендә тырпаеп торган үткен ташларга йә булмаса көчле тамырлы үләннәргә тотынып-таянып, ике атлап, бер ял итеп, тирә-юньне күзәтә-күзәтә, мышный-мышный, үҗәтлек белән тауга менүен дәвам итте.

Әлеге тау башына менеп төшү аның күптәнге хыялы иде. Төмән якларында, Уренгойда яшәгәндә үк бу турыда еш уйлый иде ул: « Туган җиргә кайтып җитә алсам, бер түгел, йөз мәртәбә менеп төшәр идем яшьлек тавыма. Ялгыз каеным гына исән булсын иде. Исәнме син, ялгыз каеным, җан дустым?!»

Балачак, яшьлек еллары бигрәк сагындыра икән шул. Чит җирләрдә яшәсәң, сагынуларың тагын да көчлерәк була икән! Шуңа да бит инде, Төмән сазлыкларын ташлап, туган-үскән якларына ашкынып-талпынып, эче тулы сагыш, моң-зар белән кайтып егылды ул.

Фатирны аңа бердәнбер туганы Акчәчәк тә эзләште. Белдерүләр буенча бармаган, карамаган йорт калмады. Акчәчәк күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, ярыйсы гына чиста урамнарда һәрьяклап уңайлыгы булган фатирлар таптылар, карадылар. Арада Даимәгә ошаганнары да булды, тик ул сатып алыр-

га ашыкмады. Күңеле тулысы белән кабул итмәде ул фатирларны. Апасының артыгы белән сайлануыннан күңеле кайтып, Акчәчәк тә бүтән эзләшергә чыкмый башлады.

Ниһаять, беркөнне Даимә кош тоткан кебек кайтып керде. Шәһәр читендәге биш катлы йортның өченче катында иде ул фатир. Акчәчәк, килеп күргәч, үз сүзен әйтте:

— Нәрсәсе белән ошады инде сиңа бу җәһәннәм тишегендәге иске куыш? Ни автобус, ни троллейбус йөри торган җир түгел. Якын-тирәдә рәтле кибет кенә дә юк. Тапкансың... Ичмасам, тәрәзәләре көньякка, кояшка караса иде, — дип тезеп китте.

Даимә сеңлесен бүлдермәде, моңсу күзләрен аңа төбәп, сөйләп бетергәнен көтте. Аннары торып, сүзсез-нисез генә, аның кулыннан барып алды һәм олы тәрәзә янына китерде.

— Әнә кара әле, сеңлем!..

Тәрәзә каршында, әйтерсең лә кул сузымында гына, искиткеч матур күренеш иде. Тоташтан диярлек агачлар үсеп утыра, тик аның аскы ягы гына киртләч-киртләч кәҗә сукмагы белән сызгаланган Аю төбәге, Кызлар таулары, иң биек тау башында мәһабәт ретрансляция манарасы, сулдарак сабантуй мәйданы...

Ике кыз туган, һич эндәшмичә, шактый вакыт шул манзараны күзәттеләр, уйландылар.

Аннары Даимә телгә килде:

— Мин — канаты каерылган, бичара ялгыз хатын, һич югында, шул урманга карап, көч алып, азмаз булса да рухланып яшәрмен. Минем балачагым, яшьлегем таулары алар...

— Минеке дә инде, — диде Акчәчәк.

— Шулай, синеке дә. Ләкин синең тормышың минеке кебек сикәлтәле булмады. Шөкрана кылып яшә: үскәндә тәртипле булдың, ирең әйбәт, балаларың — йөрәк парәләрең, күз тимәсен, янында. Шуңа күрә, бәлки, мине аңлап та бетермисеңдер...

Акчәчәк акылсыз хатын түгел иде, апасының йөрәк ярасына кагылуын тиз аңлады.

— Гафу ит, апа, гафу ит! Миңа үпкәләмә, чыннан да аңлап бетермәгәнмен. Игелеген күр фатирыңның! Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең ботак тишеге, дип, бер дә юкка гына әйтмиләрдер. Минем дә күңел күзем күреп җиткермәгән икән — бигрәк матур күренеш ачыла тәрәзәңнән. Фатирың үзеңә бәхет алып килсен.

Даимәнең «рәхмәт!» дип әйтерлек көче калмаган, тамак төбенә төер килеп тыгылган иде, шуннан соң башын гына селкеп куйды...

Фатирга күчеп тынычлап яши башлаганнан бирле, ул тәрәзәләреннән китми хәзер. Олы бүлмәгә керәме, ашныкынамы яки йокы бүлмәсенәме — аның күзләре гел урман, таулар ягында. Шул тауларның сихерләре бар диярсең.

— Менә өемне тегеннән-моннан төзәтеп, агартып-юып, аз-маз җиһазлап та җибәрсәм, шул тауга бер менеп төшәрмен инде. Һич вакыт җитми бу дөньяда. Югыйсә әллә кайчан менеп төшәсе иде... — дип сөйләнде Даимә эш арасында.

Инде хыялына ирешә язды бугай. Көч-хәл белән үрмәләп менә-менә, ул, ниһаять, тауның иң текә җирен үтеп, беренче түбәсенә аяк басты һәм хәл алырга утырды. Бу җирдә алар балачакта да шулай утырып ял итә торганнар иде. Ял итеп утырган җирдән көзге кебек ялтырап, бормалы-сырмалы аккан Көмешсу елгасын, яр кырыенда утырган балыкчыларны, әрәмәдә утлап йөргән атларны, сыер, сарык, кәҗә көтүен, көтү артыннан озын чыбыркыларын шартлата-шартлата йөргән көтүчеләрне, алар тирәсендә һау-һаулап өреп чабышкан йөнтәс маэмайларны күзәтә торганнар иде. Хәзер әнә аста бернинди ат та, сыер да, бозау да, сарык-кәҗә көтүе дә, хәтта әрәмәнең үзе дә юк, асфальт юлдан җансыз машиналар гына каядыр ашыгып чабыша...

Беренче тау түбәсеннән ул тагын өскә таба атлады һәм тагын тигезлеккә килеп чыкты. Монда инде имәнлек башлана. Элек бу имәнлек куе урман шикелле иде, хәзер исә ул да сирәгәйгән. Кайдадыр шунда Даимәнең яраткан каены булырга тиеш, әгәр исән торса, комсыз бәндәләр кисеп алып китмәгән булсалар. Ул эчкәрәк атлады, тик яраткан каены күренмәде. Юкмыни? Даимәнең йөрәге ярсып тибә башлады — дулкынлана иде ул. Текә тауны менгәндә дә болай ярсып типмәгән иде аның йөрәге. Юкмыни соң инде аның сердәш каены, шулай ук башына җиттеләр микәнни?

Шундый шомлы уйлар белән ул тагын берничә адым алга атлады һәм... йа Тәңре! Даимә алдында кинәт ачылып киткән бәләкәй алан уртасында ул — аның мәһабәт ак каены — соңгы сары яфракларын җилдә җилфердәтеп үсеп утыра. Ничә еллар аның сердәш дустын күргәне юк! Ул да әнә танымаслык дәрәҗәдә үзгәргән, күккә ашкан, ныгып, юанаеп киткән, чын-чынлап куәтле агачка әверелгән. Хәтта тирә-юнендә үсеп утырган имәннәрне дә күптән буйга узып киткән һәм аларга өстән генә карап тора сыман. Имән урманына ничек килеп эләккәндер ул каен — бусы билгесез.

Даимә, күптәнге танышын кочаклап алган кебек, ак кәүсәле каенга барып сыенды.

— Исән-саумы, каеным? Бу мин — синең гөнаһлы Даимә сердәшең. Дөнья читендә каңгырып, кагылып-сугылып, михнәт чигеп, бер чеметем ләззәткә алданып йөрдем-йөрдем дә тагын туган төбәгемә, сиңа әйләнеп кайттым. Кичер мине шулай озак йөргәнем өчен! Кичер мине барысы өчен дә... Сине бик

сагындым, һәрвакыт искә төшереп тордым үзеңне. Бик күрәсем килде. Сөйлисе серләрем дә күбәйгән иде...

Даимә каен төбенә шуып төште һәм аңа аркасы белән утырды. Ә күзләреннән тыелгысыз кайнар яшь түгелде.

...Бар, бар иде аның кайгысыз, яшьнәп торган матур чаклары. Авылда данлыклы, сылу кыз иде бит ул. Йөзе алсу, күзләре карасу-зәңгәр, сумаладай кара чәчләре маңгаена, ә ике калын толымы биленә чаклы җиткән иде һәм егет-җиләннең күңелен алгысыта иде. Гәүдәсе коеп куйган кебек, аяклары төз. Мәктәптә иң яхшы укучыларның берсе иде...

Тик кыз артык иртә яшьлек һавасына, яшьлек дәртенә бирелде һәм шуның белән бөтен киләчәген бозып ташлады. Югыйсә аның да бар күңелен биреп сөйгән егете булырга тиеш иде. Тиеш түгел, бар иде ул. Кем иренми, шул аның кулыннан тотып алып киткән вакытларда, ул еш кына сыйныфташы Фәриткә күзен теки иде. Каратуткыллы, зур күзле, буйчан һәм шаян сүзле шул Фәрит аңа барысыннан да күбрәк ошый иде. Ачык күңелле, җылы, ягымлы итеп сөйләшә, кешегә ачу саклый белми, барысына да дустанә мөнәсәбәттә, шаркылдап, рәхәт итеп көлә. Фәритнең шулай көлүеннән дә әсәрләнә иде Даимә. Тик Фәритнең күңеле... Даимәнең күршесе, ахирәте Рәхиләне яратты шул ул. Рәхилә үзе дә моңа лаек иде. Тыйнак, тотнаксызлыкны җене сөйми, егетләргә күз сирпеп тә карамый. Аның үзенең дә яратканы бер Фәрит кенә булды, башкаларга кулын да тоттырмады. Шуның белән дуслыклары, мәхәббәтләре саф булды аларның. Урта мәктәпне тәмамлагач та, бергә медицина институтында укуларын дәвам иттеләр, бергә диплом алып, бер хастаханәгә эшкә кайттылар, өйләнештеләр, балалар үстерделәр, үзләре дә табиб буларак та, җитәкче буларак та югары дәрәҗәләргә ирештеләр. Фәрит инде әнә озак еллар баш табиб булып эшли икән. Абруйлы, мактаулы исемнәргә лаек булган баш табиб.

Ә Даимәнең гомере заяга узды. Югары уку йортында да укый алмады ул, яраткан эше, шөгыле дә булмады, шактый ир-атның башын әйләндереп, берничә тапкыр иргә чыгып яшәвенә карамастан, бала табу, бала тәрбияләп үстерү бәхетенә дә ирешә алмады. Шуңа күрә сыйныфташлары, ахирәтләре, күршеләре, таныш-белешләре көнләшерлек тормыш насыйп булмады аңа. Адәм баласының гомер кояшы аска тәгәри башлагач, иң үкенечлесе дә шул була икән...

Соңгы вакытта Даимә үзенең ачы үткәне, көйсез тормышы турында еш уйлана башлады: «Нидән болай килеп чыкты, нигә тормышымның рәте булмады, нигә бәхет читләтеп үтте?» Югыйсә җитди кыз шикелле иде бит ул, ихахай да михахай килеп кенә йөрмәде, максаты да, омтылышы да юк түгел иде. Хәзер ул тормышының асты өскә килүенең төп сәбәбен якында үз анасы булмаудан, ана шелтәве күрмәүдән дип саный. Үги ана үги ана инде ул, гәрчә аны Мөршидә һич тә тибәрмәде, какмады-сукмады. Үз карынынннан чыккан Акчәчәкне ул ничек теләсә, шулай бөкте, ә өч яшендә анасы ташлап калдырган Даимәне кызганды, холыксызланган вакытында да аңа тавышын күтәрмәде, гел җаена гына барырга тырышты. Дөрес, Даимәгә дә, Акчәчәккә дә әйтәсен әйтә килде ул: «Кызларым, егет-җилән тирәсендә сак булыгыз, аларның төче телләренә ышанмагыз, итәгегезне җыеп йөрегез, йөзебезгә кызыллык китермәгез!..» — дип. Ләкин Даимәгә ул барыбер йомшак булды. Ире Сафуанның дәгъвасы, ризасызлыгы булмасын, син аны рәнҗетәсең дигән сүзенә сәбәп тумасын дип, йомшак булды ул. Бәлки, аның шулай эшләве ялгыш булгандыр?! Даимәсенә дә, Акчәчәгенә дә бертигез карап, икесенә дә тигез тәрбия бирергә кирәк булгандыр?! Әнә соңыннан үги ананың кайгыртучанлыгын санга сукмавы беленде Даимәнең. Көйсез, назлыбикә, үз дигәнчә генә эш итәргә яраткан, башбаштак, үз-үзен генә яратучы эгоист кыз булып үсте. Хәзер ул бу турыда яхшы аңлый да бит, тик терсәкне тешләп булмый шул.

Яшүсмер чакта күрше хатыннары Даимәгә: «Син әниеңә — Гөлмәрфугага охшагансың», — диләр иде. Ул вакытларда Даимә анасының төс-кыяфәтен төштә күргән кебек кенә хәтерләп калган иде. Күршедә генә яшәгән Фәтхетдин бабасы белән Бибисара әбисендә сакланган фоторәсемнәргә еш карый иде Даимә һәм үзенең анасына охшаганлыгын да сизә иде. Ләкин аннан ни файда? Җиткән кыз булып үсеп җиткәнчегә кадәр ул аны бер генә тапкыр да күрмәде ич. Анасының өч яшендә ташлап калдырган сабыен кайтып күрәсе, аның белән аралашасы килмәде, күрәсең. Әллә ул аны кирәк дип тә тапмадымы?

Әни! Бу сүзне ул үз анасына түгел, үги анасына әйтеп үсте, әмма шулай булуына карамастан, еллар үткән саен, үзен кадерләп үстергән үги анасы белән арасы суына, ераклаша барды, ә Даимәнең күңеле нилектәндер, тик төшендә генә күргәндәй хәтерендә калган үз анасына тартылды. Көннәрдән бер көнне кайтып төшәр дә: «Кызым, мин кайттым, сине сагынып, сине күрергә кайттым мин!» — дияр, кысыпкысып кочаклар, үбәр, назлар сыман тоела иде. Тик ул кайтмады да, күренмәде дә, назламады да.

Бөкре Фәтхи йортына кереп йөрүдән тыймадылар Даимәне. Фәтхи карт үзе дә, Бибисарасы да оныкларына аерым игътибар күрсәттеләр. Картлык көннәрендә бөтен өметләрен баглаган кызлары азгын сыерның үгез артыннан чыгып чапканы кебек качып киткәч, аларның бар юанычлары булып Даимә калды.

— Кияү, синең каршыңда безнең мыскал да гаебебез юк. Зинһар өчен, бердәнбер юанычыбыз булган Даимәбезне яратудан безне мәхрүм итмә, — диде Фәтхи Сафуанга. Киң күңелле, йомшак бәгырьле тимер остасы артык сүз катмады, ризалыгын белдереп, башын гына селкеде. Шуннан бирле бала ике йортны бер күреп үсте дисәң дә ялгыш булмас. Ләкин бабасы белән әбисе дә, җан җылысы бирәбез

дип, Даимәне артык иркәләделәр, узындырдылар гына, кирәкле тәрбия бирә алмадылар. Ә Сафуанның кызына игътибар итәргә вакыты булмады: буровое, җаваплы эше белән мәшгуль булды. Акчасын җитәрлек алды, гаиләсен туендырып-киендереп торды, әмма үсеп килгән олы кызын күз уңыннан ычкындырды. Хәтта Даимәсенең азынып-тузынып, һәр ым ясаган ир-егеткә ияреп китүе турында да ул соңлап кына ишетте һәм эчтән генә Гөлмәрфугасы белән үзен битәрләп алды: атасы белән анасына охшамыйча бала кемгә охшасын соң? Үзебез гаепле...

Анасын күрәсе килеп, шул турыда хыялланып яшәгән кызның үсә-үсә анасына үпкәсе арта гына барды: «Ана түгел, җансыз, каты бәгырьле бернәмәстә икән. Йөрәгенә йон үсмәсә, кызын күрергә бер кайтыр иде...»

Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше кайчан да булса бер очраша. Даимә дә анасы белән бер күреште. Аның урта мәктәпне тәмамлап апаларына, Уралга барган елы иде ул. Институтка керергә теләп, имтиханнар биреп йөргән мәшәкатьле көннәре. Шунда апаларына кырык яшьләр чамасындагы саргылт йөзле, арык гәүдәле, гади генә киемнән бер хатын килеп керде. Апасы аны ачык чырай белән каршы алды, түргә утыртты. Ә теге хатынның күзләре гел Даимәдә. Шунда кыз бу көтелмәгән кунакның анасы булу ихтималын сизенде. Сизенде дә уңайсызланып китте. Юк, үзе өчен түгел, әлеге хатын өчен уңайсызланды. Өстендә уңып беткән иске соры плащ, бөгәрләнгән яшькелт күлмәк, аягында үкчәләре ашалып беткән көрән туфлиләр. Җыерчыклы саргылт йөзеннән нур качкан. Карашы салкын, нурсыз.

Апасы чәй куеп, өстәл әзерләде. Ләкин Даимәнең бу нурсыз йөзле, өметсез карашлы хатын белән аралашасы килмәде — икенче бүлмәгә кереп, китаплар караштыра башлады.

Шунда апасы кереп:

— Әйдә инде, эреләнеп утырма, анаң килгән бит, — диде.

Даимә аптырап китте, ләкин югалып калмады.

— Анам?

Ул кабат олы бүлмәгә чыкты. Бу вакытта теге хатын да торып баскан, күзләре бераз очкынланган иде.

— Кызым... наныем... бәгырь кисәгем...

Ул, кулларын сузып, Даимәгә таба килә башлады. Ләкин мондый төче телгә күнекмәгән, бу сүзләр артында ярылып яткан ясалмалыкны танып белгән Даимә баскан җиреннән кузгалмады, кулларын күтәреп, «якын килмә!» дигән ишарә ясады да гаҗәпсенгән йөзен икенче якка борды. Аннары:

— Туктагыз әле, апа, сез ялгыша торгансыздыр, — диде.

— Юк, ялгышмыйм, син минем Даимә кызым...

— Әйе, мин — Даимә. Ләкин миңа ана булырга тиешле кеше миңа өч яшь тә тулмаган килеш сөяркәсенә ияреп ташлап качкан. Шул миһербансыз бәндә сезмени инде?

— И кызым, алай ук каты бәгырьле булма инде...

— Ә соң сез каты бәгырьле булмадыгызмыни балагызны ташлап качканда?

— Анысы тәкъдир инде, кызым...

— «Кызым» димәгез миңа. Сезнең миңа «кызым» дип әйтергә хакыгыз юк. Тәкъдир, имеш... Бик җиңел юл тапкансыз акланырга. Мин хәзер үземне белә башлаганнан бирле кемгә чын күңелдән, өзелеп, йөрәкне эретә торган «әни» сүзен әйтергә белми сыкрап йөрим, ә сез миңа каты бәгырьле булмаска кушасыз. Йә әйтегез: кем катырды соң минем йомшак бәгыремне шушы елларда?!

Өйдә тынлык урнашты. Чит хатынның кәефе китте, чырае сытылды, аннары ул хәлсезләнеп урынына утырды һәм йөзен кулындагы яулыгы белән каплады. Вөҗдан газабы кичерү галәмәте идеме бу, юкмы — Даимә төшенеп җитмәде.

Сүзгә апасы кушылды:

— Ярар, Даимә, тынычлан, кызма алай ук, җәзалама ана... — Ул анаңны дип әйтергә теләгән иде, ләкин бу сүз Даимәне чыгырыннан чыгарыр дип: — Җәзалама кешене, — дип төзәтте. — Ул үз җәзасын җитәрлек алган инде...

Бар очрашу-күрешү, бар сөйләшү-аңлашу әнә шул булды. Аның бөтен нечкәлекләре Даимәнең хәзер исендә дә калмагандыр. Ә менә апасының соңыннан сөйләгәне хәтердә.

— Минзәки белән биш-алты ел гына бергә яшәгәннәр, ни сәбәптәндер теге бәрәңге борын куып чыгарган анаңны. Аннары ул тагын берәү белән яшәп караган, тик анда да озак тора алмаган. Хәзер әнә эшли торган эше, яшәргә урыны, ашарга ризыгы юк мескеннең... Син дә инде... Начармы-яхшымы, күкрәк сөтен имезеп үстергән бит ул сине. Дөрес, син дә хаклы, ялгышкан инде, ялгышкан. Зәкинең тасма теленә ышанып ялгышкан. Бәрәңге борын!.. Кая да булса эшкә урнаштырмый булмас инде анаңны...

Даимә анасы белән тәкәббер сөйләшүенә соңыннан бераз үкенеп тә алды. Алай гына да түгел, Даимәдә аңа карата кызгану хисе дә уянды, хәтта тагын бер очрашасы, яхшылап сөйләшеп аңлашасы килгән иде. Тик шушы хәлдән соң ул полковникка тормышка чыга, фаҗигадән соң апалары белән элемтәне югалта, аннары Аккүлгә кайта, анда да озак тормый, Төмән якларына чыгып китә, тагын бер иргә кияүгә чыга, аның белән дә аерылыша, озак еллар ялгыз яши, ниһаять, соңыннан туган якларына кай-

тып егыла. Тик анасының, апаларының язмышын бүгенгәчә белми яши ул. Һәм шуны белми яшәү Даимәнең күңелендә авыр бер төер булып тора. Анасы белән уртак тел табып, чөкердәшеп бер сөйләшә алмадылар алар — шунысы аяныч...

Даимәнең уйларын кинәт шартлап сынган бер ботак бүлде. Ул сискәнеп торып басты һәм кабат карт каенга сыенды:

— Кичер мине, каеным, кичер...

Карт каен, тын калып, аның зарын тыңлады.

Киң күңелле, юмарт, бөдрә карт каен аны, бәлки, кичергәндер дә. Тик әле каеннардан да, таулардан да, болытлардан да өстәрәк кодрәтле көч бар, диләр бит. Даимә ул турыда әллә онытткан, әллә аңа ышанмый, әллә бөтенләй белми иде — ялвару сүзләрен ул аңа сөйләмәде. Эче тулы моң-зар, кайгы-хәсрәт белән тирән уйга батып, ул сердәш каены төбендә утыра бирде. Хәтта әллә нидән көннең караңгыланып киткәнен дә сизми, абайламый калды. Көчле җил исеп, урман шаулый башлады. Карт каен да, айнып киткәндәй, искән җилдә канат-кулларын җәеп, чайкалып-чайкалып алды. Өстән эре-эре яңгыр тамчылары шыбырдап җиргә төште. Шунда гына Даимә кинәт уйларыннан арынып китте һәм, хәтәр буласын сизгәндәй, башын күтәреп өскә карады. Өстә аның сердәш каены шаулый, һәм, имән башларына кагыла-сугыла, кара болыт әйләнә, куера иде. Ул шулкадәр кара, шулкадәр дәһшәтле һәм куркыныч иде — Даимәнең йөрәге жу-у итеп китте. Шул куркуыннан каушап, нәрсә эшләргә дә белми аптырап торды. Югыйсә, урманнан чыгып, тау астына төшәргә, хәтәр җирдән тизрәк һәм еракарак китәргә, ашыгырга кирәк иде аңа. Ә ул, гипнозланган кеше сыман, һаман бер урында таптана. «Язмыштан узмыш юк...» Кинәт нишләптер Даимәнең башына соңгы минутта гомере буе әледән-әле кабатлаган шушы сүзләр килде. Шулай ук аның язмышы да кыл өстенә куелганмыни инде? Ах, куанычлы, матур, мәгънәле тормыш итеп булмады. Әгәр Ходай гомерен бирсә, бәлки, бу хатаны азмы-күпме төзәтергә дә мөмкин булыр иде. Гомерне генә бирсен...

Шул мизгелдә аждаһадай кара болытны икегә-өчкә телгәләп, бөтен җиһанны мәхшәр утына чолгап яшен яшьнәде. Дәһшәтле чытырдау һәм көчле шартлаудан җир калтырап, тетрәнеп куйды, тау селкенеп торды. Карт каен, дөбер-шатыр килеп, икегә аерылып төште.

Даимәнең бу мәхшәрдән колаклары тонды, коты очты, өне югалды. Күпмедер вакытка ул баскан урыныннан кузгала алмый катып калды. Шаулап һәм ишеп яңгыр яварга тотынды. Шунда гына ул бераз һушына килде һәм, тәмам хәлсезләнгән аякларын көчкә өстерәп, калтырана-калтырана урыныннан кузгалды. Тик ерак китә алмады. Чиләкләп койган яңгыр астында тайгакланган тау битеннән ике адым да ясарга өлгермәде, аяклары таеп китеп, мәтәлеп аска тәгәрәде. Күпме тәгәрәгәндер, аны ул үзе дә чамалый алмады. Бервакытны, аркасы белән бик каты нәрсәгәдер килеп төртелгәч кенә, кабат һушына килде. Тау итәгеннән өстәрәк үсеп утырган ялгыз имәнгә килеп төртелгән икән.

Яңгыр бертуктамый һаман коя да коя. Даимәнең инде чыланмаган бер җире дә калмады, аның өсте лычма юеш һәм пычрак иде. Ләкин ул аягына баса алмады.

— Йа Ходая, бу дөньяда кылган гөнаһларым өчен мине шулай газаплыйсыңдыр инде, — диде хатын һәм, көчкә кузгалып, имәнгә аркасын терәп утырды. Авыртмаган, сызламаган җире юк, башы чатный, күкрәге кыса, сулыш алалмый. Суга батып баручы саламга тотынган кебек, ул да һаман кыймылдый, һаман бу мәхшәрдән котылмакчы була. Ах, үләсе килми шул, яшисе килә, яшисе... Гөнаһлары чиксез булса да, яшисе килә, чөнки дөнья матур, искиткеч гүзәл. Тик яшәүнең кадерен генә белергә кирәк. Ә Даимә аның кадерен белмәде. Бүген исән калса, иншалла, дөньяның, тормышның, бар җиһанның кадерен белеп яшәр иде ул. Кадерен белеп, игелек кылып, матур итеп. Тик исән генә каласы иде. Исән каласы иде...

Ике дә генә җирән, ай, бер көрән,
Әйдәп алып булмый юл белән;
Маңгаеңа язган хак язмышын
Җуеп кына алып булмый кул белән...

*Халык җыры*

# Көт син мине...

## Кошларда да кеше язмышлары

*(Кереш сүз өчен)*

Кешеләр нигә йорт сала? Аларга торыр урын кирәк, шунда яшәр өчен йорт сала, диярсез сез һәм хаклы булырсыз. Ә мин, аларга тәрәзә кирәк, шуңа йорт җиткерәләр, дияр идем. Тәрәзә!.. Тәрәзәләр ачылып китә дә, өйгә ашкынып, талгын яз исе керә башлый. Аһ шул язгы хуш ис! Тулышып аккан инеш тирәли котырып үскән зирек һәм тал-тирәкләр, су буен әйләндереп алган шаулы камыш дәрьясы, яр астында эреп бетмәгән кар, инеш суы, зәңгәр томан, туган якларын сагынып кайтучы киек казлар тавышын моңлы һәм яңгыравыклы иткән саф һава — аларның барысы да аһәңле, кабатланмас яз исен хасил итә. Тормыш яме, яшәү дәрте, илһам, рух күтәренкелеге, күңелләрне канатландыра торган яз исе...

Иркен әрәмә өстеннән җилдә җилпенеп торналар үтә: «Тор-рыйк, тор-рыйк!»

> Һаваларда торна тавышлары,
> Чит җирләрдән кайтып барышлары...

Камышлыкта үрдәкләр аваз сала: «Нарт-нарт, нарт-нарт...»

Зәңгәр күктә, кайдадыр өстә, тургай ярсып сайрый. Үзе күзгә күренми, ә җыры тирә-якны моңга сала.

Зирек агачлары башында ала карга оялары. Аларның каркылдаганнары ишетелә: «Кар-р, кар-р...» Таныш аваз, тик бүген аларда да язгы аһәң бар сыман.

Ояларын беркеткән талда дәртләнеп, канатларын җилпи-җилпи сыерчыклар сайрый. Быел да алар туган ояларын сагынып кайттылар. Әнә, ишетәсезме, тәрәзәдән сыерчык сайравы ишетелә?! Әйе, тәрәзәләр дөнья матурлыгын күрер өчен генә түгел, кошлар сайравын тыңлар өчен дә кирәк.

Бер сыерчык оясы минем тәрәзәм каршында гына. Кошлар кайту белән, челтәр элгән тәрәзә аша шул ояда барган тормышны күзәтәм. Анда сокланырлык кызыклы хәлләр белән танышырга була...

Пар сыерчык, кайтып төшү белән, ояны карап чыкты. Эченә кереп-кереп тә, түбәсен дә, ян-яннарын да карап-тикшереп чыктылар. Тал чыбыкка кунып сайрыйлар да тагын ояны тикшереп чыгалар, ә кичен шунда кереп, тынычлап кунарга булдылар. Иртән-иртүк берсе тал чыбыгында сайрап утыра, ә икенчесе, оя тишегеннән башын тыгып, парының аңа атап башкарган ариясен тыңлый. Ул тишек алар өчен бер үк вакытта ишек тә, тәрәзә дә. Тәрәзә! Әле кошларга да тәрәзә кирәк икән бит...

Аннары кошлар өй-ояны җиһазландырырга керештеләр — ашыгып-ашыгып корыган агач кисәкләре, кош-корт мамыгы ташый башладылар. Икесе дә бик уңган икән, бар көчкә эшлиләр дә эшлиләр. Эшләп азга гына тукталалар да, канатларын җилпи-җилпи, тагын сайрап алалар. Исән-имин кайтып житү шатлыгыннан, дөньяның ямьлелегеннән, тормыш матурлыгыннан, яшәү бәхетеннән оста итеп, бирелеп җырлыйлар алар.

Әнә шулай тыныч кына җырлы-моңлы берничә көн үтте. Сайрар кошкайларымның тормышы җайланды дип, мин дә иркен сулап куйдым. Тик...

Беркөнне оя өстендәге тал чыбыгында бер генә сыерчыгым утыра. Сайрамый да, талпынмый-җилпенми дә, бөтенләй пошаманга калган, боек. Үзе әле бер, әле икенче ягына карап-карап ала — парын көтә. Инде эңгер төшә башлады. Ояларына сыерчыклар, гадәттә, басу-болыннардан бик соңга калмый кайталар. Ә моның пары һаман юк. Чыбыктагы сыерчык кына түгел, инде үзем дә борчыла башладым: нишләп кайтмый?

Икәүләшеп караңгыга хәтле көттек, ә кошчыгымның пары күренмәде. Ул иртән дә, көндез дә, икенче кичне дә кайтмады. Башта кошкаем берничә тапкыр болынга очып барып кайтты — анда парын эзләде булса кирәк, аннары оя өстендә зарыгып көтте, тик пары барыбер күренмәде. Ниһаять, мин сыерчыккаемның кайдадыр без белмәгән җирдә харап булуына төшендем. Әллә явыз карчыга тырнагына эләгеп харап булды микәнни сайрар кошым?

Ә оядагы ялгыз сыерчык зарыгып көтүен дәвам итте. Озак көтте ул сөйгән ярын. Көтте-көтте дә, пары кайтмагач, ояны ташлап очып китте.

Сезгә тәкъдим ителгән әсәрдәге вакыйгалар да әлеге мизгелне исегезгә төшерер. Кошларда да кеше язмышлары... Әсәрдә олы сабырлык, зур түземлек, зар-интизар булып озак еллар буе бер-берсен көткән авылдашларым язмышы.

Аппакай Вәлинең юлга чыгып китүен хатыны Зөләйха күптән көтә иде. Ниһаять, андый көннең дә килеп җитәсе бар икән. Сигезенче март — халыкара хатын-кызлар көне дип тормадылар, авылның еллар буе юл йөрүдә сыналган уңган-булган йөкчеләрен, шул исәптән Вәлине дә, сельпо товарларын алып кайтырга дип, Бөгелмәгә озаттылар. Зөләйха моңа эчтән генә кинәнеп, җиңел сулап куйды, чөнки күрше-күләннең буй җитсәләр дә башлы-күзле булырга өлгермәгән чая кызлары аны күптән аулак өй үткәрергә кыстап йөриләр. Әле биш-алты ел гына элек үзе дә шул кызлар кебек ашкынып-талпынып, качып-посып аулак өйләргә йөргән гүзәл Зөләйха кызларның теләген үтәргә уйлап йөри иде. Беркатлы, саф күңелле, тугрылыклы хатын иреннән серен яшереп тормады, аулак өй җыярга фатихасын алып калды.

— И-и, атасы, кызларның бездә бик җыелышып утырасылары килә. Өегез зур, җылы, якты, Вәли абзый да, син үзең дә, Зөләйха апа, киң күңелле кешеләр, бер генә кич утырыйк инде, дип өзгәләнәләр, — диде сүзгә оста Зөләйха, салпы якка бераз салам кыстырып.

Вәли бу сүзләрне болай да олы күзләрен тагын да зурайтып тыңлап торды. Кыяфәте карап торуга усал шикелле булса да, Вәли җайлы, күндәм, хәтта юаш кеше. Майлап-җайлап, оста сүзе белән юмалап, авызына гына каратып тоткан Зөләйханың теләгенә Вәли каршы киләмени инде? Авылда бер чибәр Зөләйханы яратып алды бит ул...

— Ярар, анысын үзең кара! Тик ул-бу булырлык булмасын, — диде дә Вәли, атына дилбегәсен салып, капкадан чыгып китте.

Кич җитүгә, Вәлинең гуринча кебек зур һәм яңа ызбасында гөлт итеп пыяла куыклы унлы лампа кабынды. Ул арада берәм-берәм кызлар да җыела башлады. Монда чибәрлеге, көе-моңы, сүзгә осталыгы, тәртибе, итагатьлелеге белән танылган абруйлы кызлар җыелган иде. Алар арасында иң гүзәле, күз өстендә каш — түгәрәк көләч йөзле, Борһан күлендәге камыш сабагы кебек зифа буйлы, нечкә билле, үзенә әле уналты гына яшь булса да, алсу алма кебек өлгергән Палта Нурислам абзый кызы Миңнур да бар иде. Кызның өстендә әле бик күп кызларның төшенә дә кермәгән сигез балитәкле кара сатин күлмәк. Ияк астыннан алып балитәккә чаклы тигез итеп берсе икенчесенә янәшә кадалган өч дистәләп энҗедәй ак сәдәп. Кызның сылу гәүдәсенә затлы күлмәк сыланып тора. Ике калын толымга үреп салган кара чәч, зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләр... Юк, Палта Миңнуры гына димәссең! Авылда гына туып үссә дә, борынгы Болгар гүзәлләреннән һич кенә дә калышырлыгы юк. Берсеннән икенчесе чибәррәк күрше кызлары арасында Миңнур исә аерым бер гүзәл зат, чын мәхәббәт алиһәсе иде.

Авылда тире җыеп, вак товар сату белән шөгыльләнгән Палта Нурислам абзыйның икенче кызы Миңнур кинәттән генә үсеп китте, кисәк кенә җиткән кызлар арасына керерлек булды, чөнки кыз күбрәк атасына охшаган — эре сөякле иде. Нурислам абзый исә авылда бер олы гәүдәле кеше. Баһаветдин картның икенче хатынынан алтынчы, үзенең исә уникенче баласы булып туды Нурислам. Әмма Нурисламга атасы канаты астында үсәргә насыйп булмады. Баһаветдин карт сиксән яшен тутырып якты дөнья белән хушлашканда, иң кече улына унбер генә яшь иде әле. Ләкин берсеннән икенчесе әрсез, эшчән, булдыклы олы ир туганнары яраткан энеләрен үз канатлары астына алдылар. Эшкә, көн күрергә, дөнья күтәргә өйрәттеләр — бергә-бергә җир эшкәрттеләр, иген иктеләр, урман кистеләр. Хәтта аларның Палта кушаматлары да әнә шул урман кисү белән бәйләнгән иде. Алты туган, көн буе урман кисеп, кайтыр юлга чыкканнар. Кызулык белән Җәләлетдин балтасын онытып калдырган.

— Ул палта имән төбендә калды, — дигән Җәләлетдин шунда, әллә ничек теле бәйләнеп. Әнә шул сүз аларның кушаматына әйләнгән.

Нурислам туганнары янында эшчән, тырыш, һиммәтле ир-егет булып үсеп җитә. Малын да таба, тормышын да әйбәт көйләп җибәрә. Хатыны Фәрхинур да бик уңган, ул аңа бер-бер артлы сигез бала табып бирә, тик биш баланың гомере бәләкәй чакта ук өзелә, аларын саклап кала алмыйлар.

Нурислам:

— Син, аналары, булдыра алсаң тап инде балаларны. Икесенең берсе үлсә, берсе кала, ялгызның егылып үлсә кеме кала? — ди.

Шөкер, өч кыз исән-имин калалар. Нурислам аларны үлеп ярата, иркәли, назлый, бөтен игътибарын аларны тәрбияләп үстерүгә бирә. Авыл кызларының күбесе киндер күлмәк киеп үскәндә, Палта Нурислам кызлары затлы киемнәрдән генә — ефәк-атлас һәм сатиннан гына йөриләр. Киемнәрне исә Миңнур тегә. Бу сәләтле бала тугыз яшьтән үк тегү һөнәренә өйрәнә. Кыз кеше бит — аның кемнәндер күреп яңа тегелештәге, яңа модадагы киемнәрне дә тегәсе, киясе килә. Бервакыт ул, анасыннан рөхсәт сорапнитеп тормыйча, аның калын шәлен кискәләп, үзенә итәк тегә. Базарга килеп йөри торган марҗалардан күреп калган була ул итәкне. Фәрхинур абыстай өр-яңа калын шәлен бозган кызын ду китереп йорт әйләнә куып йөри, ә тегесе тоттырмый, кача. Кисәү агачы тоткан хатыны артыннан: «Тимә кызыма, тимә кызыма!» — дип, Нурислам абзый үзе тырыклый.

Утызынчы еллар уртасында авылга Чулман аръягыннан Хәмзә исемле урта яшьтәге бер тегүче абзый килеп йөри. Нурислам аңа вакытлыча өенең бер почмагын бушатып бирә. Бу агай тирә-юнь авыллары кешеләренә «Зингер» дигән аяклы тегү машинасында бишмәтләр, пальтолар, туннар, толыплар тегеп бирә. Елы-елы белән ул берничә ай торып эшли. Ләкин бер елны Хәмзә нигәдер эшен кыска тота, китәргә ашыга.

— Нурислам, бу соңгы килүем, башкача сезнең якларга килеп чыгалмам, ахры. Тегү машинасын, теләсәгез, кызыңа калдырам, — ди ул.

Бу сүзгә уникенче яше белән барган Миңнурның шатлыгы эченә сыймый. Тегүче юлга чыгып китү белән, ул машина артына утыра һәм, күп тә үтми, үсмер кыз авылда бер оста тегүчегә әверелә.

Бүген аулак өйгә киеп килгән сигез балитәкле, төнге күктәге Киек Каз Юлы кебек изү буйлап сузылып киткән ап-ак сәдәпле кара сатин күлмәкне дә үзе тегеп кигән иде Миңнур.

Кызларның барысы да аулак өйгә кул эше белән килгәннәр. Зөһрә белән Нурия кулъяулык чигә, Суфия пирчәткә бәйли, Фатыйма йон эрли, Миңнур исә бәләкәй күрше кызына тегәсе күлмәкне карап утыра.

Үз шөгыльләре белән артык мавыкмыйча, тыныч күңел белән, бер-берсенә игътибарлы-дустанә караш ташлаштырып, кызлар башта үзләренең көндәлек хәлләре белән уртаклаштылар. Аннары җыр остасы Нурия, һич кыстатмый, тыйнак, басынкы тавыш белән җыр сузып җибәрде:

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җыр күңелне ача ул.
Җырлау күңелне ача ул,
Кайгыларны баса ул.

Җырның ахырына, дәртләнеп китеп, башка кызлар да кушылды. Әнә шулай аулак өйгә җыр белән бергә моң сибелде, кызларның күңел яктылыгыннан унлы лампа уты да яктыра төшкән кебек булды һәм әлеге садәлектән өйдәгеләрнең барысы да татлы, рәхәт минутлар кичерде.

Шулчак тын урамда, март киченең талгын һавасында тальян гармун тавышы яңгырады. Кызлар, җанланып китеп, елмаешып куйдылар: «Егетләр килә...» Бары Миңнур гына сабырлыгын җуймады, елмаймады, гәрчә дикъкать белән караган кеше аның йөзе кызарып киткәнен абайламый калмаган булыр иде. «Минәхмәт!» — дип уйлады кыз. Сыйныфташы Минәхмәтнең тальянда сыздырып уйнавын ун гармунчы арасыннан да таный ул. Авылда болай оста һәм моңлы итеп Минәхмәт кенә уйный ала торгандыр. Оста гармунчы булуы белән биләде дә инде егет Миңнурның күңелен. Югыйсә үзе какча гына гәүдәле, төскә-биткә дә кызлар һушын алырлык түгел. Тик сүзгә, җырга оста. Киң күңелле, йомшак бәгырьле егет. Алар бер-берсен мәктәптә бергә укып йөргән еллардан ук белешәләр. Җидееллыкны тәмамлагач, Миңнур да, Минәхмәт тә Лашман авылына, районда бердәнбер татар урта мәктәбенә укырга китәргә уйлаганнар иде. Нурислам абзый да каршы түгел иде уртанчы кызының укуын дәвам иттерүенә. Тик Фәрхинур, олы кызы Мәдинурны Нәсип башкисәре Хәбибуллага олактыргач, Миңнурны укырга чыгарып җибәрәсе килмәде, кул арасына керер кешем калмый дип, каршы төште.

Мәдинур артык дәртле булып үсте, бик тиз өлгерде. Чибәрлеге, килеш-килбәте дә булгангамы, егетләр дә тиз күреп алдылар үзен. Тик Нәсип Хәбибулласы — ярпач, җиңел-җилбәзәк егет кисәге — барыннан да алда өлгерде: беренчеләрдән булып кызның ышанычына керде... Әй булды инде хәлләр. Ярый әле койрыгын чәнчеп чапкан кырыкмыш тайга үз вакытында камыт кигертә алдылар, алайса адәм көлкесенә каласылар иде барысы да.

Миңнур укырга китмәгәч, аңа карап Зиннәт малае Минәхмәт тә авылда калды. Ярата, бик ярата иде ул Миңнурны. Миңнурның үзенең дә йөрәге күптән инде: «Минәхмәт, Минәхмәт», — дип тибә. Әлбәттә, бу турыда аулак өйдәгеләрнең дә күбесе белә иде инде...

Хәзер Миңнурга, ишектән гармунын тотып, Минәхмәт килеп керер сыман тоелды, сабырсызланып, ул шуны көтте. Менә ишегалдында аяк тавышлары...

Ни гаҗәп, башта ишектә хәрби киемле кеше күренде. Әстәгъфирулла! Бу бит ике-өч кенә көн элек армия хезмәтен тутырып кайткан Мифтах. Аннан соң гына өйгә муенына ике башы чуклы озын ефәк шарфын ураган Минәхмәт, аның яшьтәш дуслары Голүм белән Рәхимҗан килеп керде. Егетләрне шау килеп каршы алдылар. Игътибар үзәгендә хәрби киемдәге Мифтах иде. Аның армиядән кайтуы, өйләнергә кыз эзләве турындагы хәбәр авылга бик тиз таралган, бу турыда Миңнур да хәбәрдар иде инде. Урта буйлы, киң җилкәле, төп кебек таза Мифтах егетләр арасында иң чибәре дә. Түгәрәк каратуткыл йөзле, коңгырт күзле, дулкынланып, күпереп торган кара чәчле. Вакытында кияүгә чыгып калырга хыялланган кызлар өчен менә дигән егет! Тик Миңнур өчен түгел. Кияүгә чыгарга аңа әле иртә. Инде ул вакыт җитә икән, аның әнә күзләгәне — Минәхмәте бар. Аңа аннан башка берәү дә кирәкми...

Ләкин аулак өйгә килеп керү белән, унҗиде яшьлек Минәхмәтнең генә түгел, егерме өч яшендәге Мифтахның да күзләре кара сатин күлмәкле, зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләрен аска төбәп, тын гына эшләп утыручы яшь кызга төште. Мифтах сәке кырыена килеп утыргач та күзләрен кыздан алалмый торды. Ул Вәли абзыйның Бәркәтәдән утырмага килгән кыз туганы Мөгаззәмә апа янына барып утырды һәм аның колагына:

— Бу нинди асыл кош соң әле, кем кызы? — дип пышылдап сорады.

— Әйтерең бармы, бигрәк матур шул, бу яшемә җитеп мондый да сылу кызны күргәнем юк иде әле үземнең дә. Уңганлыгына да исең-акылың китәр, кулыннан килмәгән эше юк. Палта Нурислам абзыйның икенче кызы Миңнур бит инде, танымыйсыңмы әллә? — диде Мөгаззәмә апа, шулай ук тын гына.

— Шулаймыни? Танырга бит... Мин киткәндә... Менә сиңа гомерләр... Булды бу алайса. Менә кемне каптырырга кирәк миңа, — диде Мифтах, ниһаять, фикерен очлап.

Чыннан да, гүзәлләрнең гүзәле Миңнурны күрү белән, Мифтах тынычлыгын җуйды. Ни арада үсеп җиткән диген син аны? Һәм ул кич буе — кызлар түгәрәкләнеп әйләнгәндә дә, «Йөзек салыш» уйнаганда да, табышмак әйтеп, җырлап кына утырганда да Миңнурдан күзен алмады. Ләкин кыз үзе Мифтахка күтәрелеп тә карамады. Аның каравы тальян гармун тартып утырган Минәхмәткә ул серле күзләрен еш бакты. Шул карашлары белән егетенә нәрсәдер аңлатасы килгән иде аның, ә тегесе аңлап җиткермәде бугай, әллә инде хәтәр киләсен күңеле сизмәде.

Шунысы гаҗәп булды: күзе төшсә дә, армиядә хезмәт итеп, буын ныгытып, буй үстереп, кыюланып кайткан егет кызга нигәдер ишарә ясамады. Югыйсә җитди нияте булган егеткә кыз белән очрашып сөйләшү кирәк иде. Миңнурга: «Юк, Мифтах абзый, өметеңне сузма, минем күзләгән, җаным тарткан егетем бар», — дип әйтер өчен кирәк иде бу сөйләшү. Ә Мифтах кичәнең башыннан ахырына кадәр Миңнурга текәлеп, аның белән сокланып-сихерләнеп утырды да мыштым гына өенә кайтып китте. Миңнур исә тынычлыгын җуйды.

— Ай, кызый, Мифтахның сиңа күзе төште бит. Бу кызны каптырырга кирәк миңа, ди, билләһи менә, — диде Мөгаззәмә, таралышыр алдыннан.

Миңнур коелып төште. Капка төпләренә чаклы аны Минәхмәт озатты. Кыз да уйга баткан, егетнең дә кәефе юк иде.

— Мифтах абзый, ач козгын кебек, гел синнән күзен алмады, — диде Минәхмәт, көрсенеп.

— Күрдеңмени?

— Күрмичә...

— Ә мин сине бернәрсә дә күрмисең, сизмисең дип торам, — диде Миңнур, бераз үпкәле тавыш белән.

— Мин сине беркемгә дә бирмим, белеп тор! Иртә исемдә, кич төшемдә син минем.

— Әллә мине кемгә дә булса китәр дип уйлыйсыңмы?

— Уйламыйм да бит...

— Уйлама да! — диде Миңнур һәм җиңелчә генә Минәхмәтнең кочагына сыенды.

Алар шулай бер-берсен тынычландырырга, юатырга тырыштылар. Әмма икесенең дә күңелендә төер калды.

Һәм бу төер нигезсез булмаган икән. Икенче көнне төш җитәрәк Палталарга Кыр Капка Хәйретдине килеп керде. Аның килүендә артык гаҗәпләнерлек нәрсә дә юк кебек. Нурислам абзый белән Хәйринең яшь аралары шактый булса да, бер-берсеннән ерак яшәмәгән бу ике эшлекле ирнең уртак мәнфәгатьләре җитәрлек, боткалары пешә: алыш-биреш итеп, мал суеп, булышып, дус яшиләр.

Ләкин Хәйринең бу килүендә Миңнур нидер буласын сизде: Мифтахның терәлеп торган күршесе ләбаса... Хак, шулай икән: башкода булып, кызның башын ашарга килгән бит.

Башта Хәйри серен Нурислам белән Фәрхинурга гына чиште. Миңнур бу вакытта алгы бүлмәдә тегү белән мәшгуль иде. Бераздан хәлне аңлатырга аның үзен дә чакырдылар.

— Менә, кызым, Хәйретдин абзаң сине Мифтахка сорап килгән. Барыбыз бергә киңәшләштек тә, Ходайга тапшырып, сине бирербез, дидек...

— Сарык бәрәнен сатып җибәргән кебекме? — диде Миңнур, атасын ярты сүздә бүлеп.

Моңа чаклы аның атасы белән болай тупас сөйләшкәне юк иде. Ә бу юлы түзмәде. Ата-ана сүзеннән чыкмыйча, гел аларның сүзен тыңлап, баш иеп яшәгән кыздан Нурислам белән Фәрхинур да аның болай дип җавап бирүен көтмәгәннәр иде.

— Мине шул Мифтахка кияүгә бирер өчен үстердегезмени? — дип дәвам итте Миңнур. — Үзегез яхшылап уйлап карадыгызмы соң? Мин бит аны рәтләп белмим дә. Ул да белми. Безнең аның белән бер-беребезгә сүз дә катканыбыз юк. Кияүгә, белгәнемчә, яраткан, һич югында, яхшылап холык-фигылен, тормышын, көнкүрешен белгән кешегә бирәләр. Юк, мин сезгә сарык бәрәне түгел бау белән бәйләп җибәрергә, ә адәм баласы. Үз акылым, үз фикерем, үз сүзем, ниятем бар...

Кызның кинәт күңеле тулып китте, һәм ул еларга тотынды. Бу хәлдә сүзне дәвам итү файдасыз булганын барысы да аңлады. Нурислам, ахирәтенә ым ясап, аны ишегалдына алып чыкты:

— Тынычлансын инде. Әллә ничек килеп чыкты әле. Сүзне иртәгә дәвам итәрбез. Күнәр, кая китсен, — диде.

— Син, Нурислам абзый, күндер инде аны. Булачак кияү — дастуйный парин. Армиясен үткән, кулыннан эш килә, уңган, булдыклы. Сиңа, малайсыз кешегә, бүгеннән үк настаяшшый памушник булыр, — диде башкода. Малай чактан бәхет эзләргә Урал якларына китеп, урыс арасында шомарган Хәйри сүзгә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел. Нурисламның авырткан җирен белә: улларың юк, булышчың, терәгең булыр кияү балакай карт көнеңдә...

* * *

Мәсләх Мифтахының Палталарга башкода җибәрүе турындагы хәбәр авылга яшен тизлеге белән таралды. Ул Минәхмәтләргә дә тиз килеп җитте: башкода китү белән, Миңнур аларга күрше кызын җибәргән иде: «Бар, сеңлем, Әхмәт абыеңа, Мифтах абзый Миңнур апаны сорап башкода җибәргән, диң. Калганын үзе аңлар...»

Кызның сүзләре Минәхмәтнең йөрәген урталай яргандай булды. Башта ул хәтта югалып ук калды. Әмма үзен тиз кулга алды.

— Мин Миңнурны беркемгә дә бирмим, ул — минеке, — диде ул, анасы Маһиҗамал абыстайга хәлне ачып.

Маһиҗамал абыстай да бу хәбәргә аптырап китте. Миңнурны ул күптән белә, күз алдында үскән кыз ич. Алай гына да түгел, үзенең кул арасына керердәй кызлары булмагач, шул урам кызларын әнисе еш кына ызба юарга чакыра иде. Бу уңган кызлар бүрәнәләрне, идәннәрне кыргыч белән кыра-кыра юып чыкканнан соң, өй эче яктырып, матураеп кала. Юмарт куллы Маһиҗамал абыстай игелекле кызлар өчен итле бәлешен дә сала, пилмәнен дә пешерә, коймагын да өлгертә, йомыркасын да куыра, чәен дә баллап эчертә. Матурлыгы да, уңганлыгы да, акылы да күренеп торган Миңнурны исә ул бигрәк тә ярата, аның белән Минәхмәте арасында кабынган хискә куана, киләчәккә күркәм өметләр баглый — бу сылу кызда үзенең беренче киленен, булышчысын, киңәшчесен күрә иде.

Улының кайгылы хәлен яхшы аңлаган ана алгы бүлмәгә, ире Зиннәт янына кереп китте.

Бер карашка бик кырыс холыклы булып күренгән Зиннәт абзый авылдашлары арасында катлаулы язмышлы, абруйлы кеше иде. Үз чоры өчен укымышлы, алдынгы карашлы егет башта туган авылында, аннары тирә-юньдә совет власте урнаштырып, соңыннан Себер якларында Кызыл Армия сафында Колчакка каршы сугышып йөргән, яраланган, бер күзсез калган. Гражданнар сугышыннан соң Казанга кайтып, төрле хуҗалык тармакларында зур җитәкче булып эшләгән. Дәҗҗал Сталинның кара репрессия елларында партия, совет, хуҗалык җитәкчеләрен бер гаепсезгә берәм-берәм алып китеп ата, төрмә-лагерьларга олактыра башлагач, Зиннәт, бер төн эчендә Казанны ташлап, гаиләсе белән Норлатка китә. Ләкин анда да озак тормый, тавыш-тынсыз гына туган авылына кайтып урнаша. «Мин — пенсиядәге кеше, сәламәтлегем начар», — дип, бар яхшы тәкъдимнәрдән ваз кичеп, гаиләсе белән тыныч кына яши башлый.

Хатынының кайнарланып, борчылып сөйләгәнен ул укый торган газетасыннан аерылмый гына тыңлады һәм килеп туган мәсьәләне ике сүз белән хәл итте:

— Әнә Габделкадыйр картны башкода итеп җибәр!..

* * *

Тырыш хезмәт, дин-иман, төпле акыл белән тормыш иткән, авыл картлары арасында абруй казанган Габделкадыйр карт, өйләнергә җыенган ир-егетләр үтенече буенча еш кына алар күзләгән кыз-кыркын йортына башкода, яучы-димче булып та йөри. Ыспай гына киенеп, ничек сөйләшергә кирәклеген алдан ук уйлап, үз дәрәҗәсен белеп, шулай ук Палта Нурисламның да авылда кем икәнлеген истә тотып, итагать белән ишек шакып барып керде. Өйдә Фәрхинур үзе генә иде. Нурислам һәрвакыттагыча үз эше белән чыгып киткән иде. Башта утырып дога кылдылар. Өч кыз үстереп, берсен инде кияүгә дә биргән, бу эштә азмы-күпме тәҗрибәсе дә булган Фәрхинур чамалады: Габделкадыйр карт тикмәгә генә йөрмәс.

— Фәрхинур кызым, мин бит әле бик зур үтенеч белән килдем үзегезгә, — дип башлады сүзен Габделкадыйр карт, пөхтә, түгәрәк сакалын сыпырып. — Бик җаваплы йомыш. Күршем Зиннәтулланың улы Минәхмәтне беләсез, авылга бер оста гармунчы. Бик акыллы, булган егет. Сезнең Миңнурны да бик яхшы беләм: сокланып туймаслык кыз. Андый да гүзәл затны үстергәнегез, тәрбия кылганыгыз өчен, Ходай үзегезгә мең-мең мәрхәмәтле булсын! Инде, Фәрхинур кызым, тел төбемне аңлагансыңдыр. Кыз да, егет тә бүгенге көндә бер-берсе турында уйлап яшиләр. Мин, улларының үтенече буенча, күршем Зиннәтулла, аның хәләл җефете Маһиҗамал исеменнән башкода булып килдем. Белүемчә, кызың Миңнур да Минәхмәткә хатынлыкка барырга риза. Аллага тапшырыйкмы әллә? Кавыштырыйк ике яшь йөрәкне, пар күгәрчен булып яшәрләр, иншалла. Уңай җавабыгызны көтәм, — диде дә яучы тынып калды.

Фәрхинур: «Бу картка ничек итеп әйтергә инде?» — дип бераз уйланып утырды. Ләкин югалып кала торган хатыннардан түгел иде ул, җавапны тиз тапты:

— Габделкадыйр абзый! Син инде безгә бер башкода килеп киткәнен беләсең. Әле аңа да сүзебезне кистереп кенә әйтмәдек, уйланабыз. Шуны гына искәртәм: Нурислам, Миңнурыбызны Мифтахка бирербез, диде. Олы башыңны кече итеп килгәнеңә рәхмәт. Нурислам кайткач та тагын бер кат уртага салып сөйләшербез. Тик үзең беләсең, мин — ир хатыны. Ир хакы бар, ир ничек әйтсә, шулай булыр.

— Шулай да, кызым, тагын бер кат яхшылап уйлагыз әле. Балаларның бер-берсенә тартылуы, яратышулары турында да онытмагыз. Миңнурыгыз да Минәхмәтне үз итә икән. Егет ярамаслык түгел бит. Мифтахка бирсәгез, аның белән кызыгыз бәхетле булырмы соң? Әйе, яхшылап уйлагыз! Ашыкмый-кабаланмый. Ашыккан ашка пешкән, диләр бит...

— Ярар, уйларбыз, Габделкадыйр абзый, — дип, сүзен төгәлләп, Фәрхинур башкоданы сабырлык белән озатып калды. Әмма Габделкадыйр карт чыгып китү белән: — Мин сукыр Зиннәт Мачугына ялчы үстермәдем, — диде, ярсып.

Бу вакытта Миңнур үзе дә өйдә иде.

— И-и, әни, бирегез инде мине Минәхмәткә. Гомерем буе ярдәмемнән ташламам үзегезне. Яратам бит мин аны... — диде дә елап та җибәрде.

Ләкин Фәрхинур кызының ялваруына каршы катгый итеп җавап кайтарды.

— Атаң, Мифтахка бирәбез, диде...

Башкода киткәч, Палта Нурислам да кайтып җитте. Хәләл җефете аңа барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Кызым, ярату өчен, чыннан да, гармунчы кирәктер, ләкин тормыш итәр өчен булдыклы ир кирәк. Анысын әнә анаң яхшы белә, — диде ул Миңнурга. Бераздан, тынычлана төшеп, сүзен дәвам итте: — Тыңла әле, кызым, син акыллы бала, үзең уйлап кара. Без дә бит сиңа начарлык теләмибез, булдыклы, акыллы ир белән яхшы, таза тормышта яшәсен, дибез.

— Белмим бит мин Мифтах абзыйны...

— Яши башлагач белерсең дә, яратырсың да. Без дә анаң белән яратышып өйләнешмәдек...

Күпне күргән, тормыш тәҗрибәсе туплаган Палта Нурислам кызының киләчәге, бәхете турында бер генә төн уйламады, әлбәттә. Балачагы Казанда үткән, эшкә өйрәнеп үсмәгән, авылда яшәү рәтен белмәгән Зиннәт малаеннан рәт чыкмас, атасы да әнә тавык та суйган кеше түгел...

* * *

Миңнур, сызланып-моңланып, бүлмәсенә кереп китте. Тегәсе әйберләре җитәрлек булса да, эшкә тотынасы килмәде — күңеле төшкән, кәефе юк, һәрнәрсәгә дәрте сүнгән иде. Кинәт кенә кызлар белән элек җырлаган моңсу җырлар исенә төште дә шуларны көйләп алды:

Кызыл төлке — кыр күрке,
Кыз балакай — өй күрке;
Кыз бала ул бик бәхетсез,
Юк бит аның үз күрке.

Җитеннәр чәчтем тигезгә,
Алып китте диңгезгә;
Әткәй, бирәсез тиңсезгә,
Гомер елармын сезгә...

* * *

Миңнурның Мифтахка чыгарга теләмәве, көн-төн борчылуы, елап чыгуы, ата-анасына ялваруы турында да халыкка ишетелеп торды. Бу хәбәргә Мифтахның абыйсы Имам да бик борчылды. Әле үзе дә берничә ел элек кенә өйләнеп, бик матур тормыш башлаган бу зирәк акыллы, төпле ир энесенең сайлаганын хупламады, аның Миңнурга өйләнү уеннан кире кайтуын сорады:

— Дөрес эшләмисең, энем. Кешегә дигәнне алма, уңмассың! Өйләнү — җаваплы, зур эш ул. Мондый вакыйга шатлык, бәхет белән өртелгән булырга тиеш. Ә монда күз яше... Күз яше төшми калмый, белеп тор шуны!

Ләкин Мифтахның хәле абыйсының акыллы киңәшен тыңлаудан үткән, аның ташы кызган иде:

— Зиннәт малае гына түгел, мин дә бик яратам, миңа да бик ошый ул кыз. Вакыт үтәр, онытыр. Гөрләтеп яшәп китәрбез әле менә...

— Мин үземнең эчемдәген әйттем. Гөлсем белән без, үзең беләсең, Хәлил белән Галиябану кебек үк булмасак та, бер-беребезне яратып өйләнештек. Кияү белән кыз арасында баштан ук аңлашу булырга тиеш. Юк икән, димәк, мондый тормыш баштан ук бәхетсезлеккә корылган дип сана...

Мифтах бераз уйланып утырды, ләкин барыбер үзенекен әйтте:

— Соң инде, абзый. Тегермәннең ташы җибәрелде, бөртек кенә саласы калды...

* * *

Габделкадыйр карт яхшы хәбәр алып кайта алмагач, Минәхмәтнең өмете өзелде. Егет, зур ызбаның бер бүлмәсенә бикләнеп, башта үксеп-үксеп елады, аннары, гармунын алып, моңлы-сагышлы җырлар җырлады, тик башка берни эшли алмады.

— Ярар, улым, бетеренмә әле, бу дөньяда Палта Миңнуры гына димәгән, сиңа да насыйбы табылыр, — диде Маһиҗамал абыстай, улын юатып, гәрчә үзе дә уңган-булган, акыллы, сылуларның сылуы Миңнурны үзенең килене булуын бик теләсә дә. — Нишлисең бит, насыйп булмагач...

Ә бу кичне, Миңнурны ирексезләп, аның ай-ваена карамыйча, кияүне бикәч янына, чыбылдыкка керттеләр. Шунда алар дүрт көн бергә булдылар. Дүрт көн буена яратмаган кешесе — булачак ире белән тарткалашып, кияү ирегенә буйсынырга теләмичә, җаны-тәне тартмыйча көн-төн үткәрде Миңнур. Бишенче көнне кичке якта Мифтах өенә кайтып китте — аның арчига, туй төшерергә әзерләнәсе бар иде. Дүрт көн буе беркая да чыкмаган Миңнур да, караңгы төшкәч, көянтә-чиләк асып, кизләүгә суга төшеп китте. Саф һава сулап, күңелен баскан авыр уйларны таратып, дөнья күреп кайтасы килде аның. Ашыкмыйча гына барды, чиләкләренә су алды, ашыкмыйча гына кайтырга чыкты. Кисәк кенә Минәхмәтне күрәсе, аның белән сөйләшеп аласы килде аның. Күңеле гел аңа тартылды...

Йа Хода, бар икән күрәселәр: үзләренең урамына борылган җирдә аны берьялгызы Минәхмәт көтеп тора иде. Бу очрашудан алар икесе дә бик дулкынланып киттеләр, сөйләшергә сүз таба алмый азапландылар. Вакыты да бик кыска бит аның. Карлар эреп барган апрель киче караңгы булса да, кеше күрүе бар. Ишеттерсәләр, инде бикәчкә кергән кияү егете ни дияр?

Ләкин Минәхмәт бүген тәвәккәл иде. Ул, озын-озак уйламыйча, тальянын тартып җибәрде һәм җыр башлады:

Пәкеләремне бирмәдем,
Лимон кисмәссең диеп;
Исәпләмичә дә йөрдем,
Быел китмәссең диеп.

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Кемнәргә калдырасың?
Бәгърем, гыйшык утларында
Ник мине яндырасың?..

— Җибәр, Минәхмәт җаным, тоткарлама, яхшы түгел. Кеше күрсә нишләрбез? Соң инде, барысы да соң, — диде Миңнур һәм, өзгәләнеп, өенә таба атлады.

Минәхмәт исә кайчандыр Миңнур бүләк итеп биргән чиккән кулъяулыгы белән яшьле күзләрен сөртеп калды...

Шулай да аның бүгенге тәвәккәллеге Миңнурны таң калдырды. «Элегрәк шулай батыр, ирекле, тәвәккәл булсаң икән, Минәхмәт җаным! Өйгә килеп, мине алып киткән булсаң, сиңа ияреп дөнья читенә барырга да риза идем бит мин. Ә син югалып калдың, беренче сынауда ук җебеп төштең. Әнә Мифтахны кара, нәсел үгезе кебек, киртәләрне сындырып килеп керде. Аның кебек әрсез буласы иде сиңа да...»

Миңнурның, чиләк-көянтә асып судан кайтканда, башыннан әнә шундый уйлар үтте. Ләкин, сөйгән егетенә аз-маз үпкәсе булса да, күңел түрендә аңа карата булган якты, саф хисләре әле суынырга өлгермәгән, һаман элеккечә саклана иде.

* * *

Язмыштан узмыш юк. Ихтыяры сындырылган Миңнур да, кеше арасында ким-хур булмыйм дип, туйга, арчига кешечә әзерләнде.

Күз яшьләренә тыгылып җырлый-җырлый, алсу сатиннан ун балитәкле матур күлмәк, тагын нәрсәләрдер текте.

Биек-биек ызбада
Тегү тегә кыз бала;
Киләчәк көннәрне уйлап,
Йөрәккәем сызлана.

Шушма елгасы суында
Биткәемне юдым мин;
Үзем — былбыл, чәчем — чылбыр,
Ник бәхетсез булдым мин?

Һич күрмәгән-белмәгән, яратмаган кешегә кияүгә чыгармын (дөресе — бирерләр!) дигән уй аның башына да килеп карамаган иде. Тормышта әле мондый хәлләр дә була бит. Зөбәрҗәттәй зәңгәрсу күзле, түгәрәк матур йөзле, Борһан күлендәге камыш кебек зифа буйлы, нечкә билле, үзенә уналты гына яшь булса да, алсу алма кебек өлгергән кызның игътибарына лаек булырга тырышып караган егетләр авылда бер генә түгел иде бит югыйсә. Шуларның кайсыбер ишләре арасында Миңнурга ошардайлары да бар иде. Ә менә Минәхмәт...

«Ах, яраткан егетемә чыга алмадым...» Бу уй аңа иртән дә, кичен дә тынгылык бирмәде.

Арчи ыгы-зыгысы берничә көнгә сузылды. Аннан соң елап-сыктап озатулар, кемнеңдер тальян шыңшытуы, тарантаска җигелгән бизәүле күк атларның көйсезләнеп тыпырчынуы, дугадагы җиз кыңгырауның хәсрәт тавышы белән чыңлавы, туй төшү... Әйе, туй төшкәндә һич уйламаган, һичкем көтмәгән вакыйга булып алды. Җигүле тарантас белән кияү йортына кайтып җитәргә барлыгы илле-алтмыш адым калган иде. Сукыр Сәхап, Таз Нуркайлар йорты аша үтәсе дә, уңга борылып, Мифтах йорты турысына барып туктыйсы. Юк икән шул әле! Атларны салмак кына йөгертеп кайткан бер мәлдә, әнә шул Сукыр Сәхаплар турысын үтеп барганда, кинәт тарантасның арткы уң як тәгәрмәче, күчәреннән чыгып, бер якка тәгәрәп китте. Тарантас кыйшайды, анда утырып кайткан кияү белән кәләш, кияү егете һәм башкалар чак кына егылып төшми калдылар. Арчи кайтканын карап торган авыл халкы аһ итте:

— Әстәгъфирулла!

— И-и Ходаем, ахыры гына хәерле булсын!..

— Күрәселәре бар икән әле мескенкәйләрнең...

Арчины озата килгән егетләр, арбадан сикереп төшеп, тәгәрмәчне күчәренә кую хәстәрен күрделәр.

Кемдер:

— Моның чәкүшкәсе төшеп калган бит, чәкүшкә кирәк, — диде.

Кайсыдыр чыбык кисәге табып китерде.

Миңнурның болай да телгәләнеп беткән йөрәген шом катыш курку алды: «Ирексезләп кияүгә бирүләре хәерлегә булмас микәнни?» — дип көенде ул эчтән генә. Миңнур җыелган халык арасында аягына шахтер башмаклары киеп басып торган Бүсер Хатыйп Минәхмәтенең: «Ах, парин, алманың асылын аю ашый. Ә кызы, кызы!.. Бигрәк җәл», — дигән сүзләрен ишетеп алды. Ә Мифтах, бу сүзләрне ишетмәмешкә салышып:

— Тизрәк маташыгыз, егетләр, — дип кычкырды. Шунда гына арчи теләр-теләмәс яңадан кузгалды.

Җыелган халык, бу хәлгә борчылып, пошаманга калып, аны хәвеф-хәтәргә юрап таралды.

Туй төшкәндә күчәреннән чыккан тәгәрмәч вакыйгасы вакытлар үткәч тә бик озак авыл кешеләре теленнән төшмәде.

* * *

Бер казанга ике тәкә башы сыймый. Дүртпочмаклы бәләкәй генә өйдә ике ир туган, ике килендәш, олы туганның ике баласы яши. Дөрес, Имам белән Мифтах, күз тимәсен, өем тар булса да, күңелем киң дип, дустанә аңлашып, ярдәмләшеп яшиләр. Начар гадәтләре юк. Авылда урыс аракысына бирелүчеләр арта бара, ә ике туган аның барлыгын да белмиләр. Икесе дә тыныч холыклы, киләчәккә планнары да бар. Иң тәүгесе — Мифтахка йорт җиткерү, аларның үз куышларын булдыру. Көннәр җылытып, язгы кыр эшләре төгәлләнгәч, һәм Сабан туйлары узгач та, урманда диләнке алып, йорт салырлык бүрәнә әзерләргә һәм көзгә чаклы бураны бурап, такта ярып, башка эшләрне дә планлаштырып куярга кирәк. Өй салуның ние бар — бурасы да чутласы... Шаярып кына әйтелгән бу сүзләр артында тирән мәгънә ятканын һәркем белә: алда әле никадәр күп тырышлык, көч куясы бар ике туганның. Ләкин алар аңа артык пошынмыйлар: Ходай сәламәтлекне бирсен дә, дөньялар тыныч булсын. Мал табыла ул! Икесенең дә кендеге җиргә береккән, тырышлыклары җитәрлек. Имам, үзен дә, энесен дә дәртләндереп: «Салырбыз. Авылда бер матур ызба салып куярбыз, энем, Алла теләсә. Кайгырма! — дип, бер генә әйтмәде инде. — Быел өлгертеп булмас-булуын, аның өчен, үзең беләсең, бик күп тырышлык кирәк. Ә менә киләсе елга өлгертергә мөмкин, моның өчен бик нык эшләргә кирәк...»

Әйе, ике туганның дуслыгына сокланып туймаслык. Моның сәбәбе дә бар. Аналары Гыйльминур абыстай: «Улларым, бер-берегезне ташламагыз, дус, терәк булып, ярдәм итешеп яшәгез, кеше арасында ким-хур булмагыз — минем сезгә соңгы сүзем шул», — диде үләр алдыннан.

Гыйльминур абыстайның фаҗигасе балаларын һәм якыннарын гына түгел, барлык авыл халкын тетрәндерде. Бик иртә үлеп киткән ире Мәсләхеннән тол калгач, үсеп килгән балаларның кайгыртучан аналары, киңәшче-уңашчысы дөнья мәшәкатен җигелеп тартучы да. Әле иллесен дә тутырмаган хатын гел эш белән мәшгуль булып барысына да җитешә иде.

Сентябрьнең ахырлары иде бугай, һәрхәлдә бакчадан бәрәңгеләрне алганнар иде. Мифтах төнлә генә Шонталыдан колхоз тракторлары өчен керосин алып кайтты. Тартып-йолкып яшәргә гадәтләнгән Гыйльминур абыстайның да үз башына бәла алуы булгандыр — малае йоклап яткан арада, таң тишеге белән чыгып, арбадагы мичкәне ачты һәм ярты чиләк керосин агызып алды. Хәзер керосинны почмакта әзерләп куйган шешәләргә тутырасы гына калды. Өйгә кереп, почмакка үтте. Анда әле караңгы иде, җиделе лампаны кабызып җибәрде. Лампага керосин салганда, кинәт шешәсе авып китте дә, хатынның күлмәк чабуына керосин түгелде, һәм ягулык салырга дип кыегайтып куйган лампа филтәсеннән күлмәккә гөлт итеп ут капты. Әнисе кычкырып җибәргән тавышка изрәп йоклап яткан Мифтах сикереп торды да, су дип уйлап, чиләктәге керосинны анасының өстенә тондырды. Гыйльминур абыстай бер мизгелдә утлы факелга әйләнде һәм, ачыргаланып, тышка, аннан бакчага ташланды. Ә бу вакытта Мифтах дөрләп яна башлаган өйне сүндерә башлады.

Күрше Сәхап фермадан ат алып кайтканда, Гыйльминур абыстай, җирдә ауный-ауный, өстендәге утын сүндереп маташа иде.

— Йа Ходa! Гыйльминур абыстай, нәрсә булды, нишләдең? — дип исе китеп сорады Сәхап. — Ярдәм кирәк түгелме?

— Яндым, Сәхабетдин, яндым. Үз башыма тотындым шул красинга, үз башыма, — диде дә, янып телгәләнгән күлмәк калдыкларын сөйрәп, кара янып беткән хатын, ыңгыраша-ыңгыраша, өенә кереп китте.

Бу фаҗига ике туганга нык тәэсир итте. Анасының үлемендә Мифтах үзен гаепләде.

— Мин, мин генә гаепле, кичер, әни, — дип үкседе ул үлем түшәге өстендә яткан анасына.

— Юк, улым, син түгел, үзем гаепле, үзем. Синең мыскал да гаебең юк, — диде ана соңгы минутларында.

Гыйльминур абыстай кичкә таба җан бирде. Икенче көнне аны бөтен авыл халкы җыелып соңгы юлга озатты.

Имам да Мифтахны тынычландырды: «Син гаепсез, синең урыныңда мин дә шулай эшләр идем», — диде.

Аналары белән булган хәл аларны бер-берсенә тагын да якынайтты.

Ә менә ике килендәш арасында беренче көннәрдән үк низаг килеп чыкты. Яшь килен аяк баскан көнне үк туды ул киеренкелек. Миңнур килеп урнашырга да өлгермәде, Өммегөлсем, баш булып, төксе генә:

— Әпәй сал! — дип әмер бирде.

Миңнур аптырап китте. Имәндә икән чикләвек — бик усал икән бит өйдәш-килендәш. Аптырарсың да... Миңнурның, авыл кызы булса да, ипи салганы юк иде, ул үзе дә анасы салганы гына ашап үсте.

Нишләргә? Шөкер, кызның коелып төшә торган гадәте юк — башлылыгы да, зирәклеге дә бар. Тиз генә җыенды да бакча аша гына анасы янына йөгерде.

— Миңа ипи салырга куштылар, әни, аны ничек салалар? — диде килеп кергәч тә.

Фәрхинурны бу хәл каушатып җибәрде: «Син дә үзеңне кызлар тәрбияләп үстергән ана итеп саныйсың инде, әпәй салырга да өйрәтмәгәч...» — дип, эчтән генә үзен үзе битәрләп алды.

— Соң, кызым, син бит авылда бер булган һөнәр иясе. Балачактан тегү эше белән җенләнгәч, шуның белән шөгыльләнгәч, мин аш-су әзерләү, өй җыештыру, бакчада казыну, камыр пешерү кебек эшләр белән вакытыңны алмадым синең, тегә икән тексен, дидем. Мин гаепле инде аңа.

— Әнкәем, кем гаепли сине? Син түгел, мин үзем гаепле. Иртәме-соңмы, андый эшләргә өйрәнергә кирәк. Менә килдем — өйрәт, әле соң түгел, тормышымның башы гына...

Анасыннан ипи пешерергә өйрәнеп кайткач та, Миңнур камыр басты, кунасын мич башына куйды. Шөкер, ипи уңды, калачтан ким булмады. Тик бер генә кимчелеге соңыннан беленде: Миңнур аңа тоз салырга онытткан булып чыкты. Гөлсем бу вакыйганы күпертеп бирергә тырышты:

— Әнә уңган киленеңнең әпәен ашап кара! — дип, Имам каршына китереп куйды әле яңа гына мичтән чыккан ипине.

Имам кискән икмәкне сындырып авызына капты, чәйни башлады һәм аның тозы юк икәнлегенә төшенде. Мифтах та авыз итте, кызарып китте, ләкин эндәшмәде. Ә Имам, хатынына күзенең агы белән карап:

— Бик ашыйсың килсә, тоз сибеп ашарсың, — диде катгый итеп. Аннары Миңнурга: — Рәхмәт, килен, уңдыргансың ипиеңне. Килендәшеңнән дә уздыргансың. Киләчәктә тоз салырга онытмасаң, тәмле ипи ашаячакбыз икән әле, борчылма юкка, — диде. Каенагасының изге күңелле кеше булуы турында ул элек тә ишетеп белә иде, хәзер исә үз күзләре белән күрде.

Шулай да яратмаган иргә, яңа гаиләгә ияләшү яшь киленгә җиңел булмады. Озак вакыт ул никахлы иргә «Мифтах абзый» дип эндәшеп йөрде. Югыйсә сирәк тә эндәшә ул аңа. Мифтах исә моңсу гына, әмма мәгънәле итеп хатынына карап тора. Озак карап тора ул аңа, тик эндәшми, үзе бер аңлар әле дип уйлый бугай.

Беркөнне шулай Мифтах урамдагы бүрәнәләр өстендә күрше ир-атлары белән сөйләшеп утыра иде. Өйдә ашарга әзерләнгән булган, күрәмсең, яшь килен чыкты да:

— Мифтах абзый, ашарга кер, — дип, ирен өйгә дәште.

Мифтах күршеләре янында уңайсызланып, кызарып китте. Хәзер керәм, Миңнур абыстай, дип, шаяртуга гына борып җибәрергә дә бит, әмма яшь шул әле, тәҗрибәсе җитми. Күрше ир-атлар исә, Мифтахны чеметтереп алып: «Бар, бар, «Мифтах абзый», ашың суына», — дип, абзый сүзенә аерым басым ясап, төрттереп алдылар.

— Син мине уңайсыз хәлгә калдырма инде, Миңнур, ничектер башкача эндәшергә тырыш, — диде Мифтах өйгә кергәч, йомшак кына битәрләп.

Тик Миңнур аның бу кисәтүләрен әллә онытты, әллә аңа алай игътибар итмәде — «Мифтах абзый» дип эндәшүен дәвам итте.

* * *

Шулай тыныч кына биш атна вакыт үтте. Әйе, биш атна вакыт калган булган сугыш башланырга, дөньяның астын өскә китерергә, изге хыялларны җимерергә, тыныч тормыш иткән, ачлы-туклы көн күргән халыкның бүгенгесен дә, киләчәген дә кара язмыш кочагына ташларга...

Тагын ике атна вакыт борчылып, янып-көеп, китәр көнне санап үтте. Сигезенче июльдә Мифтах бер төркем авылдашлары белән сугышка чыгып китте.

— Мин монда яши алмам, син миңа атам-анам янына кайтып яшәргә рөхсәт ит инде үзең кайтканчы, — диде Миңнур, Мифтахны озатканда.

— Әйе, әйе, кайтып тор, шулай дөрес булыр, — диде Мифтах та. Үзе алай җайсыз, киребеткән, усал кеше түгел. Тыныч холыклы, гел кайгыртып, җайлы гына сөйләшеп, хәлен сорашып, киңәш итешеп тора. — Син, Миңнур, борчылма! Без синең белән бик матур яшәрбез әле. Яңа йорт торгызырбыз, мал-туар асрарбыз. Син миңа малайлар, кызлар табып бирерсең. Аларны бергә үстерербез, укытырбыз. Мин бит сине бик яратам. Күрерсең: мин сине һич кимсетмәм, кул тидермәм, сөеп кенә торырмын, — дип кенә тора да бит.

Миңнур никахлы ирен ярата алмагач нишләсең соң?!

* * *

Анасы кызының өйләренә кайтуына шатланды гына. Йорт эшләрендә аңа булышырга кеше дә калмаган, кече кызы Минхәяткә әле ундүрт тә тулмаган. Инде тормышка чыгып, ирен сугышка озатып, аерылу-каерылу сагышларын татыган, кайгылардан басынкыланып киткән, еш кына уйланып йөри баш-

лаган кызының үз яннарына кайтуы, кабат алар белән бергә яшәве Палта Нурисламның үзе өчен дә, Фәрхинуры өчен дә, зур шатлык булмаса да, күңел тынычлыгы бирә иде: «Үз канатыбыз астында, зур афәт — сугыш барган вакытта бар авырлыкларны, кайгы-хәсрәтне бергә-бергә күтәрү җиңелрәк булыр...»

Иң яшь, иң һиммәтле ир-егетләрне, «РККА» категориясен алган иң көчле, көтү-көтү атларны фронтка озаткач, авыл бушап, шып-шыр булып калды. Колхоз эше хатын-кыз, малай-шалай, карт-коры җилкәсенә төште. Миңнур да хәзер һәр көн, иртәдән алып кичкә кадәр, басуда йә булмаса ындыр табагында булды. Иген өлгергәч, уракка төштеләр. Авыр тимер ургыч машиналарга җигәргә атлар калмагач, арышын да, бодаен һәм башка бөртекле культураларны урак белән урырга керештеләр. Ә урак өсте — авылда эшнең иң тыгыз, кызу чагы ул. Башкалардан бераз калку, инде ныгып килгән Палта Миңнуры урагын да урды, көлтә дә куйды, аны ындырга да ташыды, сугуда да катнашты, салам да өйде.

Илдә сугыш барганда, тормыш нык үзгәрде. Шатлыклы көннәр, күңел күтәренкелеге юкка чыкты. Кешеләрнең тирән хәсрәт эчендә уйларга бирелеп киткән чаклары. Аларның бар белгәне — тырышып эшләү. Эш арасында хатын-кызның телендә гел сугыш булды. Башта халык арасында: «Кызыл Армия көчле, аңа немецлар гына каршы тора алмас, алар үз башларына башладылар сугышны, безнекеләр ике-өч атнада акылга утыртырлар килешүне бозып кергән дошманны», — дигән ышанычлы сүзләр йөрде. Ләкин көн артыннан көн, атна артыннан атна уза торды, ә Германия гаскәрләре, кала-салаларны җимерә-җимерә, илнең үзәгенә таба үтеп керә торды. Мондый хәл барысының да күңеленә шом салды. Бу хәл Миңнурны да уйландыра-шомландыра иде.

Хатыннар сугышка чыгып киткән ирләреннән, туганнарыннан хатлар да ала башладылар. Кайсының хаты юлдан, кайсының инде фронттан килеп төшә.

Беркөнне кич белән почтальон Миңнурга да өч почмаклы бәләкәй генә хат биреп китте. Яшь хатынның гомерендә тәүге тапкыр хат алуы иде бу. Моңа кадәр аның үзенең әле кемгә булса да хат язганы булмады, җавап та алганы юк иде. Бу хәл беразга булса да күңелен күтәреп җибәрде. Ашыгып хатны ачты һәм укый башлады. Бу хат Мифтахтан иде.

*«Сагынычлы хат башы, яз каршы!*

*Бу дөньяда минем өчен иң кадерле кешем булган газиз хатыным Миңнур! Сиңа ашыгып чапкан эшелонда баручы ирең Мифтахтан кайнар сәлам! Шулай ук бабай белән әбигә, Минхәяткә, мине сораган күрше-күләнгә, туганнарга сәлам тапшырырсыз. Вакыт тар, кыска гына үзем турында: Казанда озак тормадык, безне — кадровый армиядә хезмәт иткәннәрне — ашыгыч рәвештә фронтка озаттылар. Юлыбыз — көнбатышка таба. Башта төрле уйлар гизә, Миңнур, күңел дә тыныч түгел. Сине дә сагынырга өлгердем, тик кайчан кайтулары билгесез. Дөресен әйтим: алда шундый язмыш көтәсен мин күптән белдем. Минем кебек армия хезмәтендә булганнарның күбесе сизенә иде сугыш буласын. Шуңа да бит мин, тизрәк кайтып, өйләнеп калуны хуп күрдем. Дөрес, минем элек авылда күзем төшеп йөргән кызым булмады — син аны яхшы беләсең. Ә менә кайткач сине күрдем дә, исем-акылым китте, гашыйк булдым. Ләкин син мине кичер: синең артыңнан йөрергә, ышанычыңны акларга минем вакытым калмаган иде — өйләнүне башкода белән генә хәл итәргә уйладым. Билгеле инде, син моңа риза булмадың... Моның өчен мин синең каршыңда үземне чын-чынлап гаепле саныйм, ләкин ул вакытта башка чарам юк иде. Иң мөһиме: мин бит сине бик яраттым, бүген дә яратам, Ходай гомерләремне биргән булса, киләчәктә дә бик-бик яратып яшәрмен. Бу дөньяда син минем өчен бердәнбер — шуны онытма!.. Тизрәк дошманны җиңеп, кайтып керүләр насыйп булсын! Яшисе иде әле, гөрләтеп бер яшисе иде...»*

Үз исеменә назлы ярату хисе белән язылган хатны укыганнан соң, Миңнурның күңеле тулып китте. Өйләнгән вакытта Мифтахның өсте-өстенә: «Мин сине яратам бит», — дигән сүзләренә әллә ни исе дә китми иде Миңнурның, ә менә бу хатны укып чыкканнан соң, аның күңел түренә нindидер бер өмет, тынычлану хисе кереп урнашты. Җылы итеп язылган хат та җанга үзгәреш кертә ала икән бит...

Миңнур барысы турында да уйлый, башы аның һәрвакыт уйда. Мифтах сугышка чыгып китте, ә Минәхмәт әле авылда. Ләкин теге апрель кичендә судан кайтканда очрашканнан соң, аларның юллары әле бер генә мәртәбә дә кисешкәннәре юк. Бер авылда яшәп тә очрашма инде! Әллә Минәхмәт үпкәләдеме аңа? Ә нигә соң әле үпкәләргә тиеш ул? Миңнурның нинди гаебе бар аның каршында? Үз язмышын, сөйгән кызы язмышын хәл итәргә кирәк булган җитди көннәрдә җебеп төшкән, бүлмәсендә гармунына багып утырган кеше үзе гаепле була түгелме соң? Беренче сынауда ук сыгылып төшеп, егетлеген исбат итә алмаган кеше белән бу катлаулы тормыш юлын иңгә-иң торып үтә алырлар иде микән соң? Бәлки, үзе теләмәсә дә, Миңнурның, ата-ана иркенә буйсынып, Мифтахка чыгуы дөрес тә булгандыр?!

Мифтах әнә үз-үзенә нык ышанган, бәйсез, үз эшен алдан ук планлаштырып уйлап башкара торган ир. Авыр вакытларда тормышта да аңа таянып яшәү мөмкин булачак. Сугыштан гына исән-имин әйләнеп кайтсын. Аның өйләнгәч тә: «Син, Миңнур, борчылма! Без синең белән бик матур яшәрбез әле. Яңа йорт торгызырбыз, мал-туар асрарбыз. Син миңа малайлар, кызлар табып бирерсең. Аларны бергә үстерербез, укытырбыз...» — дигән сүзләре бүген дә Миңнурның колак төбендә.

Юк, юк! Миңнур Минәхмәт турында, ничек кенә ул исенә төшмәсен, уйламаска тырыша. Никахлы хатынның тормышка чыкканчы яратып йөргән егете турында уйлавы да ярый торган эш түгел бит. Нишлисең соң инде язмышның шулай булгач? Өлешенә тигән көмеше Мифтах булды аның, Минәхмәт түгел. Хәзер инде ул Мифтахы турында гына уйларга, аның турында гына кайгыртырга тиеш. Инде Ходай гомер биреп, аңа Мифтахы белән яшәү насыйп иткән икән, бәлки әле, аны чын-чынлап яратып та куяр. Бер мәхәббәт бетә, икенчесе килә, дигәннәр бит борынгылар.

* * *

Көз җитте. Көннәр салкынайтып, туңдырып җибәрде, ләкин колхозда әле эш бетмәде. Хатыннар ашлык җилгәрделәр, фронтка дип икмәк әзерләделәр.

Мифтахтан хатлар килә торды: «Сугышабыз, ләкин дошман көчле булып чыкты. Чигенә-чигенә сугышабыз», — дип язды бер хатында. Аннары декабрь ахырында, һич көтмәгәндә, үзе кайтып төште. Уң кулының беләзеге яраланып, госпитальгә эләккән булган икән. Төзәлгәнче дип, өенә кайтарырга булганнар.

Аерылышып торган дүрт ай ярым вакыт эчендә тәмуг утыннан кайткан Мифтахны танырлык та түгел иде. Ул бик ябыккан, каралган, күзләре эчкә баткан, үзе кырысланган, уйчанланган. Шул ук вакытта хатынын бик нык сагынган иде.

— Сине бик ятратканга, өзелеп сагынганга Ходай минем җанымны саклагандыр, сине кайтып күрергә насыйп иткәндер. Ә анда... Анда мәхшәр, Миңнур, тәмуг мәхшәре. Көне-көне белән, бигрәк тә каты бәрелешләрдән соң, ничек исән калуыма гаҗәпләнеп куя идем. Әгәр кабат кайталмасам... Кабат кайталмасам... Көчләп өйләндем бит мин сиңа, зинһар, бәхилләрсең инде...

Миңнур үзе дә ирен юксына башлаган иде. Яраланып, сугыш михнәтен кичеп, бөтенләй үзгәреп кайткан тормыш иптәшенә карата мөнәсәбәте кинәт үзгәрде, күңеле йомшарды, бар игътибарын аның турында кайгыртуга юнәлтте. Ир хакы — Тәңре хакы. Көн саен су җылытып, булган дарулар белән аның ярасын юып, дәвалап торды ул. Тәмле-тәмле аш-су әзерләде. Шөкер, ул вакытта Нурислам йортында ризыкка кытлык юк иде.

Уйламаганда, шушы бергә булган көннәр Мифтах белән Миңнурны якынайттылар. Өйләнешкәч тә рәхәт көннәр күрергә насыйп булмаган яшь ир белән хатын тормышында яңа чор башланды бугай. Яу кырының ачы газапларын үз җилкәсендә татып кайткан Мифтах бертуктаусыз күргәннәрен сөйләде. Элек ул бик сөйләшми торган иде, ә хәзер, ни гаҗәп, уйлана да сөйли, уйлана да сөйли, әйтерсең лә теле ачылган бала.

— Миңнур, беләсеңме... Беләсеңме, мин бит сугышка барып кермәс борын ук бетә яздым!

«Бетә яздым» дигән сүзне ул ничектер тупас итеп, ачу белән әйтте сыман.

— Ә ничек?

— Сөйлимме соң?

— Нишләп сөйләмисең ди инде, сөйлә, билгеле.

Мифтах хатынына эчкә баткан, моңсуланып киткән күзләрен текәде.

— Сөйлә, мин тыңлыйм, — диде Миңнур һәм ниндидер якынлык белән иренең кыска чәчләреннән сыйпап алды.

— Мин сиңа Смоленск турында әйткән идем инде. Безнең Казанда оешкан полкны шуның тирәсенә илтеп ташладылар бит. Анда... Анда, Миңнур, коточкыч хәлләр иде ул көннәрне. Кыскасы, безне тәмуг утына илтеп керттеләр. Шулай... эшелон көнбатышка үрмәли. Башта хәвеф-хәтәрсез генә бардык. Эшелон еш кына туктап тора башлады. Беркөнне иртәнге якта ачык вагон ишекләреннән күреп аһ иттек: тимер юлның ике ягыннан безгә каршы, ягъни кире юнәлештә качаклар ташкыны агыла. Башы-ахыры күренмәгән җигүле арбалар, җәяүле халык: картлар, карчыклар, хатын-кыз, бала-чага. Кайсылары бәләкәй арба тартып бара, аркаларында биштәр, кулларында төрле зурлыктагы төенчекләр. Көтүе белән мал-туар куып киләләр — сыерлар, бозаулар, кәҗә-сарыклар, чиный-чиный төрле якка чабучы дуңгызлар. Иң кызганычы: аналары, әбиләре белән бергә атлаучы дүрт-биш яшьлек балалар. Алар да төенчек белән. Йөрәк өзгеч күренеш, кызганып үләрсең, Миңнур...

— И-и Ходаем, кая баралар соң алар?

— Соң, кая булсын инде: бераз тынычрак урынга качалар. Кая барып җитәселәрен алар үзләре дә белмиләр, мескеннәр. Бөтен максатлары — сугыш җиреннән еракграк качу, исән-сау калу, һәрберсендә җан асрау кайгысы.

Качаклар ташкыныннан ерак та китмәдек, безнең өстән берничә дошман самолеты очып үтте. Алар эшелон өстендә әйләнә башлаганнар иде дә, ачык платформага урнаштырылган ике зенит пулеметы тегеләргә ут ачты. Тиз шылдылар, каһәрләр, ут астыннан. Самолетлар көнчыгышка таба очып киттеләр. Бераздан без ул якта бомбалар шартлаганын ишеттек — фашистлар, уйлавыбызча, качакларны бомбага тоттылар. Менә шундыйлар алар фашистлар, Миңнур. Аларда бернинди иман әсәре юк. Теге кечкенә

төенчек тоткан бәләкәй балаларның, гомумән, барлык качакларның язмышы ничек булгандыр, белмим. Шуларны күз алдыма китерсәм дә, йөрәккәйләрем сулкылдап куя.

— Мифтах, ә син сугышта немецларның үзләрен күрдеңме соң? — дип сорап куйды Миңнур.

— Бик күп күрдем.

— Аттың дамы?

— Ә нигә атмаска! Аттым.

— Аларга тидеме соң?

Мифтах хатынына карап куйды, бераз уйланып торды. Башта тыныч кына, аннары тукталыш ясап һәм ярсып:

— Мин, Миңнур, кадровый красноармеец — дошман белән кети-кети уйнарга минем хакым юк. Алар әнә бер гаепсез качакларны, шул исәптән әле яңа гына тормышның ямен күрә башлаган сабыйларны да бомбага тоталар. Ә нигә миңа атмаска? Алар кырып-себереп, утка тотып, яндырып-җимереп, җирнең астын өскә әйләндереп киләләр, ә безгә нишләргә? Дошманның арт сабагын укытырга һәм булдыра алган кадәр аны юк итәргә кирәк.

Мифтах беравык уйланып эндәшми торды. Аннан соң, тынычланып, исенә нәрсәдер төшкән сыман, сүзен дәвам итте:

— Мин, Миңнур, сугышның, ул фаҗига-газапларның безнең якларга килеп җитмәвенә эчтән генә куанып та куям. Сугыш изүе астында калган халыкның күргән газаплары, кайгы-хәсрәте дә хәттин ашкан, инде безнең якларга дошманны җибәрмичә, ничек булса да тоткарлыйсы иде. Шуңа бит инде көчтән килгәнчә каршы торабыз.

— Йә, сөйләп бир инде, син бит беренче көнне үк һәлак була яздым, дигән идең...

— Ә, әйе... Фронт сызыгына якынлашкан саен, безнең өстә самолетлар ешрак оча башлады. Үзебезнекеләр түгел инде, дошманныкы. Башта берсе килеп чыга да, разведка ясап, тикшереп китеп бара, Үзәккә хәбәр бирә: фәлән-фәлән җирдә хәрби эшелон күрдек. Анда мондый хәлне күргән-белгән сугышчылар алдан ук кисәтеп куялар: «Егетләр, сак булыгыз, хәзер бомбага тотарга килеп җитүләре мөмкин. Исән калыйм дисәгез, поезд туктауга, аннан ераккарак, мөмкин булса урманга, куаклыкка качарга тырышыгыз...» Тизрәк кич булганны түземсезләнеп көтәсең, караңгы төшә башласа, теләп барасың, чөнки төнлә юлда тынычрак, «каракошлар» өстеңдә очмыйлар. Минем башта иксез-чиксез уйлар гизә: бу сугыш күпмегә сузылыр икән, азагы бер булырмы, исән кала алырбызмы, авылда нинди үзгәрешләр бар?! Син гел искә төшеп торасың, Миңнур. Анда бик сагындыра... Шулай уйлана-уйлана йоклап киткәнмен. Берзаман тормозларның шыгырдавына, вагоннарның бер-берсенә бәрелә-бәрелә туктавына, сиренаның ачы тавышына сискәнеп уянып киттем. Күктә самолет моторлары гүли. Аларның тавышы якынайганнан-якыная бара. Көтүләре белән киләләр. Командирлар әмер бирделәр: «Быстрее покидать вагоны!..» Без ишеккә ташландык. Самолетлардан бомбалар коела башлады. Беләсеңме, Миңнур, бомбалар күктән җиргә чыелдап төшәләр. Җиргә якынайган саен, аларның чыелдавы көчлерәк, куркынычрак яңгырый. Моның кайсысы минем башка төшә инде дип, башыңны тотып чабасың. Кешенең йөрәгенә курку, хәвеф салу өчен, немецлар бомбаны чыелдап төшә торган итеп ясыйлар икән. Әйтәм бит, шул тавышны ишеткәч тә зиһенең тарала, курку билəп ала, кайбер кешеләр бөтенләй югалып кала. Юк, бу сугышны бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Коточкыч!..

Без вагоннан күршем, Шонталы егете Гаяз белән сикереп төштек. Ә якын-тирәдә урман да, куаклар да юк. Кая качарга да белмибез. Шулай да андый вакытта уяу буласың икән. Инде бомбалар сызгырыпчинап төшә башладылар. Мин Гаязны әләктереп алдым да якында гына бердәнбер качып котылу урынына — тимер юл астындагы туннель кебек итеп ясалган корылма астына алып бардым, һәм без шунда яшерендек. Безнең янга тагын берничә кеше атылып килеп җитте. Бәхеткә, бу корылма безнең өчен үлемнән котылу урыны булып чыкты. Шул бәләкәй генә тишектә без унбер кеше сау-сәламәт калдык. Ә башкалар...

Самолетлар китеп барды, бомбалар шартлавы тынды. Без, тонган колакларны уч белән уа-уа, астан чыктык. Ә монда... шатыр-шотыр килеп вагоннар яна, җирнең асты өскә килгән, якын-тирәдә кеше гәүдәләре, аяк-куллар, кан. Яралылар ыңгырашып ята. Кыскасы, мәхшәр... Бер полк, ягъни мең ярым кешедән без барлыгы сиксәнләп кеше исән калган булып чыктык. Аларның да күбесе яралы иде. Ишетәсеңме? Мең ярымнан сиксән кеше... Ә бит әле сугышка кермәдек, анда барып җитәргә дә өлгермәдек. Менә нинди башка да сыйдырып булмый торган коточкыч хәлләр...

Тагын бераз тынып торганнан соң, Мифтах нindидер бер көенеч белән:

— Дошман көчле, Миңнур, мин шуңа инандым, — диде. — Ә безнекеләр мактандылар. Мактанчыкның арты ачык, дип, бер дә юкка гына әйтмиләр шул. Немец самолетлары күктә (безнең күктә!) рәхәтләнеп очып йөриләр, ә безнекеләр... чурт знает кайда — юк алар. Син инде тагын кешегә чыгып сөйләп йөри күрмә, ул эштә сак бул — бездә бит артыгын лыгырдаганны яратмыйлар...

— Юк инде, анысына гына башым җитә, — диде Миңнур, тыныч кына, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Беләм, син акыллы, ялгышлык эшләмәссең... Тегеләрнең танклары ыжгырып килә, ә безнекеләр... Алары да юк. Мин хәзер бик күп нәрсәгә төшендем, кычкырып әйтеп кенә булмый. Финляндияне аркылыга-буйга чыгаргадыр исәпләре. Тот капчыгыңны! Җиңелүдән көчкә котылып калдылар. Ә Маннергейм сызыгында безнекеләрдән күпме кеше кырылды. Монда да шулай. Кырыла безнең халык — солдаты да, качаклар да, сугыш булган җирләрдә калган халык та. Халык кына түгел — авыллар, калалар кырыла, дөрләп яна, җимерелә. Мал-туар, хайваннар кырыла... Коточкыч!

Миңнур иренең сөйләгәндә «коточкыч» дигән сүзне еш кабатлавына игътибар итте. Димәк, анда хәлләр чыннан да кот очарлык.

Ир белән хатын шулай соңгы көнгә кадәр аралашып-аңлашып, туйганчы сөйләшеп, киңәшеп-уңашып яшәделәр. Ләкин көн артыннан көн үтә торды, аерылу сәгатьләре кабат якынлаша башлады. Ярасы төзәлеп беткәч тә, Мифтах Бөгелмәгә, хәрби комиссиягә китеп барды.

— Бәлки әле, комиссиядән соң яңадан кайтып төшү мөмкин булыр, — дип, Мифтах үзенең дә, Миңнурның да йөрәгенә өмет уты салып китеп барды.

Бу кырык икенче елның март башы иде. Язның беренче ае. Кайбер көннәрне кояш ялтырап чыга да, аның җылы нуры түбәдәге карларны эретә, һәм тып-тып тамчы тама башлый. Һавада яз исе аңкый, Мифтах хатынының йөрәгенә салып киткән өмет утына шулай ялкын өсти...

Ләкин Мифтах Бөгелмәдән кире әйләнеп кайтмады. Кеше аркылы: «Мине сугыш кырына җибәрәләр, булдыра алсаң, Шонталыга килеп тор, бәлки, очраша алырбыз», — дип хәбәр җиткерде. Иртә таңнан Нурислам белән Миңнур, атлы чанага утырып, алтмыш чакрымдагы Шонталыга чыгып киттеләр. Соңга кала күрмик дип, әтисе әледән-әле атын дәртләндереп, ашыктырып атлатты. Ниһаять, станциягә дә барып җиттеләр.

— Бөгелмәдән поезд килмәде әле, тоткарлана, — диделәр аларга.

Озак кына көтеп, өшеп, туңып беттеләр, чөнки март башы булса да, салкын, җилле көн иде.

— Әллә, кызым, берәр фатирга кереп, берәр чынаяк чәй эчеп чыгыйкмы? — диде Нурислам карт.

Керергә уйлаган фатир ерак түгел, кул сузымында гына иде. Капкаларын ачып кергәндә, урман артыннан, гудогын кычкырта-кычкырта, поезд килеп туктады. Миңнур белән атасы кабат поездга таба чаптылар. Тик барып җитә алмадылар — ул кузгалып китте. Миңнурның тирләп-пешеп йөгергәнен күргән бер әби, кызганып:

— И балакаем, бер ваянный, минем семья килергә тиеш иде, күрмәдеңме, әби, дип сорады. Сез идегезме әллә?

— Без идек шул...

— И балакаем, күрә алмадыгыз инде. Мин менә көн саен пуезны каршы алырга киләм. Өч баламның берәрсе булса да кайтмасмы дип. Тик кайтмыйлар шул әле, кайтмыйлар, вакытлары юк, сугышулары авыр, ахры, бик авыр...

— Эх, тагын ике-өч минутка гына түзгән булсак... Мин гаепле, кызым, мин чәй эчәргә дип алып киттем сине, — дип уфтанды Нурислам карт һәм бияләе белән яшьле күзләрен сөртеп алды.

— Икебез дә гаепле, әти, икебез дә. Син китсәң дә, миңа калырга иде поездны көтеп, каласы иде. Үкенечкә шулай булгандыр инде, үкенечкә...

Мифтах белән очраша, аны озатып кала алмаудан уфтанып, сыкранып, тирән үкенү хисе белән ачынып, алар кайту юлына чыктылар. Юл буена икесенең берсе дә авыз ачып бер сүз әйтмәде, бер-берсенә эндәшмәде. Миңнур аркасын атасына таба каршы яктан искән җилгә толып якасын куеп, тавыш-тынсыз гына елап кайтты. Авылга кайтып җиткәндә генә, Нурислам карт, тирән көрсенеп:

— Язмыштыр инде бу, кызым, язмыштыр. Язмыштан узмыш юк. Ходай язганны күрми калмый адәм баласы. Башы исән булсын кияүнең, башы исән булса, иншалла, бер кайтыр. Кайтыр исән булса, безнең тәрәзәгә тагын кояш төшәр, — дип әйтеп куйды.

* * *

Кырык икенең апрель уртасы җитте. Илнең көнбатышында коточкыч сугыш-кырылыш дәвам иткән көннәр. Ләкин юмарт кояш, бу афәткә бөтенләй битараф калып, кайнар сулышын җиргә өрде. Кыш буе зәмһәрир суыклар һәм күз ачкысыз бураннар котырынган киң басуларда, кала-салаларда көрт-көрт булып өелеп яткан карлар эреп, тау араларындагы чокырларга ерганаклап су төште, аннары болыннарга, елга-күлләргә ашкынып гөрләвекләр акты. Күзгә күренеп, Шушма елгасы диңгезгә әверелде, Чиялек һәм Югары әрәмәләре, авыл тирәли җәйрәп яткан кул буйлары су астында калды. Гөрләвекләр шулкадәр тиз һәм тулып төште ки, хәтта Тугайдагы кайбер йортларны да су басты. Калын-калын бозлар, шаулап килеп, Борһан күле аркылы салган агач күперне дә җимереп, үзләре белән алып киттеләр. Авыл күперсез калды.

Нәкъ шул көннәрдә авылның алты егете сугышка чыгып китте. Алар арасында Палта Миңнурының күз атып йөргәне — гармунчы Минәхмәт, аның якын дуслары Голүм, Рәхимҗан һәм башкалар да бар иде. Күл аркылы салган күперне язгы бозлар алып киткәнгә һәм юлларда ташу шаулаганга, егетләр җәяүләп, кулларына озын таяклар тотып чыктылар да, Юкәле тавы ягыннан Бәркәтә авылына таба, ан-

нан район үзәге Чирмешәнгә юнәлделәр. Аларны әти-әниләре, якын туганнары озата килделәр һәм артларыннан күздән югалганчы карап калдылар.

Миңнур Минәхмәтнең һәм аның яшьтәшләренең китүе турында ишеткән иде. Озак та үтмәде, күрше Минҗамал ахирәте, хәл генә белергә кергән атлы булып, өйдәгеләр күрмәгәндә генә бер кәгазь кисәге сузды. Бу Минәхмәтнең Миңнурга атап язган саубуллашу хаты иде:

*«Миңнур! Менә безгә дә чират җитте, без дә китәбез. Кабат кайтулар, күрешүләр насыйп булырмы, юкмы — безгә караңгы. Үсеп, ныгып җитәргә дә өлгермәгән килеш сугыш корбаны булырбыз, ахры. Соңгы ел гел үкенечләрдән генә торды. Башта сине югалттым, хәзер сугышка китәбез... Яратсам да, назлы сөю бәхетенә ирешеп булмады... Гомерем булса, мин гел синең турыда гына уйлап яшәрмен инде.*

*Китәм инде, китәм инде,*
*Китсәм кайталмам инде;*
*Бер китсәм кайталмам инде,*
*Сине оныталмам инде...*
*Хуш, бәхил бул!*

*Минәхмәт».*

Миңнур, йомшарып китеп, кеше күргәнче дип, күз яшьләрен сөртеп алды.

Минәхмәтнең сугышка китүе турында ишеткәч, күңелендә аның белән соңгы тапкыр очрашып калу теләге дә туган иде. Ләкин никахлы ир хатынының элек яратып йөргән егете белән очрашуы гөнаһка санала. Мондый кырын эшеңне кеше күрсә, авылга таралса, Мифтахның туганнарына, аннан үзенә дә ишетелсә, оятыңнан ни кылырсың да, кеше күзенә ничек күренерсең? Юк инде, Палта Миңнуры үз намусына тап төшермәс...

Озак та үтмәде, Мифтахтан хат килеп төште. «Фронт сызыгына килеп җиттек, хәзер үк сугышка керәбез» дигән иде ул. Аннан соң шактый вакыт хат-хәбәр килми торды. «Әллә соң бер-бер хәл булдымы?» дип шикләнде Миңнур, ләкин борчылырга сәбәп юк, йоклаганда матур төшләр күрә иде.

Ниһаять, июнь ахырында тагын бер өч почмаклы хат килде. Мифтах тагын яраланган, Казанда, госпитальдә ята икән. «Килеп китә алмассызмы?» дигән. Миңнур белән атасы тиз генә җыенып, тагын юлга чыктылар. Юл газабы — гүр газабы дигәндәй, кайда нәрсә туры килде, шулай Казанга өч көн бардылар. Мифтахның аягындагы ярасы төзәлгән, яңадан фронтка озатырга тиешләр икән. Ул, гаиләм килде дип, госпитальдән ике көнгә рөхсәт алып чыкты, һәм алар Нурислам абзыйның Казандагы дусты Габдулла абзыйларга киттеләр, шунда ике төн кундылар.

* * *

Икенче көнне Мифтах яшь, гүзәл хатынын Казанны күрергә алып чыгып китте. Үзе аксый, кулында таяк, ләкин Миңнурын шәһәрнекеләр кебек култыклап, һаман җәяү бара.

Габдулла абзый йорты базардан ерак түгел иде. Башта алар базарга керделәр, халык арасында, төрле әйбер карап, озак йөрделәр.

Аннары Мифтах серен ачты:

— Минем сиңа истәлеккә бүләк алып бирәсем килә, Миңнур. Илдәге хәлләрне беләсең, кабат очрашырга язганмы-юкмы, кайта алмасам, истәлегем итеп сакларсың. Мәңгегә... — диде ул, моңсу елмаеп.

— Миңа бернинди дә бүләк кирәк түгел, Мифтах. Син үзең бүләк, олы бүләк, син үзең кайт, үзең...

Миңнур артык дулкынланган иде, күзләреннән яшь атылып чыкты, тамагына төер утырды.

— Ярар, ярар, кайтырмын. Син әйткәч, кайтмый булмый инде алайса, — дип шаяртып алды Мифтах. — Тик сүземне тыңла, яме? Алыйк сиңа бүләк. Ризамы?

Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына дигән мәкальдәге кебек, бер татар хатыны, тормышы авырая башлагач, сандык төбеннән өр-яңа ап-ак ефәк шәлен сатарга алып чыккан — алар шуны күреп алдылар. Шәл икесенә дә бик ошады. Мифтах сатулашып та тормады, теге хатын никадәр сораса, акчасын шулкадәр биреп, ефәк шәлне күңеле күтәрелеп киткән Миңнурына тоттырды.

Шуннан соң алар Казанның үзәк урамнарының берсенә килеп чыктылар, күз атып, бик күп могҗизаларны исләре китеп карап йөрделәр. Ләкин тагын да истәлеклерәге — «Фотографиягә» кереп, рәсемгә төшүү булгандыр. Бергә яшәү дәверендә тәүге һәм соңгы мәртәбә рәсемгә төшү! Икесе дә яшь, икесе дә искиткеч матур. Тик күзләренең моңсу карашлары гына аларның очрашуларының сагышлы булуы турында искәртә. Теге кайтуында Мифтахның чәче кыска иде, ә бу юлы ул өйләнгән вакыттагы шикелле дулкынланып, күпереп торган чәч белән төште рәсемгә. Ә Миңнурның башында Мифтахы бүләк иткән ап-ак ефәк шәл. Хәләл җефетенең иң кыйммәтле, иң кадерле, иң истәлекле бүләге! Ул аны үлгәнче кадерләп тотачак... Менә мондый фоторәсемне мәңге онытылмас, мәңге истәлекле рәсем дисәң дә була...

* * *

Менә тагын аерылышу минутлары килеп җитте. Мифтах хәләл җефете Миңнур белән каенатасын шәһәр читенә кадәр озата килде. Машина көтә-көтә шактый вакыт үтте. Бу арада ике яшь йөрәк бергә калып соңгы сүзләрен сөйләштеләр, серләрен уртаклаштылар:

— Сугыш бик озак бара, Миңнур. Аның тиз генә туктавына өмет юк. Ярты ил немец итеге табаны астында. Шуңа күрә минем сиңа әйтәсе сүзем бар, — диде ул һәм уйланып торды. — Син яшь, чибәр. Әгәр мин сугыш кырында башымны салсам, кайта алмасам, син кабат тормышка чыгарсың. Ләкин бу уңайдан минем сиңа үтенечем бар: син мине биш ел көт. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки, мин һәлак булмамын, әсирлеккә генә төшәрмен дә хат-хәбәр яза алмамын. Көт бер биш ел! Вәгъдәме?

— Вәгъдә, вәгъдә! Тик син харап булма, әсирлеккә дә төшмә, тизрәк кайт! Мин сине күпме кирәк — шуның кадәр көтәрмен, — диде Миңнур, чиксез дулкынланып.

— Менә бусына рәхмәт! Шуңа бик яратам да бит үзеңне...

Мифтах Миңнурны күкрәгенә кысты. Нурислам карт, арты белән борылып, аларны күрмәмешкә салышты.

Юл кырыена бер иске генә йөк машинасы килеп туктады. Алар ашыгып саубуллаштылар да утырып киттеләр. Ә Мифтах хәрби киемнән, кул таягына таянган килеш, кулын болгый-болгый тузанлы юл буенда басып калды. Бу очрашу алар өчен соңгысы булды. Моннан соң Миңнур ире Мифтахтан бернинди хәбәр дә алмады.

* * *

Кайгы-хәсрәт үзе генә йөрми дөньяда. Бер көзге көнне Өммегөлсемнең салам түбәле дүртпочмаклы бәләкәй ызбасына ут капты. Ире Имам күптән сугышта, Мифтах энесе китеп барганнан соң озак та тормады, бер төркем яшьтәшләре белән фронтка озатылды. Соңгы хаты Ленинград артыннан, Карелия тирәсеннән килгән иде, шуның белән хәбәре тукталды: әллә һәлак булды, әллә әсирлеккә төште инде?

Салам түбәле өй, авыл халкын гаҗәпләндереп, төрле фараз-юрауларга урын калдырып, эчтән дә, морҗа төбеннән дә түгел, ә болдыр ягыннан яна башлады. Ярый әле янгын иртәнге якта, әле төш тә җитмәс борын чыкты, чөнки төнге янгын бик куркыныч, аннан котылулары ике яклы. Өммегөлсем үзе өйдә юк, хатыннар белән ындыр табагына арыш җилгәрергә җибәрелгән иде. Ызбада берсеннән-берсе бәләкәй ике сабый — улы белән кызы. Рәхмәт инде күршеләргә, алар, янгынны күреп алып, бөтен авылга сөрән салдылар: «Янабыз, пожар...» Күрше-күлән, авылдашлар ут сүндерергә күтәрелде. Яна башлаган өй янына барысыннан да алда сугыштан яраланып кайткан яшь лейтенант Мәгъсүм килеп җитте һәм ут сүндерүне оештырып җибәрде, ә үзе, тәрәзәдән кереп, башта балаларны, аннары бар кием-салымны, җиһазларны урамга тәрәзә аша ташлый башлады. Соңгарак калсалар да, ут сүндерүчеләр дә килеп җиттеләр һәм дөрләп яна башлаган салам түбәне тиз генә сүндерделәр. Ялкын өйнең эченә үтә алмады, артык зыян салмады.

Тикшерә торгач, Өммегөлсем өенә «кызыл әтәч» җибәрүче дә фаш ителде. Бу Өммегөлсемнең якын туганы Һәдия абыстайның җитеп килгән кызы булып чыкты. Бер кичне утырмага килгәч, җаен табып, Мөгаллимә Өммегөлсем абыстасының кадергә генә кия торган яшел күлмәген киеп караган икән һәм, йөзе кара булгыры, чәлдереп тә киткән. Аны Өммегөлсем белми дә калган. Ә Мөгаллимә яшел күлмәк белән аулак өйләргә йөри, килешле итеп сикереп-сикереп бии, әле сугышка китеп бетмәгән егетләрне үзенә карата, кәпрәя, куык очыра.

Мөгаллимәнең кинәттән генә бик матур яшел күлмәк киеп йөрүе турында ишеткәч, Өммегөлсем, күңеленә шик төшеп, сандыгын ачып караган. Ә күлмәк урынында юк, аңардан җилләр искән. Ул, тәмам хафага төшеп, Мөгаллимә янына йөгерә. Ә тегесе йөзен дә чытмый: «Юк миндә андый күлмәк, минем аны күргәнем дә, тотканым да юк», — дип җан талаша, өстәп: «Миңа яла якканың өчен мин сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәм әле», — дип янап та куя. Күршеләре, янгын алдыннан гына, Мөгаллимәнең Өммегөлсем йортыннан чыгып, бакча аша гына арткы урамга йөгергәнен дә күргәннәр.

Уналты яшьлек җилбәзәк кызны әнә шундый җинаятьләре өчен әллә биш, әллә алты елга утыртып та куйдылар. Ул елларның җәзасы каты иде шул. Кешенекенә кул сузып, үзеңнекеннән коры калырсың. Шул китүдән Мөгаллимәнең туган авылында эзе дә булмады, төрмәдән чыккач та чит-ят яклардан әйләнеп кайтмады. Оятыннан кайтмагандыр инде.

Миңнур Өммегөлсем килендәшенең бәлагә юлыгуын үз кайгысыдай кабул итте. Хәленә керим дип, вак-төяк тукымалардан балаларга күлмәк-ыштаннар тегеп, Өммегөлсемгә өр-яңа ак яулыгын алып, күчтәнәчкә тегермән ташы чаклы бер ипи кыстырып, янгыннан соң әле һаман рәтләп җыештырылмаган таныш өйгә барып керде. Ике сабый, шатланышып, яңа киемнәрне киеп куйдылар һәм тәмләп ипи ашарга тотындылар. Ә Өммегөлсем, юмарт куллы, киң күңелле килендәшенең кылган игелегенә йомшарып китеп, яшен сыгып алды:

— Син, Миңнур, миңа үпкәләп яшисеңдер инде. Теге вакытта әллә ничек шунда, уртак тел табып яши алмадык, мин авыр сүз әйтеп рәнҗеттем бугай үзеңне. Үпкә тотма инде, зинһар, мин ахмакка. Югыйсә үзең миңа карата бер дә яман эш кылмадың, рәхмәт, — диде дә ул, яулык чите белән яшьле

күзләрен сөртте һәм кул арты белән битләрен ышкып-ышкып алды. Аның шулай учлары белән түгел, ә кул арты белән битләрен, маңгаен ышкый торган гадәтен Миңнур күптән белә иде.

— Үткәннәргә салават, Гөлсем апа! Кешенең ялгышкан чаклары була инде ул. Киләчәккә сабак булсын. Ә мин сиңа үпкә сакламыйм, моңа вакытым да юк. Безгә хәзер ирләребезнең сугыш кырыннан исән-имин кайтуларын теләргә, Ходайдан шуны сорарга кирәк. Алар кайткач, бергә-бергә аралашып, кошлар кебек сайрашып яшәргә насыйп итсен. Йомышың төшсә, кил, безнең капка да, ишек тә һәрвакыт ачык. Авыр минутларда терәк булырга килендәшең барлыгын онытма, — диде Миңнур һәм хәсрәтле көннәрдән соң бөршәеп калган килендәшенең аркасыннан сөеп, изге теләкләр теләп, җиңел сулап чыгып китте.

* * *

Сугыш елларының авырлыгы... Ул ир-атка да, хатын-кызга да, балаларга да тигез төште. Миңнур Мифтахы турында исәнме, үлгәнме, әллә әсир генә төшкәнме дип баш ваткан бер чорда, авылның берничә хатын-кызын Ярославль өлкәсенә торф чыгарырга җибәрделәр. Исемлекнең башында — Палта Нурислам кызы Миңнур. Аның белән бергә Насретдин карт кызы Фатыйма, Кара Нәсип кызы Әфрүзия, Мәхтүмә... Һич белмәгән, һич күрмәгән Ярославль өлкәсенең Данилов авылындагы торф предприятиесенә килеп төштеләр. Урысча ике авыз сүз белмәгән хатын-кызларны Варвара дигән бер марҗага фатирга урнаштырдылар. Нараттан салынган дүрт бүлмәле алаңгыр* кебек зур ызбада хатын япа-ялгызы яшәп ята. Бердәнбер кызы Вера очучы икән, сугышта.

Җәй көне хатын-кызлар буйдан-буйга сузылган сазлыкта торф чыгардылар. Торфны фронт өчен кирәкле кыйммәтле чимал дигән булдылар. Фронтның кайсы җиренә кирәк булгандыр инде ул тирес кебек нәмәрсә? Миңнур бу сорауга алты дистәдән артык вакыт узгач та җавап бирә алмый. Торфны шакмаклап кәсләргә бүләләр дә әйләндерә-әйләндерә киптерәләр, ә көзен ул кәсләрне әрдәнәләргә өяләр.

Ярлы авыл кешеләренең өсләрендә рәтле кием дә юк иде, булганы да тузып, тетелеп бетте. Ярый әле сазламыкта кияргә брезент оеклар бирделәр.

Ашарга да җитми. Ашханәдә кышкы салкыннарда өшегән бәрәңге шулпасы гына. Көненә ярты кило ипи.

Эштән эт кебек арып, тәмам талчыгып кайткач, кызларның бар теләге — утырып бер туйганчы ашап алу. Тик туйганчы ашарлык итеп әзерләргә ризык кирәк шул. Беркөнне алар шулай көчкә өстерәлеп кайтып керделәр, ә әзерләргә бернәрсә дә юк.

Әфрүзия, түзә алмыйча:

— Ачка бетәбез бит, кызлар, урыс арасында дөмегәбез бит, — дип елап җибәрде.

Ярый әле Варвара өендә юк иде — горур татар кызларының елаганын ишетмәде.

Сүзгә Фатыйма кушылды:

— Зинһар, бер-бер хәл кылыйк. Миңнур ахирәтем, бөтен өмет синдә. Марҗаларча сукалый башладың, сөйләш — без аларның теләсә нинди эшләрен эшләргә риза, ризык кына бирсеннәр...

Миңнур бу турыда үзе дә уйлап тора иде. Әмма аның Палта Нурислам кызы булуы, мишәр-татар дөньясының милли горурлыгын җанына, тәненә сеңдереп, шушы мохиттә тәрбия алып үсүе моңа юл куймый иде. Аннан соң көн буе сазлыкта арып-талып торф чыгарып кайткан арык, хәлсез кызлар ничек шул марҗаларга ялланып эшләрләр соң? Ул бу ягын да уйлый иде. Шулай дип ул кызларга да әйтте.

— И-и, Миңнур... Туйганчы ашарлык ризык тапсак, мин төн йокыларымны калдырып та эшләргә риза, — диде Фатыйма. — Аңла әле, дускаем, без бит хәерче кебек теләнеп ашарга димибез, эшләп, көч түгеп, хезмәт күрсәтеп... Аның нинди ояты бар? Менә ачлы-туклы торф чыгарабыз. Кемгә аны чыгарабыз, йә әйт әле? Шул ук урыска түгелме соң? Инде сугыш дисең икән, аның анысы да урысныкы. Без татарларга кайгы да хәсрәте генә. Әнә авылда яшь марҗалар җитәрлек, ә торфта эзләре дә юк, азаплана-азаплана татар кызлары чыгара...

Аның сүзләренә Әфрүзия белән Мәхтүмә дә кушылды.

Кызлар арасында иң кыюлары — шул ук Миңнур да Фатыйма. Урыс телен икесе дә бер чама сукалый. Әйе, башыңа төшсә башмакчы да булырсың. Күрше йортларга кереп, тегеләрнең телен вата-җимерә, гозерләрен җиткерделәр. Миңнур иң кирәклесен: «Работа җис?» — дигән сүзләрне яхшы белә. Алар янына «кушать надо» дигәннәрен дә өстәсәң, башка урыс сүзенең кирәге дә калмый — татар кызларының барлык уй-теләкләре марҗа башына тиз барып ирешә.

Уңган кызларга эш булсын да ашы булсын: шушы көннән башлап алар берәүләргә утын әзерләшергә — кисәргә, ярырга, өяргә тотындылар; икенчеләрнең бәрәңге бакчасында җимертеп эшләделәр; өченчеләрнең исә иданнәрен кырып-кырып юып чыгардылар.

Ләкин иң төшемле эш — Миңнурныкы. Сугышка кадәр Ярославльдә яшәгән Варвараның, бик үк шәп булмаса да, тегү машинасы бар. Тик ул үзе тегә белми. Миңнур шул машинада авыл халкына кием — күлмәк-ыштаннар, кофталар, итәкләр тегеп бирә башлады. Кием тектерүчеләр, юк дигәндә дә, тамак

ялгарга нәрсә булса да алып киләләр. Хәзер инде кызлар да: «Миңнурыбыз гына исән-сау булсын, ачка тилмермәбез, иншалла», — дип торалар. Моның өстенә Миңнур еш авырып торган хуҗа хатынның сыерын саварга, ызбасын җыештырырга да иренми. Варвара кызларга сөт бирә.

Туган авылыннан, үзенең милли мохитеннән аерылган бер төркем татар кызларының бөтен куанычлары — авылга йә булмаса фронттагы якын кешесенә утырып хат язу. Инде кемнән дә булса каршы язылган хат килсә, кызларның күңеле тагын да күтәрелә. Тик хатлар гына сирәк килә...

Беркөнне Миңнур өч почмаклы хат алды. «Мифтахныкымы әллә?» — дип шатланган иде, әмма Минәхмәттән булып чыкты, дулкынланып китте. Миңнур Минәхмәтнең һәм аның белән бер елгы башка авыл егетләренең сугышка бераз соңарып китүләре турында белә, ләкин яшьлектә сөйгән егете аңа хат язар дип уйламаган иде.

Минәхмәт әле фронтта түгел, Суслонгер дигән бер җирдә сугышка озатуларын көтеп ята икән. Яшь солдатларның хәле аяныч. Көннәр буена урманнан күтәреп агач ташыталар, ач тоталар, фронтка китәргә теләгәннәрне дә җибәрмиләр. Солдатлар ачка кырыла.

*«...Безнең дә хәл бик начар, Миңнур. Бу мәхшәрдән котылсак, сугышта да болай авыр булмас иде кебек. Еш кына сине искә алам. Мин сине элеккечә яратам. Миңа Мифтах абзыйның хәбәрсез югалуы турында яздылар. Сиңа авырдыр инде. Әгәр сугыштан исән-имин кайта алсам, без синең белән барыбер бергә булырбыз. Син көт мине...»*

Миңнурның күңеле йомшарып, хисләре яңарып китте, һәм ул елый-елый Минәхмәткә бик җылы, кызганулы хат язды. Тик җавап кына ала алмады. Бәлки, Минәхмәтне сугышка озатканнардыр да шуңа җавап хаты яза алмый тора торгандыр дип уйлаган иде Миңнур. Әмма алай булып чыкмады. Тәмуг мәхшәреннән дә газаплы Суслонгер корбаны булган икән мескен Минәхмәт һәм аның яшьлек дуслары...

Көз җитеп, торфларны әрдәнәләргә салгач кына, кызларга өйләренә кайтып китәргә рөхсәт иттеләр.

Ләкин икенче елны да Миңнурны шул ук ачы язмышка дучар ителгән дуслары Әфрүзия, Мәхтүмә, Кара Хәйретдин кызы Хәйрия, Тәзкирә һәм Хәдичә белән бергә көчләп торф чыгарырга җибәрделәр...

* * *

Ниһаять, олы югалтулар, иксез-чиксез кайгы-хәсрәт газаплары белән сугыш бетте. Тик җиңү шатлыгы бик күпләргә яшь аралаш килде. Миңнур да ике канаты каерылган кыр казы хәлендә калды: ире хәбәрсез югалды, яшьли сөйгән егете дә кайта алмады, чит җирдә башын салды. Әмма яшь хатын, ничек кенә авыр булмасын, өметен өзмәде. «Сугышта төрлесе булуы мөмкин, син мин кайтмады дип кияүгә чыгарга ашыкма, бер биш ел көт», — диде бит Мифтах һәм аның вәгъдәсен алды. Ә вәгъдә — намус көзгесе, вәгъдә — иман. Миңнур беркайчан да үз вәгъдәсенә хыянәт итмәячәк. Күктән кызыл карлар яуса да, әйткән сүзенә тугрылыклы калыр Палта Нурислам кызы. Һәм көтте ул Мифтахын...

* * *

Сентябрь керде. Көзнең тәүге ае. Җәйге көннәр кебек җылы, матур иде сентябрь ае. Һавада пәрәвез җепселләре — тоҗым оча. Көндез Миңнур белән сеңлесе Минхәят бакчадан бәрәңге алдылар, аналары да аларга булышты. Ашыкмый гына эшләп, бәрәңгене кояшта һәм җилдә киптереп, кабыктан тәгәрәтеп базга салдылар. Әле тагын аласы бар ул бәрәңгене — бакчаның яртысы да бетмәгән. Ләкин инде кич җиткән, эңгер төшеп килә, ял да кирәк. Ә тыкрык ягында коштабак чаклы тулган ай бакчага үзенең моңсу, сер тулы нурларын сибә.

Миңнур айны балачактан яратты, хәзер дә ярата. Үсмер чакта күрше кызлары белән алар тулган айдан көянтә-чиләкләр аскан Зөһрәне күзәтәләр иде. Ул вакытта риваять йөри иде. Үги анасы җәберләүгә түзә алмаган кыз төнлә урамга чыккан да айның аны үзенә тартып алуын ялварып сораган. Ай аның үтенечен кире какмаган... Бала-чага барысы да кызганалар иде ялгызы айга менеп киткән ятимә Зөһрәне...

Бүген дә ул, өйалдындагы баскычта утырган килеш, озак итеп тулган айга карап торды, төрле уйлар уйлады, сагышланды-моңланды. Зөһрә-кыз язмышы кебек булмаса да, Миңнурның үзенең дә язмышы җиңелләрдән түгел. Әллә соң бер җырлап куясымы? Күңел басылыр иде хет...

Ай югары, ай югары,
Ай югары — мин түбән;
Кайгы күлләрендә йөзәм,
Шуңа күңелем сүрән.

Ай югары, ай югары,
Ай югары салкынга;
Агач булса янар иде
Эчемдәге ялкынга...

Сугыш алдыннан авылга бик еш хәер сорашып йөри торган саилче карчык килә торган иде. Бер үк вакытта аның китап та ача торган гадәте бар иде. Миңнур беркөнне, өйдә этисе дә, әнисе дә юклыктан

файдаланып, әлеге карчыктан ярты ипигә үзенә атап китап ачтырды. Аның юравы буенча, Миңнурны алда бик кайнар һәм назлы мәхәббәт, бәхетле гаилә тормышы көтәргә тиеш иде. Ә кайда ул кайнар мәхәббәт, кайда ул бәхет, кайда ул бәхетле гаилә тормышы? Авылдагы иң гүзәл кызларның да гүзәле Палта Миңнурының мәхәббәте Зөләйха, Зөһрә, Ширин, Ләйлә йә булмаса Галиябану мәхәббәте кебек дастаннарга язарлык мәхәббәт булырга тиеш иде югыйсә. Юк, булмады ул. Әллә соң авылда Йосыфлар, Таһирлар, Фәрхадлар, Мәҗнүннәр, Хәлилләр булмадымы?

Миңнурга кызыгып, аңа күз атып, күңеле төшеп, аның белән хыялланып йөргән егетләр булмады түгел, булды. Әнә күрше Әсәдулланы гына алыйк. Аның күңеле Миңнурга тартылганын кыз баштан ук сизде. Ә егет ярамаслык түгел иде — чибәр, тырыш. Дөрес, артыгы белән тыйнак, кыюсыз. Аның: «Яратам», — дип әйткәнен гомереңдә дә ишетә алмассың кебек иде ул вакытта.

Нәгыймә абыстайның ишле гаиләсендә Әсәдулла — балаларның иң олысы, тол калган аналарының терәге, шуңа да тормыш йөген иртә тарта башлады, яше җитәр-җитмәс, авыл егетләренә ияреп, Урал якларына бәхет эзләп чыгып китте. Егетләр Түбән Тагилга барып җиттеләр, эшкә урнаштылар. Тик Әсәдулланы гына алмадылар, яшең җитми дип, борып җибәрделәр. Әсәдулла кире авылга әйләнеп кайтты да Нурислам абзый янына керде:

— Миңа яшемне олырак иттереп күрсәткән белешмә аласы иде, Нурислам абзый. Барып төртелер башка кешем юк, булыша алмассыңмы икән күрше хакына? Игелегеңне һич онытмас идем, — диде.

Нурислам абзый авылда абруйлы кеше, авыл советында да сүзе үтә, шуңа да Әсәдулла аңа кереп, барлык ышанычын баглады. Нурислам абзый да күз алдында үсеп килгән егетне күреп тора. Кичке эңгерләрдә тыкрыкта, читән буенда еш кына Миңнуры белән дә сөйләшеп-серләшеп басып торалар. Белмәссең, киявең булып та куюы бар. Булса да үкенерлек түгел: егет уңган-булган, тырыш, гаиләдә анасының олы булышчысы. Төскә-биткә, гәүдәгә дә матур — кызлар юкка гына кызыкмыйлардыр. Читән буенда Миңнуры белән очрашулары да тикмәгә генә түгелдер әле...

Нурислам абзыйның булышлыгы белән, яңа белешмәдә үзен ике яшькә олыгайтып, Әсәдулла кабат Түбән Тагилга ашыкты.

Кырыгынчы елның җәендә Әсәдулла, киенеп-ясанып, тагын кайтып китте. Үзенекеләр белән бергә Палталарга да әйберләр алып кайткан икән, Нурислам абзыйга рәхмәтләрен әйтеп, аларга да күчтәнәчләрен кертеп бирде. Нурислам абзыйның да, Фәрхинур абыстайның да моңа күңеле булды. Унҗиденче яшендә генә булса да, тәртипле, акыллы, булдыклы — менә нинди ул күрше егете! Бер ел эчендә тагын да үсеп, тазарып киткән.

Ә күрше егете бу кайтуында тыкрыктагы читән буенда Миңнур белән тагын да мөһимрәк мәсьәлә турында сөйләшеп торалар иде:

— Эшем яхшы, акчаны да әйбәт алам. Әйдә, чык миңа, бергә китик. Үзең беләсең, мин сине гомерем буе яраттым, бүген дә яратам. Курыкма, бергә булганда тормышыбыз уң булыр...

— И-и, Әсәдулла, нәрсә сөйлисең? Әзрәк уйлап кара әле: үзең ничә яшьтә дә, мин... Соң бит миңа унбиш кенә әле. Юк, юк, мин бу яшьтән үк камыт кия алмыйм муеныма. Син дә ашыкма.

— Көтәсем килми шул, Миңнур. Гаиләле яшьләр тиз аякка басалар. Аларга фатирны да тиз бирәләр. Тыңла инде, җаным, китик бергә. Гөрләтеп яшәп китәр идек. Эшлим дисәң, анда тегүчеләргә дә эш җитәрлек.

— Юк, юк, Әсәдулла, хәзергә мин риза түгел. Көт бер-ике ел... Ашыккан ашка пешкән. Көт иң кимендә тагын бер ел. Аннан күз күрер...

Әсәдулла Түбән Тагилына сөмсере коелып китеп барды. Озак та үтмәде, авылга аның анда өйләнүе турында хәбәр килеп иреште. Моңа Миңнур гаҗәпләнеп кенә калмады, бик нык кимсенде дә. Әллә Миңнурга ачу итеп өйләнде инде ул анда? Менә сиңа «яратам»...

Шуннан соң бит инде Миңнур артыннан Минәхмәт йөри башлады. Миңнур үзе дә Минәхмәткә тартылды. Тик әнә аңа да насыйп булмаган икән...

Әй бу дөньялар! Гел син дигәнчә, син уйлаганча, син ниятләгәнчә генә бармый шул ул тормыш. Син уйлыйсың алтыга, ул кала яртыга. Бәлки, Миңнур ялгышкандыр, Әсәдулла аның кулын сорап кергәндә бернигә карамый ризалык бирәсе һәм ияреп китәсе калгандыр?! Югыйсә күңеле белән үз итә иде ул күрше егетен, хәтта вакыт-вакыт аның йөрәгендә ярату хисләре дә балкып-балкып китә иде. Нурислам абзый белән Фәрхинур абыстай да гел мактап кына торалар иде. Димәк, язмаган. Язмаган! Минәхмәте насыйп булмаган. Ә Мифтахы... Ах, анысы белән бигрәк тә катлаулы мөнәсәбәт килеп чыкты. Башта һич яратмаган иде. Аннары күңеле йомшарды, ирендә күркәм генә сыйфатлар таба торды, аны якын итә башлады. Төнге күктә чәчрәп чыгардай булып балкыган йолдызга тиң якты мәхәббәт һәм татлы ярату булмаса да, якын итү хисе дә ярап тора икән кайвакыт. Тик... югалды Мифтах, суга төшкән кебек юк булды...

Озак уйланып утырды яшь хатын моңсу айга карап. Соң гына кереп ятты.

Ә төнлә ул төш күрде. Киң болын — ул да тулган ай нурына төренгән. Болын өстендә сыек буак* йөзә һәм шул буак эчендә ат көтүе йөри. Кинәт кенә шул көтүдән бер күк ат аерылды да Миңнурга та-

ба килә башлады. Килде-килде дә туктап калды һәм аңа карап торды. Аннары тыныч кына яныннан үтеп китте. Кешнәмәде-нитмәде, үтеп кенә китте яныннан...

Шул урында уянып та китте Миңнур. Ап-ачык төш, гаҗәпкә калырлык! Нәрсәгә булыр бу? Әллә соң Мифтах кайтамы? Бәлки, ул исән-саудыр?! Кайтса, нинди олы шатлык, нинди зур бәхет булыр иде. Бирсен Ходай!..

Миңнур белә: төшкә ат керсә, очрашуга, шатлыкка. Кешенең гомерлек терәге, дусты, булышчы-ярдәмчесе булган ат төшкә дә матурга, яхшыга, игелеккә юрала.

Таң атып килә. Ул, күңеле булып, урыныннан торды, юынып-киенеп, тегү машинасы артына барып эшенә утырды. Анда аның кичтән төгәлләнмәгән эше бар иде. Эше тәмамланмаган килеш тыныч кына утыра аламыни соң инде?

* * *

Иртән авылга сугышка китү белән эзсез югалган Мәсләхов Имамның кайтып төшүе турында хәбәр таралган иде. Мифтахның абыйсы, Миңнурның хөрмәт иткән каенагасы, киң күңелле, мәрхәмәтле-шәфкатьле Имам абзый... Төшнең рас килүен әйт әле син! Мифтах түгел икән бит, Имам кайтырга булган ул төш... Өммегөлсем килендәшнең шатлыклары эченә сыймый торгандыр инде. Тигез, тату тормыш итә күрсеннәр...

Икенче көнне үк Имам Палталарга килеп, Нурислам кодасы, Фәрхинур кодагые һәм Миңнур килене белән озак итеп сөйләшеп утырдылар. Сугыш башлану белән югалуы хак булган — Карелия җирендә барган бәрелешләрдә үк армияләре камалышта калган. Сазламык һәм баткаклыкларда бик күп сугышчы кырылган. Очсыз-кырыйсыз сазламыкка юлыгып, һич чыгар юл таба алмыйча, ач-ялангач килеш Имам һәм аның унбер иптәше урманда озак адашып йөриләр. Шул унике кешедән фәкать төп кебек таза Имам гына исән-имин чыккан ул урманнан.

— Мин баткаклыкта аякка басып йөрүнең һәлакәтле икәнен аңладым һәм судагы кебек йөзеп кенә чыгу әмәлен таптым, аннан шулай котылдым, — диде Имам, уйланып. — Мин үземнең иптәшләргә һәрвакыт: «Паникага бирелмәгез, каушап калмагыз, үзегезне баткаклыкта хуҗа итеп тотыгыз, өстен итеп сизегез», — дия идем. Үзем мин кулдан бервакытта да озын колганы төшермәдем. Бик хәтәр урыннарда ботаклары җәелеп киткән агачлар тирәсеннән үтә идем — төпкә китә башласаң, шул ботаклар сине коткара. Минем иптәшләрнең баткаклыкка төшеп батуы — күпчелек әнә шул каушаудан, паникага бирелүдән, кирәкле кадәр көрәшмәүдән дип уйлыйм мин. Мөмкин булган җирдә бик күп мәртәбәләр коткардым иптәшләрне, инде миннән ерак урында... Миннән ике буйга озын-озын урысларны акыртып-бакыртып төпкә тартып алды фин сазлыклары... Ә мин... мин үләргә җыенмадым, хәтта уйламадым да. Берүзем генә калгач та: «Юк, шаярмагыз, мине җиңә алмассыз, мин барыбер бирешмәячәкмен, мин барыбер бу мәхшәрдән исән-сау чыгачакмын», — дип, үземә үзем көч биреп, алга үрмәләдем. Һәм, күрәсез, мин исән...

Имам моңсу итеп елмаеп куйды. Аннары сүзен дәвам итте:

— Нурислам абзый, мин сезгә генә, сер итеп кенә әйтәм: армиядә димме, әллә сугышта димме, анда безнең кебек гади солдат, сугышчы турында кайгырткан кеше юк. Нигә безнең армия тар-мар булды дип уйлыйсыз? Чөнки командный состав, армия камалышта калгач, «кукурузник»ларга утырып тылга очты. Кыскасы, качтылар армия башлыклары. Ә безне немец баткаклыкка куып кертте. Кермәс тә идек, аталар, үләсе килми... Бөтен бер армияне кертеп батырдылар шул сазлыкларга. Минем кебек исән калу бәхетенә ирешкән кешеләр бик аз, санаулы гына булгандыр дип уйлыйм мин, моңа иманым камил.

Яшәү белән үлем арасында көрәшә торгач, Имам беркөнне чагыштырмача корырак җиргә килеп чыга. Бу инде аның өчен үлемнән котылу була. Бара-бара ул чикләвеклеккә килеп төртелә. Ә андагы чикләвек! Капчыклап җыйсаң да җитәрлек. Имам, бөтен дөньясын онытып, чикләвек ашарга тотына, чөнки аның ике атналап рәтләп ашаганы юк, ач, тамакны туйдыру аның өчен хәзер иң мөһиме. Көн буена Имам чикләвек ашый һәм тәүге тапкыр ылыслы нарат ботакларын түшәк итеп җәя дә, аякларын сузып, ятып йоклый. Иртән торып ул тагын чикләвеккә тотына. Моның өстенә ботакларда кып-кызыл җимешләре сыгылып торган камыр агачын да очрата, анысын да җыеп авызына тутыра. Имам әле үзенең шулай адашып Финляндия җиренә барып чыкканын белми. Чикләвек, камыр җимеше ашап йөргән җиреннән аны фин чик сакчылары тотып алалар. Сазга буялып, пәри төсенә кергән, сакал-мыек үскән, яланаяклы арык бу кешенең данлыклы Кызыл Армия солдаты булуына фин сакчыларының ис-акыллары китә.

Имамның бәхетенә, аны сак астында озак тотмыйлар. Юындырып, киендереп, бер җирбиләүчегә батрак итеп биреп җибәрәләр. Батрак булса да, анда аны беркем дә җәберләми-кыерсытмый, ач-ялангач тотмый. Җирбиләүченең хуҗалыгында йорт эшләрен башкарып — утын әзерләп, йорт-җир себереп, су ташып, мунча ягып, мал-туар карап гомер итә. Бу йорттагы кешеләр аңа гел үз гаиләләре кешесе итеп карыйлар: үзләре белән бергә ашарга утырталар, хәтта бәйрәм һәм ял итү чараларыннан да калдырмыйлар. Ләкин Нурислам гаиләсе өчен иң кызыгы Имамның финнарда ничек мунча керүе турында сөйләве

булгандыр. Һәр фин-угыр кабиләсенең борынгы гадәтенчә, гаиләдәге барлык ир-ат, хатын-кыз һәм бала-чага мунчага бергә, берьюлы баралар. Мунчалары гадәттән тыш иркен. Барысы да чишенеп, анадан тума калалар, бездәгечә себерке белән чабыналар, берьюлы юынып чыгалар. Тора-бара Имамга да күмәк мунча керергә ияләшергә туры килә.

Сугыш тәмамлангач, хәрби әсирләрне үз илләренә озаталар. Имам да, дүрт ел буена Финляндиядә батраклыкта булганнан соң, СССР чиген үтеп керү белән, «сортировка»га эләгә. Аны «сатлык» дип гаепләмәкчеләр, ләкин дәлил таба алмыйлар: аларның армиясеннән эз дә калмаган, документлар да юк ителгән. Мәсләхов «сортировка»дан шахтага эшкә җибәрелә, күмер чыгара. Әнә шулай мәҗбүри хезмәт срогын үтәп кайтып төшкән икән ул туган авылга.

Миңнур Мифтахның сугышта яраланып, бер тапкыр авылга кайтып китүе, икенче тапкыр Казандагы хәрби госпитальдә дәвалануы, сугышта күргән-белгәннәрен сөйләве, ә Казаннан киткәннән соң, 1942 елның июнь азакларында, аның яу кырында батырларча һәлак булуын хәбәр иткән «кара кәгазь» килүе турында сөйләде.

Имам исә:

— Мин аны һәрвакыт исән-имин дип уйлап яшәдем. Кайткандыр, өй салу хәстәре белән йөридер кебек тоелды. Аз-маз үзсүзле гадәте бар иде барын, ләкин үзе яхшы малай иде, — диде, «малай» сүзенә аеруча басым ясап. — Аның белән сиңа тормыш итү, килен, һич кенә дә авыр булмас иде. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки әле, исәндер дә. Шәп булыр иде минем кебек авылга кайтып төшсә...

* * *

Каенагасы да күңелен күтәргәч, Миңнур өметләнеп көтте Мифтахны: бәлки, чыннан да исәндер, бәлки, ул да искәрмичә генә кайтып керер... Шулай көтү газаплары белән акрын гына атналар, айлар, еллар үтә торды.

Уйланып-сагышланып йөри торгач, ялгыз хатын кинәт үзендә җырмы, әллә шигырьме чыгару сәләте барлыгын белеп алды.

Ак беләгемне талдыра
Шушма суы салкыны;
Икебезне аеры итте
Шушы сугыш ялкыны.

Ак булса да мамык булсын
Кулларыңа кигәнең;
Һич онытмыйм, гел исемдә:
«Син мине көт!» — дигәнең.

Ак каеннар яфрак коя
Сентябрь җилләрендә;
Сине уйласам, төшләр күрәм
Утырган җирләремдә.

Ак каенның яфрагы
Нигә саргая болай?
Көне-төне сине уйлап,
Мин дә саргаям шулай...

Йөрәккәйләре аша сулык-сулык итеп язган шигырьләрне кемгәдер укып күрсәтәсе, уртаклашасы килә. Ләкин сугыштан соң да һаман авыр, һаман җитешсез тормыш белән яшәгән авыл кешесенең кайсына аларны күрсәтәсең, кемгә хаҗәт алар? Әле бит: «Яудан кайтмаган ире турында уйланып хыяллана башлаган бу бахыр, шигырьләр, җырлар чыгаруы тикмәгә генә түгелдер», — дип әйтүләре дә мөмкин. Шулай да ул беркөнне, вакыт табып, авылның фельдшер-акушерлык пунктына, зур бер төбәк халкының карап торган өмете, ышанычы булган табибә Саҗидә янына төшеп китте. Ике тол хатынның язмышы уртак, икесе дә ирләрен сугышта югалттылар, икесенең дә баласы юк, серләре килә, бер-берсенә терәк булып яшәргә тырышалар. Саҗидә Миңнурдан өч яшькә олы. Миңнур аңа зур хөрмәт белән: «Саҗидә апа», — дип эндәшә. Унсигез яшьлек Саҗидә сугыш алдыннан, 1939 елда, Чистай фельдшер-акушерлык мәктәбен тәмамлап, Биләр районына эшкә җибәрелә. Ләкин озакламый үзе белән бер сыйныфта укыган, аның белән бер үк вакытта Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, армиядә офицер булып җитешкән яраткан егете Сибгать кайтып, аңа өйләнеп, Украинага алып китә. Тик аларның да бәхетле тормышын шул ук каһәрле сугыш өзә. Өлкән лейтенант Сибгать Насыйров дошман белән очрашуларның берсендә һәлак була. Саҗидә көч-хәл белән туган авылына кайтып егыла. Кырык бернең августында ул шушы медпунктта тәүге авыруларны кабул итә башлый.

Бөтен холык-фигыле, җаны-тәне, эчке рухы белән табибә булган бу ачык йөзле, йомшак тавышлы, олы җанлы шәфкать иясе авыл халкының бәхетенә бирегә кайтып төшкәндер. Кайгы-хәсрәтен, моң-зарын бушатырга кирәк булганда, Миңнур Саҗидә янына төшә.

Ләкин Саҗидәнең шигырь тыңлап утырырга вакыты юк. Медпункт тулы авырулар җыелган. Миңнурны күрү белән, Саҗидә елмаеп куйды:

— Килдеңме? — Аннары, пышылдап кына: — Су кайнат әле, Миңнур. Монда эшләр әйләнеп чыккысыз, — диде.

Әнә шулай көне-көне белән Саҗидәнең утырып сөйләшергә вакыты да булмый — авырулар күп, алар якындагы мишәр, урыс, чуаш һәм мукшы авылларыннан да килеп кенә торалар. Ә табибә медпунктта берүзе, аның булышчысы юк. Берүзенә бер челле дигәндәй, Саҗидәнең ике кулына мең эш.

Миңнур да, җиңнәрен сызганып, эшкә тотынды: башта самавырда су кайнатты, бераздан медицина җиһазларын да суда кайнатып алды, аннары йөгереп кенә кизләүдән су алып кайтты, чөнки медпунктта су бетеп килә иде. Ул гына булмады, әле юасы керләр дә бар икән — аларны юып-чайкап чыгарып элде, бер уңайдан медпунктны да җыештырып, идәнен юып, һавасын сафландырып җибәрде.

Инде соң, авырулар берәм-берәм өйләренә таралды. Ике тол хатын тынычлап, Миңнур пешергән бәрәңгене ашап, коры гына — шикәрсез-сөтсез чәй эчтеләр. Хәзер сөйләшеп-серләшеп алсалар да гөнаһ булмас. Уртак сүзләре күп аларның...

— Эшнең күплеген син күреп торасың, Миңнур. Санитар штаты бирсәләр, килерсең. Инде күптән вәгъдә итәләр. Киләсеңме?

— Миңа киләсе юк, бүген үк биредә, куш кына.

— Юк, сиңа кушасы да юк, барысын да үзең белеп, үзең теләп эшлисең, шуңа бөтен өметем синдә минем. Йа Хода... Нинди уңган-булган, нинди матур, килеш-килбәтле үзең. Ә бәхетең... Хет бала табып каласы идең Мифтахыңнан.

— Булмады бит. Балам булса торфка да җибәрмәгән булырлар иде.

— Минем дә булмады шул...

— Ә син миңа бәхетең булмады дисең. Ә үзеңнең?..

Саҗидәнең йөзе моңсу көлемсерәү белән бизәлде. Юк инде, аның да юк бәхете. Дөрес, ярата ул берәүне. Ул ирнең хатыны, өч баласы бар. Серен эчендә тотса да, Миңнур белә ул турыда. Вакыт-вакыт алар район үзәгенә бергә утырып китәләр. Һәм бу «сәяхәт» аларның икесе өчен дә бәхет китерә бугай, чөнки бер-беренә гыйшык тоту ул уртак була. Тик Саҗидә өчен киләчәктә бергә булу өмете күренми. Дөрес, ул моңа өмет тә итми, чөнки аны өметләндергән кеше юк. Бүләге кыйммәт түгел, яратуы кыйммәт... Шул яратуга алданып яши инде йомшак бәгырьле табибә, шуңа риза. Югыйсә мәктәптә бергә укыган сыйныфташы, очучы егет, яшьлек хисләрен күңелендә саклап, аның артыннан килеп, кулын да сорады. Китәсе генә бит аның белән гаиләле иргә алданып яшәгәнче. Тумаган тайга атлану шул үзе була инде. Мәхәббәтнең күзе сукыр, күрми ул күп нәрсәне...

Миңнурның Саҗидәгә кистереп кенә әйтәсе дә килә ялгышуы турында. Ләкин ул аны бик якын күрә. Үз ул Саҗидә, гөнаһысы булса да якын. Ә үзеңнеке — үзәктә. Килер бер көн — табибә ялгышын аңлар, башына тай типмәгән. Аңламаса инде, Миңнур бер җае белән генә әйтеп куяр.

Сөю — бәхет. Шуның белән үзен бәхетле сизә торгандыр аның ялгыз сердәше. Тик озакка булырмы?

* * *

Кызу урак өстендә медпунктка, җил-җил атлап, Илгизә килеп керде. Уракта артыгын тырышып ташлаган, ахры, — кулына гереш төшкән, шешеп киткән. Кысылганга дару юк дигән кебек, герешкә дә юк ул дару. Соңгы вакытта андый шешкә компресс ясыйлар, ә теге елларда Саҗидә гереш белән килгән кешеләргә үз бәвеле белән чылатылган чүпрәк урап куюдан башканы киңәш итә алмый иде. Илгизәгә дә ул ысулны тәкъдим итте. Ә Илгизә табибә киңәшен үзен мыскыл итү дип уйлады, ахры.

— Шуны да дәвалый алмагач, ни өчен сезне монда дәүләт акчасын түләп тоталар? Ярар, үзем җаен табармын. Сезгә калмаган... — дип чәчрәп чыгып китте.

Илгизә чыгып киткәч, Саҗидә дә, Миңнур да бик уңайсыз хәлдә, хәтерләре калып утырдылар. Хәтер калырлык та шул! Кешесе кеше булса иде...

Илгизә, Илгизә... Холыксыз, мәгънәсез. Аларына әле түзәр дә идең. Йөзе кара, вөҗдансыз, бөтен авылны шаулаткан хатын...

Яшьлекләрендә Миңнур белән Илгизәнең юллары кисешә тора иде. Кисешмичә, бер авыл кызлары ич! Еш кына аулак өйләрдә дә очрашкаладылар, бергәләшеп күңелле итеп кичләр утырдылар. Ул елларда Илгизә үзен бик тыйнак тота иде. Егетләргә ошарга тырышкандыр инде. Җырга-моңга да осталыгы юк түгел. Ләкин намуслы хатын булу өчен болар гына җитми икән шул.

...Сугыш алдыннан шаулап үткән туйларның берсе Хисаметдин белән Илгизәнеке булгандыр. Арчилары да матур төште.

Хисаметдин армиясен тутырып кайткач та тиз генә өйләнмәде — сайланды. Егет үзенә дә, кызларга да таләпчән: җилбәзәкләрне өнәми, чәнечкеле-төртмәле теллеләрнең янына да килми, ялкау-шапшак-

лар белән сөйләшеп тә тормый. Ә үзе уңган-булган, колхоз бригадирлары арасында иң яше һәм алдынгысы. Авылга бер абруйлы егет. Үзен колхоз рәисе итеп әзерлиләр икән, дигән сүз дә йөри башлады.

Ә өйләнергә күптән вакыт җиткән — егеткә егерме җиде тулып килә. Тик кемне сайларга? Вакыт көтми. Нишләргә белмичә, Хисаметдин соңгы мәлдә Сукыр Садыйк кызы Илгизәдән дә кулайрак парны тапмады. Матурлыкка хан кызлары кебек үк булмаса да, өсте-башы чиста, сүз сөреше чамалы, үзен тыйнак тота. Дөрес, бераз кылтая торган гадәте бар. Алай гына мулла кызында да була инде ул.

Сайлаган сазга — очраган тазга. Мескенкәем, Хисаметдин бу турыда белми дә калды. Белә калса, ни эшләгән булыр иде икән?

Илгизә, Хисаметдинне сугышка озатканда, кыз бала табып калды. Ирдән аңа әллә ике, әллә өч хат килде — шуның белән тукталды. Зур бер ил өстенә җәелгән, әлегә тиңе булмаган сугыш кырында, сугу машинасына эләккән көлтә кебек, Хисаметдин дә тапалды, юк булды.

Саный китсәң, Мифтахлар, Хисаметдиннәр кебек тапалганнар аз булмады инде авылда. Ләкин яраткан хатыннары, сөйгән кызлары олы сабырлык, зур түземлек һәм өмет белән хәләлләрен көткән бер чорда, кайбер тол калган яшь хатыннар арасында, вакытны заяга уздырмыйм әле дип, итәк асларын җиллләтеп алучылар да булды.

Кечкенә, җыйнак кына ызбада Илгизә бәләкәй кызы белән генә калды. Беркөнне колхоз рәисе аксак Мотыйк Илгизә өенә: «Кундырып чыгар әле», — дип, очлы йөзле, күсе борынлы райком вәкилен алып керде. Башта Илгизә вәкилгә урынны идәндә генә җәйгән иде, ләкин әрсез алабай вәкил, идәндә өшим дигән булып, Илгизә янына ук менеп ятты. Намуслы, пакь хатын булса очыртып кына чыгарыр иде күсе борынны, ләкин Илгизә алай эшләмәде. Ир затын тансыклаган яшь, кайнар хатын райком азгыны капшана башлауга ук эреп төште, кочагын ачты, түземлеген җуйды.

Вәкилгә күндәм хатын ошап китте бугай, ул колхозга тагын да ешрак килеп, Илгизә кочагында төн уздыра башлады. Ләкин кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә. Вәкилнең шухыр-мухыр йөргәнен райкомда тиз сизделәр һәм тиз үк фронтка озаттылар. Әмма Илгизә югалып калмады, бер авызланган хатын, нәфесен тыя алмыйча, утын ярып бир әле дип, уналтысын тутырып килгән Вакташ Мисхәтен чакырып кертте. Тегесе утынны ярды. Илгизә сызлаган җирләргә сөрткәләргә дип алып куйган аракысыннан егеткә дә өлеш чыгарды. Шайтан суын капкан егет, кыюланып китеп, Илгизә белән шаярырга тотынды...

Аннары авылда Илгизә янына Аздакы Ибрай да кергәли икән дигән сүз таралды. Анысы да булгандыр. Урман — колак, кыр — күз дигән кебек, авылның да күзе зур, үткен — күпне күрә, күпне ишетеп тора. Яхшысын да, яманын да.

Шулай беркөнне Харис, икенче көнне Варис белән дигәндәй, яшь хатын кулдан-кулга китте, Илгизә «ил гизә» башлады.

Ә берзаман Илгизә янына сугышның башы белән бер кулын имгәтеп кайткан Чамалы Хөснелгата килеп йөри башлаган дигән сүз чыкты. Хөснелгатаның авылда бер киң күңелле, йомшак бәгырьле, уңган Нурбикәсе бар, тупырдап торган өч малае үсеп килә. Имгәнеп кайттым дигән сылтау белән кибет тирәсендә уралган Хөснелгата беркөнне битенә иннек сылап, елтыр күзләренә сөрмә тарткан, ерык авызлы, артын биетеп урамнан үтүче Илгизәне күрде дә һушсыз калды. Азгынга ияргән азар, бозгынга ияргән бозылыр. Хөснелгатаның кушаматы Чамалы булса да, үзеннән шактый яшь азгын хатын тирәсендә чамасын онытып, Нурбикәсе белән өч бәләкәй баласын ташлап, Илгизәгә йортка барып керде. Түзеп тормаслык бу хәлгә авыл ду-у килде.

Ул кайгылы көннәрдә Нурбикәнең өченче баласына әле икенче генә яшь иде. Аның кайнар күз яшьләрен түгә-түгә нарасыен имезеп утырулары турында ишетеп, йомшак күңелле авыл хатыннарының йөрәккәйләре өзгәләнде. И-и Нурбикәнең сабырлыклары! Ир бирмәк — җан бирмәк. Шулай да ул бармады, йөрмәде ире артыннан, олы башын кече итмәде, горурлыгын җуймады. «Башына тай типмәгән булса, үзенең адәм мәсхәрәсе бер өстерәлчеккә барып кергәнен аңлар әле, тик соң булыр», — дип әйтә иде Нурбикә. Һәм аның шулай әйтүе хак булды. Хөснелгата башын иеп, мескенләнеп әллә ничә мәртәбә кайтты, гафу сорады, кабул итүләрен үтенде. Ә Нурбикәнең сүзе бер булды:

— Йөрмә! Мондагы өч баланы ятим итүең җитмәгән, хәзер тегендәгеләрне дә кан елатасың киләме?

Илгизә, Хөснелгатаны йомарлап кулына алгач, тиз генә чыгып ычкынмасын әле диптер инде, бербер артлы әллә ике, әллә өч кыз тапты. Ләкин аңа карап авыл халкының Илгизәгә булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, бәгыре йомшармады. Һәр уңайлы очракта аңа үзенең кемлеген таныта тордылар. Бик озак вакыт Илгизә кизләүгә суга да кара төндә генә йөрде. Кеше күзенә күренгән очракта аның ишетмәгәне калмады:

— Оятың юк икән...

— Зиначы, сине авылдан сөрергә кирәк!

— Хурлык сөягең кайда, ыштырбит?..

Шулай, авыл әйтсә — каты әйтер. Йөзе кара, намусын югалтканнарга аның каһәре зур.

Миңнур да бу хәлгә кимсенеп, йөрәге әрнеп шактый вакыт йөрде. Юк, Илгизә белән бергә үскәнгә, бергә аулак өйләргә йөргәнгә түгел, ә аның авылдагы барлык саф, пакь, намуслы хатыннарның исеменә

тап төшергәненә әрнеде йөрәге. Акылың сай булса, күзнең файдасы юк икән шул. Тыйнак кына күренгән Илгизә нинди әхлаксыз, яман хатын булып чыкты. Яшьлегендә шуның белән аралашып, бергә аулак өйләргә йөргәннәренә Миңнур үкенеп туя алмады. Хисаметдин мәрхүмнең дә рухы телгәләнә торгандыр инде хатынының вөҗдансызлыгына.

Илгизә кебек инде Саҗидә апа гына ялгыша күрмәсен. Алла сакласын! Ул да авылның каһәренә юлыкмасын иде инде...

* * *

Ниһаять, Саҗидәнең тырышып йөрүе нәтиҗәсез калмады. Тырышкан ташка кадак каккан.

— Әйдә, дускаем, тотын эшкә! Штат бирделәр...

Әнә шулай Саҗидә беркөнне күрше кызы аркылы чакырткан Миңнурны каршы алды.

Сугыштан соңгы тәүге тыныч ел. Ә авылларда — трахома, корчаңгы һәм башка вак-төяк чир. Ярлылык, үтә хәерчелек елларына гына хас йогышлы авырулар. Шуларны тамыры белән бетерү бурычы куелган чор. Саҗидә белән Миңнурның иртә таңнан кичке караңгыга чаклы медпункттан китми, хәтта еш кына якын-тирәдәге авылларга да барып, әнә шул авыруларга каршы көрәшеп йөргән еллары. Эш өстенә эш, үзең турында уйларга вакыт та җитми.

Шундый көннәрнең берсендә медпункт ишегалдында таза гәүдәле, күрер күзгә дә ярыйсы, ыспай гына киенгән бер кеше пәйда булды. Ул Миңнурның кайсыдыр бер авылдан кайтканын көтеп тора иде.

— Сез Миңнур буласызмы? — диде әлеге кеше.

— Мин идем...

— Гафу итегез, минем сезгә бик мөһим сүзем бар иде.

Юлда арып-талып кайтуына карамастан, Миңнур таныш булмаган кешене тыңларга мәҗбүр булды. Ярый әле (каян белгән диген син аны?) Саҗидә апа каршы чыкты һәм аларны, кеше күзеннән ераграк булсыннар диптер инде, үзе эшли торган якка кертеп җибәрде, гәрчә Саҗидәнең болай эшләве Миңнурга бер дә ошамаса да.

Бәлки шуңадыр, Миңнур, илтифатсыз гына:

— Тыңлыйм сүзегезне, — дип, килгән кешене ашыктырды.

— Мин үзем Туймәтнеке. Сугыштан, шөкер, исән-имин кайту насыйп булды. Әле өйләнмәгән. Хәзер менә өйләнү турында уйлап йөрим. Сезнең турыда күп ишеттем болай. Риза булсагыз, мин сезгә өйләнер идем...

Гомерендә тәүге тапкыр күргән кешедән шушы сүзләрне ишетеп, Миңнур аптырап, хәтта бераз исәңгерәп китте: «Әстәгъфирулла!» Үзе сугышта да булган, димәк, дөнья күргән кеше булырга тиеш. Тышкы кыяфәте дә ярыйсы гына, ә менә сүз сөреше... Юк, мондый ирнең булуыннан булмавы артык. Туң йөрәкле, агач авызлы, төерле телле. Өйләнергә килгән кеше нәрсәсе белән булса да кәләшнең игътибарын җәлеп итәргә, аңа ошарга тырышырга, күңелен кузгатырга, уйландырырга тиеш ләбаса. Инде ирдә булырга өлгерсә дә, әле яңа гына егерме икесен тутырган керсез күңелле, кына гөле чәчәге кебек алсу йөзле, аяз күк кебек зәңгәрсу күзле, камыштай зифа буйлы, елмайганда карап туймаслык гүзәл Палта Миңнурының кулын сорап килгәнсең икән, син телең белән кош тота торган егет булырга тиеш. Һәм синең сайравыңда булачак кәләшең аңа булган күңел яктылыгыңны, кайнар хисләреңне тоярлык булсын. Әгәр алар синдә юк икән, ничек бу асыл зат үз язмышын сиңа ышанып тапшырсын да, каян аның сиңа сыенып яшәргә өмете бөреләнсен?

Җан җылысы... Башта ул Мифтахта да бик сизелмәде, ләкин соңыннан, аеруча сугыш газапларын татып кайткач, аңарда ул чәчәк атты. Сөеп алган, сөеп барган — анысын Ходай насыйп итмәде Миңнурга. Ә алдагысы... Алдагысын Алла белгән. Булачак туй өчен хәзердән үк биеп торып булмый...

— Мин бит инде ирдә булган кеше, ә сез өйләнмәгән егет. Авылыгызда кызлар беткәнмени? — дигән булды Миңнур, әңгәмәне кырт кисмәс өчен.

— Миңа сезнең кебек яхшы хатын кирәк...

— Анысы үзегездән тора инде. Ирне ир иткән — хатын, хатынны хатын иткән — ир, дип белми генә әйтмиләрдер.

— Миңа сезне алырга киңәш иттеләр.

— Шулайдыр да бит... Минем әлегә җавабым бер: ирем сугышта югалды. Исәнме, әллә юкмы — мин белмим. Ләкин мин, хәбәре килмәсә, биш ел көтәргә вәгъдә биргән идем. Әле минем көтәсем бар. Вәгъдәмне боза алмыйм!

— Юк, мин алай озак көталмыйм.

— Анысы сезнең ихтыярда...

Тагын да сүз куерту файдасыз булуын аңлап, егет кыска гына саубуллашып чыгып китте. Җылы, чын күңелдән сөйләшү-аңлашу булмады. Аның урынында башка берәү булса, бәлки: «Сез алай кырт кисмәгез әле, өметемне сүндермәгез, миңа бик ошыйсыз, мин соңгы вакытта гел сезнең турыда гына уйлап яшим, мин көтәргә риза, әйдәгез, әлегә аралашып, очрашып торыйк, шунда бер-беребезне дә ях-

шырак белербез», — дияр иде. Ә бу базарга сыер алырга килгән кеше кебек сатулаша, үзенең шартын куя: «Мин алай озак көталмыйм...» Алмасаң соң, ай Алла! Бәладән башаяк...

Миңнур җиңел сулап куйды.

Шушы вакыйгадан соң озак та үтмәде, авылга тагын бер яңа хәбәр таралды: Макар Кәшифе кайткан. Кайдадыр Өркет* өлкәсендә, Слюдянка дигән калада яши икән. Миңнурдан бер яшькә генә олы Кәшиф белән алар мәктәптә бер сыйныфта укыдылар, һәм шул вакытта ук ул Миңнур артыннан йөргән иде. Ләкин Миңнурның эленке-салынкы укып йөргән тәртипсез бу малайга беркайчан да исе китмәде. Аның дөньяда барлыгы турында да бихәбәр иде Миңнур. Ә менә Кәшиф онытмаган. Ул да әнә тәкъдим белән килеп җиткән:

— Әйдә, миңа чык, Слюдянкага алып китәм үзеңне...

— Юк, юк, Кәшиф, минем иремә биргән сүзем, вәгъдәм бар, аны боза алмыйм...

Син теләмәгән кеше белән бәйләнмәс өчен дә шәп җавап икән ул: «Вәгъдәм бар...»

Аптырагач, Кәшиф Нурислам абзый белән Фәрхинур абыстай янына килеп, аларның ризалыгы белән үз дигәненә ирешергә теләде: «Әнә бит теге вакытта, Миңнур теләмәсә дә, Мифтахка тотып биргәннәр...»

Картлар исә, теге елларның ялгышын кабатламас өчен:

— Аңа хәзер унбиш-уналты яшь түгел, үзегез уртак тел тапсагыз — без риза, — диделәр.

Әнә шулай Кәшиф тә буш кул белән генә китеп барды...

Ишек кагып, Миңнурның кулын сорап әле тагын килгәләделәр. Аларга да җавап бер булды: «Вәгъдәм бар...»

* * *

Авыл... Ул таң белән уяна, иртә тора, иксез-чиксез мәшәкатьләр белән ыгы-зыгы килә башлый, чөнки авылда эшләргә кирәк. Тырышып эшләргә. Палталар да шулай тырыш-уңганнар. Нурислам абзый үзе, карт атын җигеп, вакыт-вакыт берәр атналык юлга чыгып китә, авылларны әйләнә, шулай көн күрә, дөнья көтә.

Фәрхинур абыстай иртәнге намазга торганда, Миңнур да урыныннан кузгала.

Анасы:

— Таң тишегеннән тормасаң... Кем сине куа? Йоклар идең әле рәхәтләнеп... — ди.

— Эшем күп, әни, аны кем эшләр?

— Әй бала, бала! Эш дип ярыласың инде...

Юк, Фәрхинур абыстай кызын битәрләми, орышмый, болай гына — үз итеп, яратып әйтә бу сүзләрне. Аналарча кызгана ул кызын. Уңганлыгына, эшчәнлегенә, тырышлыгына сокланса да, кызгана.

Юынып-сөртенеп, Миңнур тегү машинасы артына барып утыра. Авыл кешеләре эшне аңа китереп кенә торалар. Диварда әйтерсең лә бер җан иясе эленеп тора, анда келт-келт итеп сәгать йөри. Эш арасында да Миңнурның бер күзе сәгатьтә: мавыгып китеп соңга калмыймы? Медпунктка киткәнче аның әле бер көянтә су да алып кайтасы бар. Суга бару — Миңнур өчен дөньяга чыгу. Аны бит анда саф, эчеп туймаслык тәмле, мул сулы кизләү көтә. Ах ул кизләү!.. Андый гаҗәп мул сулы чишмә башка бер җирдә дә юк бугай. Миңнурлар авылының чын горурлыгы, олы байлыгы, халыкның терәге. Печән өсте дисеңме, әллә урак өстеме, янып-пешеп, сусап шул кизләү суы аккан улакларга ятып эчкәндә дә ул су тамакка тими, сусауны баса. «Ярый әле кизләвебез бар», — дип уйлый Миңнур еш кына. Эчең пошканда, чиләк-көянтәләреңне аласың да кизләүгә төшәсең. Ә су юлыннан кеше өзелми.

Кизләү ул әле шифалы су гына да түгел. Ул — авыл халкының даими очрашып, сөйләшеп, хәбәрләшеп тора торган җире. Ә очрашып сөйләшү ул — үзе бер гомер...

Тегеп бетерәсе әйберен тәмамлады да Миңнур, ашыга-ашкына, кизләүгә суга төшеп китте. Бура эчендәге зур чаннан улакларга тулышып аккан саф су белән чиләкләрен тутырып торганда, Миңнурның артында таныш тавыш яңгырады: «Ахирәтем!» Минҗамал икән. Ике күрше, ике дус дулкынланып, кочаклашып алдылар, аннары икесе дә су алып кайтып киттеләр.

— Серем бар сиңа, ахирәтем. Олы сер... — диде Минҗамал, кайта-кайтышлый. — Син минем иң якын ахирәтем. Син генә мине аңларсың да син генә миңа ипле киңәш бирерсең дип уйлыйм...

Миңнур Минҗамалның бик мөһим сүзе барын тиз аңлады. Су юлында гына сөйләшеп аңлаша торган түгел, әлбәттә. Шуңа күрә Миңнур:

— Эштән кайткач та кер үзебезгә, иркенләп сөйләшербез, — диде дустына йомшак, җылы итеп.

— Үзем дә шулай уйлаган идем. Керәм алайса?

— Кер, кер, сөйләшербез. Соңгы вакытта очрашканыбыз да юк...

Алар икесе ике капкага юнәлде.

* * *

Медпунктта, һәр көндәгечә эш тыгыз булса да, Миңнур ахирәтенең: «Серем бар», — дигән сүзләре турында еш кына уйланды. Минҗамалның болай ук хафага төшеп сөйләшкәнен күргәне юк иде әле Миңнурның. Ни булды икән?

Палта Нурислам белән Бәләкәй Нургата гомер буе бергә, терәлеп тормасалар да, якын күрше булып яшәделәр. Аларның икесе тиң чибәр кызлары Миңнур белән Минҗамал да бер үк елда тудылар, бер сыйныфта укыдылар, бергә үстеләр, ахирәт булып яшиләр. Ләкин соңгы вакытта, чыннан да, сирәк очрашалар алар. Әйе, һәркемнең үз эше, үз мәшәкате, үз катуы*.

Кичен Миңнур медпунктта озак тоткарланмады, Саҗидәнең рөхсәте белән өенә ашыкты, чөнки ахирәтенең: «Серем бар», — дигән сүзләре колагыннан китми иде.

Минҗамал да Миңнурның кайтуын сабырсызланып көтеп тора икән, өйгә кереп тә җитте. Алар, Миңнурның бәләкәй тегү бүлмәсенә кереп, аулакта калдылар.

— И-и, ахирәтем... Сүземне ничек дип башларга да белмим. Егылып китә күрмә, зинһар... — диде Минҗамал еламсырап һәм яулык чите белән күзләрен каплады.

Миңнур, аш бүлмәсенә чыгып, чәйнектән чынаякка чәй агызып керде.

— Әйдә, эчеп җибәр әле! Тынычлан, Минҗамал, — диде Миңнур.

Минҗамал чәйне йотып куйды һәм ахирәтенә текәлде. Аның күзләрендә гаҗәпләнү катыш елмаю чагылды.

— Башкода килде бит кичә, — диде дә Минҗамал, яшь аралаш көлеп җибәрде.

— Кемнән?

— Потый Шәфикътан...

«Нигә әйттем инде?» дигән кебек, Минҗамал кулы белән авызын каплады да Миңнурга текәлде: дусты ничек кабул итәр бу хәбәрне? Миңнур аптырап китте, тик Минҗамалга моны сиздертмәскә тырышты.

...Балачактан авыру Потый Шәфикъ сугыш башланганда сазап беткән карт егет иде. Җан биргәнгә юнь биргән. Җанын биргәч, бәлки, юнен дә бирер әле дигән өмет белән Потый өйләнү турында да уйлап йөри. Ләкин авыл кызларының берсенең дә шөкәтсез өрәккә генә чыгасы килми. Аптырагач, Шәфикъ чит авыллардан да белешеп карады, тик кыз табылмады. Шуннан соң ул, язмышына буйсынып, өйләнү ниятеннән кире кайтып, тагын көтәргә булды. Авыруын авыру, әмма Потый Шәфикъ тормышка берегеп яши: колхозда келәтче, эшен тырышып башкара, исәп-хисапны да төгәл алып бара — башлы, комиссия аның эшен гел тикшереп торса да, келәтчегә дәгъва юк. Дәгъва булмагач, аңа ышаныч та елдан-ел арта бара, абруе үсә. Шулай булса да кызларның аңа бер дә исләре китмәде.

Авыл ир-атларын рәттән сугышка алып киткән чорда да Потыйны алмадылар, тәүге комиссиядән үк, чүпкә чыгарып, өенә кайтарып җибәрделәр дә бүтән чакыртып тормадылар.

Ә сугыш корбансыз булмый. Соңгы сугышның исә корбаннары исәпсез-хисапсыз иде. Авылның Мифтах, Хисаметдин, Голүм һәм башкалар кебек таза-сау иң гаярь егетләре дә яу кырында башларын салдылар, хәбәрсез югалдылар. Түгәрәк көләч йөзле, коңгырт күзле, дулкынланып торган кара чәчле, килеш-килбәтле, тулышып торган күкрәкле Минҗамалның да җан сөйгәне — Рәхимҗаны әнә шул дөньякүләм афәт корбаны булды, аны кара кайгыга салып, киләчәк бәхетенә өметен өзде, канатын сындырды.

Потый Шәфикъ исә, сунарчының киек саклаганы кебек, сугыш беткәнен көтте: «Бетсен әле, бәлки, миңа да бәхет елмаер...» Һәм каш астыннан гына ул тагын кызлар күзли башлады. Ә кызлар күп. Араларында абруйлылары да бар. Шуларның берсе — Минҗамал. Ындырда ашлык җилгәрергә йөрүче кызлар арасында Минҗамалдан да уңганы, Минҗамалдан да өлгере, Минҗамалдан да күндәме юк. Сугышка кадәр бу кыз артыннан йөргән егетләрдән дә бер Рәхимҗан гына булмады. Потый Шәфикъ Минҗамал белән Рәхимҗанның вәгъдәләре барлыгын да белә. Ә егеттән инде күпме вакыт бер хәбәр килгәне юк. Бу хәл, әгәр Минҗамал белән сөйләшеп аңлашканда, Потыйны өметләндерми дә түгел. Кемгә нәрсә, корчаңгыга мунча дигәндәй, булса була инде, Минҗамал гына ризалыгын бирсен, бигрәк шәп кыз, калышса да, Палта Миңнурыннан гына калыша торгандыр...

Бәләкәй Нургата абзый йортына яучы килеп кергәч, барысы да шатланышканнар иде кебек башта, ләкин кияү егетенең кырыгын тутырган, җан асрап, җан алып яшәүче Потый Шәфикъ икәнен белгәч, һушсыз кала яздылар. Ярый әле дөнья күргән Нургата абзый югалып калмады: «Безгә бу турыда бергәләшеп уйлыйсы бар, шуннан соң җавабыбызны бирербез», — дип, яучыны тынычлындырып чыгарып җибәрде...

Минҗамал ахирәтенә озак карап торды, ә тегесе эндәшми утыра.

— Нигә дәшмисең, ахирәтем? Потый дигәч, өнең бетте, ахры. Шулай шул, бетәр дә. Ә миңа нишләргә, миңа?.. Өзгәләнүләремне белсәң иде!..

Минҗамал сулкылдап елап җибәрде. Елый-елый сүзен дәвам итте, эчендәгесен тышка чыгарды:

— Кара инде, Ходай мине нинди көнгә калдырды! Хурлыгыңнан Шушмага ташланырсың. Әй Аллам! Нигә бәхет бирмәдең миңа? Нигә минем Рәхимҗанымны хараплар иттең? Мин бит аны бик ярата идем...

Миңнур Минҗамалны кочаклап алды да, аркасыннан сөеп, тынычландырырга теләде. Аннары чынаякны тагын Минҗамалга сузды, ләкин тегесе аны кулына алмады. Шунда Миңнур үзе ярты чынаяк чәйне эчеп куйды да, кайнарланып:

— Тынычлан әле, Минҗамал, тынычлан! Бер синең Рәхимҗаның гына харап булдымыни бу каһәр төшкән сугышта? Үзең беләсең, минекеләрнең... Минекеләрнең икесе дә югалды! Мөсәвәрә абыстайның Сәхабы, Нурхая абыстайның Сөнгате, Салах Миңнурының Зиятдины, Өмминең Нуркае, әллә кемнәрнең әллә кемнәре — башын салганнарның, хәбәрсез югалганнарның исәбе юк хәзер. Ил белән, ил белән ул кайгы-хәсрәт...

Минҗамал елый-елый ярсыган иде — битен яулыгы белән каплап чыгып китте. Сүзнең очына чыга алмадылар. Миңнур ахирәтен эче пошып озатып калды.

Өйдә Нургата абзый:

— Кызым, хәлеңне бик яхшы аңлыйбыз, шуңа да безнең сиңа: «Үзең яхшылап уйла, үзең хәл ит», — дигән сүздән башка киңәшебез юк. Инде өлешеңә тигән көмешең Потый Шәфикъ икән, нихәл итәсең?.. — диде, икеле-микеле генә.

— Юк, юк! Дуадак каз кебек ялгыз яшәсәм яшәрмен, тик Потыйга чыгасым юк, — дип, ярсуын дәвам итте Минҗамал.

Шулчак ишектән ялт итеп Миңнур килеп керде. Ахирәтен бу хәлдә калдырасы килмәгәнгә, аны тынычландырырга, юатырга, башлаган сүзне дәвам итәргә кирәк булганга килеп керде ул.

— Башкайларымны кая куярга да белмим, ахирәтем. Зинһар, миңа үпкәләмә, — диде Минҗамал, бераз ярсуын тыеп. — Очрашмаган, сөйләшмәгән, киңәшмәгән туганнар, якыннар калмады, нинди уйга килергә дә белмим. Шуңа синең янга кергән идем. Хәлемне аңлый торгансыңдыр...

— Аңлыйм, бик аңлыйм, Минҗамал. Бетеренмә әле, юкка борчыласың. Әйт әле: син менә Потыйның үзе белән очрашып сөйләштеңме?

— Ю-у-ук... Кайчан сөйләшим ди?

— Алайса, Минҗамал, син Шәфикъ абзыйның үзе белән очраш! Сөйләшегез, озак итеп, яхшылап сөйләшегез, бәлки, икеләнүләрең бетеп китәр. Язмышы җиңел түгел аның, ә андый кешеләр яхшы, йомшак күңелле, рәхимле булалар. Үзең уйлап кара: авылга аның зыяны тигәне булдымы? Эшли, үз көнен үзе күрә, күршеләре дә аның турында начар сүз әйтмиләр, — диде үз башыннан үткәннәр турында уйлап.

— И-и, ахирәт, нәрсә сөйлисең син? Яраткан, һич югында сиңа кайсы ягы белән булса да ошаган кешегә кияүгә чыгарга кирәклеге турында акыл сата идең бит әле безнең ишегә, — диде Минҗамал, аптыраулы көлемсерәп. — Теге ничек әле синең: «Җан җылысы, җан җылысы...»

— Булгандыр, Минҗамал, сөйләгәнмендер, үзем дә яраткан кешемә чыга алмаганга сөйләгәнмендер. Беләсеңме, бу дөнья гел без уйлаганча гына барса икән! Булмый шул! Мин Мифтахка атам-анам сүзенә каршы килмим дип чыктым, аларны рәнҗетәсем килмәде. Шулай да Мифтахны соңыннан мин үз иттем, аны җаным-тәнем белән кабул иттем, чөнки ул йөзгә-биткә дә, гәүдәгә дә, кеше буларак та ярамаслык түгел иде. Ул гына да түгел: йомшак бәгырьле, назлы иде ул. Хатын-кызга тагын ни кирәк? Андыйны яратмау мөмкин түгел. Торган саен, аны күбрәк белгән саен яраттым мин аны. Шуңа да мин аны бүген дә өзелеп көтәм. Вәгъдәм бар, вәгъдәмне үтим дип кенә түгел, үз кешем дип көтәм мин аны. Ул кайтса, миңа башка берәү дә кирәк булмас иде...

— Мин дә Рәхимҗанны көтәм дә бит... Күңелем белән көтәм.

— Соң, алай булгач көт! Ә Шәфикъ... Ул беркая да китмәс, сине көтәр...

Өч-дүрт көннән Минҗамал тагын ахирәте янына йөгереп керде:

— Киңәшеңне тоттым бит, Миңнуркаем, тегенең белән очрашып сөйләштек. Бик куркып торган идем шул карачкы белән ничек очрашыйм дип. Юкка курыкканмын икән, тотып ашамады... Мескен Потый, артык дулкынланып, кызарып-бүртенеп чыкты, үзе еш-еш сулый. Юк, суламый, ә гыж-гыж килә, әледән-әле ютәлгә буыла. «Менә, Минҗамал, минем бар сәламәтлегем, бар булдыгым шушы инде. Сәламәтлегем булса, мин, бәлки, мондый гына Потый Шәфикъ булмас идем. Менә миңа кара да уйла, уйлан, аннары үзең хәл ит. Барысы да үз иркеңдә, үз ихтыярыңда булсын. Инде очрашу насыйп булган икән, яшермим, әйтәм: соңгы елларда мин гел синең турыда уйлап, хыялланып яшәдем. Әйе, мин — чирләшкә, гарип. Сиңа ишетүе гаҗәптер дә, әмма чирләшкәләрдә дә хис, тойгы бар. Мин дә хыяллана, уйлана, хәтта ярата да беләм. Шул ук вакытта синең буем җитмәс кыз икәнлегеңне дә аңлыйм. Әгәр минем бәхеткә син ризалыгыңны бирсәң, мин сине фәрештәләргә тиңләп яшәрмен, соңгы сулышыма чаклы бәхетле итәргә тырышырмын», — дип йомшарып китеп, елап җибәрде. Үземә дә җәл булып китте, малайкаем, җаннарым җәрәхәтләнде. Бөтенләй икенче тәэсир алып кайттым бит әле мин, ахирәткәем. Уйланам, сызланам.

Миңнур үзе дә яшьләнеп алды, яулык чите белән генә күзләрен сөртте.

— Безнең сайланасы юк шул, Минҗамал...

— Менә син сайланасың бит әле, — дип бүлдерде Минҗамал.

— Дөрес, сайланам. Менә син, Шәфикъ абзый яратам дип әйтте, дидең. Ә минем Мифтахтан соң кулымны сорап килгәннәрдән «яратам» дигән сүзне ишеткәнем юк әле. Аерма бармы?

— Әй ахирәтем, син күрдең шул ул «ярату» дигән нәрсәне, ә без?..

— Үзең беләсең, Минҗамал, мин синең бәхетле булуыңны телим. Шулай да: «Тот та чык шул Потыйга», — дип әйтә алмыйм. Синең үзеңнең дә башың түгәрәк, уйла! — диде Миңнур, сүзен төгәлләп.

Моннан соң да Минҗамал шактый вакыт уйланып йөрде һәм, ниһаять, башка кешегә кияүгә чыгу мөмкинлеге күренмәгәч, Потыйга чыгарга ниятләде...

Шуннан соң әллә ике, әллә өч атна вакыт үтте — ике ахирәт кизләү янында тагын очрашты.

— Хәлләрең ничек соң? Күнә аласыңмы? Сүзендә торамы? — дип тезеп китте Миңнур.

— И-и, ахирәтем! Күнәсең икән аны. Болай бер дә ярамаслык түгел үзе, гел уңайга гына сыпырып яши. Игътибарлы. Соңгы вакытта чире дә үзен бик йөдәтми, әллә өйләнүнең файдасы булды инде шунда... Балага уздым бит! Шатлануларын белсәң... Сиңа рәхмәтләремне әйтәсем килеп йөри идем әле. Синең киңәшең хәл итте дә салды бөтен эшне. Үзеңә дә бәхет бирсен Ходай!..

* * *

Миңнурны еш кына төрле уйлар чолгап ала. Мифтах та аңа: «Син уйчан», — дия торган иде. Уйламыйча яшәп буламы? Әнә Минҗамал малай тапкан...

Ике ахирәтнең тормышында охшашлык ярылып ята: Миңнур да, Минҗамал да сөймәгән, яратмаган кешесенә тормышка чыктылар. Кая инде монда сайлану? Тик кияүләр арасында җир белән күк арасы: Мифтах һәрьяклап сау-сәламәт, чатнап торган көчле, чибәр егет иде. Ә Минҗамал өлешенә чыккан «көмеш» көчкә сулыш ала, үпкәсе гыж-гыж килә, йөзе сары, кыскасы, өрәк инде. Һәм шул ук вакытта алар икесе дә ярату хисе белән яшәргә сәләтле булуларын дәлилләгән кешеләр. Янып торган, тап-таза Мифтах белән Миңнур аерылышканчы да берничә атна бергә яшәделәр, аннары Мифтах яраланып авылга кайткач та шактый вакыт бергә булдылар, Казанда очрашкач та назланышып төн үткәрделәр, ә Миңнур балага узмый калды. Чирләшкә җаны: «Менә чыгам, менә чыгам», — дип көчкә яшәгән Потый Шәфикъ белән Минҗамал тормыш башларга өлгермәделәр, бусы: «Балага уздым бит», — дип шәрран ярды. Озак та узмады, тупырдап торган малай тапты. Менә бит нинди хикмәтләр бар бу дөньяда! Юк, Миңнур ахирәтеннән һич тә көнләшми, киресенчә, аларның тормышына соклана. Әллә соң бу да бәхет эшеме? Минҗамал өчен Потый Шәфикъ чын мәгънәсендә бәхет күгәрчене булып чыкты ла... Йа Хода, бәхетле генә яши күрсеннәр. Барлык авыл кызлары кебек Минҗамалга да, ай-һай, күп газаплар кичерергә туры килде. Калган гомерләре газапсыз, тыныч, рәхәттә үтсен иде инде...

* * *

Беркөнне иртән Сәҗидә Миңнурны елмаеп каршы алды:

— Күрдеңме яшьлек мәхәббәтеңне?

— Юк, беркемне дә күрмәдем әле. Анысы кем инде тагын?

— Соң, әле яңа гына шунда иде бит. Әсәдуллаң...

— Әле ул да исәнмени?

Соңгы сүзне Миңнур сүз рәвеше өчен генә әйтте. Әсәдулланың исән-сау булуы, аның сугышта катнашмавы, паровоз машинисты буларак бронь белән калуы, Түбән Тагилдан Свердловскига эшелон-эшелон сугыш кораллары илтүе, бүген исә бер заводта механик булып эшләве турында Миңнур ишетә торды, чөнки Нәгыймә апа олы улының тормышына Миңнурның һич тә битараф булмавын истә тотып сөйли иде бу яңалыкларны. Үзеннән сигез яшькә олы бер хатынга өйләнеп, кызлары туа. Хатын ниндидер бер кырын эше өчен хөкем ителгән дә, Әсәдулланың кулында яшь тә җиде айлык Нуриясе калган. Кыскасы, яшьлек җүләрлеге белән ялгышкан Әсәдулла шул ялгышлыгы өчен иза чигә. Аның да хәзер Миңнурның кулын сорап кайтуы түгелдер бит? «Ярар, килсен, очрашыйк, сөйләшик, мин аңа үпкәмне әйтеп җиткерермен», — дип уйлады Миңнур. Шулай дип уйлап та бетермәде, бусагада Әсәдулла пәйда булды. Үзгәргән: тазарып, олыгаеп киткән, йөзе дә бала-чаганыкы түгел — кырысланган. Шулай да елмаюы матур үзенең...

— Син мине ачулана торгансыңдыр инде, — диде Әсәдулла, гади генә итеп.

— Каян беләсең?

— Ишетә торам. Язалар бит...

Чыннан да, тормышы бозылган Әсәдулланың тагын Миңнур каршына кайтып тезләнүе икән бу.

— Инде икебез дә бер ялгыштык, тагын да ялгышырга димәгәндер. Шуны бел: Ходай сине миңа язган!

— Минем вәгъдәм бар...

— Беләм вәгъдәң барын. Мин синең яшьлек дустың, ирең Мифтах абзыйга биргән вәгъдәңдә торуың өчен алдыңда баш иям, моңа чиксез сокланам, шуңа сине хөрмәт итәм, яратам. Мин дә синең кебек тугрылыклы хатыным булуны телим. Калган бөтен гомеремне сине бәхетле итүгә багышлармын. Теләгемә каршы килмә!

— Вәгъдәм бар, Әсәдулла, вәгъдәм... Әле тагын берничә ел көтәсем бар. Әнә бит, уйламаган-нитмәгән кешеләр кайтып-кайтып төшә авылга. Имам абзыйны гына алыйк...

— Соң, Миңнур, һәлак булуы турында «кара пичәт» килде, дидең бит. Тагын күпме көтәргә була?

— Әйе, килде. Ә кешеләр кайта. Көтмичә булмый. Мин сиңа теге вакытта да, бер ел булса да көт, дигән идем. Синең сабырлыгың җитмәде, киттең дә... өйләндең. Хәзер менә шуның җәзасын аласың, — диде Миңнур, элеккеге үпкәсен Әсәдуллага әйтеп. — Инде тагын ялгышмыйм дисәң, сабыр итеп көтәргә кала. Теге вакытта без икебез дә артык яшь, бала-чага гына идек, тормыш ал да гөл кебек булыр сыман иде. Хәзер без — тормышның ачысын-төчесен, дөньяны күргән кешеләр. Әйтсәм әйтим, мин синең теләгеңә каршы түгел. Ләкин син дә мине аңларга тырыш...

Әсәдулла Миңнурны ничек кенә күндерергә теләмәсен, барып чыкмады, ул китеп барды. Әмма ул бу юлы өмет уты кабынган килеш китте. Әнә бит Миңнур: «Әйтсәм әйтим, мин синең теләгеңә каршы түгел», — диде. Әллә шуңамы, озак та үтмәде, Әсәдулла тагын кайтып төште. Шул кичне, бүләкләр, күчтәнәчләр тотып, Нурислам карт белән Фәрхинур карчык йортына килеп керде, җылы итеп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты, үзенең уй-ниятләрен, теләген әйтеп салды, фатиха бирегез, без Миңнур белән язмышыбызны бәйләргә булдык, диде.

Миңнур медпункттан кайтып җитмәгән иде, кайтып керде дә:

— Ашыкма, Әсәдулла, ашка пешәрсең... Мин Мифтахны көтәм. Төшләрне бик матур күрәм: исән, ахры. Бәлки, кайтып төшәр... Тагын бер ел гына көтим инде, — диде Әсәдулланы тәмам аптыраштта калдырып.

Әсәдулла да зур түземлелек белән Миңнурның уңай җавап биргәнен көтте. Аңа карата тирән ихтирам, хөрмәт арткannan-арта барды. Әйе, дәһшәтле яу кырында башын салган иң якын кешесе — иренә биргән мөкатдәс вәгъдәсен соңгы чигенә чаклы намус белән үтәп, бар көчен, бөтен сабырлыгын, көнетөне сызлаган-сыкраган йөрәк ялкынын биргән изге затны ничек хөрмәт итмисең дә, ничек ригая кылмыйсың?..

* * *

Эш күп булганга, Миңнур медпунктка бик иртә төшә. Йөгереп кенә кизләүдән су алып кайта, идәнне юып, бүлмәләрне җиләтеп ала, дәвалау җиһазларын кайсын кайнатып, кайсын болай гына чистартып, пөхтәләп әзерләп куя.

Бер иртәне шулай медпунктка барып керүе булды, дәвалау бүлмәсендә Сәҗидәнең кара коелып утырганына гаҗәпсенеп калды. Гадәттә, аның кәефе һәрвакыт күтәренке була, елмаеп каршы ала.

— Нәрсә булды, авырыйсыңмы әллә? — дип сорады Миңнур, табибәнең хәленә кереп.

— Әнә кара әле бүлмәне, — диде табибә, үзе яши торган якка башы белән изәп.

Миңнур эчкә үтте, анда тәрәзә ватык, идәндә пыяла ватыклары белән бер зур таш ята.

— Кайчан булды соң әле бу?

— Төнлә... Йөрәкләрем ярылды. Тегенекеләрнең берсе инде — хатынымы, әллә малаемы?..

Миңнур: «Ташла әле шул якырыйны* , беткәнмени сиңа торырлык ир заты?» — дип әйтмәкче иде, сабыр итте, табибәнең яралы күңеленә каты орынырга кыймады, фәкать: «И-и, Сәҗидә апа, Сәҗидә апа...» — дип, мәгънәле итеп көрсенеп кенә куйды. Әлбәттә, Сәҗидә аны аңлады.

— Син хаклы. Юк, юк, бетте! Башкача мин аны яныма да китертмәм. Болай да бик якын җибәрмим бит мин аны. Тик... сөйкемле сөяге бар шуның, сөйкемле сөяге... Әллә ничек, яратып җибәрдем... Ялгышам — шуны аңладым. Хәзер бетте...

— Аны күптән шулай итәсе иде, Сәҗидә апа!

— Әйе, күптән шулай итәсе иде. Йомшак шул мин, йомшак күңелле, кешегә каты бәрелә алмыйм. Ә йомшак агачны корт баса. Үзем дә гаепле инде, гаепле... Үрнәк алырдай кешеләр янымда гына бит югыйсә. Сине әйтәм... Сокланып туймаслык сыйфатларың бар синең, Миңнур дустым. Үлгәч ун чакрымнан күренеп торырлык һәйкәл куярлык зат син. Ярый әле янымда син бар. Мине гаепли торгансыңдыр инде...

Сәҗидә, үзе турында йомшак күңелле дисә дә, Миңнур кебек көчле ихтыярлы кеше иде. Әле бер генә тапкыр да Миңнур Сәҗидәнең яшьле күзләрен күргәне юк. Һәм нәкъ шул катылыгын җөпләгән кебек, ул кабат:

— Ә тегенең белән бетте! Башкача син аның турында ишетмәссең. Мәсхәрә булып...

— Рәхмәт, Сәҗидә апа, мең рәхмәт! Дөрес эшлисең. Мин сине бик хөрмәт итәм, яратам. Гаебеңне таныдың, анысына мең рәхмәт. Бер мин генә түгел, бөтен авыл, хәтта башка тирә-як авыллар халкы да сине үлеп ярата, хөрмәт итә, гәрчә ишетми калмасалар да. Барыбер рәхмәтлеләр үзеңә. Ләкин абруеңны

саклау турында да уйламый ярамый. Әнә очучың һаман ялгыз яши икән бит. Яз үзенә! Кайтып алсын. Бәхетле гомер итәрсез...

— Уйлап карармын. Рәхмәт сүзеңә!

Миңнур пыялачы Илалетдин абзый янына йөгерде.

— Малайлар бер-берсенә кәс атып уйнаганнар да безнең тәрәзәгә килеп тигән, — дип аңлатты ул пыялачыга.

Илалетдин абзый, озын-озакка сузмыйча, өлге алып килде дә тәрәзәне куеп китте.

Медпунктта эш иң кайнаган чак — иртәнге як. Дәвалау бүлмәсе ишеге төбендәге тар коридорда иртән көн саен алты-җиде кеше була. Һәркемнең үз авыруы: берсе кулын кискән, икенчесе аягын бәргән, өченчесенең ашказаны авырта, аягын көзән җыера, кулбашы сызлый... Берәүләр дәва алып китә тора, алар урынына икенчеләре килә тора. Төштән соң йә булмаса кичке якта гына халык азая төшә — бераз эш кими. Гадәттә, бу мөмкинлектән файдаланып, Саҗидә белән Миңнур тиз генә капкалап, чәй эчеп алалар. Аннары тагын эшкә тотыналар.

Нәкъ шундый вакытларның берсендә медпунктка бер үсмер малай йөгереп килеп керде:

— Әти авырый...

Миңнур малайны тиз таныды — Имам абзыйныкы. Саҗидә белән Миңнур, нидер буласын сизенеп, Имам йортына чаптылар. Урамда сентябрь ахыры булуга карамастан, көн кояшлы, җылы һәм коры. Мондый матур көнне кешегә һич кайгы-хәсрәт килергә тиеш түгел сыман. Ләкин килә икән. Имам ятакта, ах-ух килә. Күршеләр җыелган, Өммегөлсем сыктый. Саҗидә авыруга уколлар кадады, төймә дарулар бирде. Тәне кайнар түгел. Ләкин йөрәге дулап тибә. Инфарктка охшаган. Юк, аннан да хәтәре, ахры...

Иртән Имам, күрше малаен алып, Түбән әрәмәгә читән тотар өчен тал чыбыгы кисәргә төшеп киткәннәр. Шактый тал чыбыгы кискән ул, тагын әз генә кисәргә уйлаган. Шулчак әллә ничек йөрәге чәнчеп куйган, һәм хәле бетә башлаган. Эшнең куркыныч булуын чамалап, Имам арбага менеп яткан һәм күрше малаена атны куарга кушкан. Башта фин сугышында катнашып, аннан соң Германныкына китеп, камалышта калып, шул ук финнарга әсирлеккә төшеп, авыр елларның газапларын татып кайткан, әле кырыгын да тутырмаган Имам әҗәлдән котылып калырга теләгәндер. Кешегә яшисе дә яшисе генә дә бит ул яшьтә! Тик... әҗәлләрдән калу юк икән шул. Миңнурның хөрмәт иткән каенагасы, һәлак булган ире Мифтахның бердәнбер туганы аларның күз алдында, санаулы минутлар эчендә мәңгегә күзен йомды. Йөрәкләрне сыкратып китеп барды аның якын күргән, үз иткән, гадел, киң күңелле, олы җанлы каенагасы. Ул үзе дә якын күрә иде шул тол калган киленен, кайчакта, кызганып: «Бигрәк бәхетсез булдың инде, килен», — дип әйтә торган иде. Инде хәзер кем аны шулай юатыр?..

* * *

Көн кичкә авышып, авырулар таралышкан беркөнне, медпункт бусагасында тагын берәү күренде. Бу — утыз яшьләрендәге ир-ат:

— Миңа, сеңелләрем, Миңнур дигәнегез кирәк иде. Соңладым да инде — юлым озын булды, — дип, нигәдер акланды әлеге кеше. «Әллә тагын хатын эзлиме?» — дип уйладылар бер үк вакытта Саҗидә дә, Миңнур үзе дә. Юк, алай булып чыкмады. Мифтах белән иңгә-иң торып дошманга каршы торган сугышчан дусты, аның күз алдында һәлак булуына шаһит, булган, Камышлы районының Иске Ярмәк авылыннан Әбрар атлы кеше икән. Ерак юл үтеп, һәлак булган Мифтах дустын үз куллары белән мөселманча җир куенына иңдергән кеше. Мондый кунакны олылап каршылау кирәген тиз абайлады Миңнур һәм аны Нурислам йортына алып кайтты. Кияве турында соңгы хәбәрне китергән кунак белән Нурислам карт та, Фәрхинур абыстай һәм Миңнур да ярты төнгә чаклы кич утырдылар, кунакны тыңладылар, еладылар-сыктадылар.

— Без Мифтах белән кырык иkенең җәендә таныштык, — дип башлады сүзен Әбрар. — Безнең полкка ул Казанда госпитальдә дәваланып чыкканнан соң килеп төште. Анда сезнең белән очрашуын искә ала иде. Аны безнең отделение командиры итеп куйдылар. Бу көннәрдә икенче эшелонга күчерелгән безнең полк оборонага яңа позиция әзерли иде. Траншеялар, окоплар казыйбыз, блиндажлар ясыйбыз. Бер өч көннән эшне бетерергә чамалап тора идек. Буламы соң? Икенче көнне иртә белән карыйбыз — дошман безнең янга килеп җитә язган, йөзгә-йөз торабыз. Әй, сугыш каты булды да соң! Мондый ук каты сугышны әле минем күргәнем дә юк иде. Җиңнәрен сызганган, акайган күзле, чалшайган йөзле исерек фашистлар әллә ничә кат атакага килделәр. Ләкин без нык тордык, бирешмәдек, урыныбыздан кузгалмадык. Шунда мин безнең отделение командиры Мифтах Мәсләховның батыр йөрәкле егет, оста сугышчы, кыю командир икәнен таныдым.

Кичке якта немецларның атакасы тукталды. Сугышта ул һәрвакыт шулай — төнлә дошман ял итә, көчләрен барлый, ә иртән яңадан һөҗүмгә ташлана. Безнекеләр дә төнге тынлыктан файдаланалар: кайнар ризык килә, яралыларны алып китәләр, сугыш кирәк-яракларын туплыйлар, бәрелешкә әзерләнәләр.

Әле күптән түгел генә сугыш барган кыр өстендә гадәти булмаган тынлык. Хәтта кошлар да күренми, алар бу куркыныч җирдән күптән еракка очканнар. Барыбыз да таң атканчы шулай тыныч булыр дип уйлап торабыз, төнлә йоклап алу өчен траншеяларда үзебезгә тишек әзерлибез, кайнар ботка көтәбез.

— Күңел тыныч түгел, — диде Мифтах.

— Сугышта ничек тыныч булсын инде ул күңел? — дигән булдым мин дә.

— Юк, әллә ничек, эч поша...

Тагын нәрсә әйтергә булгандыр Мифтах, шул минутта һичкем көтмәгән хәл булды. Фашистлар, үзләренең кагыйдәләрен бозып, безгә кич белән ташландылар. Аларның качып-посып, шуышып килүләрен беркем күрми калды, ахры, безнең траншеяларга күктән төшкән кебек килеп төштеләр. Офыкка төшеп барган кояш безнең күзәтүчеләрнең күзләренә тәрәп яктыртканга, алар дошманның якынлашуын күрми дә калганнар. Моның өстенә безнекеләрнең дә, дошман туптан атмыйча һөҗүмгә күтәрелмәс дип, дикъкате югалган булып чыкты. Көндезге уңышсызлыкка хурланып котырынган исерек фашистлар траншеяга сикереп төштеләр һәм, безгә каршы йөзгә-йөз килеп, кул белән сугыша башладылар. Каршы атып та булмый, чөнки үзебезнекеләрне атып егуың мөмкин. Хәнҗәрләр, штык, винтовка түтәсе белән сугышабыз, буышабыз. Ничек булгандыр, ул көнне безнең отделение командирына да пистолет биргәннәр иде. Мифтах, якыннан торып, бер немецны, икенчесен, өченчесен аударды. Дүртенчесенең каска кигән башына пистолет белән сукты, тегесе миңкеп ауды. Аннан соң мин аның ничек сугышканын абайламый калдым, чөнки үземә дә каты чәкәләшергә туры килде. Көчкә җиңдек.

Сугыш тагын тынып калды. Күзләрем белән Мифтахны эзлим, ә ул юк. Эзләп ары киттем. Карыйм, Мифтах траншеяга аркасы белән терәлгән, күзләре йомык, авызыннан кан саркый. Әйләндерсәм, аркасында фашист хәнҗәре, сабына чаклы батырылган. Йөрәк тибешен тыңлап, кулын тотып пульсын карадым — сулавы да ишетелми, йөрәге дә типми. Шулай да мин аны күтәреп алып, траншеяның иң аулак почмагына илтеп яткырдым, өстенә шинель яптым һәм төн буе саклап чыктым. Бәлки, мин әйтәм, әле исәндер, үлмәгәндер. Юк, иртән дә бернинди яшәү чаткылары күренми, йөзе дә нык үзгәргән иде. Өметем акланмады. Таң атканда, иптәшләр белән чыгып, Мифтахны снаряд чокырына җирләдек. Аннары мин, бар белгәннәремне укып, дога кылдым. Ай шәп егет иде, харап булды. Ә миңа Ходай исән-сау кайтырга язган булгандыр. Менә аның документлары, үзегез бергә төшкән фотогыз, кесә блокноты, — дип, Әбрар өстәлгә бер бәләкәй төргәк чыгарып салды.

Ниһаять, Миңнур үзенең шулай озак еллар Мифтахын көтүенең заяга булуын аңлады. Әйе, үлгәннәргә, һәлак булганнарга теге дөньядан кайту юк...

Әбрарны үзенең Камышлысына иртән генә озаттылар.

* * *

Илле икенең башында Әсәдулла авылга тагын кайтып төште. Миңнурның, ниһаять, бирәсе җавабы әзер иде. Мифтахка: «Мин көтәрмен сине», — дип вәгъдә биргәненә унберенче ел китте. Тагын күпме көтәргә була? Мифтах биш ел көтәргә вәгъдәсен алды. Тагын да көтүнең файдасы, нәтиҗәсе булса иде. Юк бит өмет, сүнде ул...

«Ходай сине миңа язган», — дигән иде Әсәдулла бер кайтуында. Күрәмсең, язган инде. Теге вакытта яшьлеге белән ялгышмыйча, бер генә ел көткән булса, алар кимендә ун-унике ел бергә яши алган булырлар иде. Әлбәттә, язган булса... Юк, язмаган булган шул. Инде моннан соң ялгышырга булмасын. Икесенә дә...

Әсәдулла да сыната торганнардан түгеллеген раслады. Ул Миңнурның уңай җавап биргәнен олы сабырлык белән биш ел буена көтте. Биш ел! Сабыр иткән — морадына ирешкән. Аның шушы сыйфаты гына да киләчәк тормышта ышанычлы ир буласын танытты.

— Мин тагын кайттым, — диде Әсәдулла, гыйнвар суыгыннан кызарган колакларын, битләрен ышкыштыргалап.

Миңнур аны аңлады: «Мин тагын кайттым. Бәлки, бу юлы синең җавабың әзердер?» — дигән сүз иде бу.

— Ярар, кайткансың, бик әйбәт. Мин риза...

— Син риза? Дөрес ишетәмме мин?!

— Дөрес ишетәсең, дөрес.

Әсәдулла Миңнурга тәүге тапкыр бик якын килде һәм тәүге тапкыр аны кочаклап алды. Сәҗидә табибә бүлмәсендә кеше юк иде — Миңнур да Әсәдулланың талпынуына каршы килмәде...

Февраль уртасында никах укытып, аны авыл советында рәсмиләштерделәр һәм тыйнак кына туй мәҗлесе уздырдылар.

Алда әле аларны шатлыклы-бәхетле, кайгылы-хәсрәтле гаилә тормышы көтә иде...

* * *

Аккан сулар кебек уза гомер. Аулак өйләргә йөреп, хисләр дәрьясында гизгән гүзәл яшьлеге дә, чиксез авырлыклары, кайгы-хәсрәте белән көйдереп үткән сугыш еллары да, шул сугышта югалып калган ирен озак вакыт көтү газаплары да, аннан соңгы еллар мәшәкате дә әллә кайда, артта, әйтерсең лә томан эчендә калдылар. Артта калсалар да, бүгенгедәй хәтерендә саклаunion һәм, әледән-әле искә төшеп, йөрәк җәрәхәте сызылып-сызылып китә.

Ә Минәхмәте дә, Мифтахы да, Әсәдулласы да еш исенә төшә аның. Уйлаганга төшәләрдер инде, уйламаса төшмәсләр иде. Һәм еш кына аларны төшләрендә дә күрә. Уйлары кебек төшләре дә борчулы. Әле менә кайчан гына аның төшенә арчи керде. Гел кырык беренче елның быелгыдай салкын яңгырлы язында төшкән арчи инде! Хәзер атлар гына ак, кырык бердә алар башка төсләләр иде. Атлар гына түгел, тарантас та ак япмага төрелгән. Мифтах та, кияү егете дә, хәтта гармунчы да ак киемнән. Гармунчы гармунын уйный. Миңнурга бик таныш көйне уйный ул. Гармун тавышы да бик таныш. Йа Хода! Минәхмәт бит бу! Ләкин Миңнур аны барыбер танып бетерә алмый азаплана, чөнки Минәхмәтнең йөзе танымаслык булып үзгәргән, боек. Кайгыдан шулай үзгәргәндер инде ул, Миңнурның башкага чыгу кайгысыннан. Миңнур аңа якынрак килә, имеш, һәм: «Хәлең ничек, кайда югалдың?» — дип сорый. Минәхмәт эндәшми, кулын гына селти, гүя ул: «Сорашма, шәптән түгел», — ди. Аннары ул гармунын тартып җырлап җибәрә:

Биек тауга менмәс идем —
Биек тауда атларым;
Кычкырып җырламас идем —
Бик янсу чакларым...

Ак киемле кияү егете, дилбегәсен баш очында болгый-болгый, ак аргамакларны куалый. Ә Миңнур: «Кума инде, тый, тагын тәгәрмәчебез күчәреннән чыга бит», — дип ялвара. Ә Мифтах: «Юк, төшми, син бит вәгъдәңдә тордың, шулай булгач төшми...» — ди, имеш. Шул урында Миңнур уянып китте. «Әстәгъфирулла! Өнемме бу, әллә төшем генәме? Булса да булыр икән...» Уянса да, колагына Мифтахның йомшак назлы тавышы ишетелгән кебек тоелды: «Бер дә юкка гына яратмадым инде мин сине, белдем ышанычымны акларыңны...»

Миңнур, әлеге төшне яхшыга юрап, торып дога укыды, күз яше аралаш авызын ерды, аннары, тынычланып, моңсу гына елмаеп куйды. Мифтахы төшенә тагын матур керде, шуңа елмаю балкыды аның җыерчыклы, ләкин һаман түгәрәк, якты, ягымлы йөзендә...

## Соңгы сүз

Әсәр геройларының күпчелеге реаль кешеләр. Алар минем авылым Елховойда яшәгәннәр, төп герой Палта Миңнуры бүгенге көндә, Аллага шөкер, сау-сәламәт. Әйе, Миңнур апа үз авылының тере легендасы, горурлыгы, чын-чынлап тарихи шәхес. Хәзер аның яшьлек елларындагы матурлыгын тирән сырлар баскан, чәчләренә ак бәс төшкән.

Ах, аның гүзәл яшьлеге!.. Искиткеч матур, уңган булуы, чиста-пөхтә йөрүе. Хан кызлары да алай ук гүзәл була алмаганнардыр. Урамга йә булмаса кизләүгә суга чыкканда, медпунктка эшкә килгәндә авыл халкы аңа соклануын яшерә алмыйча күзәтә торган иде. Юк, аның тышкы матурлыгына гына түгел, эчке дөньясының, күңел байлыгының, башка кешеләрдә сирәк була торган күркәм сыйфатларының аклыгын, пакьлеген танып, шуңа сокланып карап тора иде халык Палта Миңнурына.

Әсәдулла да Миңнур кебек сүзендә торучан, үҗәт, тормышка теше-тырнагы белән ябышкан кеше булган. Кеше арасында сүзе дә үткән, эшкә дә уңган — кулыннан килмәгән һөнәре булмаган: ул токарь да, эретеп ябыштыручы да, механик та, балта остасы да, пыялачы да... Эштән кайткач та тик тормаган, нәрсәнедер төзәткән, нәрсәнедер үзгәрткән, шомарткан, буяган.

Башта Миңнур Әсәдулла белән Түбән Тагилга китә. Шунда бер ел яшәп, беренче балалары Рәйсәне тапкач, сагынуга түзә алмыйча, Миңнур туган якка кайту турында сүз кузгата. Әнә шулай алар кабат туган авыллары Елховойга кайтып төшәләр. Әсәдулла колхозда механик булып эшли башлый. Эшен белеп эшли ул, авылның абруйлы кешесенә әверелә. Рәйсәсе артыннан Рәисе туа, аннары Рәфисәсе, Ринаты, Рамиле. Алтынчыга Әсәдулланың беренче хатыныннан туган баласы Нурия даими кайтып йөри. Ул әтисен генә түгел, аның яшь хатыны Миңнурны да үз анасы кебек якын итә. Бу Әсәдулла өчен дә, Миңнур өчен дә иң бәхетле еллар була. Балалар үсә торалар, бер-бер артлы укырга китәләр. Йорт эшләренә булышалар. Миңнур үзе дә вакытлыча бүленгән эшен дәвам иттерә — көнкүреш комбинатына фуфайкалар, күлмәкләр, туннар, курткалар тегә, матраслар сыра.

Уңган хатын кар өстендә казан да кайнаткан. Гомер агышында аның эшләмәгән эше калмаган. Сугыштан соң авыл ашханәсендә пешекче булган, аннары колхозда бригадир ярдәмчесе итеп куйганнар. Озак кына вакыт фельдшер-акушерлык пунктында санитар булып эшләгән. Колхоз эшенең исә ниндиен генә башкармаган ул. Печән әзерләгән чорда чалгыны иң оста чүкүчеләрнең берсе Миңнур булган. Утын әзерләргә барыр алдыннан пычкыларны кайраргa, тешләрен аерырга да әллә кемнәргә ялынып йөргәне булмаган, үзе үткенләгән, үзе аерган. Авылга газ килгәч, сеңлесе Минхәят белән бик күп авыл-

дашларының утын мичләрен сүтеп, газга көйләп салганнар. Бәлки шуңадыр, Нурислам карт: «Минем кызларым арыслан кебекләр», — дип горуланып йөргән.

Әсәдулла белән Миңнур утыз елдан артык бәхетле гомер кичергәннәр. Ире ир булган, үз сүзендә торган, хатынын бәхетле итү өчен булдыра алганның барысын да эшләгән. Бер генә мәртәбә дә тавыш күтәреп начар сүз белән эндәшмәгән, ихтирам итеп кенә яшәгән, хөрмәтеннән, игътибарыннан ташламаган. Шунысы кызганыч: иртәрәк киткән ул дөньядан...

Миңнур апа аңа багышлап шигырьләр яза:

Урманнарга барып, аланнарда
Җиләк җыйган идек бергәләп;
Шулчакларны искә төшерәм дә,
Бәгыремне китә телгәләп.
Икәү бергә йөрербез әле дип,
Уйсу җиргә сукмак салдырдың;
Тик син генә, минем кадерлем, дип,
Йөрәгемә язып калдырдың...

Алты бала, килен-кияүләр, унөч оныкчыгы бар аның. Инде сиксәнен тутырып килсә дә, һаман үткән гомернең һәрбер мизгелен кабат-кабат искә ала, уйлана, сызлана, моңлана.

Минҗамал белән Потый Шәфикъ та бәхетле яшәгәннәр. Минҗамал апа ике ул табып үстергән. Хәзер аларның да уллары һәм кызлары, кияү-киленнәре, оныклары әти-әниләренең игелекле эшләрен дәвам иттерәләр. Тик Шәфикъ абзыйның гомере озын булмаган. Минҗамал апаның дөнья куйганына да хәзер ун ел икән.

Сәҗидә табибәнең прототибы безнең авылда ялгызы сиксән яшькә чаклы яшәде. Халыкка күрсәткән күркәм хезмәте дәүләт тарафыннан бик югары бәяләнде — аңа Ленин ордены бирелде. Соңгы юлга аны олы хөрмәт белән, биш-алты авыл халкы бергә җыелып, бөтен урам тулып озатты. Аны ислам йолалары белән соңгы юлга әзерләүчеләрнең берсе, әлбәттә инде, гомерлек ахирәте Палта Миңнуры иде.

## Автор турында белешмә

*Прозаик һәм публицист Әсгать Салах (Әсгать Сәхап улы Салахов) — әдәбиятыбызга узган гасыр азагында килеп кергән язучыларның берсе. Күпләрне гаҗәпләндереп һәм сокландырып, туксанынчы еллар азагында һәм гасыр башында республика вакытлы матбугатында бер-бер артлы аның хикәяләре һәм повестьлары, әдәби очерклары, публицистик язмалары күренә башлады.*

*Бернәрсә дә юктан бар булмаган кебек, автор, икътисади, мәдәни тармакларда эшләп, гади эшчеләр һәм күренекле шәхесләр, язучылар һәм хезмәт каһарманнары белән аралашып, әдәбиятка шактый тормыш тәҗрибәсе туплап килгән шәхесләребездән икән. Ул 1935 елның 5 гыйнварында Татарстанның Беренче Май районы (хәзер Әлмәт районы) Елховой авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Язмышы шул чор кешеләренекенә хас булганча, фаҗигале дә, катлаулы да. Күпләрнеке кебек әрнү-сыкрау белән үткән балачак, үз тырышлыгы, үҗәтлеге белән белем алу, туган халкына хезмәт итү юлына басу. 1938 елда гаиләнең төп терәге — бабасы Салах «колхозлашуга каршы агитация алып барганы өчен» репрессия корбаны була, «өчлек» карары нигезендә Бөгелмә төрмәсендә атып үтерелә. Әтисе 1941 елның көзендә бөтен Европаны изгән Бөек Ватан сугышында һәлак була.*

*Авылның башлангыч һәм җидееллык мәктәпләрендә укыгач, Әсгать егерме чакрымдагы Лашман урта мәктәбенә йөреп урта белем ала, аннары Елховой сельпосында хисапчы булып эшли, Әлмәткә китеп бораулаучылар әзерләүче мәктәптә укый, аннан Баулыга китеп буровойда эшли башлый. Әсгать өч ел армиядә хезмәт итә. Булачак язучы Татарстандагы кара алтын ятмаларын чыгаручылар арасында кешеләр язмышын өйрәнә, киләчәктә язылачак әсәрләренең каһарманнары белән иңгә-иң торып эшли.*

*Егерме биш елга якын Әлмәттә рус телендә чыгучы «Знамя труда» газетасында сәнгать бүлеге мөдире, редактор урынбасары булып эшли, Татарстанда милли яңарыш башлангач, нефтьчеләр башкаласында, ниһаять, татар телендә беренче мөстәкыйль «Әлмәт таңнары» газетасын оештыра һәм, лаеклы ялга киткәнче, аның баш мөхәррире була.*

*Ә.Салах — Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Әлмәт төбәгенең Р.Төхфәтуллин премиясе лауреаты.*

*Газетада бер-бер артлы хикәяләре, очерклары, хатирәләре дөнья күрә. 1997 елда «Мирас» журналында «Аккан сулар» дигән хатирә-повесте басылып чыга. Аннан соң язучы иҗатына «Казан утлары» да игътибар итә, бу журнал аның «Балыкчы малайлар» хикәясен (1998, №11), «Соңгы вальс» (2002, №10), «Каеннар юлы» (2003, №6), «Көт син мине...» (2005, №1) повестьларын киң катлам укучыларга ирештерә. Язучы буларак танылуны Әсгать Салахка нәкъ әнә шул әсәрләр алып килде дә инде. 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.*

# Эчтәлек

Повестьлар

Соңгы вальс ....................................
Каеннар юлы ...................................
Көт син мине... ..................................
Автор турында белешмә .............................

Литературно-художественное издание

Асхат Салах
(**Салахов** Асхат Сахапович)

**Дорога берез**

Повести

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Әсгать Салах
(**Салахов** Әсгать Сәхапович)

**Каеннар юлы**

Повестьлар

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы *Л.П.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *С.Н.Галимуллина, Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.06.2006. Форматы 84г108 1/32. Офсет кәгазе.
«Times» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,92. Шартлы буяу-оттиск 11,34. Нәшер-хисап табагы 12,82. Тиражы 2000 д. Заказ З-430.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahatтм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.